# КАЗАН УТЛАРЫ

11

НОЯБРЬ-1975

// КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

11
НОЯБРЬ
1975

# Казан утлары

## Бу санда

В. НУРУЛЛИН. Яшьнәп үткән яшьлек. Повесть . 3
Ә. БАЯНОВ. Йолдызлар җитә... Шигырьләр . . . 61
Г. ШӘРӘФИ. Аккошлар кайтыр әле. Хикәя . . . 69
Р. ГАТАУЛЛИН. Нигез сагындырса. Шигырьләр . 98
А. ХӘЛИМ. Кышкы фантазия. Шигырьләр . . . 103

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 105
Х. ХӘСӘНОВ. Революционерның соңгы хатлары . 108
И. САЛАХОВ. Сиреньнәр чәчәк атканда . . . . 115

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

Р. МОСТАФИН. Аны комсомол үстерде . . . . 128
А. ШПИРТ. Ул легенда булып кайтты . . . . . 132
Яңа документ расый . . . . . . . . . . 137
Л. ПОПОВ. Муса Җәлил Якутиядә. Шигырь . . 139

ХӘЙ ХИСМӘТУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

Н. ЮЗИЕВ. Озын гомер, бай тормыш . . . . . 140
Х. ХИСМӘТУЛЛИН. Үткән юллар . . . . . . . 141

СӘНГАТЬ

Я. АБДУЛЛИН. Татар мәгърифәтчеләре сәнгать һәм аның социаль роле турында . . . . . 145

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

В. ХАКОВ. Гасырлар сулышы . . . . . . . . . 150

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ЗАРИПОВ. Киңрәк колач белән . . . . . . 161
Т. НУРМӨХӘММӘТОВ. Үз галәме, үз киңлекләре. 166

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. УРМАНЧЕЕВ. Әдәби осталык мәсьәләләре . 172
Р. ГАЛЯВИН. Көлке көлә килә . . . . . . . . 175

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Р. ФӘХРЕТДИНОВ.** Казан арты . . . . . . . 176

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

«Без — җиңәргә өйрәнгән халык» . . . . . . . 184

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**З. НУРИ.** «Чәнечкеле китап»тан. Шигырьләр . . 185
**З. МАНСУР.** Дуслар хөкеме. Шигырьләр . . . . 187
**ФӘНИЯР.** Эпиграммалар . . . . . . . . . . . 189
**Г. ЛАТЫЙП.** Сез иске дә без яңа дип . . . . . 189
**И. ТУКТАР.** Җөмләләр . . . . . . . . . . . 190

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 191

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/VIII-1975 ел. Басарга кул куелды 29/IX-1975 ел. ПФ 09039. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90.000 экз. Заказ Я-312. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1975 ел.

Вакыйф Нуруллин

# ЯШЬНӘП ҮТКӘН ЯШЬЛЕК

ПОВЕСТЬ

Гомере буена хаклык һәм гаделлек өчен көрәшкән коммунист Нурулла Хәлил улы Айсинның якты истәлегенә багышлыйм.

*Автор.*

## Беренче бүлек

### 1

*Революция эштә, көрәштә, ут эчендә иң житди сынаулар үтә. Әгәр син изеләсең, эксплуатацияләнәсең икән һәм эксплуататорлар властен алып ташларга уйлыйсың икән, әгәр син аны бәреп төшерү эшен ахырынача житкерергә телисең икән, ул чакта син үзеңә бөтен дөнья эксплуататорларының кысымына каршы торырга туры киләчәген белергә тиешсең; һәм әгәр син, көрәштә җиңеп чыгу өчен, шул кысымга отпор бирергә һәм яңа корбаннарга барырга әзер торасың икән, ул чакта син революционер; шулай булмаганда сине изеп ташлаячаклар.*

**В. И. Ленин.**



Алар Барсайга килеп кергәндә, иртәнге әбәт тирәләре иде. Көн чалт аяз. Кояш бар көченә кыздыра. Җил булмаганлыктан бөркү, тирләтә.

Унсигезенче елның егерменче июле иде бу. Көнне-төнне белмичә урак ура, печән чаба торган чак. Бүтән елларда мондый көннәрдә авыл урамнары буп-буш, өйләрнең тәрәзәләре ябык, капкалары бәйле була торган иде. Ә быел, әнә, капкаларда бәйләр күренми, тәрәзәләр ачык. Урамда гайре табигый җанлылык: авыл кешеләре икешәрләп, өчәрләп капка төпләренә җыелып, нидер сөйләшеп торалар. Йөзләре борчулы. Боларда урак кайгысы түгел болай булгач. Күрәсең, ниндидер житдирәк хәлләр килеп чыккан булырга тиеш...

Миңнулла әнә шуларны уйлап барганда, авылның иң матур жиренә — су буендагы тугайлыкта үзе бер кечерәк авыл сыярлык урын

биләп торган зур агач бакчалы, ике катлы йорт турысына килеп җиттеләр. Бу йорт Миңнуллага таныш иде. Февраль аенда Миңнулла шушы йортта Барсай халкын җыйнап җыелыш үткәрде. Ул җыелышта авылның ярлылар комитетын сайлап куйдылар һәм бу йортны шул комитет карамагына тапшырырга карар кылынды. Ә йортның хуҗасы Сәйфи бай, күрәсең, үз хәлен үзе чамалаптыр инде, Октябрь революциясеннән соң, семьясын тәяп, каядыр чыгып сызган да шуннан бирле тыны-көне юк. «Мөгаен, берәр чит илгә киткәндер, элек тә Англияләргә, Мисырларга барып кайткалаган адәм ие ул», дип сөйләгәннәр иде Миңнуллага аның турында.

Миңнулла олаучысы Заһит абзыйга атын Сәйфи йортының бакча коймасы янында туктатырга кушты. Үзе ялт кына арбадан сикереп төште дә таш түшәп бакча аша салынган, ян-якларына сәрби агачлары утыртылган сукмак буйлап өйгә таба китте. Ләкин болдырга менгәч, аның юлына ау мылтыгы тоткан бер кеше аркылы төште:

— Тукта, энекәш, ярамый сиңа анда керергә!

Мөгаен, бу авылда контрлар корткычлык итә башлагандыр, шуңа идарәгә кораллы сакчы куярга туры килгәндер, дип уйлап алды Миңнулла һәм:

— Ярар, абзый, булды, күрдек: постында әйбәт торасың икән, молодец! — дип, эчкә үтеп китмәкче булды.

Әмма сакчы, дәү һәм таза гәүдәсе белән ишекне каплап, селкенмичә дә тора бирде:

— Әйттем бит инде керергә ярамый дип!

— Миңа ярарга тиеш, агай,— диде Миңнулла, каны кыза башлаганга шактый ук кискен итеп.— Мин өяз башкарма комитетыннан килгән вәкил!

— Беләм, энекәш, — диде сакчы, һич тә исе китмичә. — Кайдан килүеңне дә, кем икәнеңне дә бик әйбәт беләм: үткән кыш безнең Барсайда комитет битната сайлатып киткән Гайсин Миңнулла син. Мужыт, әле үзең дә мине хәтерлисеңдер, ул чакта син бездә куныл киткәниең ич.

Кояш яктысыннан кинәт күләгәгә кергәч күзе алмашынып киткәнгә генә танымыйча торган икән Миңнулла, хәтерли ул бу агайны, бик тә яхшы хәтерли иде. Әйе, Зәйнәпнең, Миңнулла өчен дөньяда иң кадерле, иң якын, иң акыллы һәм иң чибәр Зәйнәпнең әтисе Сафиулла абзый иде бу! Узган юлы килүендә Миңнулланы менә шушы агайларга фатирга куйганнар иде. Шунда күргән иде Миңнулла Зәйнәп-сылуны. Шунда гашыйк булган иде Миңнулла ул чибәргә. Дөрес, Миңнулла ул кыз белән зурлап сөйләшә-таныша да алмады. Шулай да аз-маз сүз каткалап карады һәм шул чакта бик мөһим бер нәрсәне сизенеп калды: кыз да аңа битараф түгел, күз карашлары җылы, елмаюлары ягымлы, сүзләре тәмле, дустанә иде. Көлгән чакта бит алмалары уймакланып, тагын да чибәрләнебрәк китә, сүзләрен каушамыйча, кыю итеп әйтә торган шул кыз Миңнулланың күңел түренә әнә шул чакта кереп утырды да гел балкып, гел үзенә тартып тора иде. Миңнулланың башта волком үзәге Карыйга — үзенең туган авылына кайтмыйча, шушы Барсайга килүе дә асылда әнә шул Зәйнәп-сылуга барып тоташкан иде. Шул кыз белән иркенләбрәк бер сөйләшеп, сөйләшергә җае чыкмаса, ичмаса, күреп кенә булса да китәргә иде Миңнулланың исәбе...

— Гафу ит, Сафиулла абзый, син икәнсең бит әле! — диде Миңнулла. — Я, ни хәлләрдә яшисез соң? Әминә җиңги белән Зәйнәп тупташ исән-саулармы?

— Хәлләрнең рәте-чираты китебрәк тора шул әле-е-е! — диде Са-

фиулла агай. Аннары баш бармагы белән өске катка күрсәтте: — Әнә, тыңлап кара әле анда ни кыланганнарын.

Сафиулла агай белән мавыкканга гына игътибар итмичә торган икән Миңнулла, колак салу белән абайлап алды: өйнең өске катында шактый нык шаулашалар, кайсыдыр хәтта җыр башлап җибәрергә дә азаплана, тик кирәкле сүзләрен генә табып алып китә алмый иде.

— Сәйфи байның олы малае Шакир типтерә, — диде Сафиулла агай, Миңнулланың сораулы карашына җавап итеп. — Кичә төннә кайткан. Үзе белән тугыз-унлап солдат та ияртеп кайткан. Тәмам котырган ул нәрсә. Кичә бөтен авыл халкын урам уртасына җыйдыртып, кәмитет битната персидәтеле Хәкимҗанны үз кулы белән атып үтерде. «Сәвит яклы кешеләрнең барысын да менә шушы хәл көтә, берсен дә калдырмыйча, менә шушылай атып үтереп бетерәчәкбез», диде. Кичә минем кызны урамда күреп, тотып алган да, мин сине күптәннән күзләп йөридерием, әйдә, минеке бул, дип тинтерәтергә тотынган. Тик кешеләр җыелып кына коткарып калган.

Миңнулланың башлары әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте. Ярлылар комитеты председателе Хәкимҗан абзыйны ул бик яхшы белә иде. Коммунист ук булмаса да, Хәкимҗан агай дөньяның ачысын-төчесен күп күргән, акыллы, гадел кеше иде. Авыл халкы арасында дәрәҗәсе дә бар, председатель итеп тә бертавыштан сайлап куйганнар иде үзен. Инде менә шул кеше дөньяда юк икән... Ә Зәйнәп!.. Ну, кабахәт Шакир!!!

— Соң шулай булгач, нигә син ул бандитны саклап торасың монда? — диде Миңнулла, бар ачуын Сафиулла агайдан алырга теләгәндәй каты итеп.

— Башыңа төшкәч, сакламый нишлисең инде, энекәш? — диде тегесе, гел шулай бер дә пошынмыйча гына. — Бүген иртән Шакир ике солдаты белән өйгә килеп керде дә, мин синең киявең булырга телим, кызыңны бир миңа, дип давайлый башлады. Ярый әле, кызны төнлә шыпырт кына күрше авылга, туган тиешле кешеләребезгә илтеп кайтканыем. Югыйсә, яман буласые хәлләр.

— Кыскарак кына итеп әйтеп бир әле, Сафиулла абзый! — диде Миңнулла түземсезләнеп. — Шуннан нишләде теге кабахәт, ни белән бетте?

— Нәрсә булсын? Мин кызның кайда икәнен белмим, кичә син урамда тотып бәйләнә башлаганнан ары кайтып кына күренде дә, әти-әни, бәхил булыгыз, мине эзләп мәшәкатьләнеп йөрмәгез, бу хурлыкка түзеп тора алмыйм, башкайларымны юк итәм, дип, без алайболай аңыбызга килгәнче, өйдән чыгып та китте, шуннан бирле кайтканы юк, дип җавап бирдем. Хатын да минем сүзләрне куәтләде. Шуннан ары теге кабих төкерекләрен чәчеп: «Ах, шулаймы? Син әле кызыңны миңа бирергә теләмисеңме? Алдашып маташасыңмы? Кызыңның кайда икәнен әйткәнчегә кадәр ишек төбендә сакта тор, алайса! — дип, менә шушы мылтыкны тоттырып, шушында бастырып куйды. И һәм әйтте: «Әгәр качып китәсең икән, — диде, — җиде кат җир астыннан булса да табып, фәлән җиреңнән асып куям, бел аны!» — диде.

— Кулыңда мылтык лабаса синең, алла бәндәсе! Җитмәсә, ике көпшәле бит әле. Адәм мәсхәрәсенә калып, ул контрны саклап торганчы, шушы мылтыгың белән аның үзен атып үтерергә ярамый идемени?

— Әй, ансат та инде, ә? Әй, җиңел дә соң кешегә акыл өйрәтүләре! — диде Сафиулла агай да, ниһаять, кыза башлап. Һәм мылтыгының патроннигын ачты: — Син башта менә моны кара!

Ике көпшәнең дә патрон урыннары буш — мылтык корулы түгел иде. Бу хәлгә аптырабрак калып, Миңнулла ни әйтергә белмичә торган арада Сафиулла агай дәвам итте:

— Так шту, менә шулай, агайне! Даже бу мылтык корулы булган тәкъдирдә дә син әйткәнчә эшләп булмасые. Патамушты әнә анда, өске катта, Шакирны тагын өч солдат саклап тора әле. Ә тагын алтысы үзе белән бергә типтереп яталар. Шуның өстенә, алар кулында минеке шикелле корылмаган мылтык кына түгел, бумбыларына тикле бар аларның анда. Ә мин нәрсә? Мине ул прусты кызык итеп, кызны бирмәгәнгә ачу итеп кенә бастырып куйган монда.

— Кызылгвардиячеләр отряды бардыр ич авылыгызда?! Нигә шуларны ярдәмгә дәшмәдең?

— Кызмасана, энекәш, юкка. Синдәге баш миндә дә бар ла анысы әзрәк. Әйе, барые безнең этрәт. Мин үзем дә шуның бер әгъзасы булып йөридерием. Унжиде кеше иек без. Ну, узган атнада ундүртебезне фрунтка апкиттеләр. Өчебезне, ярамыйсыз дип, алмадылар. Мин үзем, например, менә шушы сул аяк бөгелмәү аркасында калдым. Уналтынчы елда гирман сугышында ранный булганыем. Карале, энекәш, син менә этрәт тә этрәт дисең. Үзеңнең этрәтең кая соң синең? Сине өяздә этрәт башлыгы булып йөри дигәннәрие бит.

Отряд башлыгы гына түгел иде Миңнулла. Зуррак иде аның дәрәҗәсе. Пермь губернасының Усы өязе башкарма комитеты председателе урынбасары һәм кызылгвардиячеләрнең өяз штабы члены иде ул.

Соңгы көннәрдә өязгә караган авылларда контр элементлар кыбырсый башлавы турында хәбәрләр ишетелә башлаган иде. Шуңа күрә партиянең өяз комитеты өяз башкарма комитеты хезмәткәрләрен, шул мәсьәләне тикшереп, кирәк булса контрларга карата катгый чаралар күреп, кыскасы, җирле комитетларга ярдәм итеп кайтырга дип, авылларга чыгарып җибәрде. Миңнулланы, синең эшнең нәтиҗәсе зуррак булачак, дип, Карый һәм Кече Ашап волостьларына керә торган авылларга билгеләделәр. Миңнулланың Усыдан чыгып китүенә бүген өченче көн. Кичә ул Ильиновка авылында булды. Анда алай зыянлы нәрсә юк иде. Ярлылар комитеты дилбегәне кулында нык тота икән. Тик урта хәллегә караганда байга якынрак торган, шулай да авыл халкының миһербанлылыгы аркасында сөрелмичә калган һәм соңгы көннәрдә «барыбер озакка бармаячак бу советлар, тиздән безнең якларга азатлык армиясе килеп җитәчәк тә иске тәртипләрне яңадан кайтарачак», дип, халык арасында лыгырдап йөри башлаган бер бәндәне авыл Советына дәштереп, ару гына пешекләп чыгардылар да шуның белән эш беткән иде. Ә бүген Миңнулла Барсай ярлылар комитетының хәлен белеп, кирәк булса ярдәм дә итеп, кичен үзенең туган авылы Карыйга, әти-әниләре янына кайтып кунарга ниятләгән иде. Ләкин монда мәсьәләләр катлауланган булып чыкты бит әле. Эшнең болайга ук китәрен белгән булса, Миңнулла үзе белән Шакир-контр шикелле тугыз кешелек кенә түгел, унтугыз кешелек кораллы отряд алып килгән булыр иде дә бит, ләкин...

— Бөтен бәла дә менә шунда, Сафиулла абзый, отрядсыз гына килгән идем бу юлы! — диде Миңнулла, бик нык үкенеп.— Әгәр отряд...

Аның сүзе шунда бүленеп калды, чөнки өске каттан кемдер бик әшәке итеп сүгенеп, абына-сөртенә аска төшеп килә башлаган иде.

— Бар, энекәш, ычкын исән чакта! — диде Сафиулла агай, коты алынып.— Бар, тизрәк Усыга кайт та этрәт алып килү җаен чамала!

Миңнулла йөгерә-атлый урамга чыкканда, Заһит абый кырпу бүреген салып куеп, кәләпүштән генә калган да, арбасына аяк бөкләп утырып, әле шешәсендәге сөтен, әле кулындагы ипи кыерчыгын каба-каба, бик тәмләп ашап утыра иде. Миңнулла аның янына килеп:

— Әйдә, Заһит абый, ашавыңны куеп тор да кузгалыйк әле моннан тизрәк! — дигәч, дерт итеп сискәнеп китте.

— Һәй, юлың уңгыры, син икәнсең ич әле! Котымны алдың,— диде ул.— Кай арада эшеңне бетереп чыктың соң син? Атның аркалыгын төшереп кенә өлгергән ием бит әле,— дип мыгырдана-мыгырдана, шешәсен бөкеләп, икмәген төреп капчыгына тыкты. Шуннан ары гына Миңнуллага күтәрелеп карады һәм шаккатып:

— Ни булды сиңа, олан? Йөзең аппак булган лабаса! Әллә бер-бер хәл килеп чыктымы? — диде.

Олаучысының куркак кеше икәнен белә иде Миңнулла. Өченче көн Карый һәм Ашап волостьларына барасы икәнен белгәч үк:

— Әллә бүтән кеше белән сөйләшеп карыйсыңмы, наный. Бер дә кузгаласым килми, аягым тартмый шунда барырга. Әллә ниткән хәвеф-хәтәрләргә таруыбыз бар,— дип, шактый карышып азапланган иде бу агай.

Тик Миңнулла кесәсеннән наганын чыгарып:

— Менә бу нәмәрсәкәй безнең белән булганда шайтанның үзеннән дә курыкма син, Заһит абзый! — дигәч кенә, анда да шул наганнан шикләнеп кенә ризалашкан иде. Юлда килгәндә дә әледән-әле тынгысызланып:— Ай-һай, наный, напраснырак кузгалмадык микән? Шушы карап торган бердәнбер атымнан да колак кактырырга йөрмисең микән син мине? Яхшы чакта әллә борылып кайтып кына китәбезме? — дип сөйләнеп килгән иде.

Хәзер аңа Барсайның комбед председателен атканнарын һәм этисе йортында Шакир-контрның ни кыланып утыруын әйтсәң — йөрәге ярылачак.

— Чүп тә юк, Заһит абзый! Мин барында берәүдән дә шикләнмә син! — диде Миңнулла, тегене тынычландырмакчы булып.

Әмма олаучы тынычланмады:

— Алла диең, наный! Әстәгыфирулла диең! Алтатарлы кеше бер син генә түгелдер дөньяда. Бу заманда синнән башка да житәрлектер андыйлар. Алланың бер үзенә тапшырдык дип сөйләш, ичмаса, аны!

Заһит агай әнә шуларны такмаклый торган арада Миңнулла тиз генә аркалыкны күтәрде, ат башына кидереп куелган солылы капчыкны салдырып алды да, дилбегәне үз кулына тотып, атны кайтыр якка борды. Зәһәр генә итеп сыптырып та алды. Әллә ни шәп җилдерә алмаса да, ат ару гына юыртып алып китте.

Ул минутларда Миңнулланың күңелендә бер генә уй бөтерелә иде: «Тизрәк Карый волкомына кайтырга да, шуннан кораллы отряд алып килеп, айнып җиткәләгәнче, Шакир-бандитны да, аның шайкасын да кулга алырга!»

Ләкин Карыйга алай тиз генә кайтырга язмаган икән шул.

## 2

Инде авылдан чыгып барганда гына тыкрык буендагы каравыл өе янында җыйналган утыз-кырыклап кешене күреп алды Миңнулла. Күреп алды да, атын туктатып, Заһит агайга шул туктаган урыннарында көтеп торырга кушты. Үзе теге кешеләр янына барып:

— Исәннәрмесез? — диде.

Ләкин аңа берәү дә игътибар итмәде. Җыендагыларның барысы да, муеннарын сузып, каравыл өенең нигрәсендә кызып-кызып нидер сөйләп торган яшь кенә, чибәр генә, кара мыеклы кешегә текәлгәннәр һәм, мөкиббән китеп, шуны тыңлыйлар иде. Миңнулла да ул кешене күрү белән танып алды: үзләренең Усы өязендәге Чирканды авылы мулласы малае, әле узган елда гына Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлап кайткан Хәйретдинов Хәйрулла иде бу.

«Тагын нәрсәләр лыгырдап йөргән була икән монда?» дип, Миңнулла аның сүзләренә колак салды:

— Әле менә шушы араларда гына яңадан торгызылган милли шура әгъзасы вә үзебезнең милләт язмышын кайгыртучы хак мөселман буларак, — дип сөйли иде тегe, — мин сезгә кыл дөресен генә әйтәм, җәмәгать: безгә патшасы да, камунистлары да сукыр бер тиенгә дә хаҗәт түгел! Патшасы да гомер-гомергә без мөселманнарны кимсетеп, талап килде, камунистлары да игелек күрсәтәчәк түгел. Камунистлары хәтта патшадан да залимрәк аның, беләсегез килсә. Патша заманында без мөселманнарны «гололобый» дип мыскыллаcалар да, аң-белем алырга ирек бирмәсәләр дә, ичмаса, денебезгә вә аллага тел тидермәделәр. Ә менә бу камунист дигәннәре, совет дигәннәре аллага вә дингә каршы чыгучылар алар! Әйе, җәмәгать, мин сезгә кыл дөресен әйтәм, денебезне бетермәкче безнең ул камунистлар. — Нотыгы халыкка ничегрәк тәэсир иткәнен чамалау өчен булса кирәк, Хәйрулла, шунда туктап, беркавым җыендагыларга карап торды. Тегеләрнең селкенмичә дә тыңлауларын күргәч, тагын да кодрәебрәк дәвам итте: — Шулай, җәмәгать, моннан да зуррак золымның һичкайчан булганы юк әле. Үзегез уйлап карагыз: без сезнең белән күпме кан түгеп, күпме көч куеп бер залимнән — рус патшасыннан котылу өчен революция ясадык, ә влачны кемнәр алды? Влачны камунистлар тартып алды. Бу ни дигән сүз? Бу менә нәрсә дигән сүз, җәмәгать: бер залимнән күп залимнәргә, патшасына караганда да яманрак залимнәргә килеп каптык без. Ә бит революцияне без ирек өчен дип, хөррият өчен дип ясаганыек, җәмәгать. Хәлбуки, безгә хөррият дигән нәрсә тәтемәде. Камунистлар дәүләт башында утырган тәкъдирдә тәтемәячәк тә ул безгә. Ни өчен дисәгез, камунистларны безнең ише мөселман динендә булган бәндәләр генә түгел, урыслар үзләре, вә һәм җир шарында иң бай, иң көчле булган Америка вә Англия илләренең патшалары да яратмый. Нимечләр, чихлар, мадьярлар вә шулар ише бүтән бик күп халыкларның совет влачына каршы икәнен әйтеп тә торасы юк инде. Тик шуны гына исегезгә төшереп үтүне лязим күрәм: менә шул милләтләр барысы да берләшеп, камунистларга, советларга каршы сугыш башлап җибәрде. Безгә аларга каршы торып азапланудан хасият юк, җәмәгать. Без, татар вә башкортлар, үзара бер булып, үз өязләребездәге вә вулысларыбыздагы совет влачын алып ташлап, үзебезнең ирекле милли мәмләкәтебезне — Идел-Урал дәүләтен төзергә тиешбез. Ошбу изге максатны гамәлгә ашыру өчен безгә нәрсә эшләргә кирәк соң? Безгә моның өчен иң элек үзебезнең милли гаскәребезне төзергә кирәк, җәмәгать! Аннары шул гаскәр сафларына бөтенебез дә бердәм булып басып, борынгы ата-бабаларыбыз шикелле арысланнардай батыр булып, аяусыз булып, дошманга каршы көрәшергә кирәк. Шунсыз безнең татар-башкортка ирек вә хөррият булачак түгел! Шунсыз безнең мөселман халыкларына якты көн килмәячәк! Шунсыз...

Миңнулла шуннан арыгысын тыңлап торуны кирәк тапмады, чөнки «мөселман кардәш»нең бу нотыгы аңа таныш иде инде.

Узган елның декабрь аенда Усы өязенең земская управасы каршындагы милли шура оешмасы өяз мөселманнарының съездын үткәрде. Усы укомы[1] председателе Емельян Петрович Колеговның тәкъдиме буенча, Миңнулла да шул съездда катнашты. Миңнулла ул чакта үзләренең Карый волостенда эшли, съездга аны шул волость делегаты итеп җибәргәннәр иде. Делегатларның күпчелеге, әлбәттә, сәүдәгәрләр, куылудан калган байлар, мулла-монтагайлардан гыйбарәт иде. Съездны намаз укып ачтылар. Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр артык күп булганга, аларны хәл итүне ансатлаштыру максаты белән

---

[1] Уком — уездный комитет (өяз комитеты).

бернчә комиссия төзеделәр. Укымышлы, шуның өстенә тагын сугышта да булып кайткан кеше буларак, Миңнулланы хәрби комиссия составына сайладылар. Ә ул комиссиягә булачак милли гаскәрнең структурасын билгеләү бурычы йөкләтелгән иде. Менә хәзер Барсай авылында, бәләкәй генә бер йортның ниргәсендә, төкерекләрен чәчә-чәчә, авыл апайларына нотык сөйләп торучы Хәйрулла да шул комиссиядә булып, анда да нәкъ менә шушы сүзләрне лыгырдаган иде. Миңнулла нәкъ менә шушы бәндә аркасында милләтчеләр кулына каба язып калган иде дә инде ул чакта!

Миңнулла ул съездда чыгыш ясарга тиеш түгел, аңа съездда каралган мәсьәләләр һәм съезд кабул иткән программа белән танышып кайту бурычы гына йөкләнгән иде. Ләкин әлеге шушы Хәйрулла менә хәзер такылдап торган нотыгы белән чыгыш ясагач, Миңнулла түзеп тора алмады. Председательлек итүче кешенең рөхсәтен дә сорап тормастан, атылып трибунага менде дә:

— Иптәшләр! — дип кычкырды.

Моңарчы чыгыш ясаган делегатларның барысы да сүзләрен «әфәнделәр» дип башлаганнар иде. Шуңа Миңнулланың «иптәшләр»е залдагы милләтчеләргә аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте: алар ду килеп шаулаша башладылар. Ләкин Миңнулла янә бер тапкыр, бу юлы тагын да ныграк итеп, «Иптәшләр!» дип кычкыргач, кинәт шып булып калдылар һәм трибунага текәлделәр. Миңнулла бик нык дулкынланып, әмма сүзләрен ачык әйтеп сөйләп китте:

— Минемчә, без биредә юкка гына вакыт үткәреп, һич кирәкмәгән нәрсәләр турында баш ватып утырабыз! Менә миннән алда бик дәртләнеп сөйләгән адәмнең нотыгына гына игътибар итик. Ул ярты сәгать буена татар-башкорт милли дәүләтен төзергә, ә аның өчен башта милли гаскәр оештырырга кирәклеге хакында сүз алып барды. Әйе, милли гаскәрне чыннан да оештырырга кирәк безгә. Ләкин ул, әлеге адәм уйлаганча, буржуйларны яклап көрәшә торган гаскәр түгел, бәлки совет дәүләтен саклап калу өчен көрәшә торган гаскәр, революция гаскәре, татар белән башкортларның азатлыгы өчен генә түгел, бөтен Россиядәге барлык халыкларның азатлыгы өчен көрәшә торган гаскәр булырга тиеш! Ә теге адәм әйткәнчә, милли гаскәр төзергә тырышу — контр сүзе, революция дошманнары тарафыннан уйлап табылган нәрсә ул! Ул өйрәткән юлдан китсәк, чит ил дошманнары белән берләшеп, бай-лар-буржуйлар бик тиз кулга алачак безне. Киресенчә, Рәсәйдәге барлык милләт халыклары белән берләшеп, бер нык йодрык булып, революция дошманнарына, чит ил капиталистларына каршы көтәрелергә кирәк безнең мөселман халкына. Миннән алда сөйләгән бәндә үзе әйтмешли, без мөселман кардәшләребезне менә шул бөек һәм изге максатка әйдәргә тиешбез! Тик шул чакта гына безнең татар халкы бүтән халыклар белән тигез хокуклы булыр, тик шул чакта гына безнең халкыбыз хөррияткә һәм якты көн күрә башлауга ирешер! Бу минем үз фикерем генә түгел, иптәшләр. Бу — чын мәгънәсендә ирек һәм тигезлек өчен көрәшүче Коммунистлар партиясе фикере, шул партиянең бөек җитәкчесе Ленин фикере!

Хәйрулла нотыгыннан соң залны дер селкетеп кул чапкан милләтчеләр, Миңнулла сүзен тәмамлагач, бер мәлгә телсез калып тордылар. Тик ул трибунадан төшеп, урынына утырырга бара башлагач кына өннәренә килеп, төрлесе төрле яктан кычкыра башлады.

— Кызыл этәч!

— Большевиклар шпионы!

— Милләт сатучы!

— Денсез, кяферләргә сатылган нәрсә!

Миңнулла шулайрак буласын алдан ук чамалап торган иде. Шуңа тегеләрнең кычкырышуына артык әһәмият бирмәде.

Тәнәфескә чыккач, Миңнулла янына аңа электән таныш булган бер делегат килде дә:

— Сиңа хәзер үк моннан китәргә кирәк, егет. Большевиклар агенты дип кулга алырга җыеналар сине. Чирканды Хәйрулласының Чегән Гата белән шул хакта сөйләшеп торганын үз колагым белән ишеттем! — диде.

Әйе, Миңнуллага бу контрлар җыенында калу, чыннан да, куркыныч иде хәзер. Һәм калып торуның әллә ни хаҗәте дә юк иде. «Съезд мәсьәләләренең күбесе инде каралды, программасы нигездә ачыкланды — чеп-чи милләтчеләр программасы булачак ул. Шулай булгач, инде кайтып китәргә дә ярый торгандыр», — дип, Миңнулла болдырга чыккан гына иде — каршына, мыскыллы елмаеп, Чегән Гата килеп басты:

— Гайсин Миңнулла әфәнде син буласыңдыр бит?

— Әйе, мин — Гайсин. Ләкин әфәнде түгел!

Миңнулла шуннан бүтән сүзгә килешеп тормыйча гына үтеп китмәкче булган иде, әмма Гата аның кулыннан тотып алды һәм, гел шулай ачу китергеч елмайган килеш:

— Ярый, анысы ни важны. Анысын ошатмасаң, «иптәш» дияргә дә була. Без алай артык нәзберек халык түгел. Тик син, Гайсин иптәш, ашыкма китәргә. Мин сине Идел-Урал мәмләкәте исеменнән кулга алырга тиеш булам хәзер, — диде.

— Беренчедән, синең съезд делегатына кагылырга берниндн дә хокукың юк! Икенчедән, андый дәүләт булганын мин белмим!

— Белмәсәң белерсең! Мин сине булачак, төзелеп ята торган Идел-Урал мәмләкәте исеменнән кулга алам, Гайсин! Каяле, кесәләреңне тикшереп карыйк, коралың юкмы икән?

Эшләр болайга ук китә башлагач, Миңнулла наганын тартып чыгармакчы иде, кызганычка каршы, өлгерә алмый калды: арттан аның кулларын тотып алдылар да каерып бәйләп тә куйдылар. Миңнулла кычкырырга итә башлагач, башта авызын уч белән капладылар, аннары тире бияләй тыктылар. Төрткәли-типкәли, съезд бара торган йортның ихатасына алып чыктылар. Анда җигүле пар ат тора иде. Тиз генә Миңнулланың башына капчык кидерделәр һәм аны чанага төртеп ектылар. Шыгырдап капка ачылганы ишетелде. Кемдер ачы итеп сызгырып җибәрде. Кайсыдыр чыжлатып чыбыркы белән атларга сукты. Атлар урыннан ук кушаяклап торып чабып китте.

Ләкин күп тә үтмәде, мылтык аткан тавышлар ишетелә башлады. Миңнулланы алып китеп баручылар:

— Булмады, янабыз, ахрысы! — дип, башта бик каты сүгенешеп алдылар, аннары Миңнулланы чанадан ташлап калдырып, артларыннан куа килүчеләргә ата-ата, ары киттеләр...

Гата шайкасы кулына әнә шулай чак-чак кына эләкмичә калган иде Миңнулла. Уком председателе Емельян Петровичка рәхмәт инде: андый-мондый хәл килеп чыга калса дип, съезд бара торган йортны күз уңында тотарга кушып, дежурга ул биш кешелек отряд билгеләп куйган булган икән.

Миңнулланы коткарган отряд кешеләре шул ук көнне Гатаны һәм аның ике ярдәмчесен дә тотып алып кайтып, өяз каталажкасына ябып куйганнар иде. Ләкин хөкем итәргә өлгерә алмый калдылар. Иректә калган шайкадашлары коткарган тегеләрне. Төн уртасында, каталажканы саклаучы агай йокымсырап утырган чакта килеп кергәннәр дә, аны куркытып, каталажка ишеген ачтырганнар һәм Гаталарны чыгарганнар. Аннары кулын артка бәйләп, авызына чүпрәк тыгып, каталажкага сакчының үзен бикләп киткәннәр иде. Соңыннан тагын шунысы да ачыкланды: бу эш тә шулай ук менә хәзер Барсай мужик-

ларын милли Идел-Урал дәүләте төзергә үгетләп торган Хәйретдинов Хәйрулла коткысы белән эшләнгән булып чыкты...

Хәйрулланың әнә шул чактан бирле күзгә-башка күренгәне юк иде, инде менә тагын каяндыр калкып чыккан, хәерсез! Күрәсең, аклар белән тыгыз элемтәдә булгандыр да, ак бандалар һәм унбиш миллионга чит ил буржуйларына сатылган Басарик җитәкчелегендәге чехословак корпусы гаскәрләре бу якларга үрмәләвен сизенеп, тагын үзенең кабахәт эшенә керешкәндер. Яки акларның үзләрендә үк хезмәт иткәндер дә тегеләр аны, яшерен агентлары итеп, бу тирәләрдәге хәлләрне тикшереп, хәбәр итеп торырга кушып җибәргәннәрдер.

Әле һаман Барсай халкын үгетләвен дәвам иткән Хәйруллага карап торган арада менә шундый уйлар үтеп китте Миңнулла күңеленнән. Һәм ул, әллә шушында атып үк үтерим микән бу ата контрны, дип, кесәсендәге наганын да капшап куйды. Ләкин коралсыз кешегә тиктомалга ату егетлек булмас дип, ул уеннан кире кайтты һәм, ни кылганын үзе дә сизмәстән, нәкъ узган елгы милли шура съездындагыча ялт кына, Хәйрулла янына — өй ниргәсенә менеп басты да, тегене тыңлап торучы халыкка мөрәҗәгать итеп:

— Иптәшләр! — диде.

Хәйрулла телен тешләгәндәй тынып калды. Ә Миңнулла муенын кысыбрак торган күлмәк якасының төймәсен ычкындырып җибәрде дә кызып-кызып сөйләп китте:

— Сез бу кешегә тамчы да ышанмагыз, иптәшләр! Милләтне яклаган булып, дошман сүзен сөйли бу бәндә. Совет власте бетмәячәк! Коммунистлар шулай ук бетмәячәк. Чөнки аларның башында Ленин үзе тора! Ә Ленин ул гаделлек яклы, эшчеләр һәм крестьяннар яклы! Халык җилкәсен кимереп, халык мөлкәтен ашап, симереп яткан байларга каршы ул совет дәүләте, халыкны алдап көн күрүче муллаларга каршы! Ә менә сезне ниндидер милли мәмләкәт төзергә вәгазьләп тора торган бу адәм — Чирканды мулласы малае! Шуңа совет властен яратмый ул, шуңа коммунистларга каршы сөйли. Ә дин саятыннан бер дә хафаланмагыз, иптәшләр: совет власте дингә кагылмый ул. Дин тоту-тотмауны халыкның үз иркенә куя. Икенче төрле итеп әйткәндә, дин дәүләт эше итеп каралмый, хөкүмәт аның өчен акча тотмый. Тотмаса тотмас, иптәшләр, патша хөкүмәте дә ул эш өчен безнең халыкка бер тиен дә бирми килде ләбаса! Шулай булгач, бу мәсьәләдә сезгә һичнинди зыян булмаячак. Безнең бүгенге көндәге төп бурычыбыз менә нәрсәдән гыйбарәт, иптәшләр: хәзер без, бар көчебезне биреп, ак бандаларга, яшь совет дәүләтен буып ташларга тырышучан чит ил дошманнарына, байларга һәм менә бу Чирканды мулласы малае кебек контр элементларга каршы көрәшергә тиешбез!

Миңнулла боларны бер тын белән шундый ышанычлы, шундый тәэсирле итеп сөйләде, авыл агайлары исләре китеп, сулу да алмыйча тыңлап тордылар. Хәйрулла да теш агартып сүз катмады. Тик Миңнулла сөйләп бетергәч кенә, кодрәтләнеп китеп:

— Менә, җәмәгать, бу бәндә камунистның иң азгыны инде! Камунистлар менә шушындый әтәч халык инде алар: очып кунарга гына торалар. Мин әле сезгә әйтәсе сүзләремнең яртысын да әйтергә өлгермәгән идем, ә менә бу адәм, кешенең сүзен бүлеп, үзенекен такылдап та алды. «Рөхсәт итегез, җәмәгать, миңа сүземне дәвам итәргә»,— дип, сандугач урынына сайрый башлаган иде, ләкин авыл агайлары:

— Мәтәшмә, энекәш, юк белән. Әйтәсе сүзең бар икән, менә шушы камунист егет шикелле өздереп, кыска гына итеп әйтергә кирәк аны, ничу су буе итеп сузарга! — дип, аңа ирек бирмәделәр. Миңнулланы урап алдылар да: — Син өяздән килгән нәчәнник бугай, наный, әйт әле безгә, өяз сәвите ни карый соң анда? Нигә бу араларда дилбегәне бик йомшаттыгыз? Куылган байлар тагын кайта башлады ләбаса!

Тагын мужикка көн бетә бит инде болай булса! — диешеп, төрле яктан сукранырга тотындылар.

«Әһә, бу агайларның совет властена карата иманнары нык икән!» дип куанып куйды Миңнулла. Һәм ул иплэп кенә аларның сорауларына җавап та бирә башлаган иде. Әмма шул чак җыендагыларның берсе:

— Карагыз әле, җәмәгать, тагын кайсыларыдыр килә анда безнең авылга! — дип, халыкның игътибарын җәлеп итте.

Барысы да ул күрсәткән якка борылдылар. Артларыннан тузан болыты күтәреп, атларын бик нык куалап, Барсайга дүрт җайдак якынлашып килә иде. Халык төрлечә фараз кылып торган арада тегеләр, ут өермәседәй ажгырып, килеп тә житте. Аларның өчесен Миңнулланың күргәне юк, әмма берсе таныш — шурачылар съездында үзен кулга алган әлеге Чегән Гата иде.

Бүтәннәре җыен читендә тукталып калды, ә Гата аты белән халык арасына үк килеп керде дә:

— Старостагыз мондамы? — дип кычкырды.

— Юк, монда түгел, — диделәр аңа.

— Кайда ул?

— Сәйфи бай малае Шакир кайтты, ул дәштергәние бугай аны.

— Латны. Ә дисәтникләрдән монда кемнәр бар?

Гатага җавап бирүче булмады.

— Дисәтникләрдән кемнәр монда? — дип акырды Гата.

Тик шуннан соң гына кап-кара сакал-мыегына күптәннән пәке тимәгән, сәләмә генә киемле, чандыр гына гәүдәле бер кеше тегеңә якынрак килде дә, куркып кына:

— Мин нем дисәтник, Гата туган,— диде.

— Синең ише туган белән мин күпер башында к... юган! Нигә ирләрне Васкрисинскигә кумыйсың, өтек? Әйткәннәрдер бит сиңа бер булган ир-атларны кораллландырып Васкрисинскигә аппарырга кирәк икәнен?

— Безгә бер дә ул хакта әмер биргән кеше булмаганые шул, Гатаулла. Дисәтник булырсың дип тә Шакирҗан миңа бүген иртә белән генә әйткәние әле. Безнең ир-атлар нигә дип барырга тиеш була икән соң ул урыс авылына? Ниткән корал икән инде ул тагын?

Гатаның чыннан да нәкъ чегәннәрнеке кебек каратут йөзе бүртенеп, тагын да каралыбрак китте:

— Ах, туң ми! Син әле коралның нәрсә икәнен дә белмисеңмени? Менә шушындый була ул корал! — диде дә, кесәсеннән наганын тартып алып, шул наган түтәсе белән десятникның күкрәгенә төртте. Бичара агай «һык!» итеп китте дә хәлсезләнеп җиргә чүкте. Ә Гата, аңа бөтенләй игътибар итмичә, ике тапкыр рәттән һавага атып җибәрде. Куркышып-аптырашып калган авыл агайларына карап, калын һәм карлыккан тавыш белән җикеренергә тотынды:

— Нигә авызларыгызны ачып торасыз, ахмаклар! Мин әйткәнне ишетмәдегезмени? Барыгыз, хәзер үк өйләрегезгә кайтыгыз да мылтыклары булганнар мылтыкларын, мылтыгы булмаганнар сәнәк-күсәкләр алып, менә шушында җыйналыгыз! Бер сәгать вакыт бирәм мин сезгә! Кем дә кем бер сәгать эчендә килеп житми — миңа эбижәтсе итмәсен! Җәһәннәм тишегеннән табып, менә шушы кулымдагы наган белән атып үтерәчәкмен! Ишеттегезме?!

Түгәрәк ак сакаллы бер бабай:

— Без анда барып ни эшләрбез икән соң, Гатаулла? — дип сораган иде, Гата аңа:

— Баргач күрерсең шунда, ә хәзер, бар, тизрәк кушканны үтә! — генә диде дә, каядыр китмәк булып, атын бора башлады. Шул чак теге «мөселман кардәш» аның каршына чыкты һәм, башы җиргә тиярдәй итеп бөгелеп:

— Әссәләмәгаләйкүм, Гатаулла абзый? — диде.

— Чукын инде! — диде Гата, тегенең сәламен алып тормыйча гына. — Син дә мондамыни әле, Хәйрулла әфәнде? Ниләр кыдырып йөрү?

— Безнең эш билгеле инде, Гатаулла абзый: милли шура съезды карарларын гамәлгә ашыру артыннан йөргән көн.

Гата гамьсез генә сорап куйды:

— Ничек соң, эшегез барып чыгар төслеме?

«Мөселман кардәш» әле һаман таралырга ашыкмыйча, тегеләрнең сүзен тыңлап торган авыл агайлары арасыннан Миңнулланы күрсәтте:

— Менә монавындый денен вә милләтен кяферләргә саткан адәм калдыклары булмаса барып чыгар иде дә, шушылар аяк чала шул, Гатаулла абзый! Бәлки әле хәтерлисендер дә: үткән ел Усыда уздырылган мөселманнар съездында көфер сүз сөйләп, бөтен съездның тәртибен бозган, аннары килеп сезнең башыгызга җитә язган ата камунист Гайсин Миңнулла дигән адәм инде бу!

— Шу-у-лаймы-ни? — диде Гата, бик каты исе киткән атлы булып. Аннары, бармагын изәп, Миңнулланы үз янына чакырды.— Нука, нука, кил әле монда, дененнән язган нәрсә!

Миңнулла бер сүз дә дәшмичә баскан урыныңда торуын дәвам иткәч, атыннан сикереп төште дә Гата үзе Миңнулла каршына килеп басты. Берничә секунд икесе дә күзгә-күз терәшеп тордылар. Гатаның иләмсез зур һәм таза гәүдәсенә, бәбәкләрен кан баскан нурсыз соры күзләренә карап тору бик читен булса да, түзде Миңнулла — карашын читкә бормады. Текәлеп бер карау белән теләсә кемнең өрәгген ала торган Гатаның бу хәлгә җен ачуы чыкты: тешләрен шыгырдатып куйды да утын тукмагы кадәр йодрыгын Миңнулланың ияк астына китереп терәде:

— Яле, дөресен генә сөйләп бир әле, кызыл этәч: ни эшләп йөрисең син монда? Һаман шулай халыкны денсезлеккә өндәп, милләткә каршы котыртыпмы? Яле, яхшы чакта бөтенесен дә иплән кенә әйтеп бир әле!

— Иң элек мин допрос алырга җыенучы кешенең үзе кем булуын белергә теләр идем, — диде Миңнулла, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.— Әгәр ул кешенең шуңа вәкаләте булса, мин аңа җавап бирергә әзер!

— Ах, кызыл этәч, әле сиңа вәкаләт кирәкмени?! Менә сиңа ул вәкаләт!

Гата Миңнулланың күн курткасы изүеннән шундый итеп тотып тартты — дүрт төймәсенең дүртесе дә берьюлы шатырдап өзелеп, атылып киттеләр. Аннары Гата үзе белән килгән җайдакларга боерды:

— Яле, бөркетләр, акылга утыртып алыгыз әле бу ахмакны! — Тегеләр атларыннан төшкән арада Гата:

— Каяле, коралың юк микән, алладан җәяүләп качкан нәрсә! — дип, Миңнулланы тентергә үрелде.

«Коралны алсалар — бетте баш. Ичмаса, үзен дә дөмектереп калыйм!» дигән уй йөгереп үтте Миңнулла күңеленнән һәм ул:

— Тукта, үзем бирәм! — диде дә куртка кесәсеннән наганын алып, атып та җибәрде.

Атуын атты, ләкин тидерә алмады. Гата читкә тайпылып калды. Ул арада Гатаның ярдәмчеләре дә килеп җитеп, Миңнуллага ябырылдылар һәм наганын каерып алырга тырыша башладылар. «Тере килеш бирелмәскә!» дип уйлап алды Миңнулла. Әле һаман кулыннан ычкындырмыйча тырышкан наганын үзенә таба борып, чакмага басты. Ләкин пуля аның күн фуражкасын тишеп кенә үтеп китте.

Ниһаять, Гата аның наганын тартып алды. Аннары каерылып торып яңагына сукты. Ул шунда берочтан Миңнулланы атып үтермәкче дә булган иде, тик ярдәмчеләренең берсе аның кулыннан тотып:

— Ашыкма, Гатаулла, моңарчы кеше үтермәгәнне, хәзер генә гөнаһлы булма! Синнән башка да үтерүчеләр табылыр,— дигәч тыелып калды һәм, суярга салган дуңгыз тавышы белән чинап җибәреп, Миңнулланың колак төбенә тагын берне сугу белән генә чикләнде.

Аннары ярдәмчеләренең икесенә Миңнулланың аягын-кулын бәйләргә кушты, ә берсенә арбасында дер калтырап утырган Заһит абыйны күрсәтеп:

— Син әнә теге мәхлукның атын тугарып алып кил! Менә бу «яшь этәч»не шуңа атландырып Васкрисинскигә илтергә кирәк булыр,— диде. Һәм бик дустанә рәвештә Хәйрулла белән сөйләшә башлады.

Ләкин теге кеше (Миңнулланы үлемнән саклап калган агай) атны тугармыйча гына алып килде.

— Мин сиңа нәрсә дип әйттем? — диде Гата, тегеңә күзенең агы белән карап.

— Әллә җиккән килеш кенә аппарыйкмы дигәнием, Гатаулла. Арбасы белән збруе да ару гына күренә бит.

— Дурак булсаң да акыллы сүз әйттең бу юлы! — диде Гата, тегенең карары белән килешеп. — Әйе, шулай итү хәерлерәк булыр. Каkраз тегеләрнең камандиры да берничә подвода алып кайта алмассызмы дип калганые. — Аннары йөзенә мәет төсләре иңгән Заһит абыйга карады да: — Ә син нигә өннән чыгып утырасың әле? Өегезгә кайтып, корал алып килергә дигән боерыкны ишеткәнсеңдер ич! Марш тизрәк өеңә! — диде.

— Мин бу авыл кешесе түгел, Гатаулла туган,— диде Заһит абый, усак яфрагыдай калтыранып.

— Кайсы авылныкы суң син?

— Усыныкы.

— Ә монда нишләп йөрисең?

«Миңнулла белән килгәнне әйтсәм, я мине дә бәйләп салырлар да әлләниләр сорап дупруслый башларлар», дип курыкты Заһит абый. Шуңа күрә:

— Сыерыбыз җугалганые, шуны эзләп йөрүемие,— дип алдашты.

— Латны, пунятны! Бар, эзлә инде, алайса. Ә атың безгә кирәк, без алып торабыз. Исемең ни атлы синең?

— Заһит.

— Ә фамилияң?

— Зариф улы.

— Латны. Пунятны! Ә мин ат карагы Гата булам. Чегән Гата дип йөриләр мине. Ишеткәнең бармы?

— Ишетмиләрме суң инде, Гатаулла туган, бик күп ишеткәнем бар синең хакта. Әмма ләкин сине ярлы кешеләрнең атларына тими дип әйтәләрие ләбаса. Нигә дип мине шушы бердәнбер арык алашамнан мәхрүм итмәкче буласың?

— Белеп сукалыйсың син, Заһит кордаш. Дөрес, ярлы-ябагайны әбиҗәт итә торган гадәтем җугые минем. Ну, бу юлы, бигайбә, синең атыңны алып торырга туры килә. Син бер дә хафаланма, атыңны, хаҗәте бетүгә, прәме үз өеңә китереп бирерләр.

— Юк инде, Гатаулла туган, шушындый мәхшәрдә, ата улны, ана кызны белмәгән заманда, бердәнбер атымнан аерыла алмыйм инде мин! Теләсә ни әйт, әмма алашамны кая алып барсагыз — мин шунда барам. Эшегез беткәч, үзем алып кайтырмын.

— Син ул атны кая апкитәсен беләсеңме суң, туң ми? Хәрби часка апкитәбез бит без аны! Ә анда сугышка керʼтеп җибәрергә дә күп сорап тормаслар!

— Хет дөньяның аргы ягына җибәрсеннәр. Мин атымнан калмыйм! Атсыз ни эшлим мин, аяксыз да күтсез алты баламны ничек туйдырыйм? Җитмәсә тагын, хатын да инде елдан артык урын өстендә ята!

Гата, өметен өзеп, кулын селекте:

— Чукын инде, алайса: рас яхшылыкның кадерен белмисең икән, бар! Ну, миңа үпкәлисе булма соңыннан!

— Әй, алланың рәхмәтле бәндәсе! — диде Заһит абый, үз алашасына өстәп тагын бер алаша биргәндәй куанып. — Сине безнең ише фәкыйрь-фокрага шәфкатьле дигәннәрие, тәки шулай икәнсең, Гатаулла!

— Ярый, артык күп сайрама. Кая, кил әле монда! — дип, Гата Заһит абыйны якасыннан әләктереп арбадан җиргә алып куйды. — Атыңның койрыгына алай бик каты берекәнсең икән, менә болай итәбез инде аны! — дип сөйләнә-сөйләнә, Заһит абыйның билендәге эзәрен чишеп алды һәм шул эзәре белән кулын каерып бәйләде. Аннары, ансат кына итеп, тегене яңадан арбасына күтәреп куйды. Ярдәмчеләре Миңнулланың да аягын-кулын бәйләп куйганнар иде, Гата аны да шул ук арбага сузып салып, арбадагы йөк җебе белән үрәчәгә бәйләде. Аннары ярдәмчеләренең берсенә, әлеге шул Миңнулланы аттырмыйча калганына:

— Мә, тот дилбегәне дә, атлатып кына Васкрисинскигә алып бара тор! Без озакламый артыгыздан куып җитәрбез. Килеп җитмәсәк, авылга үзең генә барып кермә, Бурсык чокыры турында көтеп тор, яме? — диде.

3

Миңнуллаларны илтүче агай башта әсирләргә бөтенләй игътибар итмичә, тик үзенә генә аңлаешлы көйгә борын эченнән ниндидер җыр мөгрәп барды. Аннары кинәт тынып калып, Миңнуллага борылып утырды да:

— Син укымышлы кешегә охшагансың, әйт әле миңа, энекәш: нишли бу замана, кая таба бара? — дип сорап куйды.

— Ә синең, агай, аның кая таба баруын һаман төшенә алганың юкмыни әле?

— Һаман төшенә алганым юк шул әле!

— Алайса, тыңла яхшылап: узган ел илдә революция булды. Менә синең белән безнең ише ярлы крестьян халкы һәм шәһәрләрдәге завод-фабрик эшчеләре үзара берләшеп, гомер-гомергә хезмәт халкын талап килгән патша һәм байлар хакимлеген туздырып ташлап, үзебезнең хакимлекне, эшче-крестьяннар хакимлеген урнаштырдылар. Аңлашылдымы?

— Надан дигәч тә син мине бөтенләй үк башсызга санама, малай! — диде агай, шактый ачулы итеп. — Боларын мин аның синнән башка да беләм: үз күз алдымда булган хәлләр! Җүнле бәндә булсаң, син миңа менә хәзер дөньяда нилəр барганын аңлатып бир. Әтү, панимаеш!..

— Ә син ашыкма, абзый кеше, сабыр ит чак кына. Аннары менә болай булды: безнең Рәсәйдә дәүләт хакимлеге эшче-крестьяннар кулына күчкәч, чит ил буржуйлары...— ә син буржуй дигән сүзнең мәгънәсен беләсеңме?.. Ярый, кызма, белсәң бик әйбәт! Әнә шул чит ил буржуйлары, үзләрендә дә революция килеп чыкмасын дип шыр җибәреп, барысы да берләшеп, безнең яшь совет дәүләте өстенә ябырылдылар. Ягъни безгә каршы сугыш ачтылар. Аларга революция көннәрендә чит илләргә чыгып сызган үзебезнең элеккеге байлар һәм буржуйлар да килеп кушылды. Менә шулар хәзер совет властен юкка чыгарып, яңадан иске тәртипләрне, яңадан үз хакимиятләрен кайтарырга маташалар. Ә без, большевиклар, эшче-крестьяннар белән берлектә, шул явыз көчләргә каршы көрәш алып барабыз! Я, ничек, төшенеп барасыңмы?

— Болары да аңлашыла. Үзем дә азрак чамалыйдырыем боларын. Син миңа менә шул нәрсәне ачык кына итеп әйтеп бир: кайсылары җиңеп чыгар икән суң аларның? Акларммы, әллә сез — кызылларммы? Вәт бит нәрсәдә хикмәт!

— Ни атлы син, агай?

— Элек Нуретдин ие, ә Гата хәзер Ябалак дип йөри.

— Нигә?

— Минем күз төнлә дә шәп күрә, шуңа.

— Зыян юк. Анысы аның кушамат кына. Ә үзеңнең чын исемең әйбәт икән: диннең нуры дигән сүз.

— Я, ярый, син мәсьәләне читкә алып китмә: кайсылары өстен булып чыгар икән бу аклар белән кызылларның?

— Син үзең ничек булыр дип уйлыйсың соң, Нуретдин абзый?

— Ничек дип уйларга да аптыраган инде. Сезнең ише сәвит яклылары килә дә, безгә иярегез, безнең эшебез хак, без җиңәбез, диләр. Сәвиткә каршылары әйтә, без генә дөрес юлдан барабыз, безгә иярегез, безнең белән барсагыз гына игелек күрерсез, ди. Бер карагандa, сезнеке хаклыдыр шикелле, икенче карасаң, тегеләрнеке дә дөрес булып чыгар сыман. Ә пука тегеләре дә, болары да керәстиян хисабыннан, аны талап көн күреп килә әле. Ахыры ни белән бетәр — анысын бер алла гына белә торгандыр.

— Бер ул гына түгел, без кызыллар җиңеп чыгачагын меңләгән, миллионлаган кешеләр белә, Нуретдин абзый. Шулай буласына чын күңелләреннән ышаналар! Һәм шул җиңү көнен якынайту өчен көрәшәләр! Синең шикелле әүле-тәүле булып, бүген кем көчлерәк булса, шуның җырын җырлап йөрүче кыйбласыз адәмнәр дә бар барын. Әмма, бәхеткә каршы, андый аумакайлар күп түгел.

— Син, давай, мине алай кыйбласызлар чутына тыкма, парин! Пука мин берегезнең җырын да җырламыйм әле. Иманым шаһит, шушы көнгәчә нә сезгә, нә тегеләргә кушылганым юк!

— Ничек алай була инде ул? Гата җырын җырлап йөрисең бит син!

— Тучны! Әйе, Гата белән йөрим. Ну бит Гата шулай ук берегез яклы да түгел! «Карап карыйк, кайсылары өстен чыгар, шуннан ары кай якка кушылырга икәнен күз күрер,— ди ул.— Ә хәзер ничу безгә алар белән буталып йөрергә. Без үз кәсебебезне белик тә, иплән кенә, дөньяда яшәүнең кадерен белеп кенә яши бирик, — ди. — Кеше үтермибез, кан коймыйбыз, ярлы керәстиян малына кагылмыйбыз. Байларныкын урлап кына көн күрәбез ич», — ди.

Миңнулла тегенә ни дип җавап бирергә дә белмичә аптырап калды. Гатаны һәм аңа ияреп йөрүче менә шушы Нуретдин агайны ул гап-гади ат караклары гына дип уйлый иде. Ә аларның, әнә, үз фәлсәфәләре, дөнья хәлләренә үз карашлары бар икән ләбаса! Үзләрен юлбасарлар итеп түгел, гадел, әйбәт кешеләргә саный икән бит алар!..

— Караклык теләсә кайчан караклык булып кала инде, Нуретдин абзый! — диде Миңнулла, шуннан да шәбрәк җавап таба алмыйча.

Болай да тын алырга да куркып, бер авыз сүз дә дәшмичә килгән Заһит абый, Миңнулла тегеңә әнә шулай дип әйткәч, бөтенләй елар чиккә җитеп:

— Җитеп торыр мәллә инде сиңа, олан! — диде.

Ләкин аның бу кисәтүе Нуретдин агайга ошамады:

— Тик кенә тор, надан! Үз акылың юк икән, ичмаса, акыллы кешеләрнең сүзен тыңлый бел! — Аннары Миңнуллага мөрәҗәгать итеп: — Алай дип карасак, сезнең сәвит блачыгыз да шулай ук карак булып чыга түгелме сун, парин? — диде.

— Ничек алай булып чыга икән ул, Нуретдин абзый, аңлатып бирә алмассыңмы?

— Ничекме? Ә менә ничек: сез талап кына калмадыгыз, байларның үзләрен дә Себергә сөрдегез лабаса! Хәлбуки, без байларның үзләренә беркайчан да кагылмадык. И һәм кагылмабыз да! Артык малларын гына урлыйбыз без аларның.

— Син, Нуретдин абзый, кармак белән бармакны бутама! Беренчедән, без революцияне сезнең кебек төнлә, кача-поса түгел, бәлки көпә-көндез, ачыктан-ачык ясадык. Бөтен ярлы халык белән бергәләп ясадык. Икенчедән, байлардан тартып алынган җирләрне шул җирләрне эшкәртеп иген игә торган кешеләргә — крестьяннарга бүлеп бирдек. Завод-фабрикаларны бөтен халык милкенә, дәүләт милкенә әйләндердек.

— Ә без ул урлаган малларны кая куя дип беләсең син? Без дә аларны шул ук крестиянгә сатабыз лабаса!

— Менә шулай шул — сатасыз!

— Суң бөтенләй үк бушка биреп булмый бит инде! Безнең дә тамак бар, безнең дә хатыннар, бала-чагалар бар, аларны туйдырырга кирәктер бит!

— Юк, Нуретдин абзый, юлбасарлык дигән нәрсә, кай ягыннан гына килеп карасаң да, юлбасарлык булып кала инде ул. Юньле юлда йөрмисең син. Ул Чегән Гатага ияреп, менә шушылай аның уң кулы булып йөрүеңне алга таба дәвам иттерсәң — башың харап булачак синең!

Миңнулла кыек атып туры тидерде булса кирәк: Нуретдин агай исе китеп аңа карап куйды:

— Ә кем әйтте әле сиңа мин аның уң кулы дип?

— Кеше әйтмичә дә бик әйбәт күренеп тора!

— Кит аннан?

— Бер дә китәсе юк, дөресе шулай!

— Һы, һы-һы!..

Нуретдин абзый әнә шулай дип куйды да, тынып калып, нидер уйланып бара башлады.

— Карале, Нуретдин агай, муендагы бауны аз гына бушат әле, бөтенләй сулыш алыр хәл калмады бит монда, — диде Миңнулла, аның уен бүлеп.

— Шулаймы? Хәзер рәтлибез аны! — дип, Нуретдин абзый Миңнулланың муенындагы бауны бөтенләй чишеп үк алды. Аннары арба төбендәге печәнне җыеп, егетнең баш астына мендәр итеп куйды да: — Ничә яшьтә син, энем? — дип сорады.

— Быел унсигез тула.

— Икмәктер диген.

— Икмәктер шулай!

— Ә мин сиңа егерме бишләр тирәсе бардыр инде дип торадырыем.

— Шулай бик олы күренәммени?

— Шулай олы күренәсең шул, наный. Хәер, яшь кенә башыңнан өяз тикле өяздә эшләп йөргәч, шулай булмый хәлең дә булмас. Ә син миңа ничәләр бардыр дип уйлыйсың?

— Илле бишләрдән дә ким түгелдер инде.

— Һи-һи-һи! Кырык икене дә тутырып житкерә алганы юк бу абзаның! Угрылык белән көн итү кешене еллап кына түгел, сәгатьләп картайта икән ул, олан! Әле моннан бер ел элек кенә янып торган егет шикелле кеше ием мин. Ә хәзер әнә син миңа илле бишне бирдең.

— Семьяң, бала-чагаларың бармы, Нуретдин абзый?

— Шушы яшькә житеп аларсыз буламы соң инде. Ике кыз, бер малай атасы инде мин.— Бераз уйланып барды да, тирән итеп көрсенеп дәвам итте: — Алтынчы ай китте инде үзләрен күргән юкка. Кешеләрдән сораштыргалап торам, болай исән-саулар үзләре. Акчага да ин-

тектермим. Таныш-белеш аркылы җибәреп киләм. Ну, менә үзләрен күрә алмыйм.

— Кайда соң алар?

— Барда ягында.

— Ә нигә кайтып күреп килмисең?

— Һы, ансат кына синә. Бар, кайтып күренеп кенә кара — хәзер тотып трибуналга озаталар да расхутка чыгаралар мине анда! Фронттан качкан кеше бит мин.

— Патша армиясеннән качкансыңдыр бит?

— Патша армиясеннән качкан булсам, уйлап та тормасыем мин!

— Шулай-мы-нипи! Үзебезнең армиядән качкан дезертирмыни әле син?

— Шулайрак булганые шул.

— Ник качкан идең соң?

— Ябь-яшь кенә көенчә үлеп каласы килмәде.

— Бу кәсебең дә сугыштагы шикелле ук куркыныч бит синең. Монысына йөрәгең житкән, ә?

— Ничек итеп булса да көн күрергә кирәк бит инде. Бүтән барыр җирең калмагач, шулай тәвәккәллисең икән аны.

— Алга таба ничек көн итәргә исәбең?

— Ул хакта уйлаган юк әле, бүгенгесе кыйбат.

— Уйланырга кирәк, Нуретдин абзый. Хәзер, дөньяның буталчык чагында гына болай иркен йөрисез сез. Акларны җиңеп илдә тәртип урнаштыргач, көн бетәчәк сезгә!

— Анысы шулаен шулай да бит, ну, ни эшлим? Ул көнгә калмас өчен кая барырга, ни кылырга кушасың син миңа?

— Хәзер безнең аяк-кулларны чиш тә, әйдә, китик бергәләп. Котыл шул Гата шайкасыннан.

— Хуш. Шуннан син мине кая аппармак буласың?

— Усыга.

— Һы, ансат кына икән! Анда мине рифкумга тапшырып, трибуналга озаттырасың киләмени?

— Ревкомга баруын барырбыз. Тик син трибуналдан курыкма. Трибуналга җибәрмәсләр. Мин барысын да аңлатып бирермен дә, хәлеңә керерләр. Аннары я фронтка озатырлар, яки Усының үзендә кызыл отрядчы итеп калдырырбыз.

— Карап-карап торам да, бик белгән атлы булып, «мин» дә «без» дип кенә сөйләнәсең син, малай актыгы! Кем суң син, берәр төрле нәчәнник мәллә анда?

— Өяз башкарма комитеты председателе урынбасары мин.

— Ышанмыйм!

Миңнулла Заһит абыйны күрсәтте:

— Менә бу агай раслый ала!

Нуретдин агай әле һаман куркуы бетмәгән Заһит абыйга борылды:

— Я, нишлим, ышаныйммы мин бу малайга, кордаш? Чыннан да өяз кәмитетендә эшлиме ул?

— Мин аның кайда эшләгәнен дә, кем икәнен дә белмим, — беренче күрүем бүген!

— Менә ишеттеңме инде! — диде Нуретдин агай, Миңнулланың «ялганын тотканга» кәефе килеп.

Заһит абыйның җавабына Миңнулла шаккатты. Ләкин аның белән бәхәскә кереп тормады. «Шулай әйтүне кирәк тапкандыр. Болай да минем аркада нужаланып йөри бит, бичара», дип фикер йөртте ул. Һәм тирә-якны тыныч кына күзәтеп бара башлады.

Сулда — юл буенда ук шактый текә тау. Тау бите — урманлык. Ләкин агачлары куе түгел. Аланлыклары күбрәк. Ә аланлыклар тап-такыр: печәннәре чабып алынган. Аннары көтү дә йөргән булса кирәк:

сыер «коймаклары» бик еш күренә. Бу таудан кыш көне чаңгы шуарга бик шәптер. Миңнуллаларның үз авыллары тирәсе тип-тигез, рәхәтләнеп чана-чаңгы шуарлык бер генә тау да юк. Шуңа тау күргән саен күңеле җилкенеп куя аның!.. Ә уң якта — бодай кыры. Урыны-урыны белән бәпкәләр дә күренә. Ура башлаган булганнар. Ләкин хәзер кырда бер адәм заты юк. Воскресенск җирләре инде бу. Воскресенск халкының да кайгысы уракта түгел булса кирәк. Хәер, нинди урак кайгысы булсын ди: Чегән Гата, әнә, Барсай ир-атларын да Воскресенскига куып калды бит әле анда. Тикмәгә йөрми торгандыр инде. Тукта, бәлки бу агай да белә торгандыр андагы хәлләрне.

— Нуретдин абзый, тагын шул Гата хакында сорыйм әле: Барсай мужикларын нигә Воскресенскига апкилмәкче ул?

— Нәрсә дидең әле син, малай?

Ниндидер үз уена чумып бара торган Нуретдин абзый Миңнулланың соравын абайламыйчарак калган иде. Миңнулла соравын кабатларга мәҗбүр булды.

— Ә-ә-ә-ә, син аны әйтәсең икән! — диде теге, ниһаять, уйларыннан аерылып.— Васкрисинскидә акларның бер звуд солдаты килеп урнашкан бугай. Әмма ләкин узвуд командиры кызыллардан шикләнә икән. Ни өчен дисәң, бу тирәләрдә ниндидер Колчин дигән бер кеше зур гына кызыл әтрәт оештырган, ди. Көтмәгәндә килеп чыгып, шуның әтрәте акларга күп зыян китереп тора икән. Бүгендә-таңында ул әтрәт Васкрисинскигә дә һөҗүм итүе ихтимал, имеш. Шул әтрәткә каршы тору өчен тегеләр күрше авыллардан ир-атларны җыйнарга булганнар бугай. Тәгаене шулайдырмы — кырт кистереп кенә әйтә алмыйм. Ни өчен дисәң, тегеләрнең камандиры Гатаулла белән сөйләшкәнен мин читтән генә тыңлап тордым. Ну, ишетелгән сүзләреннән әнә шул сиңа әйткәнчәрәк аңладым.

— Син русча язу таныйсыңмы, Нуретдин абзый?

— Китапча хәрефе белән язылганны гына аз-маз браматлыйм, әмма кулдан язылганны — булмый!

— Алайса, менә минем күкрәк кесәсендәге язуны ал әле!.. Инде шуның китап хәрефләре белән язылган җирен укып кара!

Нуретдин абзый барган уңайга гына укый башламакчы иде, арба дыңгырдаганга хәрефләр сикерә башлагач, атны туктатып торырга мәҗбүр булды.

— Тәк! — диде ул, Миңнуллага Усы өяз башкарма комитеты тарафыннан бирелгән белешмәне шактый зур азап белән укып чыккач. — Карале, син, малай актыгы, чынлап та өяздә зур урында эшлисең, ахры, ә?

— Әйттем бит инде мин сиңа өяз башкарма комитеты председателе урынбасары дип!

— Мине коткарып кала алам дип ихлас әйтәсеңме син, наный? Чынлап та мине трибуналдан саклап калырлык кодрәтең бармы?

— Сине алдап ни файда миңа? Әйдә, бор атны читкә дә, Гата килеп җиткәләгәнче, китик кереп урман эченә!

— Адашмабызмы соң? Усыга исән-имин генә барып житә алырбызмы?

— Курыкма, күземне бәйләсәләр дә, адашмыйм мин бу тирәләрдә.

— Ярый, энекәш, аллага тапшырып тәвәккәлләдек, алайса. Гата Чегән әйтмешли, беткән баш — беткән, муен калса — житкән, әйдәле, алаша! Әнә, какрас, тауның да сизгрәк җиренә җиткән икәнбез...

Урманга борылып, алар инде берәр җир бүе чамасы китәргә дә өлгергәннәр иде. Ләкин шуннан артыгын булдыра алмадылар. Башта ату тавышы ишетелде, аннары әлеге ике ярдәмчесе белән Гата үзе куып җитте.

— Кая олагыргае ниятең, Ябалак?! — диде ул, Нуретдин абзыйга бик хәтәр җикеренеп.

— Мин килеп житмәсәм, көтеп тор дип үзең әйткәниең түгелме сун, Гатаулла? — диде тегесе, бер дә алай аптырап тормыйча. — Кешекара күз алдында торганчы, ышыккарак кереп көтеп тору хәерлерәк булыр дигәнием.

— Шулай дисәң генә инде, — диде Гата, шундук йомшый төшеп. Аннары Миңнуллага ымлады: — Бу денен саткан нәмәрсә ничек, тыпырчынмыймы?

— Кая анда тыпырчыну! Син аның муенын шундый итеп кысып бәйләгән — җан тәслим кыла язды, бичара. Бавын чишеп, баш астына печән салып кына коткарып калдым үзен.

— Яраган. Әйбәт иткәнсең анысын. Безгә аны тере килеш илтеп тапшырырга кирәк, әҗерен зуррак итеп бирерләр.

— Карале, Гатаулла, сорарга да онытып торам икән: син бит Барсайдан халык җыйнап апкилмәк булып калганыең, кая суң ул халык?

— Анналарын сатасы бар ул Барсай мужикларының! — диде Гата, әрем капкандай чыраен сытып. — Шул җыелып торган чакларында барысын сөреп кенә алып киләсе калган икән аны! Таралдылар да, ярыкка кереп качкан тараканнар шикелле, юкка да чыктылар. Ник берсе әйләнеп килсен, ичмаса! Ну, ничава, анда Сәйфи бай малае Шакир унлап солдат ияртеп кайткан, ди. Мин анда әлеге Чирканды мулласы малае Хәйруллага шуның янына барып, Воскрисинскидәге хәлне аңлатып бирергә әйтеп калдырдым. Бик отчайный нәрсә ул Шакир дигәннәре. Бәлки ул берәр әмәлен табар әле.

## 4

Воскресенск урамы халык белән шыгрым тулы иде. Солдатлар да күп, гражданскийлар тагын да күбрәк. Русы, татары, ире-хатыны, хәтта бала-чагаларына тикле шунда кайнаша. Әйтерсең кырмыска оясын кемдер туздырган да шуның кырмыскалары өскә чыккан! Воскресенскиның үзендә генә бу тикле кеше булырга тиеш түгел иде. Мөгаен, бүтән авыллардан да килгәннәрдер. Солдатларның барысы да диярлек сугыш мылтыгы аскан. Ә гражданскийларның кораллары бик чуар: ау мылтыгыннан башлап, кылыч, сөңге, сәнәк, багор һәм гап-гади күсәк тотканнарына кадәр бар. «Ак бандитларга ияргән фетнәчеләр икән инде болар,— дип уйлап куйды Миңнулла.— Әгәр Гата атларны туктата калса, мөгаен, шушында безнең башка җитә инде бу тилергән халык!»

Ләкин Гата урамда тукталып тормады. Туктатырга теләп, Миңнулларның ат башыннан тотарга үрелә башлаган кешеләргә дә:

— А нука, брысь! — дип, тегеләрне атының күкрәге белән читкә кактырып, юл ярып барды.

Миңнуллаларны чиркәү каршындагы ике катлы өй каршына китереп туктаттылар. Шундук атыннан сикереп төшеп, Гата өйгә кереп китте. Ә Нуретдин абзый Миңнуллага борылып карады да, Гатаның җайдаклары ишетмәсен өчен акрын гына:

— Ярар, наный, аллага тапшырдык инде. Без дигәнчә барып чыкмады шул! — диде.

— Алданрак тәвәккәлли алмадың бит!

— Документыңны баштарак күрсәтмәдең ич.

Дүрт солдат ияртеп, өйдән бер офицер чыкты. Ул иң элек, каршына ук килеп, күзенә керердәй булып, Миңнуллага, аннары Заһит абыйга текәлеп карап торды да:

— С прибытием вас, голубчики! — дип мыскыллап көлеп куйды. Аннары солдатларына ишарә итте: — А ну-с, принимайтека-с как следует!

Тегеләрнең икесе Миңнулланы, икесе Заһит абыйны арбадан алып аттылар да, кул-аякларын чишеп, типкәли-типкәли ихатага алып кереп, караңгы таш сарайга яптылар.

Солдатлар төртеп җибәргәндә таш стенага бәрелеп, Миңнулланың яңагы сыдырылган да кан ага башлаган иде. Тиз генә кулъяулыгын алып, шул сыдырылган төшенә басты. Ә Заһит абзыйга тагын да катырак эләккән булса кирәк, бик нык ыңгырашып, ул һаман идәндә ята иде. Миңнулла аның янына килеп чүгәләде:

— Хәлең ничек, Заһит абый?

— Миңнулла-а-а, синме? — диде Заһит абзый, ыңгырашуын дәвам итеп.

— Мин, Заһит абзый. Хәлең ничек дим?

— Ни ачуың бар иде миндә? Нигә дип үтерергә алып чыктың мине, ә?

— Болай буласын белсәм, сине алып чыгу түгел, үзем дә Барсай ягына аяк атламаган булыр идем дә бит, нишлим соң, белмәдем, Заһит абый!

— Әйтмәдеммени мин сиңа, әллә сабыр итеп торыйкмы дип?

— Хәзер үкенүдән файда юк, буласы эш — булган инде. Нигә бик ыңгырашасың, әллә берәр җиреңне сындырдылар укмы?

— Тән авыртканга түгел, җан авыртканга сыкранам! Тотып атсалар, хатын нишли инде анда минем? Балалар нишләр?

Бу бандитлар кулына бер килеп капкач, исән котылуларына ышанычы бик аз булса да, Миңнулла аны юатырга тырышты:

— Кайгырма, Заһит абый! Менә күрерсең, тикшерерләр-сорашырлар да бүген үк кайтарып җибәрерләр әле. Мине тоткарласалар да, сине җибәрерләр. Синең белән нишләсен алар?

Заһит агай яткан җиреннән торып ук утырды. Өмет тулы карашын Миңнуллага төбәде:

— Чынлап та исән калырбыз дисеңме, олан?

— Ул хакта шикләнмә дә, Заһит абый! Бая Нуретдин абзый әйткәнне ишеттең ич: безнекеләр шушы Воскресенскига таба килә, диде бит ул. Бәлки бүген төнлә үк килеп җитеп коткарырлар әле!

— Рәхмәт, туган, яхшы сүзеңә! Фәрештәнең амин дигән сәгатьләренә туры килә күрсение инде берүк! Шушы тоткыннан исән-имин котыла алсам, корбан бәйрәмендә танамны суеп, бөтен авыл халкын корбан ашына дәшәрием, аллаһы бирса! Колһуаллаһы әхәдеаллаһы сама-а-ады, ямиәлиде...

Емельян Петрович Миңнуллага, ярлылар комитетларына ярдәм итәргә кирәк булуы мөмкин дип, шактый зур сумма акча бирдертеп җибәргән иде. Ул акчаларны Миңнулла, хәвефсезрәк булсын дип, аякчуына урап, итек куныччына тыккан иде. Заһит абзый җаны-тәне белән бирелеп әлеге «Аятел көрси»не укый башлагач, Миңнулла әнә шул акчаларны хәтерләде һәм: «Боларны моннан барыбер табып алачаклар. Бандитлар кулына эләккәнче, ичмаса, шушында ятсыннар», дип, ул акчаларны сарайның стена ташлары арасына кыстырып куйды.

Тәрәзәсе берәү генә, ул да кечкенә булганлыктан, сарай эче ярым караңгы иде. Шуның өстенә, Заһит абый мөкиббән китеп укынып та утыргач, Миңнулла аны берни дә сизми калды дип уйлаган иде. Ләкин агаебыз алай ул гамьсез булмаган, Миңнуллага да күз салып торган икән. Догаларын укып, теләкләрен теләп бетергәннән ары Миңнулла утырган улак буена килде дә:

— Нәрсә кыстырдың син анда, олан? Акчамы? — диде. Һәм Миңнулланың җавап биргәнен дә көтмичә: — Мә, минекен дә кыстыр шунда үзеңнеке янына, теге кяферләр кулына калып әрәм булмасын! — дип, өч тәңкәлек акча суздЫ.

Бу заман өчен өч тәңкә акча чүп кенә иде, әлбәттә. Ләкин Миңнулла ул хакта сүз озайтып тормады.

— Бик дөрес әйтәсең, Заһит абый! Монда булса беркая да китмәс алар. Шайтаннан яралган шушы акларны җиңгәч, минекен дә, үзеңнекен дә килеп алырсың, ярыймы! — дип, тегенең өчлеген дә үзенең документлары янына кыстырып куйды.

Кеше ишетеп тормыймы дигән сыман итеп, Заһит абый башта як-ягына каранып алды, аннары Миңнулланың колагына пышылдады:

— Синеке ничә тәңкә соң, олан?

«Кара инде син бу адәм баласын, үлем бусагасында басып торганда да һаман акча белән кызыксына бит!» дип, күңеленнән бик нык гаҗәпләнсә дә, Заһит абыйга бу уйларын сиздермәскә, тегенең гайрәтен чигермәскә булды Миңнулла.

— Җитәрлек, Заһит абый. Синеке шикелле ике ат алырлык бар!

Заһит абыйның күзләре шундый ялтырап куйды — сарай эчләре яктырып киткәндәй булды.

— Чыннан әйтәсеңме син моны? И шул акчаны миңа бирмәк буласыңмы?!

— Мин беркайчан да яхшы кешеләргә ялган сүз сөйләмим, Заһит абый!

— Әй, рәхмәтле җан! Бар бит агай ходайның изге бәндәләре! Рәхмәт, Миңнулла, мең яшә, олан!

— Әйт әле, Заһит абый: бая теге безне монда алып килгән Нуретдин агайга нигә мине белмим дидең? Әгәр син шул чакта дөресен әйтеп, минем сүзне раслаган булсаң — без хәзер менә бу таш сарайда ятасы кешеләр түгел идек. Иректә буласы идек без хәзер.

— Әй, наный, искә төшермә, ичмаса, шул ахмаклыкны! Ник алдаштыммы? Надан булганга, баш җитмәгәнгә инде! Теге адәм барыбер безнең белән качып китәргә риза булмый, янәсе. Ә минем синең белән бергә йөри торган кеше икәнемне белсәләр, мине дә тотып ябулары ихтимал. Ә белмәдем-күрмәдем дип барсам, атымны биреп торган өчен рәхмәт әйтәләр дә кайтарып җибәрәләр, имеш. Ну, тинтәк тә булган инде үзем дә! Ә алар, кем син, нишләп йөрисең дип сорап та тормадылар, арт якка дыңк иттереп тибеп, яптылар да куйдылар. Һей, болай буласын белгән булсам! Алдашып торган булырыеммы, җүләр!..

— Ашыкма, сорарлар әле, Заһит абый. Җиде бабаңнан алып, җиде әбиеңә тикле сорашырлар. Син инде шул сүзеңнән кайтма, ничек кенә талкысалар да, син мине белмисең дә, моңа кадәр күргәнең дә булмаган.

— Шулай итимме, әллә сине белүемне, синең олаучың булып килгәнемне әйтеп, дөресен сөйләп бирим микән, наный? Ни өчен дисәң, карга карганың күзен чукымый, мужыт, тегеләрнең нәчәнниге синең дә нәчәнник икәнеңне белгәч, хәленә керер дә, тоткынлыктан азат итеп, кайтарып җибәрер. Менә шул чакта, синең аркада, мужыт, мин дә котылырмын дип әйтүем инде бу.

— Юк, Заһит абый, бу очракта алай булуы мөмкин түгел. Икебез дә карга булсак, әлбәттә, ул мине чукымас иде. Ләкин мин карга түгел, мин бөркет бит. Син дә бөркет. Тоткында булсак та, икебез дә бөркет без синең белән. Ә ул — карга. Һәм ул карга без-бөркетләрне беркайчан да аңлый алмаячак. Шулай булгач, сиңа мине белмим дип барудан да хәерлесе булмас. Югыйсә...

Тышкы якта, ишек тирәсендә ачкычлар чылтыраганы ишетелде.

— Кемдер керә, ахрысы, тагын безне кыйнарга микән? — диде Заһит абый. Һәм, качып котылырга теләгәндәй, сарайның караңгы почмагына сыенды.

Ишек авызында кулына мылтык тоткан табак битле, курнос бо-

рынлы, бая Миңнулланың яңагын ерттырган солдат пәйда булды. Аның мичкәдән чыккандай калын, котсыз тавышы яңгырады:

— А ну, красные татары, вылазь!

Әсирләрне өйнең бер бүлмәсенә алып керделәр. Нечкә кара мыеклы, чандыр гәүдәле, күкрәгенә Георгий тәресе таккан офицер кукраеп өстәл янында утырган килеш кенә Миңнулладан сорау ала башлады. Исем-фамилиясен сорады. Миңнулла әйткәч, өстәлендә яткан кәгазьгә карап алды. Күрәсең, Миңнулланы белә торган берәр кешедән сорашып, язып куйган булгандыр да хәзер алдашмый микән дип каравы булгандыр.

— Туган елың? — диде аннары офицер.

— Тугыз йөзенче.

Офицер иңбашларын сикертеп куйды:

— Мин шаярганны яратмыйм, Гайсин.

— Ә минем шаярырга җыенганым да юк. Нигә алай шиккә калдыгыз әле?

— Бик яшь икәнсең бит.

— Хикмәт яшьтә түгел, башта!

— Кара син нинди кыю икәнсең! Туган урының?

— Усы өязенең Карый авылы.

Ул тагын кәгазенә күз салып алды.

— Так! Хәзер кайда һәм кем булып эшлисең?

— Усыда. Өяз башкарма комитеты председателе урынбасары.

Офицер янә теге кәгазенә күз төшереп алды һәм аның чырае яктырып китте — мөгаен, үзендәге мәгълүматлар белән Миңнулла биргән җаваплар туры килә иде булса кирәк. Ләкин офицер үзенең канәгатьлеген сиздерергә теләмәде, тагын элеккечә бик җитди булырга тырышып, сорау алуын дәвам итте:

— Барсайга ни өчен килгән идең?

— Эш белән.

— Мин дә уйнап йөргән булгандыр дип уйламыйм. Нинди эш белән дип сорыйм мин синнән?!

— Кызлар күзләп кайтырга иде исәп.

— Димәк, әйтергә теләмисең? Яхшы. Соңыннан әйтерсең. Безнең түземлек җитәрлек, көтеп тә тора алырбыз.

Аннары ишек төбендә торган сакчыга боерды:

— Тегеләрне алып кер әле, Мирон.

Барысын да ишетеп, көтеп үк торганнар иде, ахры, сакчы ишекне ачып дәшүгә, Гата белән Хәйрулла кереп тә җиттеләр.

Офицер, бармак изәп, Гатаны үзенә якынрак китерде дә Миңнулладан сорады:

— Таныйсыңмы бу кешене, Гайсин?

— Бер-ике тапкыр күргәнем бар.

— Кем ул?

— Ат карагы Гата. Кушаматы — Чегән.

— Нигә атып үтерә яздың син аны?

— Кызганычка каршы, язып кына калдым шул, үтереп булмады.

«Ишеттеңме?» дигәнне аңлатып, офицер Гатага карап алды. Гата ачуыннан «и-и-их!» дип акырып җибәрде дә Миңнуллага ташланмакчы иде, ләкин офицер, сикереп кубып, «стоп, не горячись!» дигәч, тыелып калырга мәҗбүр булды.

Аннары офицер Миңнулланың каршына ук килеп басты да:

— Ә син ошыйсың миңа, разбойник! — диде.

— Разбойниктан ишетәм!

— Булды, Гайсин, әйдә, җитди сөйләшүгә күчик. Карый отрядында бүгенге көндә ничә кызылгвардиячегез бар?

— Өч йөзгә якын.

— Төгәлрәк итеп әйтә алмыйсыңмы?
— Ике йөз илле тугыз.
— Кораллары нинди һәм күпме?
— Барысында да сугыш мылтыгы. Биш пулеметлары бар.
Офицерның күзләре шар булды:
— Каян килгән аларга ул пулеметлар?
— Дутов гаскәреннән качкан пулеметчылар алып кайткан.
— Ялганлыйсың бит, кызыл эт!
— Минем этнең кызылын очратканым юк әле, ә ак этләр тулып ята!
— Молчать! Телеңне артык озайта башласаң, маңгаеңа пуля җибәрергә дә күп алмам мин!
— Җибәреп кенә карагыз. Мине атсагыз, сезне безнекеләр ике көн дә яшәтмәячәк!
— Ә кемнәр соң ул «без-не-ке-ләр?» Кайда алар?!
— Адым саен. Тик алар сез аклар шикелле бугаз киереп, шаулап йөрми, эш эшлиләр!
— Минем нервлар нык, Гайсин! — диде офицер, тешләрен кысып. — Ну, кара аны, һәрнәрсәнең бер чиге була, шул чиккә китереп җиткермә мине! Әйт әле: соңгы мәртәбә Ашапта кайчан булдың?
— Өченче көн.
— Анда ник барган идең?
— Ашап отрядына өяздән корал илттек.
— Күпме һәм нинди кораллар?
— Ике йөз утыз бер сугыш мылтыгы, сигез йөз «кыяр», өч пулемет.
— Ашап отрядында ничә кеше?
— Дүрт йөз җитмеш өч. Бөтенесендә ау сугыш мылтыгы. Өч пулеметлары бар. Шуның өстенә, бер рота солдат та килергә тиеш иде. Ихтимал, инде килеп тә җиткәннәрдер.
Офицер, пошаманга калып, ишекле-түрле йөренгәләп алды. Аннары Гатага мөрәҗәгать итеп:
— Ишетәсеңме, Чегән? — диде. — Ничек уйлыйсың, ышанырга буламы моңа?
Бая Миңнуллага ыргылганда үзен тоткарлаганы өчен, офицерга бик нык хәтере калган иде Гатаның. Шуңа тегеңә теләр-теләмәс кенә җавап бирде.
— Мин берни дә әйтә алмыйм: бу араларда ул тирәләрдә булганым булмады.
— Мин синнән Ашапта кайчан булдың дип түгел, әсир әйткән сүзләргә ышанырга буламы дип сорыйм!
— Анысы инде үз ихтыярыгыз, гаспадин афитсир. Ә мин үзем күрмәгән, үзем белмәгән нәрсә хакында берни дә әйтә алмыйм.
— Яхшы. Алайса, күреп-белеп кайтырга кирәк булыр. Бар, хәзер үк чарасына кереш. Иртәгә, иртәнге сигездән дә соңга калмыйча, Ашап отряды турында төгәл мәгълүматлар әзер булсын!
— Ә күпме түлисең?
— Курыкма, ким-хур итмәм. Бар, юлыңда бул!
«Менә ул нинди икән! — дип уйлап калды Миңнулла. — Ат карагы гына түгел, шымчылык белән дә шөгыльләнә икән бит бу адәм актыгы!»
Гата чыгып киткәч, моңарчы акыллы песи генә булып утырган җиреннән кылкынып, Хәйрулла да:
— Олег Васильевич, можно мне кое-что уточнить? — дип, телгә килә башлаган иде, ләкин тегесе аңа тик торырга ишарә ясады. Тере мәет булып бер читкә поскан Заһит абый каршына килеп басты да:
— Әйдә, мужик, инде синең белән гәпләшеп алыйк! — диде.
— Мин урыйча белмим шул, энакум, — диде теге бичара, бер Миңнуллага, бер офицерга тилмереп карап.

— Он, Олег Васильевич, говорит, что по-русски не понимает [1], — диде Хәйрулла, кыштанланырга ашыгып.

— Ну вот и переведите ему мои слова [2].

Хәйрулла әсәрләнеп, торып ук басты һәм Заһит абыйның борын төбенә килеп:

— Сөйләшеп алыйк, ди ул сиңа! — диде.

— Ә-ә-ә! Шулай димени? Сөйләшергә булыр анысы, нигә булмасын ди.

— Он говорит, что готов с вами беседовать [3]...

— Спроси у него: откуда он, кто и что может сказать по поводу красных отрядов [4].

Ләкин Заһит агаебыз офицер теләгән әнгәмәче булып чыкмады. Исем-фамилиясен һәм югалган сыерын эзләп йөрүен генә әйтте дә тегенең барлык сорауларына да «белмим» дип кенә барды. Заһит абыйны кара тиргә батырганчы тинтерәтеп тә бернинди юньле мәгълүмат ала алмагач, офицер Хәйруллага:

— Ташла, барыбер рәт чыгачак түгел бу ахмактан! — дип кул селекте. Ләкин шул тикле тырышуының аз гына булса да әҗерен алып каласы килде булса кирәк: — Дурак! — дип, йодрыгы белән Заһит абыйның күкрәгенә төртте.

Заһит абый, бичара, «гыңк!» итеп артка мәтәлде һәм шул чакта аның башындагы бүреге белән түбәтәе төшеп китте. Түбәтәй кызыл эчле иде. Шуны күреп алгач, офицер күркә шикелле кызарып-кабарып чыкты:

— Ах, менә ничек. Татар кызылгвардиячесе икәнсең бит син, идиот! Шулай диде дә түбәтәен алырга дип иелгән Заһит абыйны тибеп екты. Заманында бик шәп булган, әмма хәзер беләүләнеп беткән кызыл сатин эчле түбәтәйне офицер үзе иелеп алды. — Кара син аны, нинди пароль уйлап чыгарганнар! Карале син аны... — дип сөйләнә-сөйләнә, түбәтәйне әйләндергәләп карады да өстәленә куеп, Миңнулла янына килде: — Ну-ка, синеке дә шундыймы? — дип, аның да башындагы күн фуражкасын салдырып карамакчы иде. Миңнулла ирек бирмәде. Фуражкасын үзе салды да, ачу белән:

— Мә, кара! — дип тегеңә сузды. Офицер фуражка эченнән Миңнулланың булмаган түбәтәен эзли башлады, ә Миңнулла сүзен дәвам итте: — Унбиш ел элек тегелгән инде ул агайның түбәтәе. Һәм аның кызылгвардиячеләргә бернинди мөнәсәбәте дә юк!

Ләкин офицер аның ул сүзләрен ишетмәгәнгә салышты. Түбәтәе булмаганга җене чыгып, Миңнулланың фуражкасын ертып ук ыргытты. Аннары ишек төбендә торган сакчыга әсирләрнең кесәләрендәге әйберләрен алырга боерды.

Заһит абзыйның кесәсеннән ипи валчыгы да чыкмады. Миңнулланың Зәйнәпкә бүләк итәргә дип әзерләп куйган алтын йөзеген, Барсайда үзен күрергә туры килмәсә, берәрсе аркылы калдырып китәрмен дип Зәйнәпкә язган хатын һәм армиядә хезмәт иткән чагында Гәрәй абый бүләк итеп биргән кесә сәгатен алдылар.

Аннары, ниһаять, кайчаннан бирле нәрсәдер әйтергә кыжрап утырган Хәйруллага чират житте:

— Ә хәзер, Хәйрулла Хәйретдинович, сез әйтеп карагыз инде: Карый һәм Ашап отрядларында күпмешәр кеше һәм аларның күпмешәр кораллары бар? — диде офицер, өстәл янына барып утырып.

— Мин нәкъ менә шул турыда әйтергә теләгән идем дә инде, — диде Хәйрулла, кош тоткандай куанып. — Гайсин әйткәннәрнең берсе

---

[1] Ул, Олег Васильевич, русча белмим дип әйтә.

[2] Алайса, аңа минем сүзләрне тәрҗемә итегез.

[3] Ул әйтә, сезнең белән гәпләшергә әзермен, ди.

[4] Сора аннан: кайдан ул, кем һәм кызыл отрядлар хакында нәрсә әйтә ала.

дә дөрес түгел, Олег Васильевич. Карый отрядында ике йөз илле тугыз түгел, нибары егерме тугыз кеше. Шуларның нибары унберендә генә сугыш мылтыгы бар, бүтәннәрендә ау мылтыгы. Аларының да яртысы берәр көпшәле генә әле. Ә пулемет дигән нәрсә аларның төшенә дә кергәне юк!

— Ишетәсеңме, Гайсин? — диде офицер, канәгать елмаеп.

Хәйрулла әйткәннәрнең барысы дөрес иде. «Тәки аклар агенты икән бу, кабахәт!» — дип уйлап алды Миңнулла. Ә офицерга:

— Ишетәм, ләкин ул моннан ярты ел элек булган хәлләр хакында сөйли! — дип җавап бирде.

— Ну, сез нәрсә әйтерсез, Хәйрулла Хәйретдинович?

— Ышанмагыз, Олег Васильевич, Карыйда мин нибары дүрт көн элек кенә булдым, — дип чәрелдәде теге.

— Ә мин әле кичә генә шунда идем! — диде Миңнулла, һич тә бирешергә теләмичә. — Хәзерге заманда өч көн эчендә әллә нинди үзгәрешләр булырга мөмкин.

Офицер икеләнебрәк калды. Ләкин артык исе китмәгән атлы булырга тырышып:

— Дәвам итегез, Хайретдиныч! Ашапта эшләр ничегрәк тора? — диде.

— Ашаптамы? Ашапта да хәлләр ул әйткәнгә якын да килми. Нибары җитмеш өч кенә кеше аларның отрядында. Бер рота түгел, бер солдат та юк анда. Пулеметлары шулай ук юк. Җитмеш өч кешегә утыз җиде мылтыклары бар, шуларының да күбесе ау мылтыклары гына!

Хәйрулла биргән мәгълүматлар бу юлы да дөрес иде. «Китаптан карап укыймыни, кара син аны, ничек барысын белеп-ятлап алган, кабахәт! — дип уйлады Миңнулла һәм һаман үз сүзен куәтләп:

— Сафсата! — дип кычкырды. — Мин Ашаптан бүген иртән генә чыккан кеше — барысы да нәкъ мин әйткәнчә андагы хәлләр!

Офицер кем фикеренә күбрәк ышангандыр — анык кына итеп әйтүе кыен. Тик шунысы бәхәссез: ул шактый аптырашта калган иде. Әмма бүтән төпченеп тормады. Икенче бүлмәдән аюдай таза бер солдатны дәшеп чыгарды да, Миңнулланы күрсәтеп:

— Менә бу «кунак»ны Богородскига штабка илтергә кирәк. Тиешенчә «сыйлап» озатыгыз. Ләкин кисәтеп куям: «сый» эзләре күренеп торырга тиеш түгел! Теге чактагы шикелле, Николай Харитонович тавыш куптарырлык булмасын! — диде.

— Будделыны, вашесокородие! — дип, солдат Миңнулланы ишегалдына алып чыгып бастырды да: — Менә болай килешәбез, парин: хәзер мин сиңа берне сугам, шунда егылып китмичә түзеп кала алсаң, бүтән кагылмыйм. Әгәр егылсаң, — үпкәләмә, тагын кабатларга туры киләчәк! — диде. Һәм кизәнеп тә тормастан, утын тукмагы кадәрле йодрыгы белән китереп тә орды.

Үпкә-бавырлары өзелеп киткәндәй булды Миңнулланың. Әмма түзде — егылмыйча калды.

— Вот-эт-та да! — диде солдат, күңеле булып. — Менә монысы шәп! Күпме кеше арасыннан мин сукканда аягында калучысы син тик икенче кеше! Әгәр минем ихтыярымда булсаң, каһәрләнеп китим, менә шушы минутта ук өеңә кайтарып җибәрер идем мин сине. Ну, ни хәл итмәк кирәк, безнең Олег Васильевич ул эшкә бара торган кеше түгел шул.

## 5

Миңнулланы Богородск авылына алып бардылар да тикшерү комиссиясе карамагына тапшырдылар. Комиссия элек волость идарәсе булган таш йортның бер бүлмәсендә урнашкан иде. Комиссия пред-

седателе — куе кара сакаллы, гражданский киемдәге кеше — Миңнулланы алып килгән солдатларның берсе (аны монда ике солдат китергән иде) биргән пакетны ачып укыгач, кәефе килеп, үзалдына елмаеп куйды. Аннары шул пакет эчендә килгән, Зәйнәпкә дип язылган хатны тотып, Миңнулла каршына килеп басты:

— Сезнекеме бу, Гайсин әфәнде?

— Әйе.

— Рәхим итегез.

— Рәхмәт, — диде Миңнулла, хатны алып. — Ләкин минем бүтән әйберләрем дә бар иде.

— Нәрсәләр иде, мәсәлән?

— Кесә сәгате белән алтын йөзек.

Сакал пакетны алып килгән солдатка шундый итеп карады — теге куырылып калды.

— Җир йотсын, без алмадык, ваше скородие! — диде ул, үрә катып һәм честь биреп.

— Алайса, кайт та командирыңа әйт: Гайсин әфәндедән сәгате белән балдагын бүген үк китереп җиткергән булсын!

— Слушаюсь, ваше скородие! — диде солдат һәм, өреп очыргандай, юкка чыкты.

Сакал өстәл янына барып утырды. Папирос кабызды:

— Ә хәзер, Гайсин әфәнде, менә монда өстәл янына килеп утырыгыз да ачыктан-ачык сөйләшүгә күчик.

— Мондый шартта андый сөйләшү була микән?

Сакал елмайгандай итте:

— Замечаниегез урынлы. Ләкин сез үзегезне әсир итеп түгел, ә минем коллегам дип хис итегез.

— Бу — мөмкин түгел. Коллегалар — бер төрле һөнәр ияләре, ә безнең һөнәрләребез — капма-каршы.

— Бу замечаниегез белән дә килешәм. Ну, алайса, мине үзегезнең иң якын кешегез дип уйлагыз.

— Якын кешеләр бер-берен яхшы белергә тиеш. Ә мин сезне беренче күрәм.

— Сез хаклы. Кичерегез, гаеп миндә. Таныш булыйк: Николай Харитоныч, — диде ул, кулын сузып. — Кошкарев. Тикшерү комиссиясе председателе.

— Гайсин, — диде Миңнулла да куын биреп. Аннары тегенең өстәлендә яткан донесениегә ымлады: — Ә калганнары сезгә инде билгеле.

— Анысы шулай. Ләкин безнең эштә кайбер формальностьларны сакларга туры килә.

Һәм ул әле донесениедә язылганга, әле Миңнуллага карый-карый, аның исемен дә, туган җирен дә, эш урынын да сорашып-тикшереп чыкты. Аннары Карый һәм Ашап отрядлары хакында төпченергә тотынды. Миңнулла аңа да нәкъ Воскресенскидагыча җавап бирде.

— Ә менә болары инде бөтенесе дә ялган! — диде Сакал, никадәр генә тыныч булырга теләсә дә, сабырлыгын җуя башлап. Күрше бүлмәнең ишеген ачты да кемгәдер: — Юрий Сергеич, рәхим итегез! — диде.

Ул дәшкән кеше килеп кергәч, Миңнулланың күз аллары караңгыланып китте. Чөнки ул кеше Миңнуллага таныш — Усы өязенең хәрби штабы члены Юрий Сергеевич Михайлов иде. Сабыр гына, акыллы гына күренгән, кырык бишләр тирәсендәге бу агай беркайчан да артыгын сөйләми, үзенә тапшырылган эшне һәр вакыт төп-төгәл үтәп бара торган иде. «Бу бичараны да эләктергәннәр икән», дип уйлап куйды Миңнулла. Ул арада Юрий Сергеевич та Миңнулланы таныды һәм:

— О-о-о-о-! Ково я ви-жу! Здравствуй, Миңнулла, здравствуй, дорогой! — дип килеп, кочаклап ук алды.

Михайловның авызыннан бик зәһәр аракы исе килә иде. Аның сүзләреннән бигрәк, Миңнулла әнә шунысына игътибар итте. Хикмәт шунда, әле күптән түгел генә өяз башкарма комитеты хезмәткәренең туган көнендә бергә утырганда менә шушы кеше, миңа ярамый, егетләр, дип, грамм да эчмәгән иде. Ә хәзер, әнә, чөгендер күк кызарып чыккан. Ләкин Миңнулланы барыннан да бигрәк шаккатырганы Михайлов өстендәге ак офицер киеме булды. «Әллә акларга сатылган микән бу!» дип тетрәнеп куйды Миңнулла.

Сакал Михайловның артык төчеләнүен ошатып бетермәде:

— Ярый, ялашуларны туктатып торыйк, Юрий Сергеич! — диде дә Миңнуллага эндәште: — Сезгә танышмы бу кеше, Гайсин әфәнде?

— Юк, таныш түгел.

— Ишетәсеңме? — диде Сакал, мыскыллы елмаеп. — Сине танымыйлар! Бәлки син, чыннан да, аны күргәнең юктыр?

— Ах-ха-хах-ха! Ул мине танымый! — диде Михайлов һәм, очынып килеп, Миңнулланың яңагына сукты. Аннары күзенә керердәй булып сорады: — Я, танырдыңмы инде?

— Юк, танымадым! — диде Миңнулла. Шул уңайдан тегенең эченә тибеп җибәрде.

Михайлов мәтәлеп барып төште. Берәр минут чамасы тынсыз ятты. Аннары сикереп торып, тагын Миңнуллага кизәнә башлаган иде, Кошкарев юл куймады:

— Азрак кан таратып алдыгыз, җитеп торыр! Ә хәзер бер сорау сиңа, Юрий Сергеич: Карый һәм Ашап волостьлары отрядларында ничәшәр кеше бар һәм аларның кораллары күпме?

Михайлов чалбар кесәсеннән бәләкәй генә блокнот чыгарды да, шуннан карап, бөтенесен дә төп-төгәл итеп әйтеп бирде.

— Ә менә Гайсин әфәнде әйткән саннар бөтенләй бүтән төрле бит әле монда! — диде Кошкарев.

— Алдаша ул! Мин әйткәнгә ышаныгыз, Николай Харитоныч, мин бит аларның хәрби штабында учет бүлегендә эшләдем!

— Ә без синең сатлык җан икәнеңне баштан ук белдек, шуңа һәр вакыт ялган мәгълүматлар гына биреп бардык! — диде Миңнулла.

Кошкарев дәшми торды. Аннары кисәк кенә күтәрелеп Михайловка әйтте.

— Синең бу Гайсинның яхшылап сөйләшкәннең кадерен белми икән бит. Давай, телен башкачарак ачтырып кара. Башларга мөмкин!

Михайлов Миңнулланы коридорның аргы башындагы эт оясы хәтле генә бүлмәгә алып керде. Анда өстәл-фәлән юк, тик бер иске урындык кына бар һәм ул урындыкта мир үгезе шикелле дәү гәүдәле бер солдат утыра иде. Түгәрәк тулы битле, калын кара кашлы һәм кысынкырак кара күзле кеше иде ул. «Үзебезнең Пермь ягы татары булырга тиеш», дигән фикергә килде Миңнулла. Ә солдат әйтерсең аның бу уйларын сизеп алды да, шуңа ачуы чыгып, уң кулы белән Миңнулланың изүеннән каптырып тотты, сулы белән яңагына чапты. Миңнулланың күзеннән бер көлтә ут очты, колаклары чыңлап куйды. Я, ничек, дигән сыман итеп, теге татар Михайловка карады. Михайлов хуплап баш каккач, каерылып торып, тагын берне китереп орды. Миңнулла чайкалып китте, ләкин егылмады.

— Син нәрсә, ашамадың мәллә бүген, рядовой Халитов? — диде Михайлов, солдатка ризасызлык белдереп. — Бүтән чакта болай озак мәтәшми торган идең бит! Әллә юри шулай акрын кыланасыңмы?

— Үзем дә аптырыйм инде, гаспадин Михайлов, — диде теге. —

Адәм генә түгелдер бу, тимердән ятылгандыр! Минем кул авырта, ә ул уйлап та бирми!

— Каяле, карап карыйк әле! — дип, Михайлов солдатын читкәрәк какты да, йодрыгын боксерларча йомарлап, Миңнулланың күкрәк авызына китереп төртте. Миңнулла, сыны катып, идәнгә чүкте.

Ул сулу ала башларлык хәлгә килгән арада, менә шулай итәргә кирәк аны, Халитов, дип, Михайлов солдатка акыл өйрәтә торды. Миңнулла, ниһаять, әзрәк хәл алып, аягына баскан иде, Кошкарев килеп керде:

— Я, Гайсин, дөресен сөйли башлыйсыңмы инде? — диде.— Чыгымлап торудан мәгънә булмаячак. Усы, Орда, Барда өязләре хәзер безнең кулга күчте. Шушы ике-өч көн эчендә Пермь үзе дә, Пермь губернасы да тулысы белән безнең карамакта булачак!

— Син бу экиятеңне әбиеңә сөйләрсең, Кошкарев, яме! Самодержавиене туздырып ташлаган совет власте аның калдык бандитларына гына бирешеп тормый инде ул!

— Ах, син әле һаман акылыңа килмәдеңмени! — дип чыйнады Кошкарев һәм алар, өчәүләшеп, тагын Миңнулланы дөмбәсләргә тотындылар.

6

Тигез, зур болын. Бил тиңентен үлән. Үлән арасында — чәчәкләр. Миңнулла чалгы белән шул чәчәкле үләнне чаба. Көн эссе. Тирләтә. Миңнулла, маңгаена агып төшкән эре һәм тозлы тир тамчыларын учы белән сыпырып, чалгысын янап ала да каерылып-каерылып чабуын тагын дәвам итә: чажж-чожжж, чажжж-чожж... Аның артыннан, кечерәк тау теземе шикелле булып, печән покосы сузылып килә... Ай!.. Кинәт печән арасыннан сызгырып кара елан килеп чыкты да Миңнуллага ташланды. Ләкин чага алмады — Миңнулла читкә тайпылып калды. Чалгы сабының түтәсе белән еланның башын дөмбәсләргә тотынды. Ә елан бирешми. Һаман тартыша, кырыкка бөтәрләнеп, һаман Миңнулланың аягын чагарга омтыла. Аптырагач, Миңнулла болгап торып китереп суккан иде, шартлап, тотка турыннан чалгы сабы сынып чыкты. Ә еланга берни дә булмады. Елан башын читкә борырга өлгереп калды. Аннары, Миңнулланың буш кул белән калганын күреп, үзе һөҗүмгә күчте. Хәзер инде аннан тик качып кына котылырга мөмкин иде. Миңнулла җан-фәрманга йөгерә башлады. Шул чак кинәт дөньяны кара болыт каплап алды. Чәчәк һәм үләннәрне бөгеп, ачы җил исәргә тотынды. Елан каядыр юкка чыкты. Еракта, Урал тавы итәгендә Зәйнәп пәйда булды. Миңнулланы күреп, үзе янына килергә чакырып, кул изәде. Миңнулла аңа каршы йөгермәкче иде, ләкин булдыра алмады: ниндидер бер яшерен көч аның аякларын җиргә беркетеп куйган да кузгалырга да ирек бирми иде. «Мин бара алмыйм, Зәйнәп, үзең кил!» дип кычкырмакчы булды Миңнулла. Ләкин тавышы чыкмады. Кул изәмәкче булды — кулы да күтәрелмәде. Миңнулланың хәлен аңлап алды булса кирәк, Зәйнәп үзе аңа таба йөгерә башлады. Шундый да җиңел, шундый да ансат йөгереп килә, әйтерсең аңа үләннәрне җиргә кадәр бөгеп исә торган ачы җил бөтенләй тоткарлык итми, әйтерсең аңа канат куйганнар һәм ул очып кына килә. Аралары һаман якыная бара. Әнә Зәйнәпнең елмаюларына тикле күренә башлады инде. Хәзер, хәзер килеп җитәчәк тә... Юк, булмады. Күрешергә Миңнулла кулын сузгач, әллә кайдан гына аэроплан кадәр бер каракош пәйда булды да һәркайсы берәр аршын буе тырнаклары белән Зәйнәпне эләктереп алды. Ләкин очып китмәде. Миңнулланың буе җитмәслек кадәр генә күтәрелде дә колак яргыч ямьсез тавыш белән шаркылдап көләргә тотынды. Зәйнәпне коткармакчы булып, Миңнулла үрелеп-сикереп

карый, әмма һич кенә дә буе житми... Аннары теге хәшәрәт кешечә сөйләргә тотынды: «Әйдә, егет кисәге, тырыш, ныграк сикер! Бармак очың белән генә кызга кагыла алсаң да — кыз синеке!» — ди. Ә үзе Миңнулла Зәйнәпкә үрелеп житәм дигәндә генә, ялт, күтәрелеп куя. Ә Зәйнәп, коты чыгып, телсез калган. Бер сүз дә әйтә алмый. Бары яшь тулы күзләреннән генә аның бөтен өмете Миңнуллада икәнлеге, коткар, дип ялваруы күренеп тора... Аннары, әйдә, алайса, куып тотып кара дип, хәшәрәт кош, түбәнтен генә очып, тауга таба китте. Миңнулла да аның артыннан иярде. Йөгерә, йөгерә, ләкин житә алмый бит тегене куып. Ә хәшәрәт кош коточкыч ямьсез итеп шаркылдап көлә: «Эх, син, кызыл этәч! Мине дә куып житә алмагач, нигә дип Кошкарев белән тарткалашып азапланасың? Яхшы чакта аның шартын кабул итеп кал, югыйсә, соң булуы мөмкин!» — ди. Үзе, хәзер житәсең, хәзер житәсең дип, Миңнулланы алдалап гел тауга таба оча. Ә Миңнулланың көче һаман кими, сулышы һаман кысыла бара... Менә ул инде тәмам хәлдән таеп, һушсызланып егыла ук башлады һәм... уянып китте. Йөрәге читлегеннән чыгардай булып гөрсгөрс тибә, бөтен тәне сызлый, башы авырта һәм үтереп эчәсе килә иде.

## 7

Ул йөзтүбән ята, болай яту аңа бик уңайсыз иде. Әйләнеп ятарга ярамый: телгәләнеп беткән арка тиресе кунадай каткан, селкенгәндә дә үзәкләргә үтеп сызлый иде. Шулай да көч-хәл белән генә торып утырды. Тирә-ягына карады. Кичә тегеләр кыйнап ташлаган бүлмәдә ялгызы гына иде ул. Болын да, Зәйнәп тә, каракош та, Урал тавы да юк. Бүлмә буп-буш. Хәтта кичәге бердәнбер урындыкны да алып чыгып киткәннәр. Тимер рәшәткәле тәрәзәдән төшкән кояш нурлары күзне чагылдыра. Дөнья тып-тын. Стенага тотынып кына аягына басып, Миңнулла ишек янына барды. Этеп карады. Ишек бикле иде.

Тышкы яктан татарча әйткән тавыш ишетелде:

— Ни кирәк, олан? Тышка чыгарга кысталдыңмы әллә?

Миңнулла, «эчәсем килә», дип әйтергә теләгән иде, авызы кипкәнлектән тавышы чыкмады. Ишекне шакырга мәҗбүр булды.

Сакчы, ишекне ачып, эчкә башын тыгып карагач, Миңнулла кулы белән ишарәләп, эчәсе килгәнен аңлатты.

— Хәзер, наный! — диде сакчы агай һәм бүтән бүлмәдән бер стакан су алып килеп бирде.

Эчкән шикелле дә булмады Миңнулла — ике генә йотты. Шулай да сүз әйтә алырлык хәлгә килде һәм теге мәрхәмәтле агайдан, тагын бер стакан алып килә алмыйсыңмы, дип сорады. Коридорда беркем булмаса да, агай шикләнеп як-ягына карап алды. Аннары суны чиләге белән үк алып килеп, Миңнулла алдына куйды:

— Мә, тиз генә туйганчы эчеп кал! Күрсәләр — беттем, сиңа бер йотым да су бирмәскә кушканнарые.

Миңнулла чиләк янына тезләнгән генә иде, болдыр баскычыннан менеп килүче кешенең аяк тавышы ишетелде. Агай секунд эчендә сулы чиләкне үз урынына кертеп чыкты да:

— Әйдә, әйдә, бетмәде инде синең кысталуың! — дигән булып, Миңнулланы «бәдрәфкә» алып чыгып китте.

Аннары аны тагын тикшерү бүлмәсенә алып керделәр.

Кошкарев бүлмәдә үзе генә утыра иде. Бүген ул кичәге кебек тәмле телләнеп тормады:

— Менә нәрсә, Гайсин, — дип, турыдан-туры эшкә кереште. — Синең алда хәзер ике мөмкинлек бар. Я син безнең взводны Ашапка

алып барып, волость башкарма комитетын кулга алырга ярдәм итәсең, яки без сине атарга мәҗбүр булабыз. Әгәр беренчесенә риза булсаң һәм шуны уңышлы башкарып чыксаң, мин үзебезнең югары командованиедән сиңа хәрби чин һәм яхшы хезмәт хакы биреп, үзеңне ким дигәндә рота командиры итеп билгеләүләрен сораячакмын.

Бу тәкъдим шундый көтелмәгән нәрсә булды — Миңнулла ни диярггә дә белмичә тотлыгып калды. Аның хәлен Кошкарев та сизде бугай:

— Ашыкма, Гайсин, уйла яхшылап! Ун минут вакыт бирәм мин сиңа, — дип, ялгызын гына калдырып чыгып китте.

Авыр мәсьәлә иде бу Миңнулла өчен. Нишләргә? Әгәр бу бандитның тәкъдимен кире какса, тотар да атар. Кыяфәтенә һәм сөйләшүенә караганда, шактый зыялы, мәрхәмәтле кеше сыман күренсә дә, асылда таш бәгырьле бәндә икән бит. Кичә, җене кубып, ахырдан әнә ничек тешләрен ыржайтып тотынды! Иодрыгы белән генә түгел, наган түтәсе белән төйде Миңнулланың башын...

Әллә Кошкаревның тәкъдименә риза булган булып, отрядларын иярттеп барырга да безнең отрядлар урап алырлык җиргә китереп кертергә тырышырга микән? Алай барып чыкса бик шәп булыр иде, ләкин уйлаганча гына барып чыгар микән соң? Ярый ла, безнекеләр Ашапта авыл башларына күзәтүчеләр куйган булса. Ә куймаган булып, болар отряды бернинди тоткарлыксыз барып керсә һәм безнең отряд кешеләрен кулга төшерсә? Ул чакта аның турында нәрсә дип уйлар халык? Әлбәттә, Гайсин сатлык җан булып чыккан икән, диячәкләр. Аның изге ният белән йөрүен кайдан белсен алар? Кайчаннан бирле революция эше өчен, советлар власте өчен көрәшеп йөрсен дә, менә хәзер шул эшләрен берьюлы юкка чыгарып ташларгамы? Юк, алай егетләрчә булмый...

— Мин сезнең тәкъдимне кабул итә алмыйм! — диде Миңнулла, Кошкарев әйләнеп кереп, сораулы карашын төбәгәч.

Теге әйтерсең аның сүзләрен бөтенләй ишетмәде. Өстәле артына барып утырды. Кесәсеннән бер сәгать белән бер йөзек чыгарды да:

— Менә, Гайсин әфәнде, рәхим итегез! Болар сезнең әйберләр. Воскресенскидан китерделәр,— дип, Миңнуллага сузды.

Әйберләр, чыннан да, Миңнулланыкы иде.

— Рәхмәт инде кайгыртуыгыз өчен, — диде Миңнулла, әйберләрен барып алгач.

— Я, хәл иттегезме? — диде Кошкарев.

— Мин сезнең шартыгызны кабул итә алмыйм! Үзем чын күңелемнән инанып йөргән эшкә хыянәт итәргә намусым кушмый!

— Син ныклап уйладыңмы, Гайсин? Яшьлек кирелеге, ялган горурлык кына түгелме бу? Син бит әле бик яшь, неужели яшәүдән туйдың да инде?

— Яшисе бик килә. Ләкин сатлык җан булып түгел, кешеләрчә яшисе килә!

— Димәк, үз фикереңдә каласың?

— Әйе, мин революция эшенә турылыклы булып калам!

Кошкарев бүтән бер сүз дә дәшмичә, нидер язды. Үзе янына тагын ике кешене чакырып кертте дә шул язуын тегеләргә дә укытып, икесеннән дә кул куйдыртты. Аннары, Миңнулла каршына килеп басып, шул язуын үзе кычкырып укып чыкты. Бу — тикшерү комиссиясенең Миңнулланы атарга хөкем иткән карары иде.

— Соңгы сүзең итеп нәрсә әйтергә телисең?

— Сезгә әйтүдән ни мәгънә.

— Что ж,— диде Кошкарев,— теге дөньяга китәргә алай бик атлыгып тора икән, ярдәм итик бу яшь кешегә. Каяле, сиңа аларның барыбер кирәкләре булмас инде анда,— дип, Миңнулланың йөзеге белән сәгатен алды.

Шул ук Кошкарев боерыгы буенча, күн курткасын, күн итеген һәм чалбарын салдырып алып, Миңнулланы эчке күлмәк белән эчке ыштаннан гына калдырдылар. Аннары мылтык аскан ике солдат һәм наган таккан бер офицер аны атарга алып китте.

Иртәнге сәгать тугызлар тирәсе иде бу. Бүген дә көн кичәгечә бик эссе, дөнья якты иде. Богородск чиркәве тирәсендә чиркәү чәүкәләре чыркылдаша. Авылның аргы башында чаптырып барган атлы арба тавышы, шуның артыннан өтәләнеп өреп барган эт тавышы ишетелә. Бер генә тәрәзәле, җиргә инеп барган өй каршында ике бәләкәй малай төчергәләнеп нигез туфрагыннан «бәлеш» ясап утыралар иде. «Минем дә шушылар шикелле гамьсез, рәхәт чакларым бар иде бит», дип уйлап алды Миңнулла...

Авылны чыккач, чишмәдән су алып кайтып килүче бер карт марҗа очрады. Ул, Миңнулла үтеп киткәндә тукталып:

— Господи, опять ведут! Какой молодой! Господи, помилуй! [1] — дип сөйләнеп, чукынып калды. «Берәр җиргә барырга чыкканда тулы чиләккә очрасаң — юлың уңа ди торганнар иде. Пычагым да дөрес түгел икән! Менә бу карчыкның ике чиләге тиң тулы булудан миңа ни файда хәзер!» дип уйлап куйды Миңнулла. Менә хәзер, нибары берничә минуттан, үзен атачакларын бик яхшы белә иде ул. Ләкин шуңа каршы торырлык бернинди дә чарасы юк иде. Күрәсең, әнә шул чарасызлык нәтиҗәсендәдер, ул бер дә хафаланмый, кайгырмый иде. Күңеле моңарчы беркайчан да булмаганча битараф, уе ачык иде аның. Менә хәзер елга буена алып барырлар, туктатырлар, аннары офицер солдатларга «Целься» дияр. Тегеләр мылтыкларын төзәгәч, офицер «Пли!» дип кычкырыр. Һәм атып җибәрерләр. Шуның белән барысы да бетәр, юкка чыгар. Берни дә тоймый калыр Миңнулла. Тик шунысы гына кызганыч: кичә Зәйнәпне күреп китә алмады. Их, могҗиза булсын иде дә хәзер, менә шушы су буеннан Зәйнәп сикереп менеп бассын иде... Юк, алай итмәсен. Алай итсә аны да тотып атар бу кабахәтләр. Тегеләргә күренмичә, Миңнулланың үзенә генә күренеп һәм үзе дә Миңнулланы күреп торсын иде ул кыз... Миңнулла аңа хуш, Зәйнәп, сау бул, мин сине ярата идем, ләкин яратканымны әйтергә теге чакта кыймадым, ә бүтән вакытта сезнең якларга барып чыгарга туры килмәде, дияр иде... Я менә хәзер Миңнуллага әти-әнисен күреп калырга мөмкин булсын иде. Ике айдан артты бит инде аларны күргәне юкка. Аннары соңгы тапкыр аерылышкан чакларында да бик үк әйбәт килеп чыкмаган иде. Әтисе, бичара, әллә барып йөрмисеңме инде ул Усыга, синнән башка да кеше табарларые әле, әллә шушы үзебезнең Карыйда гына эшләвеңне дәвам иттерәсеңме, улым, син монда булсаң, безгә дә тынычрак булырые, ичмаса, дип калган иде. Менә шунда Миңнулла, ярар әти, хатын-кыз башы белән әни сүз әйтмәгәндә, син кирегә сукалап утырма, үзеңнең кулыңнан килми икән, кулыңнан килгән кешегә карышма, яхшы теләк теләп кал, ичмаса, дип, артыгын дорфарак әйтеп ташлаган иде. Шуның өчен әтисеннән гафу үтенеп кенә булса да каласы иде менә хәзер... Ә әнисе ничек тә аңлар Миңнулланың хәлен. Ул яктан молодец аның әнисе. Син инде балигъ булган кеше, улым, ни эшләгәнеңне үзең беләсеңдер, дип кенә тора. Миңнулланың бер эшенә дә каршы килми, киресенчә, аның совет органнарында эшләп йөрүенә горурлана гына иде ул. Менә хәзер Миңнулланы ни өчен атарга хөкем иткәннәрен белсә дә, мөгаен, дөрес эшләгәнсең, балам, сатлык җан булып гомер иткәнче, гаделлекне яклап шәһит китүең артыграк, дияр иде ул... Елар иде елавын. Әмма тегеләргә хезмәткә куч дип әйтмәс иде... Атканда кисәтеп тормыйча, Миң-

[1] И аллам, тагын алып баралар! Нинди яшь кешене! И аллам, рәхмәтеңнән ташлама!

нуллага сиздермичә, арттан гына атсыннар иде, ичмаса. Ә башта менә шушы елгадан туйганчы бер су эчәргә рөхсәт итсеннәр иде.

Шул үтенечләрен әйтмәкче булып, Миңнулла артына әйләнгән иде, сакчы:

— Атлавыңны бел! — дип, штыгы белән төртеп, авыз ачарга да ирек бирмәде.

Елга яры буйлап берәр чакрым чамасы баргач, бик зур бер баз сыман чокыр янына җиттеләр. Миңнуллага шуның янында туктарга куштылар. Өстенә бастырык юанлыгы ике агачтан басма салынган ул чокырда егерме-утызлап мәет ята, алардан авыр ис килә иде.

— Күрдеңме? — диде офицер, читтән торып кына.

— Мин күрәм, ә син нигә якынрак килеп карамыйсың?

— Менә нәрсә, Гайсин, — диде офицер, — шушында ятып каласыңмы, әллә Николай Харитоныч әйткәнгә риза буласыңмы? Бу — синең тормышыңны саклап калу өчен соңгы мөмкинлек. Бер минут вакыт бирәм уйларга. — Аннары солдатларга боерды:

— Приготовиться!

Солдатларның мылтык затворларын тартып куйганы ишетелде.

Миңнулла өчен иң кыен, иң хәлиткеч секундлар иде бу. Шунда, секундның меңнән бер мизгелендә генә, әллә риза булыргамы, дигән уй да килеп китте аның күңеленә. Ул чак кына тыелып калды. Бу яман уйның тагын әйләнеп килүе мөмкин иде. Шуннан куркып, тизрәк әйтеп калырга ашыкты:

— Хатын-кыз түгел бит мин кат-кат сөйләшергә!

— Тагын егерме секунд вакытың бар әле, Гайсин, уйла! — диде офицер.

— Атыгыз инде тизрәк!

Офицер тәки минут үткәнче сәгатенә карап торды. Аннары Миңнуллага чокыр аша салынган басмага керергә кушты һәм солдатларга боерды: — Целься!

«Менә хәзер, хәзер, аталар да барысы да бетә. Тоелмый да калачак!» — дип, үзен-үзе юатты Миңнулла. Тегеләр атканчы ничек тә егылып төшеп хурлыкка калмаска тырышып, тар басмадан аягын шудырып кына атлавын дәвам итте. Менә ул басманың уртасына да килеп җитте, ләкин һаман «Пли!» дигән команда булмады әле. Шул чакта офицер аңа:

— Кире борыл! — дип кычкырды.

Миңнулла туктап калды. Ләкин борылырлык хәле юк, аяклары тартышып калган иде аның. Моның шулай икәнлеген офицер да төшенеп алды булса кирәк: әле һаман мылтыкларын Миңнуллага төбәп торган солдатларга:

— Отставить! — дип кычкырды һәм Миңнуллага басмадан чыгарга ярдәм итәргә кушты...

Миңнулланы яңадан Богородскига алып кайттылар. Атарга дип алып киткәндә салдырып алган киемнәрен китереп бирделәр. Киенергә куштылар. Ләкин Миңнулла — мәет тулы чокыр өстендә басып, аркасына мылтык төбәлгәнне тоеп торган кеше — тегеләрнең бу әмерен үти алмады: киемнәрен кулына тоту белән һушыннан язып, идәнгә ауды.

## 8

Ул башта кешеләр сөйләшкән тавыш ишетте һәм: «Монда да нәкъ дөньядагыча сөйләшәләр икән!» дип гаҗәпсенеп уйлап алды. Чөнки ул үзен инде үлгән дип белә иде. Аннары күзләрен ачты. Тирә-як караңгы иде. «Монда кояш юк икән», дип нәтиҗә ясады Миңнулла. Акрын гына кулын кымшатып карады — кымшады! Икенчесен селкет-

те — анысы да селкенә иде. Аннары үзенең эчәсе килгәнен тойды һәм: «Монда да шулай сусыз интектерәләр микәнни?» дип кайгыга калды. Ә мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар әле һаман ишетелә иде. Бәлки монда торып йөрергә дә була торгандыр, бәлки монда эчәргә су да бардыр, дип, шуны тикшереп карамакчы булып, ул торып утырды.

— Ыһы, һушына килде теге иптәш, — дип, Миңнулла янына ике кеше килде.

Шуннан соң гына Миңнулла үзенең теге чокырдагы мәетләр арасында түгел, ә тере кешеләр арасында икәнлеген аңлады.

Үзара сорашу-сөйләшү башланды. Менә бу — алар утыра торган караңгы таш келәт тикшерү комиссиясенең КПЗсы[1] икән. Монда утыручылар, Миңнулладан башка тагын биш кеше, төрлесе-төрле волостьтан һәм төрле сәбәпләр буенча аклар кулына эләккән кешеләр. Аларны да инде берничә кат тикшергәннәр, кыйнаганнар. Яңаклары, күз төпләре кара янып шешеп чыккан.

— Сине кичә көндезге сәгать унберләрдә кертеп ташладылар. Сулыш алганың да сизелмидерие. Без сине беткән, ахрысы, бу егет, дип уйлаганыек инде! — диделәр Миңнуллага.— Үлмәсә дә үлми икән адәм баласы: нәкъ бер тәүлек ятканнан ары өнеңә килдең менә!

Миңнулланың киемнәрен дә шушында кертеп атканнар иде. Теге иптәшләрнең ярдәме белән киенде дә, хәле бетеп, тагын йөзтүбән ятты. Болай яту аңа кыен, әмма чалкан ятарга һич мөмкин түгел — аркасындагы яралары бик каты сызлый иде.

Бераздан кичә атарга алып барган солдатларның берсе кереп, Миңнулла янына килеп карады да:

— Әһә, тере икәнсең! — дип, нигәдер куанган сыман итеп чыгып китте.

Аннары Миңнулланы тагын Кошкарев янына алып керделәр. Кошкарев аны күптәнге эшнәсен каршылагандай елмаеп каршы алды. Култыклап алып килеп, өстәле янына утыртты. Миңнулланы алып кергән солдатны чыгарып җибәрде дә, дустанә елмаеп:

— Бәлки башта бергәләп иртәнге ашны ашап алырбыз, ә? — диде.

— Ике-өч тәүлеккә бер тапкыр азрак ашап алу зыян итмәс иде, — диде Миңнулла. — Ләкин мин, әгәр мөмкин булса, башта бер туйганчы су эчәр идем!

— Нигә су? Без аның судан шәбрәген дә табабыз! — диде Сакал һәм, күрше бүлмәнең ишеген ачып, ике кешелек ашамлык кертергә кушты.

Күрәсең, алдан ук әзерләп торганнардыр, шундук парлары чыгып торган ит бәлеше, ике буш стакан һәм бер графин аракы кертеп куйдылар. Кошкарев ике стаканга да яртышар итеп салды да:

— Я, сезнең исәнлеккә! — дип эчеп тә куйды.

Эчәсе килүдән бигрәк тамак чатнавын басар өчен, Миңнулла да бетереп тотып куйды.

Икесе дә сүзсез генә бераз ашап алдылар. Аннары Сакал Миңнулла стаканына тутырып ук салды да:

— Тагын берне күтәреп җибәрегез, комиссарлар эчәргә ярата диләр! — диде.

— Үзегезгә дә салыгыз, урядниклар да кимен куймый торган иде! — дип, Миңнулла да тегенең стаканына тутырып салып куйды.

Кошкарев сискәнеп китте:

— Минем урядник булганны син кайдан беләсең, Гайсин әфәнде?

— Кыяфәтегездән күренеп тора! — дигән булды Миңнулла. Ә чынында аңа Кошкаревның Чернушка ягында урядник булып эшләгәнен әлеге караңгы келәттәге әсирләрнең берсе әйткән иде.

---

[1] КПЗ — вакытлыча ябып тору камерасы (камера предварительного заключения).

Теге ярты стакан аракы Миңнулланың кан тамырлары буйлап таралырга өлгергән иде инде. Шунлыктан тәнендәге җәрәхәтләренең сызлавы да басыла төшкән кебек булган иде. Шунда аның күңеленә, моңысын да тәвәккәлләп куйсам тагын да җиңелрәк булып китмәсме, дигән уй килде. Һәм ул:

— Әйдә, якты киләчәк өчен боларын да күтәрик булмаса! — дип, тагын эчеп куйды.

Кошкарев та:

— Мин риза бу тостка! Рәхәтләнеп эчәм мин моның өчен! — дип, тамчысын да калдырмыйча йотып җибәрде. Аннары: — Үзем рус булсам да яратам шушы татарларның ит бәлешен, ну, шәп тә нәрсә инде! — дип, комарланып бәлеш ашарга тотынды. Табанның төбенә төшеп кенә язгач, «гы-ы-ык» иттереп бер кикерде дә, кашыгын куеп, тагын сүзгә кереште: — Шәп әйттең әле син киләчәк турында — диде ул, Миңнулланың баягы тостын искә алып. — Ул якты көннәргә күп калмады инде. Фронтлардан көн саен куанычлы хәбәрләр килеп тора бу араларда. Чиләбе — бездә, Самара — бездә, Уфа — бездә, Оренбург — бездә. Тиздән кызылларның тагын бер бик мөһим үзәге — Казан шәһәре дә безнең кулга күчәргә тиеш! Аннары боҗраны кыса-кыса китереп, Пермь дә, Кунгур да безнең кулга күчәчәк! Беләсеңме син бу ни дигән сүз?..

Кошкарев бик белдекле кыяфәт белән әйткән бу хәбәрләр Миңнулла өчен берсе дә яңалык түгел, ул аларны Усыда чакта ук белә иде инде. Шуңа ул Сакалның лыгырдавын һич тә исе китмичә генә тыңлый бирде.

— Бу, — дип дәвам итте Кошкарев, үз соравына үзе җавап биреп,— безгә, азатлык армиясенә, карышып торудан мәгънә юк, без барыбер кызыл этләрне туздырып ташлап, көлләрен күккә очырачакбыз дигән сүз! Бу — бая син әйткән якты киләчәк тиздән, бик тиздән килеп җитәчәк дигән сүз! Бу — советларны юкка чыгарганнан ары без синең белән типтереп яшибез дигән сүз! Ә син, юләр, кичә киреләнеп, алла үзе кулыңа китереп тоттырган форсатны ычкындыра яздың. Рәхмәт әйт инде миңа туры килүеңә. Минем урында башка берәү булса, теге мәетләр чокырыннан кире кайтарып тормас иде. Кешенең нинди икәнлеген бер күрүдә сизәм мин. Белдем мин синең менә шушылай акылга утырачагыңны, шуңа саклап калдым тормышыңны. Әйдә, якты киләчәк өчен тагын берәрне күтәреп куйыйк әле!..

— Кошкарев, графинаны алып, башта үзенә салды. Аннары Миңнулла стаканына үрелгән иде, ләкин Миңнулла стаканын учы белән каплады да:

— Миңа җитеп торыр, болай да күз алларым әлҗе-мөлҗе килә башлады,— дип, читкә алып куйды. Һәм әйтте: — Кичерегез, Кошкарев әфәнде, ләкин без икебез ике төрле телдә сөйлибез булып чыкты бит әле! Мин тостымны үзем көткән, үзем ышанган якты киләчәкне — коммунистик киләчәкне күздә тотып әйткән идем!

Кошкаревның күзләре шар булды. Ул нидер әйтмәкче иде, әмма ачуы килүдән буылып, беркавым тынсыз-өнсез торды. Аннары, кабалана-кабалана, стаканын тутырып салды, голт-голт итеп эчеп җибәрде. Стаканын болгап торып идәнгә бәрде дә, Миңнулланың каршына килеп басып: — Әле син мине һаман аңламадыңмыни, сволочь?! — диде.

— Кызганычка каршы, бик үк төшенеп җитә алганым юк шул әле: үз ягыгызга аударып, минем белән нишләмәкче буласыз соң сез? — диде Миңнулла, салкын гына итеп.

— Курыкма инде, ахмак! — диде Кошкарев, тагын ягымлыга әверелеп. — Көчең җитмәстәй эш кушмыйбыз без сиңа. Булдырырдаен гына тапшырачакбыз!

— Конкретрак мөмкин түгелме?

— Алдан ук серне чишеп куярга тиеш булмасам да, үзеңне якын иткәнгә әйтәм инде, алайса: без синең үзебездәге мөселман солдатлары арасында агитатор булуыңны телибез. Бигрәк тә әсир ителгәннәр белән эшләргә, аларны безнең якка өндәргә кирәк булачак.

«Ыһы, менә нәрсә өчен тырыша икән бу Сакал! Менә ни өчен мине атарга алып барган җирдән кире алып кайтарткан икән, паразит!» дип уйлап алды Миңнулла. Ә үзе тыныч кына җавап бирде:

— Ышанычыгыз өчен рәхмәт, Кошкарев әфәнде, ләкин аклый алмам мин сезнең ул ышанычны. Сөйләү осталыгым юк минем.

— Аңа осталык кирәкми! — диде теге, әсәрләнеп, — үзеңнең элек кем булганыңны һәм үзең теләп безнең якка чыкканыңны әйтеп, әсирләрне дә шулай эшләргә чакырсаң — шул бик җиткән! Отлично булачак!

«Ах, менә ничек? Үзегез асып, атып, өркетеп, максатыгызга ирешә алмагач, Гайсин аркылы эш итмәкче буласызмыни? Тотыгыз менә...»

— Әйдә, болай эшлик, Кошкарев әфәнде: тотыйк та безнең якка чыгыйк! Шулай акыллырак булыр ул. Һәм без сезнең белән, чыннан да, менә диген итеп бергәләп эшләрбез.

Кошкарев шуннан ары бер сүз дә дәшмәде. Күзен тутырып беркавым Миңнуллага карап торды да, сакчыны чакырып:

— Минемчә, акылга җиңеләйгән бу егет. Бар, алып китеп әсирләр янына ябып куй үзен! — диде.

## 9

Кошкарев Миңнулланы бүтән чакыртмады. Ә икенче көнне иртән, әле кояш та чыкмас борын ук, тоткыннарны урамга алып чыгып, икешәрләп тезделәр һәм кулларын артка каерып бәйләделәр дә акларның тыл ягына — Янапай авылына бара торган олы юл буйлап алып киттеләр. Кичә Миңнулла Кошкарев белән «әңгәмә» алып барган арада теге караңгы келәткә тагын егермеләп әсир китергәннәр иде. Аннары янә бер тапкыр унберне, икенчесендә унҗидене китерделәр. Шулай итеп, алар иллегә якын кеше җыйналганнар иде.

Әсирләрнең күбәюе күңелле хәл түгел иде, әлбәттә. Тагын да яманы шул, ул кешеләр бер тирәдән генә түгел, төрлесе төрле җирләрдә әсир ителгәннәр. Усы, Орда өязләрендә, хәтта Көнгер өязендә аклар кулына капканнары да бар иде. Бу — аклар элеге өязләрдә шактый көчәя бара дигән сүз иде. Шул ук вакытта әсирләр белән сөйләшүнең Миңнулла өчен куанычлы ягы да булды. Әсирләр барысы да кызыл отрядчылар һәм кызылармеецлар булып, кайсы аклар ягына разведкага барганда, кайберләре отряд алдында дозорда барганда эләккән кешеләр иде. Ә иң мөһиме шул, ул иптәшләрнең әйтүенә караганда, безнекеләр Көнгер, Уинск, Усы, Орда һәм Ашап якларыннан һөҗүм итеп, акларны куып киләләр иде!

— Тиздән Богородскига да килеп җитәргә тиешләр, Кошкарев безне шуңа болай таң тишегеннән озату ягын карады,— диде Миңнулла белән рәттән баручы агай. Карап торырга йомыкый гына күренсә дә, сүзгә бик җапташ һәм дөньяны шактый күргән кеше булып чыкты ул. Уинскида әсир иткәннәр аны. Ә үзе шул өязнең Харис авылыннан икән. Өяз базарыннан үз авылларына кайтып барган атлы булып, разведкага барган чагында эләктереп алганнар. Дүрт бала атасы. Кырык тугызынчы яше белән бара икән. Агай бер дә алай аһ ормый.

— Ничава, — ди, — беренче генә плин төшү түгел, нимесләрендә дә, пуләкләрендә дә булган бар инде. Так шту боларыннан әллә ни өреккән юк. Ни әйтсәң дә, болар үзебезнең урыслар әле! — ди. — Аннары тагын шунысын чуттан чыгарырга ярамый: фрунт эшләрен

Ленин үз кулына алган, ул тотынса, барыбер үз дигәненчә алып барып чыга инде — барыбер капут ясаячакбыз ул акларга! — ди.— Канса кансоф, алай-болай аклар баганага элә или маңгаеңа пуле җибәрә икән, анысына да шаккаткан юк, туган: минем балалар үсеп бетте инде, ә хатынны мин болай да яратып тормыйдырыем. Безнең заманда көчләп өйләндерәләрие. Мине дә эти-әни көчләп өйләндергәннәрие. Бер кавышкач иялэштек, тату гына тордык. Ну, яратып тору булмады инде ул. Так шту, хатын дип тә алай искитте юк! — ди.— Ә менә сине алай-болай итә калсалар, анысы начар булачак, энем! — ди.— Син әле яшь. Самый каймак чагың. Өйләнеп торып җибәреп, дөнья гөрләтеп яшәр чагың синең! — ди.— Аннары килеп, яшь кенә булсаң да, зур урында эшләгәнсең икән. Значит, башың бардыр, башың булмаса, шушы яшеңнән өяз тикле өязгә эшкә алмасларые. Ну, шулай да бер хата җибәргәнсең. Шушындый чакта этрәтсез юлга чыгарга ярыймы суң? Үзең белән алып баралар аны,— ди. Аннары тагын юатырга тотына:— Ярар, туган, адәм баласының берсе дә хатадан хали түгел аның. Бик алай аптырама. Эшең өчен дә артык хафаланма. Синең урынга бүтән берәүне куеп торырлар әле. Мужыт инде куйганнардыр да. Синең урынга гына түгел, патшалар урынына да кеше табалар,— ди. Беркавым нидер уйланып дәшми бара да янә сүзгә керешә:— Кара әле, туган, яшь кенә булсаң да, байтак ил-җир гизгән икәнсең: Мәскәвендә дә, Казанында да, Питрбурында да булганың бар икән инде. Әйт әле миңа, Ленинны күрергә туры килгәне булмадымы сиңа? — ди. Миңнулла, юк шул, Сәмигулла абзый, дигәч:— Ах-ма! Анысы бик жалкы икән! Үзем күрә алмасам да, ичмаса, аны күргән кешене генә булса да күрәсие бер! Безнең ише прастуй адәм генә микән ул, әллә аллаһы тәгалә тарафыннан илче итеп, безнең ише ярлы халыкка ярдәм итәргә җибәрелгән берәр фәрештә-мазар микән? — ди...

Ә вакыт һаман үтә тора. Әсирләр Богородскидан егерме бер чакрымдагы Янапайга якынлашканда кояш төшлеккә җитеп килә иде инде. Бүген дә көн бик эссе. Күк йөзе чип-чиста. Дөнья тып-тын. Тик еракта, Орда якларында ара-тирә туп тавышлары ишетелгәләп кенә Миңнулланың болай да борчулы күңелен тагын да ныграк борчуга сала. Тирләтә. Миңнулланың эчке күлмәге аркасына ябышкан. Тозлы тир сеңгән ул күлмәк болай да сызлап торган яраларга ышкылып, үзәкләргә төшеп авырттырып бара.

Бәлки шушында туктатып бераз ял иттерерләр дип өметләнеп килсәләр дә, әсирләргә Янапайда су да эчермәделәр. Авыл халкы, бу кемнәр, кая алып барасыз боларны, дип кызыксына башлаудан шикләнеп булса кирәк, басу капкасы төбендә үткән-сүткәнне тикшереп торучы сакчылар аларны, Янапайның урамына да кертмичә, ындыр артлатып кына үткәреп җибәрделәр. «Димәк, бу авылда акларның хәле мактанырлык түгел икән! — диде әлеге Сәмигулла абзый Миңнуллага.— Хәлләре ару, көчләре житәрлек булган чакта алар, менә без кызылларны ни эшләтәбез, дип мактаныр өчен, әсирләрне юри авылның уртасыннан үткәрә торганнарые.

— Аларын ук каян беләсең, Сәмигулла абзый? Әллә аклар кулында да булганың бармы инде?

— Һы, бармы? Ничә тапкыр дип сора син. Үнберенче майда Оринбур тирәсендәге Ново-Сиргиефка дигән станцияне саклап азаплaнганда Дутыф бандитлары камап алды безнең этрәтне. Унжиде кеше иек, унжидебезне дә берьюлы әсир иттеләр. И рәтләп сорау алып та тормастан, эшкә — акуп-траншилар казырга куштылар. Җунләп ашату юк, ә эшне бер караңгыдан икенче караңгыга тикле эшләтәләрие. Уникe көн шулай чиләндек. Ярый әле, бәхеткә каршы, ул катржаннар хезмәтеннән Блюхер этрәте коткарды. Егерме өченче майда әлеге шул

Оринбурдан ерак булмаган Сырт дигән стансыда Дутыф гаскәрләрен кырып ташладылар да, безне коткарып, үзләре белән бергә нәртеп киттеләр. Аннары без ак казаклардан Оринбурны алдык. Ну, аны үз кулыбызда озак тотып тора алмадык. Май ахырында чихлар курпысы фетнә күтәреп ак казаклар белән Дутыф гаскәрләренә ярдәм итә башладылар да бишенче июльдә безне кысрыклап чыгарып, Оринбурны тагын үз кулларына төшерделәр. Шул чакта мин, бәхетсез, янә акларга каптым. Ну, бу юлы алай артык тинтерәтергә җитешә алмый калдылар. Этап белән Чиләбе ягына куа башлагач, икенче төнне үк бер урманлыкта җаен туры китереп сыпырттым мин алар кулыннан! Арттан ата-ата куып караганнарые да тидерә алмадылар. Кайда нәрсә туры килә шуның белән ризыкланып, көндез кырларда, чокыр-чакырларда посып ята-ята, төнлә-төнлә генә үзебезнең якларга кайтып җиттем. Кайтсам — бездә дә тынычлык юк, бездә дә шул аклар и фетнәчеләр дөньяны болгатып яталар икән. Мин, кәнишне, кайту белән үзебезнекеләр этрәтенә язылдым. Инде менә тагын әсирлеккә эләктем. Менә шулай, энекәш, эшләр. Шундый хәлләрне башыннан кичергән кеше бу абзаң!

Янапайдан соң әсирләрне Уфа тракты буйлап алып киттеләр. Бишалты чакрым баргач, юл урманга килеп керде.

— Зур урман булырга тиеш бу, — дип куйды Сәмигулла агай. — Куллар бергә бәйләнмәгән булса, качып китәр өчен бик шәп буласы икән дә, кулларыбыз бәйле шул.

Ул бу сүзләрне акрын гына, Миңнулла ишетерлек итеп кенә әйткән шикелле иде. Ләкин яннан килүче сакчының колагы очлы икән:

— Я, чыгыгыз әле сафтан! — диде ул татарчалатып.

Сакчы белән шаяру хәтәр эш, буйсынырга туры килде.

Шул арада колонна башында баручы атлы офицер да борылып килеп җитте һәм, кызарынып-бүртенеп, ни булды тагын? дип җикеренә башлаган иде, сакчы иплэп кенә:

— Зыян юк, менә монысы кече хаҗәтенә бик кысталган, гаспадин әфицир,— дип, Сәмигулла абыйны күрсәткәч, артык төпченеп тормады:

— Давай, тиз генә эшен бетерсен дә — сафка! — дип, тагын алга китеп барды.

Сәмигулла абзый, чалбарын чишә-чишә:

— Әй, әүлия да кеше икәнсең, кордаш, прәме чыдар әмәл калмаганые! — дип рәхмәт укырга тотынган иде, ләкин сакчы аңа җаелергә ирек бирмәде:

— Тик кенә тор да мине тыңла! — диде ул, пышылдап кына, ләкин бик җитди итеп.— Син безнең күрше авылныкы икәнсең,— Миңнуллага ымлады: — Бу егет тә ару гына нәрсә күренә.— Колонна артыннан барган сакчыга ымлап: — Ул да минем авылдаш. Без, аның белән сөйләшеп, сезнең икегезне коткарырга булдык. Озакламый бер күпергә җитәбез. Анда урман бик куе. Шунда җиткәч, мин сезнең кулыгыздагы бауны кисәрмен дә тиз генә урманга кереп сызарсыз, яме. Мин артыгыздан сезгә тидерерлек итмичә генә ата-ата чапкан булырмын. Ә хәзер, барыгыз, сафка! Иң арттагы рәткә басыгыз да тыныч кына атлавыгызны белегез.

Сакал-мыегын тап-такыр итеп әле бүген иртән генә кырган, өстенә яшел инглиз гимнастеркасы, аягына ыштыр урап инглиз ботинкасы кигән бу сакчы агайга икесе дә күңелләреннән алдан ук рәхмәт укып, сафка барып бастылар. Икесе дә үзләрен инде иректә дип хис итә башлаганнар иде.

Ләкин аларның өмете акланмады. Күпер төбенә җитәргә берәр җир бүе ара калгач, тегеләрнең ниятен сизенеп алгандай, атлы офицер чатырдап тагын колонна артына төште дә Миңнулланың янынннан гына

бара башлады. Ул монда чакта сакчы агай тегеләрнең кулларын бәйләгән бауны, әлбәттә, кисә алмый иде. Бөтен өмет күпер тирәсендә, һич югы, күперне чыккач булса да, теге тоз күз офицерның алга китүендә иде.

Күпергә дә җиттеләр, күперне үтеп тә байтак ара киттеләр. Ләкин офицерның алга чыгарга уенда да юк иде. Әсирләр урман куелыгын үтеп, ачыклыкка җиткәч кенә колонна башына китте ул.

— Булмады... — диде сакчы агай, теге киткәч тозлап-борычлап бер сүгенеп. — Сизенде бугай теге тәре — ирек бирмәде!

## 10

Бүген августның сигезе. Миңнулла һаман исән әле. Һаман дошман кулында. Башта аларны Пермь губернасының Атыр Чишмә, Алмаз авыллары аша Уфа губернасының Бирск өязендәге Аскын авылына алып бардылар. Бик ашыктырып, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр куып алып барганнар иде. Ләкин ашыгуларының нәтиҗәсе булмады: әсирләрне Аскында кабул итмәделәр. Янадан Пермь губернасына — Алмазга кайтардылар.

Болай арлы-бирле йөртүләренең сәбәбе соңыннан ачыкланды: Стәрлетамак, Шафран якларыннан Бирскига таба Блюхерның партизан отряды һөҗүм итеп килә икән, шуңа әсирләрне Аскында алып калырга курыкканнар. Миңнуллалар төркеменә Аскында тагын унөч әсир кушып җибәргәннәр иде, моны шулар әйтте.

Әсирләрне Алмазда бик зур бер таш амбарга яптылар. Анда аларга кадәр дә җиде әсир утырган булган икән. Шулай итеп, җәмгысе алтмышка якын җыелганнар иде. Ләкин аларны аз-азлап алып китеп бетерделәр. Аклар үзләренә окоп казырга һәм башка шундый эшләргә озаттылар булса кирәк. Кайберләрен атканнар, имеш, дип тә сөйләнделәр. Сәмигулла абзыйны да монда килгәннең икенче көнне үк алып киттеләр. «Минем ише прастуй солдатны атып ни файда аларга. Берәр авыр эшкә илтеп тыгалар инде мине. Ну, мин алардан барыбер ычкынам, энем. Ә менә син нишләрсең икән?» — дип, киткәндә дә үзе өчен аптырамыйча, Миңнулла өчен борчылып китте, бичара. Аны ни эшләткәннәрдер — билгесез... Ә Миңнулланы тик бер тапкыр гына чакырттып, кем иден, кайда әсир иттеләр, фәлән дә фәсмәтән дип сораштылар да шуннан бирле борчыганнары юк әле. Кичә кичтән бу келәттә ул ялгызы гына калган иде. Төнлә тагын бер кешене китерделәр. Алмаздан кырык чакрымнар тирәсендәге Чернушка тимер юл станциясе начальнигы урынбасары булган ул. Моннан бер атна элек станциягә аклар бәреп кергән. Ә бу агай — Степан Петрович Соловьев — соңгы минутына кадәр безнекеләрне эвакуацияләү белән мәшгуль булып, качып китәргә өлгермәгән. Аклар кулына эләккән. Башта аны атып үтермәкче дә булганнар. Ләкин кем икәнен белгәч, тимәгәннәр генә түгел, күтәреп дип әйтерлек йөртә башлаганнар. Шулай булмый хәле дә юк: станция начальнигы урынбасары (ә начальнигы эвакуациягә китеп өлгергән) уен түгел ул сиңа!

Тыштан тегеләргә бик теләп хезмәт итеп йөргән атлы булган Степан Петрович. Ә үзе безнекеләр белән бәйләнештә торган: ниндидер «бик җитди» сәбәпләр табып, тегеләр йөге төялгән составларны я вакытында җибәрмәү ягын караган, яки алданрак озаткан. Һәм билгеле инде, моның составлары «нигәдер» гел безнекеләр кулына эләгә башлаган. Шуннан аклар шиккә калган. Степан Петровичны, кулга алып, Алмазга озатканнар.

— Тагын бер генә тәүлек тегеләргә сиздермичә эшли алган булсам да, үзебезнекеләр килеп җитәчәк иде, ну, кызганычка каршы, сизенделәр шул, бандитлар! — дип үрсәләнде Степан Петрович. Аннары тынып

калып, караңгы амбарда әрле-бирле нидер уйланып йөрде дә, Миңнулланы култыклап алып, бергәләп качып китәргә инде башлады: — Монда сезне олы хаҗәткә бәдрәфкә алып чыгалар икән. Шуннан файдаланып калырга кирәк. Төнлә, беребез кысталган атлы булып, ишекне ачтырабыз да, сакчыны тынсыз итеп, шыпырт кына чыгып сыптырабыз. Мин ишек ярыгыннан карадым, монда урман якында гына икән, күп куйганда да бер чакрымнан артмас. Урманга исән-сау барып җитә алсак — котылдык дигән сүз!

Аның шулай артык дәрәҗәдә ашкынып, әле юньләп белеп тә бетермәгән кешегә серен бик тиз ачуын ошатып бетермәде Миңнулла. «Моны миңе провокацияләү өчен утыртканнар булса кирәк», дип шикләнде. Шуңа күрә, күңеленнән тегенең фикере белән тулысынча риза (ул үзе дә ничек булса да качып китү турында баш вата иде) булса да, тыштан битараф кыланып:

— Сез, нәрсә, дөньядан туйдыгызмыни? — дигән булды.

— Туйган булсам, мин син маңканы качарга үгетләп тә тормас идем, — диде Степан Петрович, чын-чынлап Миңнуллага үпкәләп.

Миңнулла аңа амбарны төнлә бер генә сакчы түгел, ике сакчы саклавын әйткәч тә аптырап калмады:

— Ә сакчыларны сәгать ничәдә алыштыралар? — дип сорады. Миңнулла сигездә алыштыралар икәнен әйткәч, тагын да кодрәтләнебрәк китте: — Бик шәп, алайса, эш пеште дигән сүз! Сигезенче яртыларда караңгы төшә башлый. Сигез туларга ун минут кала — сакчы әле ялгыз чагында тотабыз да бәдрәфкә дип ишекне ачтырабыз. Монысын мин эшлим. Син миңа караганда яшьрәк, җитезрәк. Көчлерәк тә күренәсең. Син минем арттан атылып чыгасың да, сакчыны күз ачып йомганчы буып алып, авызына менә минем кулъяулыкны тыгасың. Тыны да чыкмый кала тегенең. Ә мин шул арада аның мылтыгын алам да кулын артка каерып бәйлибез. И — әйдә су буена! Анда елга аркылы ару гына басма бар. Шул басманы үзебезнең арттан суга алып ташлыйбыз да — урманга! Аннан кичке караңгыда эзләп табып карасыннар инде безне!

— Монысы турында уйлап карарга ярый шикелле, — диде Миңнулла. Ләкин әле һаман, аклар агенты түгелме икән, дип шикләнеп: — Шулай да берәр көн сабыр итәргә кирәктер,— дип өстәде.

— Юк! — диде Степан Петрович, Миңнулла белән һич тә килешергә теләмичә. — Иртәгәгә калдырсак — беттек. Акларның хәле монда көнләп түгел, сәгатьләп начарлана бара. Алар үзләре дә сәгатеминуты белән китеп барырга приказ гына көтеп торалар. Мине алып килгән сакчыларның сөйләшүеннән шулай аңлашылды. Син бер нәрсәне яхшы аңла: киткәндә үзләре белән сөйрәп йөрмәячәк алар безне. Обязательно шушында атып калдырачаклар!

Шуннан ары гына Миңнулла, ниһаять, бу агайның чынлап торып сөйләвенә ышанды һәм ул дигәнчә тәвәккәлләп карарга ризалык бирде.

Алар билгеләнгән вакытның килеп җитүен түземсезлек белән көтә башлаганнар иде инде. Ләкин максатларына ирешү мәсьәләсе бик шиклегә әйләнеп китте әле монда. Алар сүз беркетеп куюга ун минут үтте микән, сакчы:

— Соловьев, киттек! — дип, Степан Петровичны алып чыгып китте дә шуннан кайтарганнары юк әле. Кайтарылармы-юкмы — билгесез. Шулай да көтә Миңнулла. Ә көткәндә, үзегез беләсез, вакыт коточкыч акрын үтә. Тоткында чакта бигрәк тә! Моның шулай икәнлеген Миңнулла бик яхшы белә инде. Унбишенче елның ахырында Петербургның жандарм участогында утырып чыккан иде инде ул. Хәер эстән көн күргән чагы иде. Ашарлык кына юнәтә иде юнәтүен. Әмма торыр урыны юк — шунысы бик тә кыен иде. Шуңа күрә, ичмаса,

туйганчы бер җылыда йоклармын дип, үзе теләп эләккән иде ул. Көпә-көндез һәм жандармның күз алдында каурыйлы эшләпә кигән бер ханымның нидер алырга теләп, кибетчегә сузган акчасын тартып алган иде дә шуның өчен ябып куйганнар иде аны. Анда, чыннан да, җылы иде. Туйганчы ук булмаса да, ару гына ашаталар да иде. Ә барыннан да бигрәк — җаны тыныч иде Миңнулланың. Тамак туйдыру өчен хәер эстәп, йөз кызартып йөрисе юк иде. Тик бер ягы гына кыен — вакыт бик акрын үтә иде анда. Ул инде анысына күнегә дә башлаган иде. Ләкин анда да озак тотмадылар. Кем син, әти-әниләрең кем, кайда тудың, дип тинтерәттеләр дә, Миңнулла, әти-әниемне дә, туган җиремне дә белмим, хәтта чын исемемне дә белмим, дип, үз сүзендә бик каты торгач, атна тулган көнне үк, бар, үз көнеңне үзең күр, ну, бүтән урлашу белән шөгыльләнмә, дип, артына тибеп чыгарып җибәрделәр...

Ә менә монда, Алмаз баеның таш амбарында, жандарм участогында яткандагы шикелле генә түгел. Монда бүген вакыт андагыга караганда мең мәртәбә акрынрак үтә. Ниләр генә уйлап, нәрсәләр турында гына хыялланып карамады инде Миңнулла! Усыда хәзер ниләр бар, анда эшләр ничек икән? Хәзер кайтып керсәң, иптәш Колчин нишләр иде икән? дип тә уйланып утырды. Моннан исән-сау котыла алсам, киләчәктә акыллырак булыр идем — ерак юлга чыкканда үзем белән кимендә дүрт-биш кешелек кораллы отряд алып чыгар идем, дип тә планлаштырып куйды... Әй, үзем дә булмаган җан шул мин, шунда Барсайга барган җирдә этисеннән Зәйнәпне кая илтеп куйганын да сорап китә алмадым инде, дип үкенүе дә күп булды... Акылы булган кеше үз якларына командировкага чыккан чагында иң элек туган авылына, әти-әниләре янына кагылыр иде. Ә мин, юләрләнеп, башта авыл Советларының хәлен үз күзем белән күреп кайтыйм дигән булып, Ильиновкаларга, Барсайларга барып йөргән булдым, дип, үзен кат-кат орышып та алды...

Ә менә хәзер үзенең бала вакытларын күз алдына китереп, шулар хакында уйлана башлады.

...Миңнуллаларның өендә этиләре түгел, әниләре хуҗа иде. Төскәбиткә чибәр, гәүдәгә баһадирдай таза булса да, этиләре чамадан тыш юаш кеше аларның. Яшьләй ятим калып, үз авылларының бер баенда, Галәветдин байда, башта йомышчы малай, аннары хезмәтче булып үскән. Белеме дә бик чамалы: әнисе исән чакта мәдрәсәгә бер кыш кына йөреп калган. Анда да юньләп түгел. Өс-башына рәтле киеме булмаганга, кышкы суыкларда унар көн укуга бара алмый яткан чаклары еш булган. Аннары үзе дә алай укыйм дип атлыгып тормаган булса кирәк. Нигәдер Миңнуллага шулай тоела. Эшкә дә кулы әллә ни ябышып тора дип әйтеп булмый. Җир, иген эшен, дөрес, беләярата, эшли анысын. Әмма бүтәнгә юк инде бичараның. Хәтта ир-атларның иң пешмәгәне дә булдыра ала торган нәрсәгә — тавык чалырга да йөрәге җитми... Ә менә Миңнулланың әнисе!.. Ир-ат булып туган булса, нишләмәс иде икән ул? Әле менә шушы хатын-кыз башы белән дә... Галәветдин байның бердәнбер кызы булган ул. Шуңа бик кадердә үскән. Ни сораса, этисе шуны алып биргән аңа. Ә кыз әллә ни күп нәрсә сорамаган: бәләкәй чагында үзе шикелле авыл балалары белән җиләккә йөргән, таш-таш уйнаган, ә исәя төшеп остабикәдән укырга өйрәнгәч, китапка хирысланган. Аның бу хирыслыгын әнисе бик үк ошатып бетермәсә дә, этисе хуплаган. «Укысын! Укыса остабикә булыр да кадер-хөрмәттә генә йөрер», — дигән. Кыз, чыннан да, этисенең өметен аклар шикелле күренгән. Авылларындагы остабикә «мәктәбен»дә иң алдынгы укучы булган. Галәви агай зур расходларга төшеп, аны Петербургка хатын-кызлар гимназиясенә урнаштырырга да тырышып караган икән, ләкин нияте гамәлгә ашмаган: безнең

уку йорты тик христиан динен тотучылар өчен генә! дип, кызны укырга алмаганнар. Шуннан соң Галәви агай Гайнижамалны үзләренең кибетендә сату итәргә өйрәткән. Ә үзе сәүдә эшен тагын да киңәйтеп, төрле шәһәрләргә йөри башлаган.

«Нихәл, әтием, юлларың уңдымы?» — дип сораган кыз бервакыт атасы Мәкәрҗә ярминкәсеннән кайткач. «Синең бәхеткә булсын инде, балам,— дигән Галәви бай,— уңды, бик уңды: үз гомеремдә күпме сату-алу итеп, бу тикле үк отышлысына туры килгәнем җүгые әле»,— дигән. «Әтием,— дигән аңа кызы Гайнижамал,— эшләрең уң булып кайтсаң, мин сиңа бер бик зур үтенечемне әйтермен дип адарынып торганыем. Әйтсәм үтәрсең микән шуны?» — дигән. «Малымның яртысыннан артыгын үк сорамасаң, үтәрмен, кызым!» — дигән әтисе. «Курыкма, әтием, — дигән кыз, — синнән бер тиен көмеш тә сорамыйм мин. Үзебезнең Хәлиуллага кияүгә чыгарга хәер-фатихаңны бирсәң — миңа шул җиткән!»

Кызының бу сүзләрен ишеткәч, Галәветдин агай лып итеп кәнәфигә утырган да шактый вакыт теленнән язып торган. Ә теленә килгәч: «Беренче һәм соңгы кабат әйтәм, кызый, тыңла яхшылап,— дигән.— Мин сине шул уҗым бозавына муеныма пычак салсалар да бирәсем юк! Бүтән ул хакта теш агартып сүз әйтәсе булма миңа!» Кызы Гайнижамал һич кенә дә аптырап калмаган: «Нишләргә икән суң инде безгә, әтекәем? Без Хәлиулла белән тора башлаган идек шул инде»,— дигән. Аннары болай да авызын ачып катып калган әтисен тәмам шаккатырып: «Бергә торгач балабыз да булыр инде!» — дип тә өстәгән. Ә үзләре кая әле анда бергә тору! Хезмәтче Хәлиулланың Гайнижамалга ул хакта сүз әйтү түгел, күтәрелеп караганы да булмаган.

Кызы белән ике араларында булган әнә шул сөйләшүдән соң Галәветдин авыруга сабып, өч көн урын өстендә яткан. Ә терелеп аягына басу белән хезмәтчесе Хәлиулланы дәштереп керткән дә, бугазлап алып: «Син чынлап ук минем кызым белән яши башладыңмыни инде, ахмак?!» — дигән. «Бүтән торыр җирем булмагач, нишлим суң инде, бай абзый»,— дигән егет, тегенең ни әйтергә теләгәнен бөтенләй аңламыйча. Галәви агай исә аны бик белеп җавап бирде дип уйлаган да: «Бар, эттән туган нәрсә, хәзер үк күземнән югал! Минем йортымда бүтән эзең дә булмасын!» — дип, типкәләп чыгарып җибәргән.

Шул ук көнне байның кызы Гайнижамал да өйләреннән чыгып китеп, алдан сөйләшеп кую буенча, сиксән яшәр бер карчыкка фатирга кергән. Ә икенче көнне кая барырга, ни эшләргә дә белмичә каравыл өендә утырган Хәлиулланы әлеге карчык аркылы чакыртып китергән дә болар чынлап ук бергә тора башлаганнар.

Хәер-фатиха бирү турында әйткән дә юк инде, хәтта кызын күрергә дә теләмәгән Галәветдин агай. Кайгысыннан сәүдә итүен ташлап, эчүгә сабышкан. Әмма кызның әнисе яшьләрне ташламаган. Галәви агайга сиздермичә генә тегеләргә әйберләр илткәләп, кулыннан килгәнчә ярдәм күрсәтеп торган. Шулай елдан артык вакыт үтеп киткән. Боларның беренче балалары — Миңнулланың абыйсы Зәйнулла дөньяга килгән. Шуннан соң да кызы белән киявен күрергә теләмәгән Галәви бай. Тик Зәйнулла аягына басып, урамнарга чыккалап йөри башлагач кына, ниһаять, түзә алмаган: кояш белән бергә торып, үзенең иң шәп юртагын җиккән дә өчесен дә төяп өенә алып кайткан. Ул чакта Миңнулла тик ана карынында гына булган әле.

Галәветдин бабасы белән Гайшәбикә әбисен Миңнулла төштә күргән шикелле генә хәтерли. Аңа өч тулганда әбисе, дүрткә чыккач кинәт кенә бабасы үлеп киткәннәр. Миңнулла аны-моны аңлый башлаган чагында алар гаиләсендә сәүдә белән шөгыльләнүче кеше юк иде инде. Шулай да тормышлары нык иде аларның. Һәр елны кышка ике баш ат, ике сыер, егермеләп сарык калдыра торганнар иде. Болар — бары-

сы да Миңнулланың әнисе тырышлыгы нәтиҗәсе. Әтиләре шул җир сөрү белән терлек асты чистартудан башканы белми дә, белергә дә теләми иде. «Көч белән эшли алудан тыш, адәм баласы азрак кына булса да баш белән дә эшли белергә тиеш ләбаса, Хәлиулла! Нигә шул хакта азрак уйлап карамыйсың? Нигә бер дә кешеләр белән аралашмыйсың? Нигә дөнья хәлләре белән кызыксынмыйсың?» — дип, әнисе күпме генә әйткәләп караса да, әтисе ыжлап та бирми: кайчакта бөтенләй дәшми кала, ә кайчакта: «Куйсана инде, әнисе, булмастай нәрсәләрне сорап җанны кыйнамасана инде! Кемгә кияүгә чыкканыңны алдан ук белеп чыктың бит!» — дип кенә куя да шуның белән бетерә торган иде.

Аның әнә шул тиешле урынында ир була белмәве аркасында үндүрт яшеннән укуын ташлап, бер башы чит җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр булды да инде Миңнулла. Бабалары вафат булганнан соң алу-сату белән эш итүне ташласалар да, һәртөрле мулласыдыр, побыдыр, өяз начальникларыдыр, чуртыдыр-гуртыдыр Карыйга килгән чакларында, иске гадәтләре буенча, фатирга Миңнуллаларга туктала торганнар иде. Кунак килсә — ит пешә, ит пешмәсә — бит пешә бит инде. Итне кызганмый торган иде әниләре. Мул итеп пешерә иде. Ә менә шул пешкән ит белән кунак сыйлап табын янында утыруны һич тә яратмый. Кунак сыйлау ир-ат эше булырга тиеш дип саный. Ә әтиләре андый чакта ничек тә бер эш тапкан булып, чыгып китү ягын чамалый да кунакны тәрбия кылу да әниләренә кала иде. Ә килгән кешеләрнең төрлесе була. Кайберсе алдан «кабып» кергән була, кайберсе кесәсенә берәр «чәкүшкә» кыстырып керә дә, бик нык туңдырды, эчкә суык үтмәсен, аш астына салып калдырыйк әле, дигән булып, табын янында сала торган иде. Ә «капкан» кеше, үзегезгә мәгълүм, кирәкмәгән нәрсәләрне дә лыгырдый башлый бит инде. Әнә шундый әрсез һәм ямьсез кунаклар киткәч, әнисенең:

— Сөйләшмәсәң сөйләшмә, ашамасаң ашама, эчмәсә, табын янында утырсаң да ярар иде! — дип, әтиләренә үпкәләп елап җибәргән чаклары була торган иде.

Барсай бае шадра Сәйфи аларга аеруча еш керә һәм әнисенең дә, Миңнулланың да ачуын китереп, аеруча күп сөйләнә иде. Теге чакта да шулай булды. Кышын Сарашта мәдрәсәдә укып, Миңнулланың җәйге ялга кайткан вакыты иде ул. Миңнулла шуннан алып кайткан күчтәнәчләр белән чәй эчеп купканнар гына иде, әлеге шул шадра килеп керде. «Кабып» кергән: табак кадәр бите белән сугым пычагы җитмәслек юан муены кара-кучкылланып кызарып чыккан, хәтта теле дә билтәкләнә башлаган. Миңнулла бу кешене бүтән чакта да бер дә өнәми иде. Ә менә шундый ямьсез хәлендә килеп кергәч, ул көнне бөтенләй кыралмас булды. Шуның өстенә тагын, әнисе чәй яңартып, чәй утырткач, Сәйфинең теле отыры озынаеп китте дә Миңнулланың җен ачуларын чыгарды.

— Әйдәле, абый, тотып ярыйк шушы шадра тәрене! — диде Миңнулла, урманга барырга ат җигә башлаган абыйсы Зәйнулла янына ишегалдына чыгып.

Ләкин абыйсы:

— Кит моннан, нәрсә сөйләп торасың син, төрмәгә кереп утырасың киләмени? — дип, ишетергә дә теләмәде.

Абыйсы да әтисенә охшаганрак шул аның. Юаш. Ә әтиләре өйдә юк иде. Хәер, өйдә булса да мондый эштә ярдәм көтеп булмый инде аннан. Миңнулла ни эшләргә белмичә аптырап өйләренә кергәндә, Сәйфи һаман әрсезләнүен дәвам итә иде әле:

— Шушы матурлыгың була торып, ничек яшисең син шул мокыт Хәлиулла белән? — дип лыгырдап тора. Миңнулла кече якка үткәч,

тагын да ныграк йөгәнсезләнеп китеп: — Бер кочаклаттырсаң да ярты байлыгымны бирер идем мин сиңа! — дип үк ычкындырды бу.

Менә шуннан соң Миңнулланың түземе төкәнде инде. Ни кылуын үзе дә белештермичә, ботаклы башы теленмәгәнлектән кистәнгә охшап калган чыра агачын эләктереп, ул атылып олы якка чыкты да, исерек бай аны-моны абайларга өлгергәнче, шул агач белән тегенең маңгаена китереп тә орды. Бай шундук өнсез калып, сыерылып төште. Ә Миңнулла: «Менә сиңа матур хатын! Менә сиңа, шадра тәре!», дип, тагын берничә мәртәбә тамызды да эле чыгып китәргә өлгермәгән абыйсын дәшеп кертте. Икәүләп көчкә сөйрәп, байны ишегалдында аты җигүле торган тарантасына чыгарып салдылар. Бәладән башаяк дип, Миңнулланың абыйсы шундук урманга китеп барды. Ә Миңнулла урамга чыгып, кеше-кара күренмәгән чакны саклап торды да, әле һаман өненә килмәгән Сәйфинең юртагын ишегалларыннан чыгарып, Барсай ягына кайтарып җибәрде.

Ике көннән Миңнулланы кулга алырга дип, өйләренә урядник килде. Урядниккаияреп барырга һич ярамый — төрмәгә тыгып куячаклары көн кебек ачык иде. Шуңа күрә Миңнулла, хәзер, бәдрәфкә генә чыгып керәм, дигән булып, бакча артлатып кына авылларыннан чыгып сызды.

Ачтан үлмәс өчен, ул авылдан авылга хәер эстәп йөрде. Шулай йөри торгач, Оренбургка барып житте. Мондый кәсеп белән көн күрүчегә бер урында озак юанырга ярамый — ояты бик зур иде. Аннары ул, үзенең исәнлеген белгертеп, аның өчен борчылмаска кушып, әнисенә хатлар да язгалап тора иде. Хат салган җирдә шулай ук тоткарланырга ярамый, шул хатларындагы штемпельләре буенча эзләп табулары бар иде. Шуңа ул әнисенә хат язып салган саен икенче җиргә күчеп китәргә мәҗбүр иде. Йөри торгач, Оренбургтан Казанга, Казаннан Мәскәүгә, Мәскәүдән Петербургка барып житте. Петербургта жандарм участогында утырып чыккач, яңадан Мәскәүгә, аннан Казанга килде.

Унбишенче елның соңгы ае кергән иде инде. Казанга килеп төшүнең икенче көнендә үк ул бер офицерга юлыкты. Юлыгу дигәнебез әлегә шул хәер эстәгәндә булды инде. Егетнең бәхетенә каршы, офицер кешелекле кеше булып чыкты. Миңнулла бер кибет янында «ярдәм итә алмассызмы?» дип торганда, офицер аны кеше күз алдыннан читкәрәк дәшеп алды да:

— Дөресен генә әйт әле, егет: шушы тазалыгың белән нигә бер җирдә дә эшләмичә хәер сорашып йөрисең син? — диде.

— Бик эшлисе дә — эш юк!

— Эш табып бирсәм, эшлисеңме?

— Ат урынына эшләр идем, абый! Ләкин мине эшкә алмыйлар бит.

— Анысы өчен хафаланма, мин әйткәч алырлар!

Офицер Миңнулланы берничә байга тәкъдим итеп карады. Ләкин аны, документы юк дип, берәү дә эшкә алмады. Дөресен генә әйткәндә, Миңнулла үзен эшкә алмаганга сөенде генә. Эшли башласам, жандармнар табып алып, төрмәгә утыртып куярлар дип курыккан иде ул.

— Нигә болай сукбайлыкта йөрисең син, энекәш? Туган җиреңне, әти-әниеңнең кемнәр икәнен генә булса да әйт, ичмаса? Мин сиңа бары яхшылык кына телим бит! — дип, офицер бик үтенгәч, Миңнулла аңа үзенең серен ачмыйча булдыра алмады.

— Менә монысы икенче мәсьәлә! — диде офицер куанып. — Димәк, сиңа авылыгызга кайтырга да, берәр җиргә эшкә урнашырга да ярамый икән. Алайса, әйдә, риза булсаң, мин сине үзем белән фронтка алып китәм.

— Мин риза да соң, ләкин армиягә яшем житми бит әле минем, — диде Миңнулла.

— Анысы өчен борчылма! — диде офицер. — Буең-сының килгән. Калганын үзем җайлармын мин аның.

Һәм, чыннан да, барысын да җайлады ул: Миңнуллага 1895 елгы итеп, ягъни аны биш яшькә олыгайтып, белешмә юллап алып бирде дә аны үзе белән ияртеп фронтка китте.

Миңнулла баштa әлеге офицерның денщигы, аннары адъютанты булып йөрде.

Гәрәй исемле иде теге офицер. Фамилиясе Гарипов. Артиллерия батареясы командиры иде. Сөйләшүенә карап кына бер дә татар димәссең: русчаны су урынына эчә. Миңнулла белән дә кеше алдында гел русча сөйләшә торган иде. Русча сөйләшергә дә, русча укырга да һәм артиллерия эшенә дә Миңнулла шул Гәрәй абзыйдан өйрәнде. Ә унҗиденче ел башында Гәрәй абзый Миңнулланы үзе белән яшерен революцион түгәрәк утырышларына да йөртә башлап, сәясәткә алып кереп китте. Шунда Миңнулла партиягә керде. Февраль революциясе алдыннан түгәрәк члennарыннан унике кешене, шул исәптән Гәрәй абзый белән Миңнулланы да, кулга алдылар. Ләкин суд ясарга өлгерә алмадылар: революция булды да, алар, төрмәдән котылып, үзләре хезмәт иткән частька кайттылар. Шунда аларны полк комитетына да сайлаганнар иде. Әмма Вакытлы хөкүмәт тарафдарлары кулга алу куркынычы килеп чыккач, комитет җитәкчесе аларга бүтән частька күчеп китәргә киңәш итте.

Анда да озак эшли алмадылар. Бер провокаторның чагуы нәтиҗәсендә Гәрәй абзыйны тагын кулга алдылар. Болай булса, минем дә эзгә төшәрләр дип, Миңнулла шуннан соң армиядән качып, туган авылы Карыйга кайтты.

Язган хатлары килеп торганга (армиядә хезмәт итә башлагач, хатларны курыкмыйча яза иде инде) Миңнулланың әнисе артык хафаланмаган, ләкин бик нык сагынган иде. Ә этисе күрше авылга тегермәнгә барып кайткан кеше белән күрешкәндәй генә итеп:

— Ниһәл, малай, син дә кайттыңмыни? — дип кенә сорады да шуның белән вәссәлам.

Абыйсы Зәйнулла да әллә ни шаккатмады.

— Әле ярый, авылдан чыгып качарга башың җиткән, югыйсә, эшләрең харап булган булырые. Син киткәч, үзеңне ел буе эзләп-сагалап йөрделәр! — диде дә каядыр чыгып китте.

Әнисеннән сорашып, Миңнулла Шадра мәсьәләсен дә ачыклады. Ул имансызга пычак та булмаган. Миңнулла тукмаган көнне үк аңына килгән һәм Карыйга, волость урядникына жалоба белән чапкан.

Миңнулла әйләнеп кайтканда заманнар шактый үзгәргән: Карыйда һәм Карый волостена караган авылларда патша власте вәкилләренең дәрәҗәсе шактый кимегән иде инде. Карыйга кайтып, кемнең кем икәнен аера башлагач, Миңнулла үзенә фикердәшләр туплап, халыкны байлар кулындагы җирләрне тартып алырга һәм совет оештырырга өнди башлады. Аннары күрше авыллардагы революцион фикерле кешеләр белән дә элемтә урнаштырып, агитация эшен тагын да киңәйтеп җибәрде.

Ләкин контрлар да тик кенә ятмаган иде шул. Унҗиденче елның август ахырларында, ярлы халыкны Вакытлы хөкүмәткә каршы көрәшкә оештыруда гаепләп, Миңнулланы тагын кулга алдылар. Башта аны Усыга өяз суд тикшерүчесенә илттеләр. Аннары Көнгер төрмәсенә алып барып яптылар. Унбер тәүлек шул төрмәдә утырганнан соң үзе оештырган революцион комитет члennарыннан өч кеше, дүрт йөз тәңкә залог калдырып, Миңнулланы порукага алдылар. Шуннан соң...

Шуннан соңгысы билгеле инде: Октябрь революциясе булды. Патша самодержавиесе бәреп төшерелү турындагы хәбәр килеп җитүгә,

ревком членнары белән бергәләп, моңарчы волость үзәге булган Карыйда волость советы төзеделәр. Аның председателе итеп бертавыштан Миңнулланы сайлап куйдылар. Шул көннәрдә Усыда өяз советы да оештырылган иде. Өяз советы башкарма комитетының кушуы буенча, Миңнуллага күршеләрендәге Юго-Осокино һәм Ашап волостьларында да советлар оештырып йөрергә туры килде. Аннары аны шушы елның февраль аенда өяз башкарма комитетына эшкә алдылар...

Миңнулланың уйларын бүлеп, келәт ишеге ачылды да, сакчы:

— Гайсин, әйдә, сине чакыралар! — дип кычкырды.

## 11

Степан Петровичны ни эшләткәннәрдер — анысын Миңнулла белә алмады. Ә менә ул үзе әсирлектән исән-имин котылып бара бугай инде. Миңнулла хәзер Алмаз урманында. Ябалдаш чыршы астында утыра. Урман тып-тын. Яфрак арасында тычкан кыштырдап куюын исәпкә алмаганда, шылт иткән тавыш та юк. Әйтерсең дөньядагы барча җан иясе үлеп беткән. Шомлы, куркыныч тынлык. Үч иткәндәй, җил дә исми, ичмаса. Аз гына агачларны шыгырдатса да ярар иде. Ә болай Миңнулланың сулу алганын ишетүләре бар. Аны куып килгән солдатлар нибары утыз-кырык адымда — урман буенда гына. Алар Миңнулланы сагалыйлар. Пошкырып, аяклары белән таптанып, тынлыкны бозмасыннар өчен, куа килүчеләрнең башлыгы атларын да ераккарак алып китеп торырга боерды. Ә җәяүгә калган солдатларга:

— Аның әллә кая качарлык арасы юк әле. Шушы тирәдә генә булырга тиеш ул, эзләгез яхшылап! — дип, бик каты кисәтеп куйды.

Башы эшли икән имансызның! Дөрестән дә, Миңнулланың ерак китәргә арасы булмады. Ишек ачкан сакчыны кисәк кенә касыгына төртеп тынсыз итте дә пуля урынына очты Миңнулла. Ә сакчы өнена килеп, разбуй сала-сала мылтыгыннан атарга керешкәндә, Миңнулла елга буена төшеп җиткән иде инде...

Дөрес, барысы да алдан уйлаганча шома барып чыкмады чыгуын: басманың бөтен такталарын да алып ташлап тора алмады Миңнулла. Шулай да аргы як ярдагы бер торыгын алып ташларга өлгерде. Шул аңа бик ярап куйды. Куа килүчеләр басма юклыкка аптырашып, суга сикерергә кыймыйча торган арада Миңнулла шактый ерак китеп өлгерде һәм урманга тегеләрдән алдарак барып җитте. Ул башта, йөгерүен дәвам итеп, урман эченә үк кереп качмакчы булган иде. Ләкин аяк астында чыбык-чабыклар бик шатырдый башлагач, тукталып калырга мәҗбүр булды һәм бер яшь, ябалдаш чыршы ботаклары арасына кереп посты... Ихтимал, әлеге шул чыбык-чабыкларны, коры яфракларны кыштырдатып йөгергәндә куа килүчеләр аның кайда икәнен сизенеп, урап алган да булырлар иде. Ләкин, Миңнулланың бәхетенә, шул тирәдә генә бер тукранның бик кызып тукылдатып торган чагы туры килде. Тегеләргә аның кайда икәнен абайларга шул ирек бирмәде. Куа килүчеләр, тукраны да шул кызыллар яклы бит дип, бик каты сүгенешеп, мылтык атып куркытканнан соң гына тынып калды ул. Рәхмәт ул изге кошка!

Миңнулла качканда сигез тулып килә иде. Хәзер тугызлар бардыр инде. Кирәк чакта, үч иткәндәй, караңгысы да тизрәк төшми бит аның. Куа килүчеләр сүгенешеп һаман урман буенда йөри. Ичмаса, ачуын китереп, тамак төбе кытыклана башлады Миңнулланың. Шул кадәр тамак кырып бер рәхәтләнеп йөткереп җибәрәсе килә — түзә торган түгел. Ничек тә чыдарга кирәк инде. Йөткерсә — бетте!.. Әһә, тегеләр янына, атын бик каты чаптырып, тагын кемдер килде. Өлкән командирлары булса кирәк — җикеренә башлады:

— Нигә урман буенда терәлешеп каттыгыз? Нигә качкынны эзләмисез? Үзе сезнең янга килеп чыгар дип көтәсезме әллә?

Тегеләре дә югалып калмады. Берсе:

— Бар, бик акыллы булсаң, үзең кереп эзләп кара! — ди.— Ләкин шуны исеңдә тот: син аны тапканчы кызыллар үзеңне әләктереп алмасын! Әле кичә кич кенә шушы тирәләрдә кызылларның разведкачылары йөргәнне үз күзләрем белән күреп кайттым!

«Әһә, боларның үз хәлләре дә бик үк шәптән түгел икән әле!» дип куанып куйды Миңнулла.

Тегеләр тагын бераз тарткалашып тордылар да, бәхетең инде, кызыл эт, тота алмадык, тота алсак, терелэй тунаган булыр идек, дип сүгенешеп кайтып киттеләр.

Берәрсен сакка калдырмадылар микән дип, Миңнулла алар киткәч тә шактый гомер шым гына утырды. Аннары сакланып кына урман буена чыкты һәм тимер юл ягына таба китте. Степан Петрович, кача алсак, шул якка китәрбез, безнекеләр шунда булырга тиеш, дип әйткән иде аңа...

Август аенда гына була торган тып-тын һәм салкынча төн иде бу. Агачыннан өзелеп ботакларга бәрелә-бәрелә төшкән нарат күркәсе, коры яфрак арасында нидер эзләнеп йөрүче тычкан кыштырдаулары, адәм баласы елаган аваз чыгарып, мәче башлы ябалаклар кычкырып куюы — барысы да Миңнулланы сискәндереп, сагайтып җибәрә иде. Шулай бара торгач, баягы тукран исенә төште. Бер уйлаганда, чыннан да, гаҗәп бит, тукран булып тукран кешегә ярдәм итә: Миңнулланың тормышын саклап калышты. Ә менә кешеләр, ни эшләгәннәрен аңлап эшли торган һәм аңлап эшләргә тиешле кешеләр, бер-берсен ничек үтерү өчен әллә ниләр кыланалар. Мылтыклар, пулеметлар, туплар уйлап тапканнар, кешелек акылы ирешкән иң зур нәтиҗәләрнең берсе булган аэропланны да хәзер бер-берсен үтерү өчен файдалана башладылар — бомбалар ташлыйлар. Ныклабрак уйлап карасаң, коточкыч хәл бит бу? Дөньяда иң усал, ерткыч җанварлар да бер-беренә тимиләр ләбаса! Дөрес, кайчакта бәрелешеп-сугышып алалар. Ләкин бит алар хайваннар, аңсыз җан ияләре. Кешеләр шул аңсыз хайваннардан да аңсызрак микәнни соң инде? Бер хәзер генә түгел, элек-электән бер-берләренә каршы сугышып, бер-берләрен кырышып килгән бит адәм балалары. Нигә алай икән, нидән башланды икән аларның үзара шулай дошманлашуы? Әгәр алар үзләренең бөтен тырышлыкларын, акылларын бары тик бер-беренә ярдәм итүгә, бер-беренә гел яхшылык эшләүгә генә юнәлткән булсалар, бу җир йөзендә күптән менә хәзер без төзергә тырышып йөри торган тигез хокуклы кешеләр дәүләте төзелгән булыр иде инде. Ә алар, кызганычка каршы, тарихның буеннан-буена һич кирәкмәгән нәрсәләр: бер-берен үтерү, берәүне икенче берәүгә хезмәт иттерү, берсенең илен икенчесе яулап алу белән шөгыльләнгән. Шуның нәтиҗәсендә менә дигән хан сарайлары урынында таш өемнәре генә утырып калган. Зур-зур шәһәрләр җир белән тигезләнгән. Кем өчен, нигә шулай эшләнгән бу? Ниндидер ахмак ханнарның яки патшаларның нәфесен, мин-минлеген канәгатьләндерү өченме?.. Тик шуның өчен генәме? Әллә кешеләрнең табигатенә үк хасмы икән мондый явызлык?.. Юк, алай булырга тиеш түгел. Совет илендә андый хәлләр булмаячак! Тик менә аның дошманнарыннан гына тизрәк котыласы иде бит!..

Урман буйлап сигез-ун чакрым баргач, Миңнулла тимер юлга килеп чыкты да, Степан Петрович өйрәткәнчә, көнчыгыш якка — Чернушка станциясенә таба китте... Бичара Степан Петрович ничек качарга, кая качарга, кайчан качарга икәнен барысын да исәпләп-уйлап куйган иде, ә үзе шул максатына ирешә алмады. Менә хәзер алар икәү бергә булса, ничек әйбәт булыр иде! Миңнулланың бу юлдан

гомерендә бер тапкыр да ни җәяүләп, ни поезд белән үткәне юк. Ә Степан Петровичка мондагы һәр шпал таныш булгандыр. Менә бит дөньяда нинди үкенечле хәлләр була. Картлар моны язмыш дип атый инде. Ә бу...

— Тукта, кем килә!

Үзенең уйларына бирелеп бернинди дә хәвеф-хәтәр көтмичә барганда Миңнуллага кинәт әнә шулай дип кычкырдылар. Ул аны-моны абайларга өлгергәнче, кинәт җир астыннан калыккандай, юлның ике ягыннан ике солдат килеп чыкты да Миңнулланың күкрәгенә штык терәделәр.

— Кем син?

— Мин — кеше!

— Кеше икәнеңне күрәбез, син безгә шунысын әйт: акмы син, кызылмы?

— Ак та түгел, кызыл да түгел.

— Кая барасың, ни эшләп йөрисең?

— Эш белән йөрим.

— Нинди эш белән?

Төн караңгы булганлыктан, солдатларның аклармы, кызыллармы икәнлеген һич тә аерып булырлык түгел иде. Шуңа Миңнулла тегеләргә җавап биреп тормаска булды һәм иплә генә итеп:

— Ә ни эшләп йөрүемне һәм кая баруымны мин бары тик сезнең командирыгызга гына әйтәчәкмен! — диде.

Тегеләр артык төпченеп тормады. Миңнулланың кесәләрен тентеп, бер әйбер дә таба алмагач (аның бар булган әйберләрен Богородскида Кошкарев алып калган иде бит), кулларын артка каерып бәйләделәр. Аннары берсе шул урыннарында сакта калды, берсе Миңнулланы үзе барган уңайга — Чернушка ягына таба алып китте.

Байтак баргач уңга борып, солдат Миңнулланы урман эченә әйдәде. Тар гына сукмак буйлап дүрт-биш чакрым баргач, тирән чокыр ярына ясалган бер землянкага килеп керделәр. Землянка эчендә җиделе лампа янып тора. Идәндә өч солдат йоклап ята, ә ике солдат зуррак кешенең уч төбе кадәр генә булган өстәл янындагы бәләкәй бүкәннәрдә йокымсырап утыралар иде. Солдатлар барысы да яшел чалбар, яшел гимнастерка кигән. Утыручыларының башларында фуражка. Ятканнарының да, утырганнарының да иңнәрендә погоннары юк. Күкрәкләрендә һәм җиңнәрендә кызыл тасмалар да күренми иде. «Аклар, ахрысы, болар! Котылып кына барганда тагын килеп каптым болай булгач!» дип уйлап алды Миңнулла. Читләтебрәк бармыйча, тимер юл буйлап килгәненә үкенеп, үзен-үзе орышып куйды.

Йоклаучыларның берсе башлыклары икән. Аны уяттылар. Кырык белән илле арасындагы чандыррак кына гәүдәле ул агай, йокысыннан айный алмыйча, беркавым күзләрен ышкып торды. Аннары әлеге солдатлардан бушаган урындыкларның берсенә үзе утырды, икенчесенә Миңнулланы утыртты да, кем син, нишләп йөрисең төннәләтеп, дип сораштырырга тотынды. Тегеләрнең аклармы, кызыллармы икәнен тәгаенли алмаганга, Миңнулла аңа да баягыча җавап бирде һәм үзен штабка илтүләрен таләп итте.

— Шунда мин барысын да сөйләп бирермен. Ә хәзер, гафу итегез, мин сезгә берни дә әйтә алмыйм, ярамый! — диде.

— Яхшы, — диде тегеләрнең командиры, өметен өзеп, — бу кире беткәннән барыбер рәтле сүз ишетеп булмас, ахры. Бар, Семенычка илтегез! Ул бик тиз ачар аның телен.

Миңнулланы тагын урман эчләтеп алып киттеләр. Алар ун-унбиш йортлы гына бер авылга килеп җиткәндә яктырып бетә язган иде инде. Кырый йортның ишегалдында ике солдат ат эчертеп торалар иде. Миңнулланы алып килгән кеше алардан:

— Командир тордымы әле? — дип сорады.

Тегеләр, бар, кереп кара, дип шаярып җавап биргәч, сакчы Миңнулланы өйгә алып керде. Анда тәртип ягы бик чамалы: ике өстәлнең икесендә дә кыр сумкалары, карталар, револьверлар аунап ята; берсендә тартылып бетмәгән тәмәке төпчеге пыскый: стена буенда кылычлар сөялгән... Командир дигәннәре инде торган, ләкин юынырга өлгермәгән иде булса кирәк: чәчләре тузгыган, күз кабакларының йокы шешенкелеге бетмәгән иде. Шулай да Миңнулла аны танып алды: узган ел фронттан качып кайтканда Миңнулла белән Әгерҗедән Карыйга тикле бергә кайтып, Миңнуллаларда ике кич кунып, мунчалар чабынып киткән Лысьва кешесе Александр Семенович Колчин иде бу! «Дядя Саша, здравствуй!» — дип кычкырасы килде Миңнулланың. Ләкин тегенең акмы-кызылмы икәнен белмәгәнлектән, тыелып калды. Шул арада Александр Семенович үзе дә Миңнулланы танып алды һәм:

— Миңнулла, кадерлем, син бит бу! — дип, гимнастеркасын төймәләп тә бетермичә, кочаклап үбәргә тотынды. Икесенең дә күзләреннән шатлык яше бәреп чыкты. Аннары, берсен-берсе бүлә-бүлә, узган ел Карыйда аерылышканнан бирле кайларда булулары, ниләр эшләүләре турында сорашырга керештеләр.

## 12

Теге чакта Миңнуллаларда кунып киткәннән соң, Александр Семенович Лысьвага кайтып җитә алмаган. Аны юлда тотып алганнар да яңадан фронтка озатканнар. Анда штраф ротасында немецларга каршы сугышып йөргән. Аннары тагын качып киткән. Әмма бу юлы Лысьвага кайтырга ашыкмаган. Барда тирәләренә кайтып җиткәч тукталып, үзе шикелле өч «дезертир» белән бергә, качкын булып, урманда яши башлаган. Байларның һәм сәүдәгәрләрнең малын урлап көн күргәннәр. Бер байның юлына каршы чыккан чакта болар белән бай арасында атыш башланган да Александр Семенович шунда яраланган. Ярасы төзәлгәнче өч айга якын «эшкә чыга алмыйча» урманда, бүген Миңнулла күргән землянкада яткан. Ә иптәшләре «эш»не дәвам иткән. Акларга хезмәт итәргә теләмәгән кешеләр хисабына качкыннар төркеме һаман зурая барган. Ярасы төзәлеп «госпитальдән» чыккач, качкыннар үзләре белән җитәкчелек итүне тагын Александр Семеновичка тапшырганнар. Аклар бу якларга да килеп җиткәч, Александр Семенович үзенең егетләре белән акларның кечерәк обозларына һөҗүм итүдән дә тартынып тормаган. Шулай итеп, алар кулына киемсалым һәм азык-төлек кенә түгел, корал да эләккәли башлаган. Әнә шулай акрынлап үрчи-арта килеп, аның группасы хәзер шактый зур отрядка әверелгән. Утыздан артык атлары, ике пулеметлары, хәтта бер җиңел туплары да бар. Шактый зур районны үз контрольләрендә тоталар икән.

— Ләкин шушы көнгә кадәр Кызыл Армия гаскәрләре белән бәйләнешкә керә алганыбыз юк әле, — диде Александр Семенович. — Коралны да, кием-салымны да, хәтта азык-төлекне дә гел үзебез юнәтергә туры килә: аклар һәм контрлар хисабына яшибез.

— Бик кыен түгелме соң алай? — диде Миңнулла. — Аклардан ничек сакланасыз? Ни әйтсәң дә, алар кадровый гаскәр бит.

— Әйе, сугыш тактикасын белү ягыннан алар, чыннан да, бездән өстен. Корал мәсьәләсендә дә иркенлек аларда. Сан ягыннан өстенлекләрен әйткән дә юк инде. Ләкин без алардан куркып тормыйбыз. Безнең үз өстенлекләребез бар. Беренчедән, җирле халык безнең яклы. Икенчедән, безнең отряд җыйнак һәм бердәм: тиз генә күченеп китә,

маневр ясый ала. Өченчедән, отрядтагы кешеләрнең яртысыннан артыгы шушы тирәнекеләр — урманнардагы һәр агачны ук булмаса да, һәр сукмакның кая алып барганын күз бәйләп тә белә алалар. Дүртенчедән, без тагын үзебез ише ике отряд белән элемтәдә торабыз. Менә иртәгә дә Биктанышов җитәкчелегендәге Бирск отряды һәм матрос Морзыев отряды белән бергәләп, Алмаздагы акларга налет ясап кайтырга исәп бар әле. Андагы хәлләр турында син нинди мәгълүматлар бирә аласың?

— Минем мәгълүмат белән генә әллә кая барып булмас, Александр Семенович. Анда караңгы таш амбарда ятып нәрсә күрәсең дә ни беләсең? Миңа калса, солдатлары артык күп түгел бугай. Аннары безнекеләрдән шикләнәләр дә икән. Урман буенда мине эзләп йөргән чакларында сөйләшүләреннән шулайрак сизелде.

— Куркулары яхшы. Ләкин аларның анда көчләре аз түгел. Ике батальон солдатлары бар. Кораллары да күп.

— Алай булса, ниятегез барып чыгар микән соң?

— Тәвәккәлләргә туры килә. Бөтенләй үк туздыра алырбыз дип әйтүе кыен, ну, безгә алар кулындагы әсирләрне коткарырга кирәк.

— Мин соңгы әсир идем бит инде анда!

— Юк, брат! Син утырган урын бөтенләй башка, үлемгә дучар ителгәннәр арасында утыргансың син! Синең белән булганнарның күбесен атып бетергән алар. Анда тагын бер гади әсирләр төркеме бар әле. Соңгы мәгълүматларга караганда, өч йөзгә якын кеше булырга тиеш. Менә шуларны коткарырга кирәк безгә!

— Монысы — изге теләк. Монысы өчен тәвәккәлләргә була!

— Булуын булыр инде ул, Миңнулла. Тик беләсеңме нәрсә... Синең планнарың ничегрәк? Кая барырга, ни эшләргә уйлыйсың?

— Мөмкин кадәр тизрәк өязгә кайтырга иде исәп. Кайда югалды икән бу дип аптырап беткәннәрдер.

— Анысы шулай, әйе, көтәләрдер. Ләкин хәзергә анда кайта алмассың әле, дустым. Усының бу ягындагы барлык волостьлар да диярлек дошман кулында. Мин синең исән-сау кайтып җитәреңә ышанмыйм.

— Алайса, ни эшләргә икән соң миңа?

— Мин сиңа Усы өязен дошманнан чистартканчы отрядта калып торырга киңәш итәр идем.

— Мин бит әле тере мәет. Чыкмаган җаным гына бар. Зыяннан башка бернинди файдам тиячәк түгел.

— Ничек кенә тиячәк әле! Мин синең отряд комиссары вазифасын өстеңә алуны телим.

— Комиссарың юкмыни?

— Бар. Бик әйбәт кеше. Ләкин ул — рус. Ә минем отрядның яртысыннан артыгы — татарлар. Бер дә русча белмәгәннәре күп. Кыскасы, миңа татар комиссар кирәк. Син кирәк миңа, Миңнулла!

— Комиссар кеше сугышчыларга һәр яктан үрнәк булып торырга тиеш. Бу хәлемдә мин аларга нинди үрнәк күрсәтә алам?

— Аңлыйм, дустым, хәлең җиңел түгел икәнен бик яхшы аңлыйм. Ләкин мин синнән мылтык тотып атакага баруны таләп итмим. Сугышчыларга совет дәүләтенең сәясәтен һәм, шуңа бәйләп, отряд алдында торган конкрет мәсьәләләрне аңлатып бирсәң — бик җиткән.

— Башкаларга аңлатудан элек, ул бурычларны мин үзем дә юньләп белмим бит әле.

— Ленинның «Барысы да Көнчыгыш фронтка» дигән мәкаләсен укыганың бармы?

— Бар.

— Совет дәүләтен саклап калырга кирәк икәнен, ә аның өчен бөтен эшче-крестьяннар ак бандаларга каршы аяусыз көрәшергә кирәк икәнен беләсеңме?

— Беләм.

— Соң тагын атаңның башы кирәкмени инде сиңа! — диде Александр Семенович әсәрләнеп. Һәм бүтән сөйләшеп торырга урын калдырмаслык итеп: — Шушы минуттан үзеңне комиссар дип исәплә! Әмин хәзер отрядны сафка тездертәм. Сине сугышчыларга тәкъдим итәм дә бераз сөйләшеп алырбыз үзләре белән, — дип чыгып китте...

Башта Александр Семенович икешәр рәт булып сафка баскан һәр сугышчыны бик җентекләп карап-тикшереп чыкты. Кайберләре янында тукталып, исемнәрен әйтеп, хәлләрен сорашты. Кайберләрен мактап алды. Кайсыларына замечание ясады. Шуннан соң «Вольно!» командасын бирде дә дүрт биш минут чамасы речь тотты. Аның рече нигездә Миңнуллага бая әйткәнне тулырак итеп, шактый гына «тозлы» сүзләр дә кыстырып сөйләп чыгуга кайтып калды. Аннары ул акларның кабахәтлекләре хакында сөйләргә керешге һәм әнә шуның нәтиҗәсе итеп, сугышчыларга Миңнулланың кара көеп, тоташ кутырга әйләнеп беткән аркасын ачып күрсәтте:

— Монысы гына ничево әле, — диде ул, сүзен дәвам итеп. — Ни генә булса да, иптәш Гайсин исән-имин качып котылган әле ул бандитлардан. Ә менә аның белән бергә әсирлектә булган алтмышлап бүтән иптәшләренең барысын атып үтереп бетергәннәр! Алмазда булган бу хәл. Шул ук Алмазда хәзерге моментта нәкъ менә минем белән сезнең шикелле ук совет яклы өч йөзләп кеше аклар кулында тоткында ята. Аларны шулай ук үлем көтә. Хәзерге моментта безнең алда торган иң изге, иң зур бурыч — әнә шул иптәшләрне ак бандалар кулыннан азат итү! Ничек кенә булса да, иртәгәдән дә калмыйча, без менә шушы бурычны үтәп чыгарга тиешбез, иптәшләр! Ә аны үтәү өчен...

Аннары Александр Семенович отряд кайчан һәм кайсы юнәлештән һөҗүм итәргә тиешлеген аңлатып бирде дә:

— Все поняли, товарищи, то, что я вам говорил? — дип сорады [1].

— По-о-няли! — дип җавап бирде сафтагылар.

Александр Семенович алгы рәттә торган нык гәүдәле, кап-кара кашлы, кара күзле чибәр генә бер агайны бармак ишарәсе белән үзе янына чакырып китерде дә:

— А ну-ка, Шакирзян, расскажи-ка мне, что ты понял? [2] — диде.

— Я бит паруски низнает, таварищ камандир, — диде теге.

— Менә күрдеңме инде? — диде Александр Семенович Миңнуллага. — Менә ничек «понятно!» аларга. Мин сөйләгәннең яртысын да аңламады алар. Яле, үзегезнең туган телегездә сөйләп бир әле шуларга!

Миңнулла отряд командиры сөйләгәннәрне тәрҗемә иткәч, йөзләре ук яктырып китте безнең агай-энеләр. Миңнулланың «аңладыгызмы» дип сораганын да көтмичә:

— Күптән шушылай чарт ярып әйтеп бирергә кирәгие аны!

— Менә хәзер төшендек, ичмаса!

— Маладис, энекәш, мең яшә! — дип кычкырдылар.

## 13

Колчин отряды авылдан кичке эңгер төшкәч чыгып китте. Алмаздагы әсирләрне азат итү операциясе иртәгә иртән генә башланырга тиеш булса да, төнлә уңайрак позиция алып, һөҗүмгә барасы урыннар белән әйбәтрәк танышып куярга кирәк, дип Александр Семенович шулай алданрак кузгалуны мәгъкуль күрде.

---

[1] Мин әйткәннәрне барыгыз да аңладыгызмы?

[2] Яле, Шакирҗан, әйтеп бир әле миңа, син нәрсә аңладың?

— Дошманның башын чабармын дип үк вәгъдә итә алмыйм. Ләкин кылыч тотарлык һәм ат өстендә торырлык кына рәтем бар. Мин дә барам! — дип сорап караса да, Александр Семенович Миңнулланы алып бармады.

— Сабыр ит, Миңнулла, өлгерерсең әле. Ә хәзер сиңа дәваланырга һәм бик яхшылап ял итәргә кирәк! — диде дә, отрядның лазаретына үзе илтеп куеп, андагы фельдшерга: — Менә бу иптәш безнең яңа комиссарыбыз! Ләкин син аңа комиссар итеп түгел, ә гап-гади авыру сугышчы итеп кара. Дәвала. Беркая чыгарма! — дип калдырып китте.

Лазарет дигәннәре авыл карчыгының алты почмаклы йортының түр ягыннан гыйбарәт иде. Анда ашыгыч кына әтмәлләп куйган биш агач караватт булып, шуларның өчесендә яралы сугышчылар ята. «Госпиталь» начальнигы — чандыр гына, житез генә, бик хәтәр итеп ике якка бөтереп җибәрелгән кара мыеклы, өстенә ак халат, башына ак кәпәч кигән һәм кыяфәтенә карап кына ничә яшьтә икәнен һич тә чамаларга мөмкин булмаган Гыйлемдар агай — Миңнулланы кырыс кына каршылаcа да, ахырдан гаҗәеп әйбәт кеше булып чыкты. Үзе Оренбургныкы икән. Сугышка кадәр ат фельдшеры булган.

— Ә хәзер менә атларны гына түгел, кешеләрне дә дәваларга туры килә. Минем врачлык чамалы гына инде, энекәш, — диде ул.

Үзе турында әнә шулай артык зур фикердә булмаса да, эшнең рәтен белә икән. Миңнулланың аркасын ниндидер дарулар белән майлап җибәргән иде — җаннары рәхәтләнеп китте егетнең. Аннары:

— Мә, шушыны йотып җибәр дә төренеп ят! — дип, ясмык кадәр генә бер дару каптырган иде, Миңнулла кичке уннардан алып бер уянусыз иртәнге тугызга кадәр йоклаган.

Александр Семеновичның:

— Миңнулла, тор! Тор инде! — дип аягыннан селкетүенә уянып китте ул. Торып утырырга да өлгермәде, тегесе балаларча куанып, пулеметтан аткандай сиптерергә тотынды:

— Әйткән идемме мин сиңа, отрядтагы татар иптәшләргә мәсьәләне үзегезнең телдә аңлатып бирергә кирәк, шул чакта арысланнардай сугышачак алар дип. Тәки шулай булып чыкты бит! Бүгенге сугышта татар дуслар ут өерде акларны! Морзыев отряды белән бергәләп, сиздермичә генә Алмаз янына ук килеп, иртәнге биштә, акларның рәхәтләнеп йоклаган чакларында «урра!» кычкырып авылга бәреп кердек тә тотындык урырга, тотындык урырга — тегеләр киемнәрен дә рәтләп киярга өлгерә алмыйча чыгып качарга мәҗбүр булдылар. Ну, мылтыкларын калдырмаган, сволочьлар! Ярый әле, Алмазның көньягына Биктанышов отряды засадага куелган иде. Ну, кызык хәлләр булган соң анда. Аклар Алмаздан чыгып кача башлагач, Биктанышовныкылар да эшкә керешмәк булып күтәрелгәннәр икән, тегеләрнең командиры:

— Братцы! Безгә ярдәмгә киләсезме? Әйдә, тизрәк булыгыз, югыйсә, эшләр харап! — дип боларга үзе каршы чыккан.

— Әйе, — дигәннәр аңа, — сезгә ярдәмгә киләбез. Яле, ташлагыз әле коралларыгызны да, күтәрегез әле кулларыгызны! Каршылык күрсәтергә маташудан файда юк, сез — чолганышта!

Ак сволочь — ак сволочь булып кала шул инде. Шунда да солдатларына:

— Бирелмәскә! Ятарга һәм соңгы сулышка кадәр сугышырга! — дип кычкырган теге паразит һәм револьверыннан безнекеләргә атарга тотынган.

Ну, эш алайга киткәч, билгеле инде, Биктанышовныкылар шундук тынсыз иткән тегене. Шунда бер уңайдан каршылык күрсәтергә маташкан солдатларын да хәл иткәннәр.

— Ә әсирләрне коткара алдыгызмы соң? — диде Миңнулла, түземсезләнеп.

— Ничек кенә коткардык әле! Берсенә бер кагылырга өлгерә алмый калды аклар. Конюшняның ишеге бикле иде, ачкычын, күрәсең, качканда сакчы үзе белән алып киткәндер. Ишекне үз кулым белән ватып ачтым да:

— Хәзерге минуттан сез иректә, иптәшләр! Дүрт ягыгыз кыйбла: кая телисез — шунда китә аласыз! Кемнәр коткарды дип сорасалар — Колчин отряды кызыл гвардиячеләре коткарды диярсез! Шуннан башка без сездән берни дә таләп итмибез! — дидем.

Колчакчылар шул тикле куркытып, өннәрен алып бетергән бичараларны — әсирләр башта аптырап, ышанмыйча тордылар. Тик каным кызып китеп:

— Ике минут эчендә урамга чыгып тезелмәсәгез — яхшылык күрмәгез! — дип кычкыргач кына, урамга чыгып тезелделәр. Санаткан идем — ике йөз дә илле җиде кеше булып чыкты.

— Бүтәннәрегез кая, сез бит болай гына булырга тиеш түгел идегез? — мин әйтәм.

— Кичә кичтән утыз икебезне каядыр алып киттеләр, — дип җавап бирделәр.

— Ярый, — мин әйтәм, — монысы аңлашылды. Инде хәзер, барыгыз, таралыгыз — сез иректә!

Ышанасыңмы, Миңнулла, ник берсе урыныннан кузгалып карасын тегеләрнең! «Без беркая да китмибез, китеп тагын аклар кулына эләгәсебез килми! Давай, ал безне үзеңнең отрядыңа, командир?» — диләр.

— Шуннан?

— Шуннан нәрсә? Миңа аларны отрядка алудан ни мәгънә? Үзләре ябык, хәлсез, үзләренең ни юньле киеме, ни коралы юк. Шулай булгач, мин аларны отрядка алып нишлим? Сәяси-тәрбияви яктан чыгып караганда, аларның үз илләренә, үз өйләренә кайтып китүләре отрядта калуларына караганда күп мәртәбә файдалырак бит!

— Сез моны нәрсәне күздә тотып әйтәсез? — диде Миңнулла, тегенең эшне кая таба борганын төшенеп җитмичә.

— Ул әсирләрнең ике йөз иллесе (кайбер авыллардан яки шәһәрләрдән икешәр-өчәр кеше булган дип исәпләгәндә дә) кимендә йөзләп авыл һәм шәһәргә кайтырга тиеш, шулаймы?.. Шулай. Ә кайткач алар аклар турында ничек дип сөйләячәк тә, аларны үлемнән коткарган без кызыллар турында ни дип сөйләячәк? Совет властен яклап, аңа ярдәм итәргә кирәк дип сөйләүче менә дигән агитаторлар булачак бит алар!

— Карале, чыннан да шулай икән ич! — диде Миңнулла тегенең белән килешеп. Аннары сорады: — Соңыннан нишләде ул иптәшләр, кайтып киттеләрме?

— Тәмам интегеп беттем бүген мин алар белән. Сырып алдылар да һаман отрядыңа яз да, отрядыңа яз, диләр. Берсе-бер китәргә теләми. Нишләргә хәзер? Уйладым-уйладым да тегеләрне ике рәткә тезеп, яшьрәк-егәрлерәкләрен, безнең авыр шартларда да бирешмичә сугыша алырдайларын сайлап алдым. Утыз тугыз кеше булды андыйлары. Ә калганнарына, гафу итегез, иптәшләр, башкаларыгызны алырга һич тә мөмкинлегем юк, дидем. Шуннан соң да күбесе китәргә теләмичә, мине генә ал да, мине генә ал инде, диешеп торалар иде әле. Ну, бәхеткә каршы, шул чакта отрядның бер отделениесендәге егетләр дошманның биш олавын эләктереп алып килделәр. Йөкләрен чишеп карасак, берсендә безгә әҗәл даруыдай кирәкле патроннар, ике йөге — пешкән икмәк, ә калган ике йөгендә өр-яңа солдат мундирлары белән солдат ботинкалары! Үзең беләсең, минем отряд егетләренең

киемнәре алай зарланырлык түгел. Ә артык әйбер төяп йөрүнең безнең ише кучмә халыкка шулай ук хаҗәте юк. Шуңа күрә тоттым да киемнәрне әлеге әсирлектән котылган кешеләргә өләшергә куштым.

— Барысына да җиттеме?

— Гимнастеркалары белән чалбарлары җитте, хәтта азрак артып та калды әле. Тик ботинкалары гына җитеп бетмәде. «Ну, анысы өчен бигайбә инде, иптәшләр, — дидем мин аларга. — Заказ биреп кайтарткан әйберләр түгел. Ә хәзергә сау булыгыз! Исән-имин генә өйләрегезгә кайтып җитүегезне телим! Отрядыңа алмадың, дошманнарны кыйный алмый калабыз инде дип бер дә борчылмагыз. Совет властеның дошманнары тылда да, кызганычка каршы, җитәрлек әле, шулар белән көрәшегез!» — дидем. Аннары, юлыгызга булыр дип, теге ике олау икмәкне бүлеп бирдерттем. Тик шуннан ары гына таралыштылар.

— Кызганыч, мин шуларның берсен дә күрә алмыйча калдым бит, — диде Миңнулла, үзенең авыру булуына үкенеп.

— Анысы, әйе, чыннан да кызганыч, — диде Александр Семенович, аның белән килешкәндәй итеп. — Ә шулай да бу җиңүне җиңел аягың белән син алып килдең безгә! Моңарчы күпме бәрелешләрдә булып, бу кадәр зур уңышка ирешкәнебез юк иде әле. Ә үзең катнаша алмаганга артык хафаланма. Дошманның тиз генә бирелергә исәбе юк әле анда. Киресенчә, һаман совет властен кысрыклап килүен дәвам итә. Сугышырга өлгерерсең.

## Икенче бүлек

### 1

Ләкин Миңнуллага ныклап торып сугышырга язмаган икән. Ул — егерме өч тәүлек буена дошман кулында, типке астында яшәгәндә бирешмәгән кеше — Колчин отрядында комиссар вазифасын үти башлагач, тәнендәге җәрәхәтләре инде төзәлеп килүгә һәм ашау яклары да арулануга карамастан, көннән-көн ябыга, хәлсезләнә барды. Ә иң яманы шул: еш кына кан төкерә башлады. Бу, әлбәттә, Кошкарев белән «дустанә сөйләшүләр», таш амбарның җир идәнендә тәүлекләр буе һушсыз ятулар нәтиҗәсе иде. Моның шулай икәнлеген Миңнулла үзе дә яхшы белә. Ләкин ул, Колчин, бу егет сугыштан шүрли икән, тылга китәсе килә икән моның, шуңа авыру булып кылана дип уйламасын өчен, сер бирмәскә, сәламәт булып күренергә тырыша иде. Шулай ул дошман белән бәрелештә бер катнашты, ике катнашты, өч катнашты. Ихтимал, әле алга таба да шулай дәвам иткән булыр иде, ләкин бер көнне Колчин аны «җинаять» өстендә тотты.

Шактый озак тартышканнан соң, ниһаять, унбер генә йортлы бер авылны аклардан азат итеп, шунда ялга туктаганнар иде. Мондый киеренке вакыйгалардан соң хәле тагын да кыенлашасын белеп, Миңнулла фатирга ялгыз гына урнашты. Азрак ял итеп алырга дип яткан гына иде, Колчинның адъютанты килеп керде:

— Әйдә, иптәш комиссар, Александр Семенович минуты белән килеп җитәргә кушты!

Акларның бер мичкә самогонын кулга төшергәннәр икән. Колчин азрак татып та караган иде булса кирәк, болай да түгәрәк тулы йөзе тагын да тулышып, алсуланып киткән. Миңнулланы да килеп керү белән кыстый башлады. Нишләсен, ул да азрак авыз итеп куйды. Ләкин кызмача кешедән тиз генә котылып буламыни?

— Шушы стаканындагыны бетереп куймасаң, мин синең белән бүтән сөйләшмим дә! Атакага барганда алда идең бит, шулай булгач, монысын да ялт иттереп куярга тиеш син! — дип, чәер урынына ябышты теге.

Бәлки командир хаклыдыр, бәлки авыруыма сихәте тияр, дип Миңнулла да тәвәккәлләгән иде, шундук күңеле болганып, укшыта башлады. Миңнулла тиз генә ишегалдына чыкты һәм гөрләтеп кан косып җибәрде. Ул арада Александр Семенович та чыгып җитте һәм, егетнең хәлен күреп, исе китеп торды. Аннары әйтте:

— Син, Миңнулла, минем үзем өчен дә, отряд өчен дә бик кадерле, ифрат дәрәҗәдә кирәкле кеше! Отрядка син килгәч, ярты кайгым беткән иде минем. Халыкны ышандырып, ялкынлы итеп сөйли аласың. Сүз белән генә түгел, сугыш вакытында да үрнәк күрсәтәсең аларга. Ләкин, шулай булса да, мин сине менә шушы минуттан комиссарлыктан азат итәргә тиеш булам, кадерлем. Хәлең бик шәптән түгел икәнлеген мин моңарчы да сизенә идем. Әмма үтәр әле дип уйлый идем. Ә синең эшләр әнә кая ук барып җиткән икән! Тыныч җирдә, урынга ятып дәваланырга кирәк сиңа, егет!

Миңнулла, зыян юк, үтәр, эчкәннеке генәдер бу, сез мине бөтенләй үк сызып ташларга җыенмагыз әле, Александр Семенович, дип караса да, Колчин эшне бик кызу тотты:

— Мин коммунист, иптәш Гайсин, күрә торып кешене үлемгә дучар итәргә минем хакым юк! — диде дә, ун кешелек атлы отряд биреп, Миңнулланы икенче көнне үк Усыга озаттырып куйдыртты.

## 2

Эш сәгате инде күптән чыккан булса да, өяз башкарма комитеты председателе Емельян Петрович Колегов кайтып китмәгән иде әле.

— Ниһаять, кайттыңмы, иптәш Гайсин! — диде ул куанып.— Сине әзләтә-эзләтә чәчләр агарып бетә язган иде инде монда! Берсе әйтә исәндер ул, ди. Икенчесе әйтә, үтергәннәр аны Воскресенскида, үтергәннәрен үз күзләре белән күрүчеләр булган, ди... Әйдә, әйдә, якынрак килеп утыр да сөйлә әле: кайларда булдың, ниләр күрдең, ничек исән калдың?...

— Ярый, ничек булса да булган, иң мөһиме шул — үзең исән-сау әйләнеп кайткансың! — диде ул, Миңнулла аңа башыннан үткән хәлләрне сөйләп биргәч. — Ну, шулай да мин бер нәрсәне һич тә аңлый алмыйм: теге чакта я Карый, я Ашап волкомыннан отряд алмыйча, нигә башта Барсайга ялгыз гына барасы иттең син?

— Волкомга караган авыллардагы хәлләрне үз күзем белән күреп кайтмак булган идем, Емельян Петрович.

— Юк, минемчә, син нәрсәнедер яшерәсең монда! Күзеңнән күреп торам — яшерәсең!

Эшләр болайга киткәч, Миңнулла серне ачарга, Зәйнәп турында сөйләп бирергә мәҗбүр булды.

— Менә монысына мин ышанам! — диде Емельян Петрович. — Үзем дә шундыйрак бер нәрсә түгел микән дип уйлаган идем аны. Эх, егет-егет! Яратам дип, хатын-кыз артыннан йөри торган заманмы соң хәзер? Ил куләмендә генә түгел, бөтен дөнья куләмендә буржуйларга каршы иң кискен көрәш барган хәзерге вакытта гына түгел, тыныч заманнарда да менә дигән ир-атлар харап булган лабаса шул мәхәббәт дигән чир аркасында. Хатын-кызның итәге киң аның, энем, аңа барысы да сыя. Тарихка гына күз сал азрак: күпме сугышларның башы шул хатын-кызларга барып тоташа! Күпме байлык туздырылган, күпме халык кырылган, күпме балалар ятим калдырылган, күпме

патшалар тәхетләреннән колак каккан шул ярату дип атала торган йөгәнсез хис аркасында! Инде килеп, менә син... Шулай башсызланып йөрергә ярыймы соң инде синең шикелле җаваплы эштә эшли торган кешегә! Уком председателе урынбасары лабаса син, Гайсин!

Рәхмәт көтмәгән иде Миңнулла. Ләкин бу агай мәсьәләне болай тирәнгә алып кереп, тарихка һәм сәясәткә үк китереп терәр дип тә уйламаган иде. Шулай да бирешергә теләмәде.

— Тарихта сез әйткәннәрнең киресен раслый торган мисаллар да аз түгел, Емельян Петрович.

— Мәсәлән?

— Мәсәлән, теге сез әйткән зиннәтле сарайларның җимертелүе генә түгел, салдырылуы да шул ук мәхәббәт дигән нәрсә белән бәйләнгән бит. Аларның күбесе хатын-кызлар хөрмәтенә, хатын-кызлар исәлегенә яки шуларга атап салынган!

Миңнулланың бу җавабына каршы куярлык дәлиле юк иде булса кирәк, Емельян Петрович нервланып ишекле-түрле йөренеп алды һәм, ныклап ук ачулана башлап:

— Син, егет, мине андый юк-бар белән бутарга маташма!—диде. — Үзең уйлап кара азрак: күпме көч, күпме кан түгеп яулап алынган революция язмышы кыл өстендә торган хәзерге вакытта башкалар да, менә шушылай синең кебек, дөньяларын онытып, яраткан кызы артыннан чаба башласа һәм дошман кулына синең кебек барып каба башласа — кая китәр ул аннары? Кем сугышыр ул дошманга каршы, кем саклап калыр совет властен?

— Ярар ла инде, Емельян Петрович, очраклы гына килеп чыккач бер нәрсәдән әллә нинди зур нәтиҗәләр ясамагыз, зинһар. Сүз дә юк, мин гаепле. Гаебемне таныйм һәм кичерүегезне сорыйм. Ләкин шунысын да әйтми кала алмыйм: әгәр әнә шул Барсай кызын яратмаган булсам, аклар шул тамаша кыйнаганда мин, ихтимал, түзә алмаган булыр идем!

— Я, рабби! — диде Емельян Петрович, аптырап. — Ул әле һаман бер нәрсә дә аңламаган икән! Ну, егет, әгәр бүтән чакта шушылай сөйләнеп утырсаң, билләһи дип әйтәм, минут та тотмыйча берәр атнага каталажкага ябар идем мин сине! Кызганычка каршы, вакыты андый түгел. Син миңа менә болай (ул муенына баш бармагы белән аркылы сызып күрсәтте) кирәк хәзер! Шуңа гына кичерәм мин сине. Ә хәзер, давай, конкрет эшкә күчик...

Емельян Петрович өяз башкарма комитеты аппаратларындагы хәлләрне аңлатып бирде. Миңнулла «командировкада» йөргән арада анда да шактый үзгәрешләр булган икән. Кайбер иптәшләр үзләре теләп фронтка киткән. Кайберләрен эшләрен тиешенчә алып бара алмаганга азат иткәннәр. Ә берсе теге сатлык җан Михайлов белән аклар ягына сызган.

— Шулай да хәзер эшләр ярыйсы инде, — диде Емельян Петрович. — Тик менә үземә урынбасар итеп куярлык кешене генә таба алмыйча йөри идем әле. Синең кайтып төшүең бик тә яхшы булды. Давай, иртәгәдән үк шул постка җигел дә йөкне бергәләп тарта башларбыз!

— Андый эшне эшләрлек хәлем булса, Колчин отрядыннан да китәсе түгел идем мин. Сәламәтлекнең рәте китебрәк тора шул, Емельян Петрович. Кимендә ун-унбиш көн ял кирәк миңа. Шуңа күрә үзебезнең авылга кайтырга да әти-әни тәрбиясендә булып, азрак рәткә кереп килергә иде исәп.

Петрович, күңелсезләнеп китеп, берәр минут чамасы уйланып торды да:

— Революция язмышы хәл ителгән бу көннәрдә безнең җинүне те-

ләгән бер генә кеше дә авырырга тиеш түгел! — диде.— Ә коммунист кеше, иптәш Гайсин, бигрәк тә!

— Барысын да бик яхшы аңлыйм, Емельян Петрович. Ләкин сез дә мине аңлагыз: хәлем әйбәт түгел минем.

Өстәлдә яткан кызыл йолдызлы фуражкасына карап, Петрович беркавым уйланып утырды. Аннары кинәт кенә дәртләнеп китеп:

— Яхшы,— диде.— Алайса, син дигәнчә эшлибез. Урынбасар мәсьәләсен хәзергә ачык калдырып торабыз. Ә син иртәгә үк үзеңнең Карыеңа кайтып китәсең. Шунда ял итәрсең, дәваланырсың. Ләкин шул ук вакытта кайбер эшләр белән дә шөгыльләнергә туры килер. Мәле, тот әле кулыңа каләм белән кәгазь дә язып бар әле нинди эшләргә кирәк булачагын. Башладык: а) Карый волостена караган авылларда партия ячейкалары төзергә; б) җирле халыктан кызыл гвардиячеләр отрядлары оештырырга; в) волость хәрби комиссариаты төзергә; г) фронтка кешеләр мобилизацияләүне оештырырга; д) комбедларга продналог җыюда ярдәм итәргә. Булдымы?

— Булуын булды да, Емельян Петрович, ләкин мин боларның... — дип Миңнулла авыз ача башлаган иде дә тегесе:

— Ярый, Гайсин, иртәгә бәйрәм түгел, кайтыйк инде,— дип, сүз юзайтып торырга юл куймады һәм: — Сау бул! Ә иртәгә секретарь килгәч, мин сиңа вәкаләт мандаты яздыртып бирермен,— диде дә, кайда тукталдың, кереп кунар җирең бармы, дип сорарга да онытып, кайтып китте.

Миңнулла исә кичкырын кеше борчып йөрергә арусынмады, өяз кызыл гвардиячеләр отряды штабына барып кунды.

### 3

Карый волкомында хәлләр шәптән түгел икәнлеген Емельян Петрович сүзләреннән үк сизенгән иде Миңнулла. Әмма андагы эшләр ул көткәнгә караганда күп мәртәбә мөшкелрәк булып чыкты.

Теге чактагы шикелле көтелмәгән күңелсезлекләргә юлыгып, тагын әти-әнине күрми калмагаем дип, Миңнулла бу юлы Карыйга, туп-туры өйләренә кайтып керде. Әтисе дә, әнисе дә өйдә иделәр. Әтисе, гадәтенчә, бер дә алай исе китмичә генә каршы алды:

— Син дә исән икәнсең әле, улым, нихәл? — дип кул биреп күреште дә, эше шуның белән беткәнгә санап, шыпырт кына сәкегә барып утырды. Ә менә әнисе, бичара, ни эшләргә дә белмәде инде! Башта:

— Әй, балакаем, әй, җан кисәгем, исән икәнсең ләбаса! Исәннәр генә икәнсең, күз нурым! Сине Бугурутскига апкитеп атып үтергәннәр, имеш, дип котларыбызны алып бетергәннәрие бит безнең! — дип, дөньядагы бар кешенекеннән дә йомшак җылы куллары белән Миңнулланың битләрен, киемнәрен сыпыра-сыпыра сөенеченнән бер елап алды. — Кайларда гына булдың, нинди эшләттеләр сине, бала: коры сөяк белән тирегә генә калгансың ич! Кай җиркәйләрең авырта? Бигрәкләр бетерешкәнсең бит! — дип, кайгырып, икенче тапкыр елады. Шуннан соң, әй, үзем дә инде, онытылып утырам икән, каяле, чәй куеп җибәрим әле дип, самаварга тотынды. Үзе шунда, эш арасында, Миңнулланың кайларда булганын инәсеннән җебенә хәтле сораштырырга да онытмады. Аннары үзләрендә булган хәлләрне сөйләргә керешге:

— Алланың каһәрессе генә төшсен инде, улым, акларына да, байларына да. Шулар болгата бөтен дөньяны. Менә әле атна-ун көн элек кенә безнең дә котларыбызны алып, теңкәләребезгә тиеп беттеләр. Теге Чирканды мулласының малае Хәйрулла дигән нәрсә җиде төн уртасында дүрт мылтыклы кеше ияртеп керде дә, бер каммуныңның башына җиттек, икенче каммуның кая, дип Зәйнулланы таптырырга тотынды. Ярый

эле, шуннан ике көн алдан гына абыең фрунтка язылып китеп баргане. Мин тегеләргә, кайда икәнен белмим, сугышка алып киттеләр аны, дигәч, әлеге шул Хәйрулла дигәне, әһә, аның да сәвитләрне яклап сугышырга киттемени дип, тешләрен ыржайтып килеп, яңагыма чапты. Аннары, малайларыңның байларны талап җыйган алтыны кая, дип дүпрусларга тотынды. Безнең өйгә андый нәрсәнең кергәне дә жук, нахак сүз сөйләп гөнаһлы булма, дигәч, малайларың гына түгел, син үзең дә камунист, ахры, җен карчыгы, дип җелегемә тиде. Аннары бер сарыгыбызны суйдылар да итен үзләре белән алып киттеләр. Йөрәк-бавырын да калдырмадылар.

— Абыйга ник бәйләнә соң алар, әни? Коммунист түгел иде бит ул.

— Камунист булды шул инде ул да. Сине үтергәннәр дип ишеткәч, аның урынына үзем калам, дип камунист булганые. Һәй, улым, безнең Карыйдагы хәлләрне белсәң син!

— Ниләр булды тагын, әни?

— Ярар, сөйләп кенә бетерә торган түгел ул. Вулкумга баргач, үзең күрерсең, тикшерерсең эле. Әйдә, дөнья хәлләрен куеп торып, һәйбәтләп бер чәй эчик эле башта. Синең өчен кайгырып инде кайчаннан бирле җүнләп чәй дә эчкәнем жугые.

## 4

Миңнулла волком бинасына барып кергәндә барлык бүлмәләр дә шыр ачык һәм буш, тик ишегенә «председатель» дип язганында гына сакалын ялт иттереп кырган, башына колакчын бүрек кигән бер агай, дөньясын онытып газетага текәлеп, өстәл янында утыра иде. Миңнулла кергәнне әллә сизмәде, әллә сизмәгәнгә салышты — күтәрелеп тә карамады. Тик Миңнулла юри каты итеп икенче тапкыр сәлам биргәч кенә, ниһаять:

— Безнең хәлләр ничава. Әмма моңарчы безгә ишек шакып керә торганнарые! — диде. Ләкин Миңнулланың комиссарлар кия торган күн тужуркадан, бил каешына наган тагылган икәнен күргәч, кинәт йомшара төшеп: — Әйдә, түргә уз! Сине кем дип белик, кайдан килеш? — дип тезеп китте. Урыныннан торып, өстендәге брезент кожаның рәтләгәндәй итте. Кожан эченнән пинжәк кигән, пинжәген каеш белән буган һәм шул каешына кылыч тагылган иде. «Волком дежурные булса кирәк» дип уйлап алды Миңнулла.

— Мин шушы авыл егете. Өяздән килдем. Исемем — Миңнулла. Фамилиям — Гайсин. Ә сез үзегез кем буласыз?

— Безме?.. Кая, дукумитыңны күрсәт эле, энекәш?

Миңнулла үзенең Карый волостена өяз вәкиле буларак, андагы эшләрнең торышын тикшерергә җибәрелүен, кирәк булган очракта хәтта волком составын үзгәртергә дә вәкаләте булуын раслаган мандатын сузды.

— Рәхим итегез!

Агай бик зур дикъкать белән, ләкин хәрефләрне йөзтүбән тотып «укый» башлады. «Шыр надан, ахрысы! — дип уйлап алды Миңнулла.— Кем икән соң бу?»

— Тәк,— диде агай, мандатны «укып» чыккач.— Пунятны. Значыт, үязни кәмиттән килгән иптәш буласың икән? Бик хуп, бик хуп, әйдә, түргә уз! Зерә дә кирәк чакта, зерә дә вакытында килеп төштең бит эле син! Әтү безнең эшләрнең рәте-чираты китеп, эт — баш, сыер — аякка әйләнеп барадырые монда. Фамилияңне ничек дигәниең эле?

— Гайсин. Ә сез үзегез кем буласыз соң?

— Безме? Без, иптәш Гайсин, шушы Карый авылыныкы Сабитов Сәгыйдулла булырбыз.
— Мин сезне нигәдәр белмим, Сәгыйдулла агай?
— Белмәвең гаҗәп түгел, беләм дисәң гаҗәп булырые. Күп еллар читтә йөргән кеше мин. Кайтуыма ике ай да тулмаган әле.
— Кайда идегез?
— Баку якларында. Нефте эшендә чиләндем.
— Нигә кайтасы иттегез соң?
— Туган илемне сагынып кайттым.
— Ә волкомда кем булып эшлисез?
— Кучер булып эшләгәнием. Ну, пука вулкум персидәтеле урынында эшләп торырга туры килә әле.
— Ә председатель үзе кайда?
— Аклар ягына сызды ул.
— Кайдан беләсез? Сезгә әйтеп киттемени кая барасын?
— Әйе. Мине дә үзе белән китәргә кыстаганые. Ну мин бармадым.
— Нишләп?
— Какуй интирис миңа симияне, бала-чагаларны ташлап, әллә кемнәргә ияреп йөрергә? Болай да өч ел чегән тормышында яшәттем инде ул бичараларны.
— Кем иде соң ул председатель?..
Сораша торгач, Миңнуллага менә нәрсәләр мәгълүм булды: июль ахырларында советка каршы элементлар Карыйда да фетнә күтәргәннәр дә элекке волком председателен атып үтергәннәр икән. Волком члennарыннан өч кешене кулга алып, каядыр озатканнар. Өяздән отряд китереп ул фетнәне бастыргач, волком аппаратын яңадан оештырырга туры килгән. Әмма әлеге шул контрларның тырышлыгы белән аның составына күбесе советка каршы кешеләр кертелгән. Председатель итеп билгеләнгән Шәйхелислам Шәйхетдинов белән секретарь итеп билгеләнгән Гарифулла Таҗиевлар, эшли башлауларының беренче көннәреннән үк контрлар коткысына бирелеп, шулар мәнфәгатен кайгырта башлаганнар. Ә менә хәзер, бу якларга кызыл гаскәрләр якынлашып, тегеләрнең артларына су керә башлагач, волком эшен ташлап, төннәләтеп аклар ягына сыптырганнар. Волость идарәсе комиссары шулай ук аларга ияреп тайган. Менә шул хәлләрдән соң, бөтенләй үк хуҗасыз булып тормасын дип, волком председателе вазифасын Сәгыйдулла агай үз өстенә алган да кулыннан килгәнчә эш итеп торган көне икән.
— Сез партия членымы?
— Түгел. Теләктәш ләкин. Партиягә дә керергә исәп бар иде дә, укый-яза белмисең дип, алмадылар.
— Минем мандатны укыдыгыз бит.
— Мин болай гына, фурмысы килсен өчен генә укыган атлы булдым.
— Председательлек итү читен түгелме соң?
— Бу заманда кемгә җиңел инде ул, энекәш. Кыен булса да түзәргә туры килә.
— Кайчаннан бирле председатель инде?
— Бүген атна була.
— Ниләр эшләдегез шул бер атнада?
— Шәйхеттинев заманында, фронтка кешеләр җыйнап җибәрергә кушып, өяздән кәгазь килгәние. Авылларга шул хакта күрсәтмәләр җибәрдем. Аннары авыл ярлылары кәмитетләренә прутналук җыярга кушып хәбәр иттердем.
— Ничек соң, үтиләрме күрсәтмәләрегезне?
— Бик алай ашкынып тормыйлар шул үтәргә. Бер кеше дә, бер олау икмәк тә җибәргәннәре юк. Миннән һаман сорашасың да сора-

шасын, үзеңнән дә сорыйм әле: син үзең нинди эш белән чыккан кеше соң? Әллә шул прутналук белән мибилизация буенча йөрүме?

— Алар белән дә кызыксынам. Эшлисе эшләр күп иде, Сәгыйдулла агай, ләкин сезнең монда кайдан башларга да аптырабрак калдым әле.

— Әгәр син безгә ярдәм итеп, безнең эшне юлга салырга дисең икән, иң башта син минем автарититны күтәрү чарасын уйла. Иң башта Карый халкы да, вулыс авылларындагы халык та мине персидэтел итеп танырга тиеш! Югыйсә, минем белән исәпләшергә теләмиләр. Бүтәннәре турында әйтеп тә тормыйм инде, хәтта хатынга тикле, синнән персидэтел чыкканчы кызыл кар явар, шайтан да кушмаганга йөрмә куштаннанып, дип нирбыга тия. Менә шуның авызын томалар өчен дә, бүтәннәрне ышандырыр өчен дә миңа бик һәйбәт кенә пичәт кирәк булыр.

— Волкомның печәте булгандыр ич. Кая соң ул?

— Кая булсын, әлеге шул Шәйхеттинев апкиткән инде. Син мине тыңлап бетер әле. Аннары килеп, вулкумда палитаттил, зиматтил, прутаттил вә һәм шуныңише башка аттиллар да булырга тиешле бит инде. Шуларны да тергезеп җибәрергә туры килер.

— Алары шулай. Ләкин, укый-яза белмәгәч, председатель булып эшли алырсыз микән соң, агай? Бик мәшәкатьле эш бит ул.

— Камунист түгел дип кенә әйтмәсәң, анысы өчен хафаланма, энекәш. Башы эшләп, сиклитары әйбәт булган нәчәнниккә уку-язуны белүнең алай артык кирәге юк аның. Дукумитларга кул куя белсә — шул җиткән.

— Ә секретарь итеп кемне алмак буласыз соң?

— Алып торасы юк, эшли инде ул.

— Кем ул, кайда?

— Үземнең малай. Йомыш белән бер җиргә генә җибәргәнием әле.

— Русча укый-яза да беләме?

— Әйе.

— Кайда укыган иде соң ул?

— Кайда дип, алай мәптәкләргә йөреп үк укыганы булмады булуын. Тегендә, нифте чыгара торган җирдә, урысы-татары бергә яшидерие. Урыс малайларыннан өйрәнгән инде шунда.

— Ничә яшьтә улыгыз?

— Озакламый унҗидегә чыга.

«Миннән бер генә яшькә кече икән,— дип уйлап куйды Миңнулла. — Чыннан да укый-яза белсә һәм тererәк булса, берәр эшкә тартырга кирәк булыр үзен».

— Волкомыгызның хуҗалары качып киткәнен өязгә нигә шушыңарчы хәбәр итмәдегез, Сәгыйдулла агай?

— Башта үзеңә бер сорау бирим әле, энекәш: син безгә ялгызың гына килдеңме, әллә этрәт беләнме?

— Отряд белән.

— Туты шул менә! Ярый әле, этрәт алып чыгарга акылың җиткән. Бер үзең генә чыккан булсаң, минем белән менә шушылай итеп төпченеп тора алмаган булырыең.

— Нишләп?

— Ялгыз юлга чыгулар бик хәвефлегә әйләнеп китте бу араларда. Әле кичәгенәк кенә Усыга барырга дип кузгалган ике кешенең башына җиткән контрлар. Кешеләре кемнәр диген әле син аның: алтмышка җиткән бер карчык та алты-җиде яшендәге бер сабый бала бит!

*Ахыры киләсе санда.*

## Әхсән Баянов

### Йолдызлар җитә һәркемгә

Нидер калды кырылып — уздың таптап,
Ишетмәде бәгырең һичнәрсә.
Күккә багып эзли бәхетен кеше,
Әгәр җирдә шатлык җитмәсә. —
Һәм эзләдең. Бар туасы туып,
Үлгән терелеп кайтса әгәр дә,
Синнән генә түгел, алардан да
Артып калыр йолдыз галәмдә.

Сайла, ярат! Салма тик кесәңә...
Җитми калса, күкләреңә ат
Үзең ясап. Тәрән, кәйлә белән
Чыгар айкап — күкрәгеңә так!
Инде тәмам алдар булса өметең,
Барма сорап әҗәт һичкемгә.
Кеше дигән горур исемең мактап,
Янар йолдыз каберең өстендә.

Күктә йолдыз җитә һәр кешегә,
Шатлыкларны тигез өләшә.
Йолдыз ача белмәс кешеләр генә
Ятлар өлешеннән көнләшә.

1974

### Урам көе

Чыккан ул җирнең үзеннән
Бодай кыягы белән.
Шуңа да туа-тумыштан
Җир дип, ил дип өзелгән.
Бураэналар буйлап йөргән
Сабанчылар артыннан.
Чалгы чыңы белән бергә
Кояшларга талпынган.
Йөргән сабан туйларында.
Калмый афәт-яулардан,
Кан, тир, яшь белән булыгып,
Ят кырларда аунаган.

Нишләтик, булган талымсыз —
Үзен һәркем сөйгәнгә,
Йөргән фахишләр белән дә,
Эчкечеләр белән дә
Кочаклашып урамнардан
Узган этләр өрдереп,
Шуңарга да аның даны,
Аты — урам көе бит.

Калаларны буйлап йөргән,
Киңәйтим дип ил-көнне.
Өстендә — җир тесле сырма,
Һәм балчыклы итеге...

Ертык эшләпәсен салып,
Сәхнәләрдән баш игән.
Кызыл авыз көйләр аннан
Хихайлап кайчак кәлгән.
Урам көе шулар белән,
Әллә чын, әллә юри,
Көязләнә, чытлыклана,
Тилерә, көлә, бии...

Иркә көйләр, көяз көйләр —
Исерткеч өермәле.
Кул-аяклар бутый-бутый,
Баш түбәле йөрмәле.
Тик кырга чыкса көязләр,
Яңгырда тузганактай
Сибелгәч, җиргә күмелгәч,
Шытмый бер үлән хәтта...

Урам көе — яшел диңгез,
Шаулый узган көнебез,
Ак чулпанлы таңнарыбыз,
Җиребез һәм күгебез.
Ул безнең моңсу Агыйдел,
Камабыз, Иделебез.
Сөембикә манарасы
Күк атылган сөнгебез.

Ул безнең тимер сүзебез —
Заводларда яңгыраган.
Ташый күмер, тоз, аракы
Баржалар, вагоннардан.

Егылса да таеп хәлдән,
Тәгәрәп баскычлардан,
Канлы тирләрен сөрткән дә
Яшь көнне алкышлаган.

Бәхәсләшмә, дәрестер бу —
Җыр белмидер чиркану.
Эт мәетен күтәреп тә
Каберлеккә илтә ул...

Тик таңнар-иртәләр аша
Күкләрдә чыңлый-чыңлый,
Кыз сафлыгы төсле көнне,
Җирне якты хис урый.
Чыңлый көй, чыңлый синең дан,
Синең җан, минем җаным.
Минем балам, синең балаң —
Карында нәселең, каның.

Булган ул борын заманда,
Бар һаман да — җил, сулыш.
Бар кайгы, бәхет, мәхәббәт,
Бар Табигать, бар Тормыш!
Ул чыңлый, чыңлый колакта,
Елларга чакырып хисне:
«Үлсәм исемем калыр илдә
Халкымның үзе төсле....»

1971—73

## Күнекмә

Моңсызлыкка, әй, күнекмә, күңел,
Дөньяң хәтта булса җитешле.
Ач күзеңне, син бит антидөнья
Хәбәрчесе анда, чит кеше.

Минутлар юк, көннәр — кино-лента,
Акрынайткан кемдер йөрешен.
Әллә атлый, әллә туктый кеше,
Кем белсен.

Көлү дә юк анда, елау да юк,
Тәрәзә ачсаң, керер җил дә юк.
Эшләү кирәк бәлки бер җүләрлек,
Гайбәтчеләр ярышып сөйләрлек?

Моңсызлыкка, әй, күнекмә, күңел,
Вакыт читләп узар бит сине.
Ташланыйк без күгенә гамьсезлекнең
Янып төшкән йолдыз шикелле.

1967

## Баш ияргә мөмкин

Табигатьтән сиңа баш бирелгән
Тик уйларга, иелергә түгел.
Бил бирелгән — бөгелергә түгел,
Кул бирелгән — төйнәлергә түгел,
Күз бирелгән — кызыгырга түгел,
Тез бирелгән — тезләнергә түгел.

Бил бирелгән, мәйдан уртасында
Егылсаң да, туры, сау кайтырга.
Кул бирелгән үрелергә күккә,
Йолдыз җыеп җиргә таратырга.
Күзләр — сокланырга киләчәккә,
Бүгенгене ләкин яратырга.

Яклар өчен җир бирелгән сиңа
Һәм матурлык атлы гүзәл зат та.
Күзләреңнән синең алып киңәш,
Кирәк чагын белеп аңлатыр баш:
— Тезләнергә мөмкин бары туган җиргә,
Баш ияргә — бары мәхәббәткә!

1974

## Син булганда

Яшел серем, урман күмгән яшьлек җирем,
Онытмасам җилләр телен, яфрак телен,
Мин кайда да ялгыз түгел.

Шау-шулардан, мәхәббәттән һәм дуслыктан,
Һәм бәхеттән, һәм үземнән — бар тормыштан
Арсам да мин... ялгыз түгел.

Яфрак кипсә, дулкын туңса, җилләр тынса,
Күзләр кысып, күк илаһи сүзләр куша —
Мин кайда да ялгыз түгел.

Әй, юлдашым, фикердәшем — яшел серем,
Ә картайсам, хыянәтсез бирдәнберем!
Мин кайда да ялгыз түгел...

Син булганда.

1974

●

Ник ашкынып китәм туган җирдән?
Хисләремне аңлап булмастыр.
Калды тагын, калды өзелеп сөйгән
Моңлы суым — Базы елгасы.

Китәм инде, ялыкканнан түгел,
Туган җирдән ничек бизәрсең.
Тар суларга сыймый ярсу күңел,
Киң суларда килә йөзәсем.

Җилләүләре, күкрәүләре белән
Озата барды сәер минутлар.
Әллә ялгыш, әллә каргыш шундый —
Яшен атып калды болытлар...

1954

●

Бу җырларда минем исем белән
Ялан аяк йөргән бер малай
Кайда хәзер, кайда? Колагымда
Тик тавышы чыңлап торгандай...

Әй, әйләнер идем аның белән
Саз-болыннар буйлап юлсыз да.
Ялан аяк йөргән шук малайга
Күрешергә диеп кул сузам.

Ә ул кача еллар аръягына.
Бу җырларда урын тар микән?
Малай, сине кемнәр эзли тагы?
Сагынучы бүтән бар микән?

Сагына сине Әшмән урманнары,
Кайдалыгың алар беләләр.
Мин тапмагач, кошлар белән бергә
Моңсу гына итеп көләләр.

1974

●

Мин югында кыен булган сезгә,
Базы буендагы үзәннәр.
Ярларыннан керәшәләр киткән,
Сазларыннан бизгән челәннәр.

Артык сагынып инде кипкән күлләр,
Көрәнләнеп көйгән келәмнәр.
Йортсыз, җырсыз калган бакаларым,
Каз-торналар җәфа күргәннәр.

Җир-су йөген бергә тарт, тарт диеп,
Тартайларым озак түзгәннәр.
Кайт, кайт, диеп түзгән-түзгәннәр дә
Кайтуымнан өмет өзгәннәр.

Инде кайттым, сез дә кайтыгыз, әй! —
Эндәшмиләр, ахры, бизгәннәр.
Мин югында кыен булган сезгә,
Базы буендагы үзәннәр.

Кыен булган...

1974

## Миләшең

Өй янында үсә миләшең,
Миләшеңә килеп эндәштем:
«Тәрәзәгә зинһар кагыл да,
Берәү, диген, өзелеп сагына.»

Уйларымны сиңа сөйләсен
Өй янында үскән миләшең.
Аңлатсын ул сагыну хәлләрен,
Сөюеңдә нинди тәм барын.

Үзе кызыл кебек булса да,
Тәлгәшендә сары төс яна.
Тәмнәрендә — минем күз яшем,
Өй янында үсә миләшең.

1952—73

## Әйләнмәле сәхнә

Алдыбызда — әйләнмәле сәхнә,
Музыкантлар,
Биючеләр чыга.
Сүз бирелә,
Эш бирелә
Шамакайга,
Жонглерга,
Гипнозчыга
Һәм җырчыга.

Ир-егетләр бөгелә, бии, чиный маймыл,
Ирдәүкәдән куркып чаба арыслан ул.
Чыга кызлар, тоткан кулга утлы хәнҗәр,
Акыра адәм, көлә җәнлек, мырлый җанвар.
Берәү ырлый, берәү ыргый, берәү сикерә,
Кемдер эзли, кемдер кача, кемдер шуа,
Кемдер куа, илне-җирне дөбер китерә.
Ихай-михай көлеп кемдер эчен уа.

Сәхнә инде гел, әлбәттә, әйләнмәктә —
Ир-егетләр һәм маймыллар китә артка.
Былбыл-кызлар, арысланнар оча бармыш,
Куллар чабып озата халык, мисле язмыш.
Искеләрен озата да яңаларын
Каршы ала куллар чаба-чаба тагын.
Яңа шаулый, искеләрнең эш бик хөрт тик:
Сәхнә артлый шыңшып йөри биюче эт...

Караңгыда күлмәгенә абынган да,
Җырчы бикә егыла язып шыңшый анда,
Ни булганын аңлый алмый, җыялмый һуш —
Шулай сәхнә чайкаламы, башмы сәрхуш.
«Браво, браво!» — зал ягыннан килә тавыш,
Абына-абына инде шунда чаба ялгыш.

Шаулы алкыш бүтәннәргә ләкин күптән,
Бу бикәне бәлки күптән онтып беткән.
Бикә кергәч, шул ялгыштан һәркем көлгәч,
Апаң таймыш караңгыга, түгеп күз-яшь.

«Ул тилергән, ул тилергән!» — күз бәйләнә,
Баш әйләнә, җир әйләнә, күк әйләнә.
Узып-тузып, артта кала илләр-көннәр,
Галиҗәнаб император һәм вәзирләр.

Вакытын белеп,
Һәм иблисләр,
Һәм аллалар
Мәңгелеккә
Ял алалар.
Һәм исемнәр,
Һәм җисемнәр килә-китә.
Кала бары иң зур алла —
Афродита.
Әйләнмичә,
Ул моң гына карап тора.
Елмайттыра,
Таныштыра,
Яраттыра.
Ярап тора — тормыш гүзәл, тормыш бара...
Җир, ахрысы, әйләнмәле сәхнә.

1973

●

М. Ю. Лермонтовтан

Мин төш күрдем, анда аерылыштык
Синең белән озак елларга.
Һәм уяндым, уянгач та ләкин
Күз яшьләрем акты елгадай.

Мин еладым төштә: мине, бәгърем,
Яратасың, имеш, син чынлап.
Һәм уяндым, күз яшьләрем тагын
Тыя алмый тордым бик озак.

1951

●

М. Ю. Лермонтовтан

Без аерылдык, сурәтеңне ләкин
Күкрәгемдә һаман саклыймын.
Якты көннәремнең ак шәүләсе,
Ул арттыра җанның шатлыгын.

Бирелсәм дә башка тойгыларга,
Мин аны һич ташлый алмадым.
Буш калса да храм, җуймый исемен,
Җиңелсә дә кумир — алла ул.

1951

## Бүредән алда

Кеше рәнҗетте гаепсез этне,
Маэмай үпкәләп читкәрәк китте.
Күпмедер минут узгач та тик эт
Гафу сорады, хуҗага килеп.
Ялагач кулын, болгагач койрык,
Яңарды дуслык, берни юк кебек.

Кешедә бүре яшәгән яшьтән,
Кешегә яшьтән нык ияләшкән.
Шушы бүрене,никтер, типкәләп,
Рәнҗетте хуҗа бер мәл тикмәгә.
Ә дуслык... дуслык бүренең анда
Үзеннән алда чапты урманга.

1974

## Юри генә

Уйный мәче тычкан белән юри генә,
Корбанының никадәрле интекканен,
Качмак булып кан йотканын, яшь түккәнен
Белми генә.

Тычкан белән уйный мәче инде менә
Дус шикелле сыйпап кына — ай, шаян бик!
Ят газаптан тәм табу юк, юк наянлык.
Белми генә...

Уйный мәче усаллыклар сизми бер дә.
Тик тычканга ни җиңеллек? Мәче азак
Кызык итеп кызып китеп, куя ялмап,
Белми генә.

Юри генә...

1974

## Габдулла Шәрәфи

# АККОШЛАР КАЙТЫР ӘЛЕ

хикәя



Түзмәде Әхмәтша бабай, бүген тагын китте. Юк, балык тансыклаудан гына түгел, бигрәк тә карчыгы Миңҗамал әбигә үч итеп китте бу юлы. «Соң, ике сүзнең берендә шуны китереп кыстырмаса! Имеш, миңа гына кирәк, имеш, персидәтел белән булышам, ясмыкны ястык итәм, янәсе. Итте ди, итмичә. Ул да пошынмагач... Миңа нәрсә, бер аягым җирдә булса, икенчесе гүрдә хәзер. Ун-унбиш чабак тотам икән... Әле шуның өчен дә кара тавыш чыга. Елгасы кибеп, күлләре коргаксып беткәч... Юк инде, юк, кая ул элекке бәртәсләр, җумбалар!.. Һе... Күзгә хәтле көтик, янәсе, тотарбыз, бүлербез, имеш. Тот соң, бүл соң, кем аңа каршы. Күлнең суын җибәр дә, имеш, капчыклап чумыр. Чирткән булып, капкан булып җаныңны кытыкламагач, балык тотумыни ул! Һе...»

Үзалдына шулай сөйләнә-сөйләнә, Әхмәтша бабайның таң белән күлгә барышы. Барышы дигәч тә, әллә ни барасы юк, Әхмәтша бабайларның мунча асларында гына ул, тау гына төшәсе.

«Күлен әйтер идем... Элек анда мунчалага дип юкә генә сала идек без. Аннан-моннан казыштырдылар да... Авыз суларын корытып, шуңа күл дип йөрмәсәләр. Маймычлар җибәргән булдылар тагын, адәм көлкеләре. Алкын елганы бусалар соң... Дию пәриләре күк машиналар була торып соң...

Элекке елларда, әле яшьрәк чакларында, бер табалык кына балыкны Миңҗамал җиңгәгез сыер савып көтү куган арада каптырып менә иде аны Әхмәтша абзагыз. Их, бар иде Алкын елганың алтын чаклары, мөлдерәмә вакытлары... Елга гынамы соң! Аңа тоташкан күлләр, тын култыклары күпме иде... Чуртаны кирәк икән, әнә Камышлы күлгә бар, корбандыр, бәртәстер ишесен теләсәң, Кәрәкә күленә томыр иден кармагыңны. Тирә-юньдә дан бер балыкчы иде дә бит Әхмәтша... Хәзер менә утыр инде, шушы күлдәвеккә табынып!..»

Әхмәтша бабай, уфтана-уфтана, сукрана-сыкрана, яр буенда бер ялгызы моңаеп, йокымсырап утырган карт өянке янына килеп чүгәләде. Аннары, кармагын сүтеп, җим каптырып күлгә ыргытты да, каз каурыеннан ясаган ак калкавычка текәлеп, тын калды.

Күзе калкавычта булса да, күңеле әллә кайларда иде Әхмәтша ба-

байның. Уза бит гомер дигәнең, әллә ни арада узып киткән. Әле кайчан гына кебек, югыйсә. Шулай бервакытны, күрше килененең буйга узып, ризык талымлап йөргән көннәре булды, ахрысы, энисе: «Улым, Хәтимә апаң балык ашыйсым килә дип әйтә», — дигәч, Кәрәкә күленә барып, кичтән ук кармак салып кайтты. Ә иртәгесен, менә бүгенгедәй таң тишегеннән торып, шул кармакларын карарга дип килгән иде. Күл кыриендагы җикән камышларын аралап су өстенә күз салса... шаккатты Әхмәтша. Кая карама анда — йомры-йомры төнбоек чәчәкләре. Талтирәкләр ышыгында тынып, каралып яткан шоп-шома түгәрәк күл өстендә ап-ак чәчәкләр. Кайберләре әнә хәзер генә ояналар, күз алдында ачылалар. Сизелер-сизелмәс талпынгандай итәләр дә, йокысы туеп күзләрен кинәт шар ачып җибәргән нарасый бала кебек елмаешып, нур сирпеп иртәнге кояшка багалар. Әхмәтшаның мондаен галәмәтне әле беренче күрүе иде. Юк, төнбоек чәчәкләрен түгел, аларның менә шулай җиңелчә генә сискәнешеп, назланышып күз ачу вакытларына беренче мәртәбә тап булуы. Әхмәтша, табигатьнең кеше күзеннән яшерергә теләгән шикелле эшләнә торган үтә дә пакь, үтә дә садә бу хикмәтенә туры килүеннән оялгандай каушап, бер мәлгә югалып калды...

Ак калкавычның бер тартылып, уйнаклап куюы Әхмәтша бабайны уйларыннан айнытып җибәрде. «Чү, чиртә түгелме соң?! Чиртә шул, чиртә!.. Яле, я... һап!.. Әй, мәхлук, бармак буе нәрсә... Кармагы белән үк йотмасаң! Нишләтим инде мин сине? Җибәрсәм, барыбер үләсең, мәчегә ярарсың әле, чум инде булмаса чиләккә...»

Әхмәтша бабай ташбаш малаен чиләккә салды да, кармагына яңа җим каптырып, тагын күлгә томырды һәм, бүленеп калган тәмле төшен күреп бетерергә ашыккандай, кабат баягы уйларына, яшьлегенә әйләнеп кайтты.

...Әллә ни мулдан булмаса да, бөтенләй үк буш кул белән кайтасы түгел, ярыйсы гына бер корбан, бер кара балык капкан иде ул чагында аның кармакларына. Кара балыкны җиңел генә суырып чыгарды, ә корбаны, ычкынырга тырышып, күрәсең, кармак җебен төнбоек сабакларына уратып, чуалтып бетергән иде. Чишенеп күлгә чуммыйча булдыра алмады. Бер җайдан, кызыгып, дүрт-бишләп төнбоек чәчәге дә өзеп чыкты. Әмма кызыгудан гына микән? Алай гына түгел иде шул, хикмәт монда бигрәк тә башкада, тиздән куенына керергә җыенып йөргән Миңҗамалында иде. Шуңа дип алып чыкты бит ул төнбоек чәчәкләрен.

Ун-уникe яшьләр булгандыр, икәүләп шушы күл янына килгәннәр иде. Төнбоек чәчәкләрен күргәч: «Ай, нинди матурлар!» — дип тәмам әсәрләнде Миңҗамал. Мондый хәлдән соң түзеп тора аламы инде егет буласы кеше. Үзенең әле рәтләп йөзә дә белмәвен онытып: «Хәзер алып чыгам мин сиңа аларны», — дип, тотты да сикерде күлгә, алакай. Чәчәкләр янына житеп, инде берничәсен өзгән дә иде Әхмәтша, инде чыгыйм дип кире дә борылган иде. Менә шул чагында сынатты да куйды. Сыңар кул белән генә йөзәргә бөтенләй дә өйрәнмәгән икән шул әле, калдырырга туры килде чәчәкләрне. Ике куллап маташа торгач та чак-чак кына чыгып житте. «Әллә нинди сөлекләр ябышкан»,— дигән булды аннары Миңҗамалга. Шул чактагы оятын бүгенгәчә оныта алганы юк Әхмәтшаның. Хәзер менә алып кайтсын әле ул аларны, куйсын әле тәрәзә төпләренә.

Әхмәтша, кеше бик үк кайнаша башлаганчы дип, чык ера-ера, болын аркылы турыдан гына авылга ашыкты...

Авылга кайтып житкәч, әлеге дә баягы, шул кеше күзенә чалынасы килмичә, Миңҗамалларга ындыр артлатып кына китте егет.

Менә ул аларның бәрәңге бакчалары турысына килеп туктады. Якягына карангалап алды да киртә аркылы бакчага сикерде һәм, буразна буйлатып кына барып, арт капкадан лапаска керде. Керсә, ни күрсен,

лапасның бер почмагында, тәбәнәк бүкән башына утырган килеш, чаж-чож китереп, Миңҗамалның әнисе сыер сава. Ярый әле, керү уңаена арты белән утырган. Үзе сава, үзе тагын шул арада:

— Җәсәнә... харап инде... Синдә генә булган икән... Чү, чү!.. — дип, янәшәдәге аралыктан чыгарга өтәләнгән бозавына таба башын сузып мөгри, сабырсызлана башлаган сыерын тыярга азаплана. Әйдә, сөйләнә бирсен, Әхмәтшага шул гына кирәк тә, мыштым гына кереп китсен әле ул менә...

Үтте егет, сизмәде бугай әби буласы кеше...

Уйлары шул турыга җиткәндә, тагын бүленде Әхмәтша бабай. Бу юлы калкавыч уйнаклап-нитеп тормады, балыкмы — нәрсә, аны кинәт кенә тындырып, су астыннан өстери үк башлады. Әхмәтша бабай, каударланып, кармак сабына ябышты һәм:

— Яле, яле... Әттә-тә-тә... Һап! — дип сөйләнә-сөйләнә, кул яссуы кадәрле кызыл канат тартып чыгарды. «Менә монысы ярый, ичмаса, баягысы пше генә түгел. Әйдә, чум, җаный, чиләккә».

Әхмәтша бабай, уйларыннан бүленә-бүленә, өзелеп калган хәтер җепләрен ялгый-ялгый, ыбыр-чыбыр балыкларны күлдән суыра тора.

«Их, ул яшь чаклар, егет вакытлар... Һәр кыланышың бер гомер икән ләбаса... Әле бүген генә булган кебек ич һәммәкәе дә...»

Миңҗамалы йоклаган ак келәт тәрәзәсенә Әхмәтшаның элек тә килгәләгәне бар иде. Анысы шул күз бәйләнгәч, караңгы капкан тирәләрдә була торган иде. Ә бүгенгедәй яп-яктыда, көн балкышында бу тирәдә алай ук әрсезләнеп йөргәне юк иде әле. Йа хода, лапас белән келәт арасы оҗмахның бер почмагы икән ләбаса! Күр инде бу бакчаны! Күр инде бу бояр гөлләрен! Булса да булыр икән. Аклы-кызыллы, зәңгәрле-чуарлы, граммофон торбасы кебек чәчәкләре белән балкып, дөньясын нурга күмеп ташлаганнар. Җитмәсә тагы, әнә чәчәкләр арасыннан ак келәтнең каерып ачылган бизәкле тәрәзәсенә корылган кардай ак пәрдә җилфердәп тора. Шушы илаһи нурда коенып, шул сихерле тәрәзәгә баккан килеш, мәңге кузгалмыйча торыр иде дә Әхмәтша, юк шул, булмый шул. Ишетә ич әнә, чаж-чож китереп, сузыпсузып саумый бит хәзер әби буласы кеше, чиләккә төшкән сөт тавышы кисәк-кисәк кенә, бетәм-бетәм дип кенә, чәш-чеш итеп кенә ишетелә башлады. Йомышны үтәргә дә яхшы чакта табанны ялтыратырга кирәк.

Әхмәтша, гөлләрне имгәтмәскә тырышып, тиз генә тәрәзә янына килде. Килде дә, кулындагы төнбоек чәчәкләренә карап, бер мәлгә икеләнеп калды: «Шулай гына куйыйм микәнни? Шиңмәсләрме?..» Һәй, бирим дигән колына... Әнә ич, рәшәткә башында нихәтле чүлмәк! Егет чүлмәкләрнең берсен алды да, келәт почмагында торган кисмәктән су чумырып, төнбоек чәчәкләрен шунда утыртты. Аннары, песи кебек кенә, кабат тәрәзәгә елышты һәм, пәрдәнең бер почмагын гына ачып, төнбоеклы чүлмәкне тәрәзә төбенә куйды. Келәт эченнән ул-бу сизелмәде, шылт иткән дә аваз юк. Йоклый җаный... Назлый әнкәсе, җәлли кызын... Әнә бит иртәнге һавага дип тәрәзәсен дә ачып куйган. Киткәнче, үз кулымда чагында йоклап калсын ди торгандыр инде.

Лапас аркылы хәзер Әхмәтшага юл юк иде инде. Шуңа күрә ул, сузан буйларын сындырып, урам капкасыннан мыштым гына чыгып шылды...

Ә кичке уенга Миңҗамалы, әллә кайдан ук җаныңны эретерлек наз бөркеп, айның ундүртләре кебек балкып, ашкынып килгән иде ул көнне...

«Әй, кортка онытты микәнни соң шул вакытларын. Миңа гына кирәк, имеш, күле дә, елгасы да. Әнә, табып карасыннар хәзер им өчен хет бер генә төнбоек чәчәген. Табарсың, бар. Кая карама — чокыр да чакыр, ком да тузан. Ут себергәнмени дөньясын!»

Күңеле тәмам ургып, балыгына да, күленә дә кул селтәп, инде кайтып китәм дип кенә торганда, Әхмәтша бабай янына колхоз председателе Билал килеп туктады.

— Әхмәтша бабай, ни кылануың бу, ә! Олы кеше ләбаса син. Ничәмә-ничә әйттем үзеңә... Сиңа карап бүтәннәр узына бит.

— Һәй, каныктың ла соң. Тотмыйм мин синең ул карп-марпларыңны, тотмыйм. Котың очмасын... Әнә, кара чиләкне...

— Син тотмасаң, башкалар тота... Бер дә сайлап тормыйлар.

— Әй, улым, улым, дисәм дә инде үзеңне... Күрмисеңмени соң? Сасыган бит күл... Әнә кара су өстен, нихәтле балык үлгән! Авылның бөтен чүп-чары төшә бит шунда. Ә чыгар җире юк. Алкын елганы буСак соң!..

— Һидият абый белән сүз куештыгыз мәллә?! Берегез болын дип, икенчегез елга, күл дип колак итемне ашыйсыз. Вакыты җитәр менә, буарбыз. Син уйлаганча ансат кына түгел лә ул...

— Түгел, түгел, имеш... Кем әйтә сиңа ансат дип. Ат белән дә, кулдан ташып та буа идек без аны тегермән бар чакта. Бездән ары тагын башка авыллар... Алар да буа иде... Син бала идең шул әле... Шомырт башыннан мәтәлеп төшкәч соң?!. Мин сөйрәп чыгардым ич елгадан. Анысын онытмагансыңдыр, нибуч... Әнә чыпчык атлап чыгарлык бит хәзер елга аркылы... Һидият дөрес әйтә ул, болыны да харап булачак. Их, яшь чагым булса кана...

— Бер дә харап булмас. Сукалыйбыз аны, ашлык чәчәбез. Күле дә чистарыр... Ә син, Әтмәтша бабай, шулай да уйла әле, котыртма халыкны.

— Юк инде, җаный, бигайбә, киләм мин монда, аты коргыры, киләм. Балык дип җәһәннәм астына йөрер хәлем юк минем хәзер. Син лутчы әнә без әйткәнне тыңла. Су кирәк авылга, елга кирәк, күл кирәк. Ә кирәк ул, Билаттин улым, тирәкне ега. Менә шулай... Хуш әлегә...

Әхмәтша бабай, бер кулына чиләген, икенчесенә кармак сабын тоткан килеш, инде болай да сизелерлек булып чыккан җилкәсен отыры күтәрә, кабарта төшеп, салмак кына атлый-атлый өйләренә менеп китте. Алды бераз салынып, арты күтәрелебрәк торган иске сырмасы, шактый ук ямьшәйгән тула эшләпәсе аның бу иртәдәге кыяфәтенә нәүмизлек чалымнарын тагын да өсти, арттыра төшкән иде.

Ә Билал Алкын елга аша күперсез-нисез генә сузылган юл буйлап күрше авылдагы колхоз идарәсенә китте.

*

* *

Әхмәтша бабай, кармак таягын өй почмагына сөяп, балыклы чиләген болдырга куйды да ишегалдына күз йөртеп чыкты. Аннары, ашыгыч бер эшен исенә төшергән кеше төсле, кабаланып лапаска кереп китте. Ә болдырның икенче башында, кояшка күзләрен кыскалап, рәхәткә чумып яткан зур гына соры мәче, әйтерсең шуны гына көткән, урыныннан сикереп торды да хуҗасы куеп калдырган чиләк янына килде. «Карасана... Сизгән иде шул аны, дөрес икән, балык ич чиләктә!» Борынын да төртеп карый Миауша, тәпие белән дә үрелгәли, әмма морадына ирешә алмый, чиләге тирәнрәк.

«Кирәк иде бит, югыйсә, берсеннән генә булса да авыз итәсе иде... Их, тәтеми, ахрысы... Нигә дип тузына соң әле бу хуҗа лапас бетереп!» Мәче, шунда таба башын борган килеш сагаеп, шөгыленнән туктап калды. Ә лапаста тавыш, ыгы-зыгы һаман көчәя бара:

— Себерке сабына хәтле пычратмасагыз... Көш, игелексезләр, көш!..

Ул да түгел, кыткылдый-кыткылдый, лапастан башта яныл торган кызыл әтәч, аның артыннан очына-тузына тавыклары, үрдәкләр атылып чыкты. Һәм менә, кулына саплы себерке тотып, эшләпәсе күзенә үк төшкән Әхмәтша бабай үзе күренде.

Хәерлегә түгел бу дип, мәче дә бер якка таярга уйлаган иде дә, болдыр кырыенда гына торган чиләккә орынып китте. Чиләк ишегалдына мәтәлде, балыклар чәчелде. Песи, хуҗасыннан шүрләсә дә, җирдә ялтырашып яткан балыкларны күргәч түзмәде, болдырдан сикереп төште һәм, — тамак тәмугка кертә дигәннәре хак икән, — Әхмәтша бабайның әле тоткан чакта ук: «Менә монысы ярый, ичмасам» дип мактаган бердәнбер кызыл канатын эләктереп баскыч астына шылды.

Ул арада, чәчелеп яткан балыкларны үрдәкләр дә күреп алып, болдыр тирәсенә йөгерешә башладылар. Килеп җитүләре булды, Әхмәтша бабай күзенә төшкән эшләпәсен күтәрергә дә өлгермәде, балыклардан җилләр исте. Үрдәкләр муеннарын як-якка сузгалап, эзләнгәләп карадылар да, күзләренә башка берни дә чалынмагач, бигрәк аз булды ла бу дигән кебек, «вак-вак-вак» дип, ава-түнә капкага таба китеп бардылар.

Лапас янында себерке сабын сөрткәләп маташкан Әхмәтша бабайның инде сүрелеп барган ачуы, үрдәкләрнең бу кыланышларын күргәч, тагын бер кат сиздереп алды:

— Вак, вак, имеш. Һәй, ачкүзләр. Эресен әнә үзегез төшеп тотыгыз күлгә!.. Һе...

*

* *

Әхмәтша бабайның елга, күл, болын хакындагы сүзләре кичәдән бирле болай да әйле-шәйле йөргән Билалның ярасына тоз салгандай булды. «Әллә идарә утырышы турында ишеткәнме картың? Юктыр, өлгермәгәндер әле, утырыш кичен соң гына бетте ич. Алай да нәкъ Һидият абый әйткәннәрне сукалый... Саттар абый да никтер каршы чыкты. Югыйсә, үзе дә председатель булган кеше ләбаса. Ул елганы, бу болынны юньгә китерү өчен хәзер... Явымлы елларда әле бер хәер, азмыкүпме печәне була, терлек йөртәсең. Ә быел... Дөрес чыгардык карарны, сукаларга кирәк. Ә алар икәү әнә каршы, авыл Советы сессиясенә куябыз, диләр. Әйдә, куйсыннар, без дә дәлилле белербез».

Дүрт авыл арасында җәелеп яткан болын уртасына баскан килеш, як-ягына карана-карана, Билал шулай байтак кына уйланып торды. Аннары, кызу-кызу атлап, юлын тагын дәвам итте. Менә ул Алкын елганың Зирекле авылына орынып ук «аккан» икенче тармагына килеп җитте. Текә юлдан йөгереп аска төште дә, елга төбендә юаш кына чылтырап яткан тар суны сикереп, икенче ярга күтәрелде.

Идарәгә якынлашкан саен болын кайгысы арткырак исәпкә кала барды. Председательнең күңелен хәзер башка уйлар, башка борчулар биләп алган иде. Әнә бит, игеннәр өлгереп килә, ә комбайн турында хәбәр-хәтер юк. Узган атнада ук инде тиздән кайтыр шикелле әйткәннәр иде әйтүен. Шуннан бирле үзенең дә белешкәне булмады, эш белән мавыгып, ничектер, онытыбрак җибәргән. Кичәге тарткалашулардан соң төн йокламый ята торгач, кылт итеп шул комбайн исенә төште Билалның. Иртә таңнан торып идарәгә ашыгуы да шуңа иде. Кирәкле кешеләре таралышып беткәнче, район белән сөйләшеп алырга иде исәбе. Инде менә килеп җиткәч, бүген якшәмбе икәнен хәтерләп, кабинетына керәсе килмичә, ишек төбендә туктап калды. Аннары, кесәсеннән папирос чыгарып, шуны бармак арасында әвәли-әвәли, болдырга барып утырды. Әмма папиросын кабызырга да өлгермәде, ачык тәрәзәдән телефон чылтыраганы ишетелде. Трубканы идарәдә дежур торучы Әхтәм бабай алды:

— Кем бу?.. Районнан дисеңме?.. Юк шул, юк, килеп җитмәде әле персидәтел...

Билал утырган җиреннән сикереп торды да тәрәзә янына атылды.

— Әхтәм бабай, куйма трубканы, әйт тизрәк, килде диген!

— Карале, кем, тыңлыйсыңмы?.. Килде персидәтел, килде...

Бабай телефон трубкасын тәрәзә аша Билалга сузды.

— Илдар Хәерович, сезме бу?.. Шулайдыр дигән идем... Ураккамы?.. Бүген-иртәгә дип торабыз... Китче!.. Бик кирәк иде, бик... Кеше дисезме?.. Җибәрәм, җибәрәм... Әйе, әйе, иртәгә... Рәхмәт, Илдар Хәерович, рәхмәт... Бүген ял көне булгач... Өегездәнмени?.. Рәхмәт инде, бик зур рәхмәт...

Билал трубканы бабайга кире сузды да, малайларча җилкенеп, бер-берсенә шап-шоп суга-суга, кулларын угаларга тотынды.

— Тагын бер комбайн кайткан безгә, Әхтәм бабай, аңладыңмы?!

— Аңламый соң, ишетеп тордым ич.

— Шәп... Самый вакытында җибәргәннәр.

— Шулай булмыйни... Бирсен ходай, Билал энем, бирсен. Бә-әк кирәкле нәстә...

— Инде кайтсаң да ярый, Әхмәт бабай. Мин әле монда булам. Бер уңайдан Илһамнарга да сугыла кит, эшкә барышлый минем янга керсен.

— Кайсы Илһамнарга дисең, Билал энем?

— Сезнең очта Илһам бер генә ич инде. Механикны әйтәм.

— Ә-ә, ярый, ярый, киттем, алайса.

Билал кабинетына кереп, өстәл янына утырган гына иде, тыштан Әхтәм бабайның кемгәдер җикеренгәне ишетелде.

— Һәй, норсыз... Үләсен дә белмәс. Башка җирдә беткәнмени... Монда килеп кысылмасаң?!.

Билал, тәрәзәгә үрелеп, урамга күз салды. Аклы-каралы зур гына кәҗә идарә йорты алдындагы бакча рәшәткәсенә башын тыккан да хәзер әнә чыгара алмыйча тыпырчына. Әхтәм бабайның сукрана-сукрана шуны коткарырга азаплануы иде.

— Баш тыкканчы мөгезең барын да онытмыйлар аны, мәнсез!..

Әхтәм бабай, кәҗәне ничек кирәк алай ычкындырып, инде китәм дип кенә торганда, муенына бәйләнгән кызыл чүпрәкне шәйләп алды. Кәҗәнең ул каршы йортта гына торучы Гарифә карчыкныкы икәнен белә иде. Әле менә кызыл чүпрәген күргәч, көлеп җибәрде. Колхозлашып, беренче тапкыр уракка төшкәч, бөтен хатыннарны уздырып, Гарифә гел алда барган иде. Шуннан соң «Пионер ул безнең Гарифә» дип, стена газетасына язганнар иде үзен. Тәки тагылып калды пионер дигән исем Гарифәгә. Әхтәм бабай шул дәртле елларны, шуңа бәйләп, күрәсең, үзенең яшьлеген дә искә алып, тирән генә бер көрсенеп куйды. Аннары:

— Пионер башың белән соң... Оялмыйча, — дип, кызыл чүпрәкне капшап, кәҗәнең маңгаеннан сыйпаштыргалап торды да, сыңар аягына аксый-аксый, үз юлына китеп барды. Ә сакалбай, Әхтәм бабай киткән якка карап, әллә аны үчекләп, әллә инде рәхмәт әйтеп, бер мәэлдәп куйды да рәшәткә арасыннан баш сыярлык икенче урын эзли башлады...

Ярата шул карусыз картны Билал. Әле председатель итеп сайланган гына чакларында, идарәдән кеше тынгач, икәүдән-икәү генә калып, төн урталарына хәтле сөйләшеп, киңәшеп утырган вакытлары күп булды. «Син, энем, — ди иде аңа Әхтәм бабай, — башта тамырына кара эшнең, тамырына, Саттар абыең шикелле. Әйт дигәнгә һәйт дип торма, үз башың бар, гыйлемең житәрлек... Саттар абыеңны әйтәм әле. Талкып та карадылар кешене теге вакытта, үләл турысында. Тәки үзенекен итте итүен, әмма бетерешә соңыннан шулай да. Сугыштан кайткан авыруы яңарды. Югыйсә кана... Ә син, энем, борчылма, батырып эшлә, батырып. Хәзер инде... Кая ул...»

Гарифә карчыкка йорт саласы булгач та Әхтәм бабай йөргән иде бөтерелеп. Идарәдә сүз күп булды бу хакта. «Урыны бик җайлы — авыл уртасы, клубы, кибете, почтасы шул тирәдә, әллә икенче җиргә күчерәбезме карчыкны? Бер башына ташпулат салмабыз бит инде!» — диючеләре дә табылды. Әмма Билал: «Гомер иткән нигезеннән кешене ничек кузгатмак кирәк, — дип каршы төште. — Үзе риза булса, сүзем юк, күчсен, ә болай ярамас. Салабыз икән, зур итеп, матур итеп салырга кирәк»,— диде. Шулай килештеләр дә. Инде карчык белән сөйләшәсе калды. Әмма бу нәрсә йорт салудан да кыенрак булып чыкты. «Шушысын гына сиплӛп бирсәгез дә миңа бик җиткән, балам. Күпме гомерем калгандыр, зинһар, зурдан купмагыз, мин кем ул кадәре. Икенче урынга да күчәсем килми, балам»,— дип, яулык чите белән күзен сөртә-сөртә бик ялварып калды Гарифә әби.

Күңеле кузгалып, каефсезләнеп чыкты Билал Гарифә карчык янынан. «Күчү турындагысын ялгышрак ычкындырдым, ахрысы. Анысын әйтмәскә үк иде. Белә торып бит, шайтан алгыры». Әмма карчыкны ничек тә күндерергә кирәк иде. Икенче көнне Билал: «Син үгетләп кара әле» дип, Әхтәм бабайга кушты.

Әхтәм бабай кергәндә Гарифә әби бер ялгызы, нәүмиз генә чәй эчеп утыра иде.

— Ни хәлләрең бар, Гарифә? Күптән сугылганым юк иде үзеңә.

— Кермисең шул, Әхтәм, күренмисең бу араларда. Ашым аш, йокым йокы түгел әле кичәдән бирле.

— Ник алай?..

— Персидәтел кергән иде дә... Эчем бик пошып калды. Күчерсәк ничек булыр икән, Гарифә әби,— ди.

— Дөрес аңламагансың син, Гарифә. Кысыр хәсрәт белән утыруың икән ич.

— Нишләп дөрес булмасын. Нигә миңа шул кадәр зур өй. Кеше көлдереп, оялмыйча...

— Әй, Гарифә, Гарифә. Котың очкан икән. Булса соң, зур булсын. Ахырысын бер дә уйламыйсыңмыни? Яшең бара лабаса. Ялгыз башың дим... Нишләрсең? Әнә укытучы кызларны кертерсең. Я булмаса башкасын... Утыны-ние дигәндәй... Колхоз бирә ич.

— Анысы алай да...

— Алай да түгел, болай да түгел, ризалаш. Билал кушты миңа синең белән сөйләшергә. Борчылмасын, рәнҗемәсен безгә дип әйтергә кушты. Зур йорт салырга рөхсәт бирмәсә дип кенә әйткән сүз ул, ди.

— Бигрәк инде, Әхтәм...

— Нәрсәсе бигрәк?.. Син, Гарифә, үзеңне генә уйлама. Җитәкчеләрнең дә хәленә кер. Авыл уртасына, идарә каршысына тавык кетәге салып булмый бит инде хәзер. Бу тирәдә әллә ниләр булачак әле, күрдем мин рәсемен. Шатланырга кирәк.

— Шатланмаган кая инде ул, рәхмәттән башка бер сүзем юк. Әле болай кинәт кенә... Мә сиңа, карчык, йорт, имеш...

— Соң, ни дип әйтим Билалга?

— Ярар инде, алайса, Әхтәм, салсыннар, күчерә генә күрмәсеннәр.

— Шулай диләр аны, җүләр. Югыйсә соң, балалар күк... Әйдә, яса инде болай булгач миңа да бер чынаяк. Сиңа тукый-тукый авызым кибеп бетте...

Берне генә дип тотынган Әхтәм бабай, яңа аертылган бәлны капкалап, сөйләшә-сөйләшә эчә торгач, онытылып китеп, әллә ничә чынаякның башына җитте. Гарифә әби самаварны иеп үк агыза башлагач кына исенә килеп:

— Һай, һай, һай, Гарифә, бу кадәрле дә тәмле булыр икән чәең,

тәмам эредем, — дип, түбәтәе белән битен җиллләтә-җиллләтә, урыннан кузгалды.

— Бик харап инде. Әллә нигә бер кереп...

Әхтәм бабай чыгыйм дип инде бусаганы ук атлаган иде. Шул чагында Гарифә әби, тагын нидер әйтәсе килгән шикелле талпынып торды да, булдыра алмагач, йөзенә яулык читен каплап, мич буенда торган сандык өстенә утырды. Карчыкның тавышы-тыны юк, бары тик иңбашлары гына сизелер-сизелмәс калтырана иде.

Әхтәм бабай, чыгасы җиреннән туктап, әле генә торып киткән урындыгына кире барып утырды да башын иеп уйга калды.

Берсе бер сүз дәшми-нитми озак кына утырдылар. Һәм, ниһаять, Гарифә әби йөзеннән яулыгын алды да, яшь аралаш елмаерга тырышып:

— Миннән соң дим, Әхтәм, ә... Барыбер колхозга кала ич ул, имә?... — дип куйды.

*

* *

Шәп итеп салдылар Гарифә әбигә йортны. Зур итеп, биек итеп. Тәрәзә тирәләрен бизәкләп, челтәрле кәрнизләрен буяп, түбәсенә шифр да ябып җибәргәч, урам өсте ялт итте. Гарифә әби үзе дә, яңа салынган йорты кебек, эчтән-тыштан балкып, яшәреп киткәндәй булды. Яулыгын артка чөеп, итәкләрен кыстыргалап өй тирәсендә ап-ак йомычка җыеп йөрүләре узган-барганнарга да бер куаныч, бәйрәм иде.

Мал-туар таптамаган ишегалды ямь-яшел чирәм. Урта бер җирдә ап-ак булып зур гына ялпак таш ята. Таш кырыена, дутыш күгәрченедәй бүксәсен киереп, җиз комган менеп кунаклаган. Бары да әйбәт, барысы да күзне иркәли. Тик ишегалдын әйләндереп алган иске читән генә җитәкчеләрнең эчен пошыра иде. Әмма Гарифә әби: «Галиуллам төсе ич, Галиуллам истәлеге, анысы гына булса да калсын», — дип кырт кисте. Бу юлы инде Әхтәм бабай да югалып калды. Чөнки читән аның үзенә дә бик газиз, бик кадерле иде.

Кече туганнары вак булгач, Галиулла олыгаеп кына башка чыккан иде. Шуна күрә капка-койма өлгертергә хәле дә, арасы да булмады. Алкын елга буеннан тал кисеп, Әхтәм бабай белән бергә үргәннәр иде бу читәнне. Чатлыктагы тал казыкның берсе инде шул елны ук тамырланып яфрак җибәргән иде. Хәзер әнә нинди зур тирәк булып үсеп житте. Ә елга буенда талларның эзе дә калмады...

Озакламый сугыш башланды. Галиулла белән алар бер көнне үк чыгып киттеләр. Әхтәм менә, аксап булса да, әйләнеп кайтты, ә Галиулла дусына туган туфракка аяк басулар насыйп булмады.

Шулай да Гарифә әби белән тагын бер сөйләшергә туры килде Әхтәм бабайга.

— Бала булмасана, Гарифә, — диде ул аңа. — Асыл ташка чуен балдак ич бу килеш. Бик телисең икән, әнә, ишегалды ягыннан бер торык калсын. Истәлеккә шул җитәр...

Ишләсен Гарифә әби, кордашы, иренең яшьлек дусы шулай үз итеп үгетләгәч, күнмичә дә хәле юк иде...

*

* *

Билал, тәрәзәдән аерылып, аны-моны караштырыйм дип кенә торганда, кабинетка Илһам килеп керде.

— Исәнмесез, Билал абый! Мине чакыргансыз икән.

— Ничек болай бик тиз? Әхтәм бабай әле киткән генә иде ич.

— Каршыга очрады ул... Комбайн кайткан, ди, дөресме бу хәбәр?

— Әйе, дөрес. Иртәгә менә Салих белән шуны алып кайтырсыз. Куансын инде. Югыйсә, быел да шул Нух арбасына калам дип теңкәгә тигән иде.

— Беткән шул комбайны, бик беткән. Әле дә тырышты инде кеше дигәнең.
— Ярар, хәзер минә янасына утырыр... Карале, Илһам, кайчан өлгертәсез бульдозерны? Көн аязында торбаларны күмеп бетерәсе иде. Бигрәк күз алдында, урам уртасында бит. Канауны әйтәм. Бала-чага уйный... Мал-туар төшүе бар.
— Бездән тормый, Билал абый, запчасть юк ич. Кырык-илле метр гына араны болай да күмеп була инде.
— Була, була... Каян табасың хәзер кешене?
— Беткән ди Ак Чишмәнең үзендә карт-коры. Авыр эшмени, иш тә төшер, иш тә төшер. Суы булгач, рәхмәт әйтсеннәр.
— Белмим шул. Силоска да җиктек үзләрен, өшәнгәннәрдер. Һаман-һаман килешеп бетәр микән?
— Килештерсәң килешә ул, Билал абый...
Илһам сүзен әйтеп бетермәде, ишектән Ак Чишмә авылындагы бригадир Фәрит килеп керде.
— Исәнмесез!.. Иртәләгән сез бүген.
— Үзең дә соңга калмагансың бит.
— Әнә, Билал абый, бригадир сөйләшеп карасын үзенең картлары белән.
— Ни булды, нәрсә турында?
— Булмады ла... Су торбаларын тизрәк күмдерәсе иде дим.
— Кирәк иде, кирәк. Илһам ич... шул бульдозерны рәтли алмый.
— Аның әнә үзенең бер дә исе китми, картларын кушсын, ди.
— Ә-ә... Юк инде, агайне, җитәр, яхшы түгел...
— Ник, Фәрит абый, Әхмәтша бабайны кузгата алсаңмы?!.
— Ай-һай... Минә председатель сөйләшеп караса гына инде. Ә ник, Билал, иләп кенә, ә? Үземә уңайсыз, билләһи. Оялам. Болай да инде...
Билал күзендә шаян очкыннар уйнатып механик белән бригадирга карап торды да ризалашкандай итеп әйтеп куйды:
— Ә син, механик, бульдозерны барыбер тизләт!..



*
* *

Билал башлап Әхмәтша бабайга сугыласы итте. Тик минә талканы бик коры картның. Бу арада бигрәк тә сәерләнеп китте кебек. Әллә Билалга гына шулай тоеламы? Иртә белән юкка бәйләнде, ахры, юкка рәнҗетте...
Капка төбендәге эскәмиядә утырып торган Миңҗамал әбине күргәч, Билал адымнарын кызулата төште. «Шәп булды әле бу. Кем белә аныкын, капылт кына килеп кергәнче...»
— Ни хәлләр, Миңҗамал әби, исән-сау йөрисеңме?!.
— Шөкер әле, Билаттин улым, шөкер. Безгә килүең түгелдер ич?
— Сезгә шул, Әхмәтша бабай янына иде. Ничек соң кәефе?
— Иртәдән бирле көйсезләнебрәк йөрде дә... Ятып тора иде әле.
— Алай икән... Ярый инде, алайса. Күл янында сүзгә килгән идек шул. Икенче әйләнермен әле...
— Йомышың бар идемени? Хәзер дәшим әле үзен. Йоклавы түгел ул... Син аңа карама. Картлар күңеле пыяла инде ул, тоттың исә уала. Ә болай, салам ялкыны гына ул, гөлт итеп кабына да сүнә. Хәзер, хәзер...
Байтак көтте Билал. Һәм минә шыгырдап өйалды ишеге ачылды, аннары капка артында кыштыр-кыштыр аяк тавышы ишетелеп торды да, ниһаять, җилкәсенә сырмасын салып, аягына киез ката кигән Әхмәтша бабай килеп чыкты.

— Ә-ә!.. Билаттин, күптән күрешкән юк иде. Нигә монда гына утырасың? Әйдә, өйгә керик. Миңҗамал әбиең чәй яңарта калды.

— Рәхмәт, Әхмәтша бабай, вакыт бик тар.

— Соң?..

— Соң дип... Су торбалары күмелми ята. Идарәдә киңәштек тә менә, тагын сезне борчырга булдык.

— Ничәнче бригада соң без, ә? Хет номерын әйтсәгез икән! Югыйсә... нәрәткә генә кертәсегез калды инде. Юк, булмый миннән, бигайбә, кәефем юк.

Әхмәтша бабай инде кереп китәм дип капка келәсенә үк тотынган иде.

— Башкаларга әйтеп мине калдырган, кинә тота икән дип үпкәләмәсен дигән идем. Ярый, алайса, Әхмәтша бабай, бүтән борчымабыз, — дип, борылып та карамыйча, Билал китеп баргач, карт капка баганасына сөялеп туктап калды. Аннары, иңбашыннан шуыша башлаган сырмасын күтәрә-күтәрә, эскәмиягә барып утырды.

Озак утырды Әхмәтша бабай. Тик Миңҗамал әби, баскыч төбенә чыгып:

— Атасы, ник кермисез инде, чәй ясыйм,— дигәч кенә кузгалды. «Һе!.. Үпкәли ди, үпкәләмичә. Тапкан үпкәләр кеше...»

Чәе чәй булмады Әхмәтша бабайның. Капка төбенә дә ничә чыгып, ничә кермәде. Шулай бер чыгып, бер кереп, әрле-бирле йөри торгач, баскыч төбенә килеп утырды да карчыгына кычкырды:

— Кая, чыгар әле минем итекне!..

Озак та үтми: «Кая барырга җыенасың?» — дип, итек күтәреп, Миңҗамал әби килеп чыкты.

— Кая барсам да барырмын... Үпкәлим ди... Тапкан...

Әхмәтша бабай, үзалдына шулай сөйләнә-сөйләнә итеген киеп алгач, торып басты да тагын Миңҗамал әбигә кычкырды:

— Күрәк кайда?!

Бу юлы инде Миңҗамал әби өй эченнән генә җавап бирде:

— Ах алла! Үзең тотасың ич, урыныңдадыр. Карап ал шунда.

Чыннан да, күрәк үз урынында иде, болдыр култыгында, күз алдында ук тора...

Әхмәтша бабай менә тагын капка төбендә. Моннан, тау өстеннән, түбәнге урам уч төбендәге кебек аермачык күренә. Тик Әхмәтша бабай күзенә түгел. Әнә бит, җиде кеше кайнашуын күрә дә, кемнәр икәнен танымый. Кемнәр чыккан икән, беләсе иде.

Әхмәтша бабай, күрәк сабы белән өй түрендәге рәшәткәне шакый-шакый, тагын Миңҗамал әбине дәште:

— Анасы, чыгып кер әле монда, чык!..

Һәм менә, алъяпкычына кулын сөртә-сөртә, капкада Миңҗамал әби күренде.

— Тагын ни бар инде?

— Карале, анасы, синең күз җетерәк, кемнәр ул әнә тегендә?

Миңҗамал әби Әхмәтша бабай күрсәткән төштә кайнашучы картларны санап чыкты.

— Һе...— диде Әхмәтша бабай, тыңлап бетергәч.— Мукәлә Хәерттине юк, алайса?

— Юк, күренми.

— Куян Гаязы дамы?

— Ул да юк.

— Шулай булыр дигән идем аны... Пыранлатыйм әле үзләрен!...

Әхмәтша бабай, эшләпәсен батырыбрак кия-кия, кирза итекләре белән лап-лоп басып, түбәнге урамга төшеп китте...

Әхмәтша бабай кергәндә, Хәертдин карт баз өстен рәтләп маташа иде. Кая җитте анда иске такта кисәкләре, балтадыр, пычкыдыр өше эш кораллары аунап ята. Ә карт үзе, капкага арты белән торган килеш, тезләнеп, тук та тук китереп нидер кадаклый иде. Шуңа күрә ул капка тавышын да ишетмәде. Әхмәтша бабай мыштым гына базга таба атлады. Шул чагында Хәертдин бабай, кадагы бетте, ахрысы, кинәт туктап калды. Аннары уңга-сулга карангалап алды да, кулыннан чүкечен дә төшермичә, мүкәли-мүкәли, үзеннән бер җиде-сигез адым читтәрәк торган кадак тартмасына таба китте. Моны күргән Әхмәтша бабай туктап, ике кулы белән көрәк сабына таянган килеш, башын селкә-селкә тавышсыз-тынсыз рәхәтләнеп көләргә тотынды: «Ай, Мүкәлә, Мүкәлә, бу кадәрле дә килешеп торыр икән үзеңә кушаматың! Алтыдагы алтмышта дип белми әйтмәгәннәр, күрәсең».

Хәертдин, ни сәбәптәндер, җиденче яшенә чаклы тәпи басмады, гел мүкәләп йөрде. Шуннан соң кайсыдыр бер кычыткан теле аңа Мүкәлә дигән кушамат таккан иде. «Кара син аны, җитмешенә җилкенсә дә, шул гадәтен онытмаган икән!»

Әхмәтша бабай шулай көлә-көлә яшьтәшенә карап торды да, тавышына кыркурак төс бирергә тырышып, керешсез-нисез әйтте:

— Хәерттин, синең янга Билаттин кердеме?

Хәертдин бабай, мүкәләгән җиреннән кинәт туктап, капкага таба борылып, җиргә утырды да, ни әйтергә белмичә, Әхмәтша бабайга текәлде...

— Җә, әйт, кергән идеме?

— Кергән иде дә бит... Кәефем юк иде. Соң, кордаш, булышмыйбыз түгел ич инде...

— Күренеп тора, синең кәеф тә шул минеке төслерәк булган икән. Кордаш булсаң, әйдәле кырдаш та бул, ал да көрәгеңне, киттек. Килеп терәлмәсә, безгә инәлмәсләр иде.

— Шулай инде, аңысы. Су үтә башлаган бит әнә. Карчыкның киптереп куйган корты күгәргән. Тапкан куяр җир,— дип сөйләнә-сөйләнә, Хәертдин бабай аягына торып басты. Аннары чалбар төбен кага-кага өстәп куйды:

— Сыер дуласа, үзең беләсең. Бәласеннән башаяк дип тотыну иде... Син дә кузгалгач, бармый булмас инде.

Хәертдин бабай баз тирәсен аннан-моннан гына җыештырды да икәүләп урамга чыктылар.

Гаязлар турысына җиткәч, урам буендагы бакчаларында кемдер кайнашканны сизеп, Әхмәтша бабай туктап калды. Аннары, юлдашына да ым кагып, койма ярыгыннан бакчага күз салды. Күрә, Гаяз карт бакча уртасына баскан да, бер кулын алъяпкыч күкрәкчәсенә тыгып, икенчесенә зур гына ак алма тоткан килеш, алгы тешләре белән генә чәйнәштереп, авызын мүкелдәтә-мүкелдәтә, бик иркенләп, гамьсез генә бер кыяфәттә алма ашап тора иде. Аның өчен дөньяның бөтен ләззәте, бөтен рәхәте бу минутта әйтерсең лә әнә шул ярмалы ап-ак алмага тупланган. Күрәсең, бакчада инде байтак казынгандыр, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан. Кара бәрхет түбәтәен баш артына ук шудырып җибәргән дә хәзер әнә күзләрен кыскалый-кыскалый рәхәтләнеп алма ашый. Бу галәмәттән Әхмәтша бабайның да авызыннан сулар килде. Ләкин ул тавыш-тын чыгармады, кордашын бүлдерәсе килми иде аның. Шуңа күрә артына әйләнеп, Хәертдин бабайга да ишарәләп алды. Тавышланма, янәсе...

Һәм менә Гаяз карт, алма белән эшне бетергәч, сакал-мыегын сыйпаштыргалап алды да җирдә яткан китмәненә иелә башлады. Шул чагында Әхмәтша бабай эченнән генә: «Ә-ә-ә, карт куян, чыгар исәбен

юк, ахры, синең. Туктале мин сине...» — дип куйды һәм: «Һайт, Гаязтин!» — дип кычкырып җибәрде. Гаяз бабай кинәт тураеп, ялт-йолт карана-карана, агачлар арасына кереп югалды.

Озак та үтми, капка келәсе күтәрелгән тавыш ишетелде. Шуның артыннан ук бер кулына көрәк, икенче кулы белән алма төялгән алъяпкыч итәген тотып, Гаяз карт килеп чыкты.

— Хәзер барам дип тора идем...

— Шулайдыр шул. Белеп кетәбез ич без...

Алар килеп җиткәндә, канау күмүче картлар инде шактый гына эш майтарып ташлаганнар иде. Бу өчәүне күргәч, көлешергә тотындылар:

— Карагыз әле, кара килешләрен... Әллә кибет тирәсендә чуалдыгызмы, качкалаклар?!

— Юк ла, — диде Әхмәтша бабай, — менә Гаязлар бакчасыннан сезгә дип алма җыйдык...

*

* *

Инде кояш баерга да күп калмаган иде. Картлар, әледән-әле туктап, билләрен капшаштыра башладылар. Әмма эшнең чиге күренеп торгач, бүленмәскә иттеләр, иртәгә дә көнне ваклыйсылары килмичә, бүген ук очлап куярга иде исәпләре. Шул чагында алар янына авыл Советы председателе Һидият килеп чыкты. Башына салам эшләпә кигән. Көн шактый эссе булса да, өстендә пинҗәк. Ак юллы зәңгәр күлмәк якасын тышка кайтарып салган. Терсәктән түбән протезлы уң кулы гадәттәгечә пинҗәк кесәсендә. Култык астына тәгәрәтеп төргән ниндидер кәгазь кыстырган. Озын буйлы, эре сөякле, әле иллесен генә узган бу кеше, сакал-мыек йөртмәвенә карамастан, кай ягы беләндер юлаучы бер картны хәтерләтә. Хәер, «кай ягы беләндер» дип икеләнеп торуның кирәге юк бугай. Бар аның ул ягы, бар.

Һидият, тора торгач, авылларны урап кайтырга ярата. Сыңар кулын артка куя да, уңга-сулга караштырып, китә шулай җайга гына. Кем дә булса юлын бүлдермәсә, ачык капкаларга күз салгалап, очраганга сәлам биреп, беркайда да озаклап тукталмыйча, салмак кына атлый-атлый бара бирә. Күңеленә хуш килмәгән берәр нәрсәгә тап булса да тукталмый ул, бары тик адымнарын тагын да әкренәйтә төшеп, төбәлебрәк карый да, «алай икән боларда» дигән сыман, әллә ни исе китмәгәндәй уза да бара. Я, юлаучы түгелмени? Алай да ашыкмыйк әле.

Шулай бервакытны моның янына, язылышу турында гариза бирергә дип, комбайнчы Салих белән фельдшер кыз Дилбәр килә. Икесе дә чуктан киенгәннәр. Ай да кояш болар, берсен алып берсен куярлык түгел. Дилбәре Дилбәр инде, ә менә гел эш киеменнән күреп өйрәнелгән Салихны Һидият башта танымыйча ук торды. Аннары: «Кара син аны, малай актыгын, ә, вәт хәчтерүш, вәт егет», —дип куйды эчтән генә.

— Менә шулайрак инде безнең хәлләр, Һидият абый,— дип, Салих председательгә бер кәгазь кисәге сузды да, авызын ерып, өстәл каршысында торып калды. Ә Дилбәре, башка вакытта, медпунктка ул-бу кирәк булганда чәт-чәт итеп торган Дилбәр, әйтерсең лә Һидият абыйсын беренче күрүе, түргәрәк узарга да кыймыйча, оялчан балалар төсле башын иеп тик тора.

— Ярый, ярый... Ярый торган эш бу,— диде Һидият, кәгазьгә күз йөртеп чыккач. — Хәерле сәгатьтә булсын. Ә туйны кайчан итәбез?

Салих, ерылган авызын әле һаман да җыя алмыйча, икесе өчен дә җавап бирде:

— Без бүген үк әзер дә бит, язмассыз шул, срок диярсез.

— Кара син аларны! Диярбез шул. Ярый, ярый, ниятегез нык икән, туе качмас, өлгерерсез. Ә хәзергә уйлашыгыз...
Яшьләр китәргә җыендылар. Шул чагында Һидият:
— Салих, син чыкмый тор әле, йомышым бар,— диде.
Алар икәү генә калдылар.
— Менә нәрсә, Салих, кайчан тәртипкә кертәсең ул йорт тирәгезне? Ишегалдыгызда рәт-баш юк. Коймаңа терәү куйгансың. Капка төбенә якын килерлек түгел, чүп-чар, утын өелгән. Ә үзең килен төшерергә йөрисең?!
— Вакыт булмады ич, Һидият абый.
— Башкага табасың. Кибет тирәсендә азрак чуал, яме. Күргәләдем мин. Бу турыда кабат сүз әйтерлек итмә, ишетсен колагың. Өйләнәсе егет дип тормам, хур итәрмен. Калырсың шешә кочаклап.
— Бер генә булды ич ул, Һидият абый... Егетләрне озатканда гына...
— Бер булса да берәгәйле булган, шулайрак ишетелде.
— Ни бит, Һидият абый...
— Нәрсәсе ни? Кара аны, егет, кыз бик әйбәт, бер дигән. Ничек караган әле ул сиңа. Ярый инде, бәхетең бар икән. Шулай булгач, ычкындырма. Килештекме?
Салихның авыз җыелган иде инде. Әле генә мөлдерәп ташырга, очынырга торган күңеле кинәт бушап, сүрелеп калды. Әйтерсең лә аның Дилбәрен, бердәнберен, менә хәзер үк тартып алачаклар, әйтерсең лә аңа хәзер нәкъ менә шул турыда инде һич тә үзгәртеп булмаслык катгый бер карар укыганнар.
Егетнең болай шүрләп калуына, сөмсере коелуга сәбәп тә бар иде. Белә ич ул Һидият абыйсын, әйттем исә кайттым кеше түгел. Хәтерендә әле, бик тә хәтерендә. Шулай бервакытны авыл Советы: «Кирәклекирәкмәс авылга трактор белән кереп йөрмәскә!» — дип карар чыгарган иде. Ә дусы Баһрам моны санга сукмаган булып кыланды. Бу хәл Һидият абыйларына ишетелеп, шелтә дә алган иде егет. Ләкин моңа карап кына мутлыгын барыбер ташламады. Шуннан соң авыл Советы Баһрамны ике айга трактордан алуларын таләп итте. Эш өсте, кызу чак дип, колхоз председателе яклап та караган иде. Әмма Һидият абыйлары ишетергә дә теләмәде. Шулай итеп, Баһрам тракторына кабат утыра алмыйча армиягә китеп барды. Бик үпкәләгән иде киткәндә. Бераз кәгеп алган баштан, дусын яклаган булып, Һидият абыйсына карата Салих та хәтәр генә сүзләр ычкындырган иде, тинтәк. Баһрам ул әнә гафу үтенеп хат язды да котылды. Ә минеке менә торып-торып килеп чыга...
— Җә, ник дәшмисең, ник торасың инде, Дилбәр көтәдер,— диде председатель, егеткә күз кысып.— Бар, бар, җебемә. Сораса, әйтерсең, мотоцикл төзәтергә кушты диген.
Әй, яшьлек, юләр яшьлек... Бу кадәрле дә булырсың икән! Шелтәләрәк бер сүз әйтсәләр дә, кара кайгыга төшәсең, бер күз кысу белән күгеңдә кояш балкый. Кара инде менә бу тилесен, авызы тагын колагына җиткән. Нәрсә ди бит әле, ерык авыз, тапкан сүзен:
— Бар да наять булыр, Һидият абый, рәхмәт, онытмам...

*
* *

— Армый эшләгез!
— Ә-ә, Һидият... Армыйбыз, куәт бар бездә.
— Ун ат көченә торырлык.
— Әйтмәсәң дә. Унау икәнсез шул...
Картлар, теләр-теләмәс кенә туктап, көрәк сабына таяныштылар да Һидияткә төбәлделәр.

— Нәрсә, персидәтел, әллә безнең эшне хисапларга килдеңме?
— Исәп юк түгел. Анысы инде эшне бетергән булыр. Әлегә менә моны карагыз, — дип, Һидият алып килгән төргәген сүтәргә җыенды. Әмма аның үзенә җайсыз иде. Шуңа күрә якынрак торган ике карт төргәкне үз кулларына алдылар. Сүтеп җибәрсәләр, кәгазьдә авыл Советының чираттагы сессиясен чакыру турында шәмәхә кара белән эре-эре итеп язылган белдерү иде.

БЕЛДЕРҮ

Зирекле авыл Советының чираттагы сессиясе чакырыла.
Көн тәртибе:
1. «Партизан» колхозында җирдән файдалануның торышы турында колхоз идарәсенең отчеты.
Докладчы авыл Советы депутаты, «Партизан» колхозы председателе Билал Харисов.
2. Зирекле авыл Советы территориясендәге елга-күлләрне, чишмәләрне тәртипкә китерү турында.
Докладчы Зирекле авыл Советы башкарма комитеты председателе Һидият Хәкимуллин.
Сессиягә, депутатлардан тыш, колхоз идарәсе членнары, бригадирлар һәм көн тәртибенә куелган мәсьәләләр белән кызыксынучы барлык колхозчылар чакырыла.

— Һе... — диде Әхмәтша бабай, белдерүне укып чыккач.
Гаяз картның исә сүзе озынрак булды:
— Белмим шул, ничек кенә тәртипкә китерерсез икән. Кайда соң ул күлләр хәзер, юк бит инде, киптеләр, туган, беттеләр алар.
Ә калганнары ярым-йорты җөмләләр белән генә чикләнделәр.
— Күптән кирәк иде дә бит...
— Белмим шул... Ай-һай...
— Исләренә төшкән икән....
— Чынлап торып тотынсалармы?! Һәй әле...
Һидият, картларны бүлдермичә, башта елмаеп кына тыңлап торды да, ниһаять, үзе дә сүзгә кушылды:
— Карап-карап торам да сезгә, агайлар, тагын бер карап куям. Айдан төштегез мәллә? Үз колхозыбыз, үз тирәләребез хакында бара бит сүз. Ә сез бөтенләй чит кешеләр күк сөйләшәсез. «Исләренә төшкән», «Тотынсалар», имеш. Юк инде, сездән башка эш чыкмый монда.
Картлар, бер-берсенә карашып, көлешергә тотындылар:
— Менә сиңа мә, иске авыздан яңа сүз... Тагын да без кирәк!
— Ник көләсез, кирәк шул. Бу белдерүне мин сезгә әллә күрсәтү өчен генә алып килдемме? Юк инде, аксакаллар, киләсез сессиягә, рәхим итәсез.
— Кунак булып кына түгел икән, алайса?
— Түгел. Үзегез ич: «Елганы кайчан буабыз?», «Чишмәләр кибә», «Куаклыкны, вак урманны харап иттегез!» — дип күзне ачырмыйсыз. Ә хәзер бер дә атлыгып тормыйсыз шикелле.
Карсак буйлы Хәертдин карт баскан урынында камыт аяклары белән таптангалап алды да көлә-көлә әйтеп куйды:
— Бетте болай булгач, җәмәгать. Пенсия кыягазен иртәгә үк кире илтеп бирәм. Бер дуласын әле карчык. Чукынмас баз өсләре.
— Чыннан да, шулай ит син, Хәерттин, — диде аңа төрттереп Гаяз бабай. — Мең дулаганга түзгәнне, берсенә генә исең китмәс, тирең калын әле.
Моңа каршы Хәертдин карт:

— Үзең соң, кордаш...— дип башлаган иде дә, сүзне Һидият бүлдерде:

— Ярый, агайлар, мин китим. Болай да шактый вакытыгызны алдым. Тик онытмагыз, уен эш түгел бу. Ил картлары була торып, киңәштабыш та итешмәсәгез...

— Алай бик кирәксенсәгез, ярар, калмабыз, — дип, картлар тагын эшкә тотындылар.

Инде шактый киткәч, Һидият, артына әйләнеп, Әхмәтша бабайга кычкырды:

— Әхмәтша бабай, исән булсалар, теге рәсемнәрне дә алып кил, яме?

— Ярар, — диде карт, башын селкеп, — барсам алып килермен...

*
* *

Бармыймы соң Әхмәтша бабай. Тетмәләрен тетәсе иде үзләренең дип, инде күптән үк кызышып йөри ич. Тик моңарчы җае гына чыкканы юк әле. Туры килгәндә я Билалга, я башкасына тәрттерүдән ары уза алмый. «Шәп нәрсә уйлаган Һидият, ахрысы, тотынды бугай», — дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, күрәген иңбашына салып, Әхмәтша бабай өенә кайтып килә. Шулай кайта торгач, Һидиятнең рәсемнәр турында әйткән сүзләре исенә төште. Рәсемнәр дигәч тә, саргаешып беткән нибары ике фоторәсем инде ул. Берсендә — Әхмәтша бабайларның капка төбеннән торып төшерелгән болын, әрәмәлекләр, шулар арасыннан бормалана-бормалана, ике тармакка бүленеп, болынны һәр яктан уратып, бу тирәдәге дүрт авылның дүртесен дә читләтмичә, һәркайсына орынып ук диярлек аккан Алкын елга күренеше. Икенчесендә — Ак Чишмә авылы. Монысы да ерактан, болын түрендә торып төшерелгән. Шуңа карамастан, бер ягы биегрәк, икенчесе сөзәгрәк булып, дугаланып килгән тау өстенә утырган авыл уч төбендәге кебек. Дуганың нәкъ урта бер җиреннән — тау астыннан ургып чыккан чишмә өстенә корылган алачыкка кадәр аермачык күренә. Тирәсендә өянкеләр, эт миләше куаклары. Уйлый калсаң, үзгеңне өзәрлек истәлекләр...

Шулай бервакытны, җәй башында, Гаязның Казанда укып йөргән каенесе Җәмил кайткан иде. Менә шул егет белән Әхмәтша, ничектер, бер-берсенә бик тиз ияләшеп киттеләр. Хикмәт, күрәсең, икесенә дә балык җене кагылуда, су буйларын, гомумән, табигатьне яратуларында булгандыр. Шуның өстенә тагын, көннәре дә мач килгән иде. Чалгытырма көйләнеп, арба-фәләне майланып та, әле печәнгә төшәр чак җитмәгән бер ара иде. Ничә генә таңны бергә каршыламадылар да ничәмәничә тапкыр, болын аркылы чык ерып, билдән суга батып кайтмадылар.

— Их, Әхмәтша абый, яшисез дә соң оҗмахта,— ди торган иде Җәмил.— Кара инде син, әй! Бу елга, бу болын... Күлләрен генә булса да бирмәгән бит табигать дигәнең безнең авылга. Ата-бабаларыбыз ни карагандыр, белмим.

— Бирмәсә бирмәгән инде,— ди Әхмәтша көлемсерәп.— Каян житкерсен барысына да. Ә син уфтанма, кайт шулай ел саен безнең авылга. Җизниләр үзләре дә бик ишле, җайсыз дисәң, безгә кайт, бездә урын җитәрлек.

— Юк, киң күңелле алар. Эш андамыни, сокланып кына әйтүем...

Ә беркөнне Җәмил Әхмәтша абыйсы янына фотоаппарат асып, өч аяклы агач штатив күтәреп килде.

— Синең әле андый һөнәрең дә бармыни? Кая жыендың болай?

— Менә ич, синең янга килдем. Әйдәле, Әхмәтша абый, вакытың булса, тагын бер әйләнеп кайтыйк әле. Синең белән күңелле. Үзебез-

нең училище егетләренә дә күрсәтәсем килә сезнең якларны. Аһ итсеннәр әле бер.

Бу юлы Әхмәтшаның әллә ни вакыты юк иде югын. Егет шулай үз итеп, якын итеп килгәч, әсәрләнүен дә сизеп, ничектер, күнмичә булдыра алмады.

— Ярар, әйләнербез. Башта син менә бу төштән, тау өстеннән төшер әле. Әнә, елгасы да, болыны да, әрәмәлекләре дә — барысы да берьюлы күренә.

— Тау өстеннән төшергән идем инде мин. Тик эшләнмәгән генә. Әллә чыккан, әллә юк, тагын бер төшерү зыян итмәс, — дип, Җәмил аппаратына тотынды...

Бу көнне алар кунак егетен әсәрләндергән, авыз суларын корытып ул мактаган бөтен күренешләрне төшереп кайттылар. Алкын елга буенда шау чәчәккә батып, оя-оя булып утырган шомырт куаклары да, зиреклек тә, тегермән буасы да, өчәүләшеп бер тирәгә тупланган Аккош, Камышлы, Кәрәкә күлләре дә — берсе дә, берсе дә калмады. Тик аккошларны туры китерә алмаулары өчен генә Җәмилнең кәефе бераз кырылган иде. Сирәк күренәләр шул алар бу чакта, күп вакытларын кеше күзеннән читтәрәк, күлнең сазламыграк, аулаграк читендә, камышлар арасында үткәрәләр. Барлыгы ике аккош, ел да кайта үзләре. Бала чыгаралар да... Икенче елны тагын әйләнеп кайталар.

Инде кайтып килгәндә, болын уртасына туктап, Җәмил: «Монысы соңгы кассета»,— дип, Әхмәтша бабайда әле бүген дә саклана торган шул ике күренешнең берсен—Ак Чишмә авылын төшереп алган иде.

Ә иртәгесен, ике рәсем күтәреп, кош тоткандай очынып, җилкенеп килгән иде Җәмил.

— Менә, Әхмәтша абый, барысы да шәп чыккан. Әлегә икесен генә ясадым. Истәлегем булсын, ал! — дигән иде.

Берничә көннән сугыш башланды. Җәмил әллә үз авылларына, әллә инде Казангамы, каядыр китеп барды. Тик ун-унбиш көннән соң жизнәсе Гаяз аркылы гына аның армиягә алынуын ишетте. Озакламый Әхмәтшаның үзенә дә чират житте. Действительныйда хезмәт иткән чакларында авылларын өзелеп тә сагынган иде Әхмәтша. Инде менә тагын китәсе булгач, бик сагынсам бер карармын дип, Миңҗамалы, үзе, ике улы бергә утырып төшкән рәсемнәре белән әлеге шул ике фотоны да алган иде.

Дүрт елга якын йөрде Әхмәтша. Ике тапкыр яраланды, әмма сугышның азагына хәтле сафтан чыкмады...

Әхмәтша төнлә кайтып төшкән иде. Иртән иртүк торып, су буйларын әйләнеп кайтыйм дип капка төпләренә чыкса, исе-акылы китте. Ни булган бу болынга?! Хәер, болын, әлбәттә, үз урынында, элеккечә үк ямь-яшел иде. Ә елга буендагы әрәмәлекләр әйтерсең бөтенләй дә булмаган. Болынны су басмасын өчен, уйсурак урынга өелгән таш «күпер» тирәсендәге берничә карт өянке дә елгадан чак кына читтәрәк, тау итәгендә утырган өч карама гына күренә. Ишелгән, җимерелгән елга кырыйлары, текә ярга әверелеп шәп-шәрә булып калганнар. Ә Алкын елга — һәр вакыт мөлдерәмә тулып, ташырга житешеп торган Алкын елга үзе — оятыннан кая барырга белмичә аптырагач, әнә шул ыржаеп торган ярлар арасына качкандыр да акрынлап сулгандыр төсле тоелды солдатка. Әхмәтша әрәмәлекне кисеп ягулары, тегермән буасының китүе, кабат буа алмаулары турында Миңҗамалы язган хат аркылы белә иде. Әмма ул болай ук булыр дип күз алдына да китерә алмады. Шулай бик озак карап торгач, бу хәл белән инде килешә язган сыман, уйлап куйды: «Дүрт авыл дүрт яктан кыра башлагач.... Ярый инде, нишләсеннәр».

Әхмәтша, бәлки күлләр элеккечәдер, шулар тирәсеннән әйләним, дип кузгалырга гына тора иде, түбәнге урамнан үзләренә таба кем-

нендер килгәнен күрде. Кеше якынлашкан саен адымнарын кызулата, сыңар кулы белән җәһәтрәк селтәнә иде. Менә ул менеп тә житте.

— Әхмәтша абый?!

— Һидият!

Кочаклашып күрештеләр.

— Солдат киеменнән булгач, сиңдер дип уйлаган идем. Ничек соң хәлләр?

— Әй, энем, сорап торасың. Илгә кайткач соң!.. Исән сау, тагын ни кирәк?

— Ә мин менә сыңар канат белән калдым.

— Болай гына ярый, туган, кайгырма. Минекеләр.... Башкалар әнә ятып та калдылар... Җимертеп эшлисең ди әле Миңҗамал җиңгәң.

— Бик җимертеп булмый шул, Әхмәтша абый, кеше юк. Әй... Ни кирәксә шул юк... Нәрсә, танымадыңмы болынны? Шуны карап тора идеңме? Танымассың да. Үземнең дә үзәк өзелә.

— Ә күлләр? Бармы әле алар, исәнме?

— Бар белән юк арасында. Бик саектылар, кибәләр.

Әхмәтша, күрсенеп, күкрәк кесәсенә үрелде. Башын кесә өстенә үк иеп, бармаклары белән кармаланып торды да ике фоторәсем тартып чыгарды.

— Мәле, карале, танырсыңмы?

— Әхмәтша абый, каян килде сиңа болар?!

— Килде инде. Бик сагынганда шуларга карый идем.

— Әллә үзең белән йөрттеңме?

— Күрәсең ич... Минем белән нилэр генә күрмәде алар.

— Кайчан кайтарырбыз икән тагын шул хәленә, ә?

— Кайтыр, кая китсен. Гитлерны дөмектергәнне, монысын гына булдырырбыз...

Истәлекләр дәрьясында йөзә-йөзә, Әхмәтша бабай кайтып җиткәнен дә сизми калды. Хәзер дә әнә, шул татлы да, моңсу да хатирәләреннән, аерыласы килмичә, күрәгән коймага сөяп, эскәмиягә барып утырды. Өйгә керсә, барысы да онытылыр, тышта калып, һәммәсе дә югалыр, таралышыр төсле иде аңа.

«...Эшләсә эш төтмәс, йөрсә йөреп туймас ир уртасы чакларында, җиңү шатлыгыннан исереп, айга сикерердәй булып йөргән вакытларда барысы да кулдан килер төсле иде. Юк икән шул, булмады. Кайту белән Һидият шикелле үк бригадир итеп куйдылар. Ул чагында буалар, күлләр кайгысы идемени?! Аннан дүрт авыл берләшеп зур колхоз булдылар, инде аны күтәр, аны аякка бастыр. Тагын да олырак мәшәкатьләр, төн йокыларын качырган борчулар... Айга да сикердек сикерүен, Әнисын да күрдек. Өс тә бөтен хәзер, тамак та тук, әмма җанны җылытырлык, күзне иркәләрлек ямь генә бетеп бара.

Хәер, Саттар председатель вакытта талпынып карадылар каравын. Хәзер инде аякка бастык, тернәкләндек, башласак та була дип, буа проектын төзергә белгечләр дә чакыртып йөргәннәр иде. Барысы да изге ният килеш кала бирде. Саттары авырып, Әхмәтша үзе олыгаеп эш башыннан киттеләр. Һидият хәзер әнә авыл Советы председателе. Шулай итеп, колхозның дилбегәсе яшьләр кулына күчте. Сүз дә юк, белемлеләр, әйбәт алып баралар. Кая ул хәзер! Ә элеккене белмиләр, хәтерләмиләр. Аларга тирә-як һаман да шушы килеш, чокыр да чакыр, ком да тузан булган кебек. Ә Билал? Ул белергә тиеш ич. Шомырт башыннан мәтәлеп төшкәч соң...» Уйлары шул турыга җиткәч, Әхмәтша бабай сискәнеп куйды. «Шомырт!» Аларны да төшергән иде ич Җәмил, күп итеп төшергән иде. Кайда соң барысы да?! Гаязларда сакланмады микән?!»

Әхмәтша бабай тиз генә торды да, күрәгән алып, кабалана-кабалана өенә кереп китте.

Капка тавышын ишетүгә, баскыч төбенә Миңҗамал әби чыкты.
— Атасы, нишләп бик озак? Ашым куерып бетте ич инде! Эштә генә йөрмәгәнсеңдер бу гомер. Дөньяны онытып...
— Туктале, анасы, куерса куерыр. Сыегын да күп ашаган, — дип, Әхмәтша бабай көрәген болдыр култыгына сөяде дә кире капкага таба китте.
— Тагын кая инде?!
Хәзер, анасы, хәзер, Гаязтиннарга гына барып кайтам.
— Әй, карт иләс!..

*

* *

Өстен-башын да алыштырмаган килеш, кирза итекләре белән дык та дык басып, Әхмәтша бабай килеп кергәч, сөлгене муенына салып, карчыгы белән бик тәмләп, янып-пешеп чәй эчеп утырган Гаяз бабай «ул арада ни булды икән?» дип аптырап калды. Аннары сөлге очын сакал-мыек тирәсендә уйнатып алды да, сәбәбен тизрәк беләсе килеп, теленә килгән беренче сүзләрне ычкындырды:
— Тагын дәшмиләрдер ич?
— Син нәрсә, Гаязтин, әллә мине йомышчы дип белдеңме?
— Әй, тыңламасана шуны. Ул тозсызның шул булыр инде. Кешене башта табынга дәшәр идең, — дип, карчыгы урыныннан купты. — Әйдәле, Әхмәтша, түрдән уз, чәй ясыйм.
— Рәхмәт, Мәһизәләл, хәзер китәм. Миңҗамал да табын әзерли калды.
Әхмәтша бабайның тыныч кына күренүенә карамастан, Гаяз картның күңеле әле һаман да урынына утырмаган иде. Шуңа күрә ул тагын бер сорыйсы итте:
— Ул-бу юктыр ич?
— Юк ла, юк, зинһар, борчылма. Җәмил хакында гына сорыйсым килгән иде.
Җәмил исеме чыккач, Мәһизәләл әби дә сагая калды. Моны сизгән Әхмәтша бабай сүзен ачыкларга ашыкты:
— Киткәндә берәр нәрсә калдырмаган идеме дим?
— Юк шикелле. Ул гомердән бирле инде... — Гаяз карт бераз уйланып торды да карчыгына ымлап өстәп куйды:
— Белмим тагын, әнә апасыннан сорап карыйк. Ә, карчык?
— Сезгә кирәкле ни генә калдырсын икән студин кеше...
Карчыкның тел төбе бөтенләй үк буш түгеллеген сизеп, Әхмәтша бабай тагын сорап куйды:
— Шулай да хәтерләп карале, Мәһизәләл?
— Хәтерлә дип... Калдырган иде ул калдыруын да... Ни икәнен генә белмим. Әйдәгез, алайса, булышыгыз,— дип, Мәһизәләл әби түр стена буенда торган сандык янына китте...
Картлар зур гына җәенке кисмәктә утырган фикус гөлен идәнгә куйдылар. Мәһизәләл әби, калайлап эшләнгән агач сандыкның капкачын ачты да, кайсы баштан тотынырга соң әле дигәндәй, бер мәлгә туктап калды. Әхмәтша бабай, карап торуны яхшысынмыйча, читкә үк китеп, яны белән бер урындыкка утырды.
Озак та үтми: «Менә шушы иде инде ул», — дип, Мәһизәләл әби кызыл башлы сөлгегә төргән бер нәрсә чыгарды. Сандык тирәсендә таптангалап торган Гаяз карт төргәкне кулына алды да өстәлнең бушрак бер почмагына китереп куйды. Әхмәтша бабай да өстәл янына ашыкты. Икәүләшеп сөлгене сүттеләр. Әмма әле ни икәнен тәгаен генә белерлек түгел. Бик әйбәтләп «Кызыл Татарстан» газетына төргән бәләкәйрәк кирпеч сыман бер әйбер иде. Әхмәтша бабай, төргәкне кулына алып, авырлыгын чамалап торды да:

— Шул булырга тиеш,— диде.
— Нәрсә шул?
— Фото әйберләре булса кирәк...
Картлар газетны да сүтәргә тотынгач, читтәнрәк карап торган Мәһизәзәл әби: «Моны беркемгә дә бирмә, ачма да, ярамый, дигән иде, җанашым», — дип, ике кулы белән йөзен каплап ачык сандык кырыена барып утырды.
— Нишлик соң алай булгач, карчык?
— Хәзер инде нишләтсәң дә ярый. Үзегез карагыз шунда...
Әхмәтша бабай Гаяз картның әле һаман да төргәк өстендә торган кулын читкәрәк этеп куйды.
— Чынлап та, Гаязтин, мин әйткән әйбер булса... Якты төшмәсен.
— Ие шул. Карале син, ә. Ярамас шул, — дип килеште Гаяз карт та. — Менә табышмак... Карале, нигә кирәк булды ул сиңа?
— Миңа гына түгел, сиңа да кирәк ул, Гаязтин. Барыбызга да... Әйдә, Салих янына барыйк әле, ул аның рәтен белә. Юлда сөйләрмен.
Картлар төргәкне күтәреп комбайнчы Салихларга киттеләр.

* * *

— Хәзер беләбез аны, — дип, Салих өйалды почмагындагы кечкенә бүлмәгә кереп китте. Картлар болдыр баскычына утырыша калдылар.
Озак та үтми, кулына кара пыяла кисәге тотып, Салих килеп чыкты.
— Негативлар болар, «фотокор» негативлары. Әй дә шәп чыккан! Менә карагыз әле...
Картлар негативны кулдан-кулга йөртеп, әле алай, әле болай китереп карап бактылар да кире Салиховка суздылар.
— Шәп дисең инде, алайса, — диде Әхмәтша бабай тамагын кыргалап. — Шәп булса, син безгә шуларны кәгазьгә төшереп бир инде.
Гаяз бабай өстәп куйды:
— Хакыннан тормабыз, улым, бәхилләтербез, яса гына.
Салих көлеп җибәрде. Көлмәслек тә түгел, Гаяз бабай чын-чынлап, икеле-микеле уйларга һич тә урын калдырмыйча сөйләшә иде. Салих, авызын тагын да ера төшеп, сорап куйды:
— Каян актарып чыгардыгыз соң боларны, бабайлар?
— Син анысын сорама инде, әйтербез әле, әйтербез. Яса син башта, яса гына, — диде Гаяз карт.
— Түлке бик тиз кирәк. Әмма кеше-кара күрмәсен. Әлегә сер, аңладыңмы? — дип кисәтте Әхмәтша бабай.
— Бик тиз кирәк дисез инде, алайса. Кызык бит әле бу... — Салих башын кашып алды. Бабайлар көлемсерәп куйдылар.
— Кашынма син, кашынма. Аның каравы, әҗере зур булыр. Саваплы эш кушабыз ич без сиңа, саваплы эш.
— Комбайнга барасы бар иде шул иртәгә, вакыт бик тар...
— Ә син кичләрен эшлә, төннәрен, — диде Әхмәтша бабай. Аннары, Салихка якынрак килде дә: — Безнең дә бар иде ул... яшь кияү чаклар, — дип мәгънәле генә итеп кабыргасына төртеп алды.
Салихка, ничектер, уңайсыз да, шул ук вакытта, ниндидер бер эчке горурлык хисләре уянып, рәхәт тә булып китте.
— Ярар инде, тырышырмын сез дигәндә, озаклатмам...
Картлар киттеләр. Салих, ни дип уйларга да белмичә, башын чайкап карап калды.

* * *

Ни генә уйламасын, бабайлар салып киткән оеткы шактый көчле булып чыкты. Салихның хәзер бер генә минут та түзәр әмәле калмаган иде. Проявителен-нием әзерләп, шундук эшкә тотынды. Байтак негатив-

ны кәгазьгә күчерсә дә, әмма әле барыбер бернәрсә дә аңламый иде. Нindидер күлләр, камышлар, таллар... Берсе дә күз күргән җирләре түгел... Һәм менә... Таный ич монысын, таный, үзләренең Ак Чишмә авыллары! Менә тагын... Тегермән! Әкиятләрдә сөйләнгән шомлы-сихерле йорт кебек, агачлар куелыгыннан ишекле бер стенасы да түбә кые-гы гына күренеп тора. Салих белә башлаганда ук бик тузган иде инде, Аны сүткәндә ялан аяк малай гына иде әле ул. Шушы тегермән белән авыл рәсемен күрсәтмәсәң, яшьләрдән хәзер берсен-бер кеше танымаячак. «Безнең тирәләр микәнни болар һәммәсе дә?! Өлкәннәрнең сүзе юкка түгел икән, юкны сөйләмиләр икән шул...»

Салих, мавыгып китеп, картлар китергән негативларның барысын да шул ук кечне кәгазьгә төшереп бетерде. Иртәгесен иртүк торып, киптерү өчен җәеп куйган рәсемнәрне тагын бер кат карап чыкты. Шул чагында ул өченче бер рәсемне дә танып алды. Монысын Алкын елга борылышларыннан, таш «күпер» буенда әле дә үсеп утырган карт өянкеләрдән таныды.

Рәсемнәрне җыеп газетка төрде дә комбинезон кесәсенә салып куйды. Зиреклегә — колхоз идарәсенә чыгышлый картларга бирә китү иде исәбе. Әмма, капка төбенә чыккач, башта Һидият абыйларына сугыласы итте. «Нигә кирәк булган ул аларга, ник шулай ашыктыралар икән? Бәлки ул беләдер, картлар тирәсендә кичә ул чуалган иде ич?»

Салих килгәндә Һидият болдыр баскычыннан төшеп килә иде. Аның артыннан ук өйалды ишегендә комган тоткан хатыны Сәгадәт күренде.

— Исәнмесез!

— Ә-ә, Салих, исәнме, исәнме. Ник болай иртә кузгалдың?

— Комбайнга барабыз!..

— Әйтәм, авызың ерылган... Туктале, тукта, шуңа гына микән?! Кичәдән бирле инде... Җыелырга вакыт иде ул авызга, ә?! — Һидият үзе дә ишегалдын яңгыратып көлеп алды.

— Шундый авыз инде ул минем, Һидият абый. Дилбәр әнә «басу капкасы» ди аны.

Сәгадәт карап-карап торды да ирен ашыктыра башлады:

— Шул кадәр ихахайламасаң. Әйдә, юынсаң юын тизрәк, минем эшем болай да җитәрлек.

— Бирегез комганны, Сәгадәт апа, үзем салып торам...

Хатын кереп киткәч, Һидият юынган арада, Салих картлар турында сөйли башлады:

— Кызык хәл килеп чыкты бит әле, Һидият абый. Кичә кич Әхмәтша бабай белән Гаяз бабай килгән иде безгә. Әллә каян иске негативлар табып китергәннәр, кәгазьгә күчереп бир, диләр. Ә үзләре рәтләп берни дә әйтмиләр, бик сәер, серле кыланалар. Ярты төнгә хәтле шулар белән утырдым. Шәп төшергән дә соң, каһәрең, күрсәң исең китәр.

— Кем төшергән, нәрсәне?

— Күп анда. Күлләр, чишмәләр, агачлар... Кем төшергәндер, белмим.

— Кая соң алар?

— Хәзер, менә сөртенегез дә күрсәтәм.

Һидият сөлге белән маташкан арада Салих комбинезон кесәсеннән фоторәсемнәр чыгарды.

— Менә алар. Карагыз әле, танырсызмы?

Һидият дәшми-тынмый рәсемнәрне карарга тотынды...

— Шәп бит, ә, Һидият абый?

— Әй, энем, энем, шәп кенәме соң! Беләсеңме болар ни?

— Әзрәк чамалыйм.

— Чамаласаң, менә шул, тарих бу, алтынга бирмәслек рәсемнәр! Каян казып чыгарганнар диген, ә?

— Зурайтасы иде боларны, Һидият абый, картина шикелле итеп.
— Үзем дә шуны уйлап торам. Әйдәле, Салих, тотын шуңа. Өч көн срок сиңа.
— Булмый, Һидият абый, минем зурайткыч ярамый боларга. Икенчене эмәлләргә кирәк. Өч көндә генә булмый.
— Районда да эшләмәсләр микән?
— Юктыр, Казанга илтмичә булмас.
— Алайса, бар. Мин җыенган арада негативларны китер әле. Синең белән районга барам. Аннан Казанга.
— Ә бу рәсемнәрне нишләтим?
— Бир картларның үзләренә, карый торсыннар...

Ние бар аның, ясарлар да бирерләр дип уйлаган иде Һидият. Юк икән шул, андый заказлар белән йөрүче бер ул гына түгел икән. «Эш муеннан, иптәш, бер айсыз да өлгертер чамабыз юк», диделәр калада. Әллә ничә җиргә кереп, әллә кемнәргә ялынып-ялварып та эш чыкмагач, соңгы автобус белән кире авылга кайтып китте...

Кичкырын, Зирекледән Ак Чишмәгә чыгып килешли, Һидият Алкын елга буенда Әхмәтша бабай белән Гаяз бабайны очратты. Председательнең йончыган кыяфәтен күреп, картлар сагая калдылар.
— Син нәрсә, Һидият, балтасы суга төшкән кеше кук?
— Калага барган идем дә... Арылган, күрәсең. Сезнең рәсемнәрне зурайтырга иде исәп. Барып чыкмады. Бер айсыз да булмый, диделәр.
— Шулай ук диләрмени?
— Шәп буласы икән дә кана...

Һидият, портфеленнән негативларны чыгарып, кайсына тапшырырга белмичә икеләнебрәк торды. Аннары, Гаяз бабай кулын сузгач, төргәкне шуңа тоттырды.
— Саклагыз. Бер эшләтербез әле. Сессиягә кадәр өлгермәгәч, калдырасым килмәде. Ничектер, күңел сүрелде...

Иртәгесен иртүк ике карт калага китеп бардылар.

*
* *

Билгеләнгән көн килеп җитте. Әхмәтша, Гаяз, Әхтәм бабайлар, сессиягә килүчеләрне күзәтеп, киң, иркен фойеның бер почмагында тыныч кына утыралар. Клуб ишегендә үз кордашлары күренсә генә, кәрәкерешенә үк каршысына баралар да, күрешеп, хәл-әхвәл сораша-сораша үз яннарына алып китәләр. Тик андыйлар күп түгел, барысы да утыз-кырыклар тирәсендәге «яшьләр» иде.

Шулай, читтән генә күзәткәләп утыра торгач, Гаяз карт каршы стенага эленгән комаяк[1] рәсеменә ымлап, Әхмәтша бабайның кабыргасына төртеп куйды:
— Хәтерлисеңме, кордаш, әнә шундый комаяк турысында печән чапкан идек? Теге елны дим?

Әхмәтша бабай, җавап кайтармыйча, йөзен генә җыерып куйгач, тагын бер төртеп алды:
— Ник, әллә оныттыңмы, картлач? Шәп иткән идең син ул чакта директорны. Ә хәзер...
— Нәрсә хәзер? Бетте ул тугай хәзер, менә шул. Күле-ние белән.
— Юк ла, мин ул хакта түгел... Гәзитенә язалар, радиосы сөйләп тора. Фәлән завод фәлән суны агулаган, фәлән кадәр штраф түләткән-

[1] Комаяк — елга ярында ком салган урын.

нәр, имеш. Пычагым! Кем түли соң аны?! Барыбер дәүләт акчасы! Безнең завод түләмәгән идемени? Шуның артыннан ук тагын сасытты Алкын елганы...

— Һе... Аннан соң туктадылар ич.

— Туктадылар... Син барып имләп кайткач.

Икесе дә көлеп җибәрделәр...

Ул арада, халыкны залга чакырып, звонок чылтырый башлады...

Башлап сүзне колхоз пердседателе Билалга бирделәр. Доклад шактый озын иде. Шулай да игътибар белән тыңладылар. Докладчының соңгы сүзләре йокымсырап утыручыларны да уятып җибәрде.

— ...Шулай итеп, депутат иптәшләр, соңгы ун ел эчендә уңыш гектарына бишәр центнерга артты. Бездәге туфракны, үзегез беләсез, карау да карау, ашлау да ашлау кирәк. Элегрәк, иң әйбәт килгән елларны да, ун-унике центнердан узмый идек. Ә азакка таба унбишәр-уналтышар центнер алып килдек. Өченче ел исә унтугызар центнер уңыш җыйдык. Ләкин бу да чик түгел, тырышсак, тагын да зурракны өмет итәргә була иде. Шуңа исәп тотып, агымдагы бишьеллыкка зур планнар кордык, күтәренке йөкләмәләр алдык. Тик, күреп торасыз, эшләр без дигәнчә бармый, ике ел рәттән корылык, ике ел рәттән иген уңмады, планнар үтәлми. Ничек тә җаен табарга, бу хәлдән чыгарга кирәк. Шуңа күрә колхоз идарәсе инде байтактан бирле безне әллә ни мантытмаган болынны сукалап ашлык чәчәргә дигән карар чыгарды. Бу бит, иптәшләр, меңнәрчә центнер өстәмә иген дигән сүз. Ә менә идарә членнарыннан ике кеше — авыл Советы башкарма комитеты председателе Һидият Хәкимуллин, колхозның элекке председателе Саттар абый — сөйләп күрсәткәнемчә, бу эшкә каршы килделәр. Башта Алкын елганы буыйк, болынны шул килешендә тәртипкә китерик, диләр. Алар тырышлыгы белән мәсьәлә менә сессиягә куелды. Нигездә моңа беребез дә каршы түгел. Әмма ул бик кыйммәткә төшәчәк. Безнең әле болай да төзисе, төгәллисе объектларыбыз күп. Хәзергә вакыты кыйммәт. Буа хакында тиешле җирдә сөйләшенде. Елга үзәненең берничә урынында зур-зур плотиналар кору киләсе бишьеллыкта дәүләт планына кертеләчәк. Монда күрше колхозлар файдасы да күздә тотыла. Үзебезнең комаяк тирәсендәге тугайлар да элекке хәленә кайтачак. Менә шулай, иптәшләр, идарә карар кылганча эшләргә кирәк.

Зал беравык гөжләп торды, өзек-өзек сүзләр ишетелеп алды:

— Дөрес әйтә председатель, ни печәне хәзер, ни чүрты...

— Ашыкма, чамалабрак...

— Чамалангандыр инде...

— Җәл бит болын...

— Идарәдә дә башсызлар түгел...

— Һе...— дип куйды Әхмәтша бабай да. Әмма моны янында утырган Гаяз карттан башка берәү дә ишетмәде бугай.

— Нигә һеһелдисең, әнә Хәсәнбай тугае да элекке хәленә кайтачак ди ич.

— Ай-һай...

Әхмәтша бабай тынып калды. Ул хәзер үз уйларына бирелгән иде. Сессиягә керер алдыннан гына комаяк турысында печән чапкан вакытларын, завод директоры белән булган хәлләрне искә төшереп, көлешеп алганнар иде. Әле менә Билал да шул тугай хакында сүз кузгаткач, Әхмәтша карт үзалдына җанланып, көлемсерәп куйды.

Хәзер инде көлеп кенә искә алсалар да, вакытында Миңҗамалдан байтак яшь түктергән, Әхмәтшага шүре туны кидергән вакыйга булды ул.

Өйләнешкән генә чаклары иде. Колхозның да оешкан гына еллары. Шулай күмәкләшеп печәнгә төшкәннәр иде. Гармуннар белән. Булган икән, әйдә булсын инде дип, әртил казанына бер үгез дә чаласы иттеләр. Шуның өстенә тагын Әхмәтшалар бригадасына Хәсәнбай тугае дип йөртелгән ерак болын туры килгән иде. Ерак дип әллә ни ерак та түгел, Ак Чишмәдән өч-дүрт кенә чакрымда ул. Ә урыны... Оҗмахың читтәрәк торсын! Бер ягы карлыганлы, шомыртлы куе әрәмәлеккә килеп терәлсә, икенчесе зиреклеккә барып тоташа. Өченче кырые ачыклыкта җәелеп үскән юан-юан наратларга кадәр барып җитә дә, аларны аралап, эреле-ваклы аланлыклар ясый-ясый, мари урманнарына ук кереп китә. Калган бер почмагы исә комаяк турысындарак шул ук Алкын елга буена килеп чыга. Ай-һай, калын булып төшкән иде соң ул елны печән. Килде-китте чалгычыга якын да бармалы түгел иде.

Һәммәсе дә бик әйбәт, бик күңелле башланган иде. Хәер, елы ук туа-тумышыннан гел елмаеп, гел көлеп кенә торган иде Әхмәтшага. Ник дисәң, беренчедән, сөйгәненә өйләнеп, кышын ул яшь кияү булды. Башка чыгарга ниятләгәч, колхоз буралык юнәтешергә вәгъдә итте. Инде килеп, әле узган сабан туенда гына батыр калды. Хәзер әнә печәнчеләргә аш пешерүче итеп аның Миңҗамалын сайладылар. Мондый да мәртәбәле эшне яшь киленгә түгел, гомер иткән кайбер апайларга да кушмыйлар. Кем белгән дә, кайсы гына рәхмәт төшкересе җиткергәндер Миңҗамалның осталыгын!

Күңеле күккә ашар өчен авыл егетенә тагын шул җитмәгәнмени?! Алай да ул: «Әйдәле, батыр, монда да күрсәтеп кара үзеңне, юлны син яр» дигәч, каушабрак калды. Юк, булдырмам дип түгел, сынатмас иде анысы. Елның елында, беренче чалгычы булып, башлап йөрүче — Гаяз дусының этисе Солтангали абзасы алдында уңайсыз иде аңа. Егет үзе баш тарткач, кыстап интектермәделәр. «Ярый, алайса, башы яшь, өлгерер әле, минем артка бассын» дип, гадәттәгечә, алдан Солтангали абзасы кереп китте...

Хәл алырга туктаган бер арада Әхмәтша Миңҗамалы янына килде. Анысы сулы мичкә торган арба күләгәсендә бәрәңге әрчеп утыра иде. Әхмәтшасын күргәч, яшь килен сөенеп, эчтән-тыштан балкып китте. Аннары иркәләүчән бер тавыш белән сорап куйды:

— Армадыңмы?

— Бар бераз. Солтангали абзый артыннан баруы!.. Алай да түзәргә була. Син генә сынатма.

— Бәрәңге юарга су алып килсәң, сынатмам.

— Менә ич су, — диде Әхмәтша, мичкәгә сугып.

— Чишмә суы ич, әрәм була. Кирәге күп әле аның.

Әхмәтша, ике чиләк тотып, елгага таба йөгерде.

Комаякның авылдашлары «казан» дип йөрткән чоңгыл бер турысыннан су чумырып, инде кайтам дип кенә торганда, Әхмәтшаның борынына ят ис бәрелеп китте. Елга өстенә юньләбрәк күз салса, башларын судан чыгарып, агым уңаена хәлсез генә йөзгән балыкларны күрде. Кайберләре инде йөзә дә алмыйлар, елга өстенә чалкан яткан килеш, ак корсаклары белән ялтырашып чак-чак кына кыймылдыйлар. Әхмәтша барысын да аңлады: былтыргы хәл кабатлана. Монысы әле башы гына, ахыры ни белән бетәсен дә бик яхшы белә ул. Узган көз борыныңны кысмыйча елга тирәсенә якын килерлек булмаган иде. Хәтта каз-үрдәк бизде. Яр кырыйларында, су өстендә — кая карама анда — үлгән балык иде. Алкын елгада бер генә җан иясе дә калмагандыр дип уйлаган иде егет. Хәзер генә тагын!.. Әхмәтшага эсселе-суыклы булып китте һәм ул, урман артыннан морҗасы гына күренеп торган спирт заводына карап, җан ачуы белән кычкырып җибәрде:

— Бәдбәхетләр!.. Корткычлар!..

Буш чиләкләрен шылтыратып, төсе качкан ире йөгереп кайткач, яшь киленнең коты алынды.

— Ни булды? Пәри күрдең мәллә?!

— Пәри, пәри... Завод энә тагын буза җибәргән! Туктале мин аларны!..

Әхмәтша йөгән тезгене белән арбага бәйләнгән килеш печән ашап торган атны каударлана-каударлана чишәргә тотынды. Иренең ниятен чамалап алган Миңҗамал:

— Йөри күрмә, зинһар, син барып кына...— дип ялына, ялвара башлады.

Тик Әхмәтша инде сүз тыңлар хәлдә түгел иде. Менеп атланды да, чабата үкчәсе белән алашаның янтыгын төя-төя, урыннан ук кушаяклатып завод ягына чапты...

Президиум өстәлендә графинга каккалаган тавышка Әхмәтша бабай уйларыннан бүленеп калды.

— Иптәшләр, тынычланыйк әле. Нишлибез, берьюлы икенче докладны да тыңлыйбызмы, әллә фикер алышуга күчәбезме?

— Шулай булсын...

— Ничек шулай?

— Тыңлыйк икенчесен дә.

— Каршылар юкмы?

— Юк...

— Юк...

— Алайса, килештек. Сүз авыл Советы башкарма комитеты председателе Һидият Хәкимуллинга бирелә...

— Иптәшләр! Җирдән файдалану, шул ук вакытта табигатьне саклау — бер-берсеннән аерылгысыз нәрсәләр. Шуңа күрә сессия утырышына бу ике мәсьәләнең бергә куелуы аңлашылса кирәк. Сүз дә юк, хәзер бездә җиргә кадер, хөрмәт дигән нәрсә бик нык артты. Шуның аркасында елдан-ел ныгыйбыз, үсәбез. Колхоз председателе моны саннар, фактлар белән дә күрсәтте. Болар һәммәсе дә безнең төп байлыгыбыз булган икмәккә, ашлыкка бәйле. Тик, иптәшләр, кайвакытта без, җирне әрәм яткырмыйк, чәчү мәйданын киңәйтик, сөрү өчен басуларны җәйлырак итик дип, алдын-артын уйлап тормыйча, чаманы да югалтабыз, каш ясыйм дип күз чыгарабыз. Ак Чишмә янындагы калку кырны нишләттек? Башта, кем житте шул чыбык-чабык кисеп, аннан сөрергә җайсыз, теләсә кем теләсә кайдан сукмак сала, иген таптала дип, вак урманны кырып ташладык. Ә хәзер анда энә ерганак, җирне ашый, аралыкны юшкын басты.Инде кабат агач утыртырга туры килде. Тик соңгардык бугай. Шундый зур хәзинәне, байлыкны харап иттек. Нихәтле үлән үсә иде аралыкта, печән чаба идек. Ә хәзер мал-туар кертерлеге дә калмады. Шуның өстенә тагын чишмәсе дә томаланды. Мәликә чокыры белән дә шундый ук хәл. Тирә-ягында, яр битләрендә нинди әйбәт чикләвек куаклыгы иде! Анда да басу таптала, анда да җирне саклыйбыз, имеш. Кыркыдык энә нихәтлесен, киңәйде ул басу! Аның каравы, никадәр ерганак барлыкка килде, берьюлы ике чишмәне томаладык. Барысы да бер елны, бер үк шаукымга бирелеп эшләнде. Авыл Советы күрмәде түгел, колхоз идарәсе белән сүзләшеп тә йөрдек. Тыңламадылар. Башкарма комитетның ныклыгы җитмәде, вакытында чарасын күрмәдек...

Инде болын мәсьәләсе. Дөрес, хәзер ул печәнне элеккечә бирми. Былтырлы-быеллы бигрәк тә. Тик ашыкмыйк. Бичарадан ни чара дип кенә тотыну зур отыш бирмәс. Ни өчен ул шундый хәлгә килгән? Әлеге дә баягы, шул Алкын елга кибүдән. Дым тартмый, чык төшми. Елга тулып торса, аның дымы чакрымнарга китә. Ә бит безнең болын дүрт яктан да елга белән уралган. Шуның өстенә тагын язгы ташулар вакытында су астында кала иде...

Һидият колхоз председателе китергән саннарга, фактларга каршы үз саннарын куйды, исәпләгәндә болынның бүгенге хәленә карап түгел, ә элеккесен һәм киләчәген күздә тотып фикер йөртергә кирәклеге турында кат-кат тукталды.

— ...Өлкәннәр хәтерлиләр, билдән булып төшә иде анда печән. Менә исәпләп карыйк, күпме була ул өч йөз гектарга? Бу бит бушлай килгән байлык, бернинди көч куймыйча, чыгым тотмыйча. Әлбәттә, хәзер инде болар юк, сукалап ашлык чәчү файдалырак төсле. Ә төптәнрәк уйласаң, киләчәкне күздә тотсаң? Юк, иптәшләр, безгә аны әлегә табигый хәлендә сакларга, башта Алкын елганы буып, элеккечә суга туендырып карарга кирәк. Аннан күз күрер....

Һидият сулыклар турында куерта башлагач, Әхмәтша бабайның уйлары тагын да шул Алкын елгага, бая бүленеп калган хатирәләренә әйләнеп кайтты. Колаклары доклад тыңлый, ә күз алдында күптәнге вакыйгалар җанлана.

...Эшнең нидә икәнен сизгән иде шул Әхмәтша. Шуңа күрә туп-туры завод янындагы буага ашыкты. Һәм, чыннан да, алданмаган. Моны ул Алкын елга кушылдыгы Чапкыр суга барып җиткәч тә белде. Урман чишмәләреннән башланып, яланга чыккач, иркә-назлы кызлар кебек бормалана-сырмалана, эреле-ваклы бусагалардан сикерә сикерә аккан көмеш сулы шук елганың карарлыгы да калмаган. Яр буендагы үләнкамышларга, тал төпләренә, су өстенә асылынган тал толымнарына әйтерсең дегет сылаганнар. Яр кырыйлары буйдан-буйга каралып, шомлы бер ялтырау белән ялтырап ята иде.

Буа дигәне — урман буйлатып Чапкыр суга килеп чыга торган коры елга. Завод аны бер яктан буган да үзенең бөтен калдыгын-пычрагын шуңда агыза. Ул шулай ел буе тынчып, язгы ташуларга хәтле тирәюньгә «хуш исен» таратып ята бирә. Язгы ташулар исә бу пычракны буасы-ние белән алып китә тора. Чакрымнарга җәелгән болганчык, язгы мул су аркасында янәшә-тирә авыллар моны рәтләп сизми дә кала. Рәхәт завод җитәкчеләренә, мәшәкате юк. Ташу узгач, аннанмоннан кабат буалар да — җаннары тыныч.

Әхмәтша килеп җиткәндә буа тирәсендә унлап кеше кайнаша иде. Ерылган урынны ямарга тырышып, кайсы чыбык-чабык, кайсы тачка белән таш, җир ташый. Агасы инде житәрлек кадәр аккан. Шулай да әле буада мазут катыш лайлалы су байтак иде. Чөнки буа төбенә чаклы ерылмаган. Су хәзер ургылып, ишелеп үк акмаса да, барыбер юлын таба. Кешеләрнең дә әллә ни пошынулары сизелми. Әйтерсең лә берни булмаган, каударланмыйча гына үз җайларына кыймылдый бирәләр. Моны күргәч, болай да җен ачуы чыгып килгән Әхмәтша түзмәде, кулларын йодрыклап, баш өстендә селкә-селкә:

— Җансызлар!.. Ваемсызлар!.. Бу ни хәл?! — дип кычкырды.

Эшчеләр күтәрелеп карадылар да үзләре дә кычкырырга тотындылар.

— Син кем әле ул кадәрле безгә җикеренергә?!

— Каян килгән белдекле баш!..

— Чабаталы нәчәлник!..

Ул да түгелү арадан берсе, тачкасын калдырып, Әхмәтша янына килде. Завод тирәсендә сезонлы эштә йөрүче күрше авыл кешесе иде бу. Танышлар.

— Син, энем, алай бик тузынма. Безмени. Буа саркый башлагач ук, карарга, ныгытырга кирәк, дип әйтә килдек. Юк бит, тыңламадылар. Җитмәсә, кичә генә нихәтле буза агызганнар. Юлын бер тапкач, күп кирәкмени ул. Төнлә белән ерган да киткән.

Шау-шуга каяндыр завод директоры килеп чыкты. Өстенә хәрбиләрчә яшькелт гимнастерка, куе зәңгәр галифе чалбар, башына күн фуражка, аягына хром итек кигән юка гына, чандыр гына бер кеше. Киле-

килешенә, сары мыегын тырпайтып, ат өстендә яман да ачулы кыяфәттә утырган Әхмәтша янына атлады.

— Син кем? Ник шаулыйсың? Ник тыкшынасың үзеңә кагылмаган эшкә?!

Әхмәтша кыза-кыза һаман үзенекен тукыды, бу хәлнең корткычлык икәнен аңлатырга тырышты. Әмма директорның аңлар исәбе юк иде. Әле ул гынамы? Мыскыллы елмаеп: «Әйдә, йөрмә монда сару кайнатып»,— дип, йөгәнгә ябышты да атны кайту ягына бора башлады. Бу кадәрле кимсетүгә, күзенә карап мыскыллауга Әхмәтшаның түзәр чамасы калмаган иде. Һәм түзмәде дә. Дүртәр потлы арыш капчыкларын чөеп кенә йөрткән егеткә әлеге чүрәкәй үрдәкне генә очыртуы берни түгел иде. Ат өстеннән үрелеп, култык асларыннан йомарлап күтәрде дә буага очырды директорны. Эшчеләр ни кылырга белмичә аптырашып тордылар да, кайсы көрәк, кайсы чыбык тотып, директорны коткарырга ашыктылар...

Шул көнне үк кичкырын болынга ике милиционер килеп, Әхмәтшаны район үзәгенә алып киттеләр. Байтак тоттылар егетне, айга якын тикшерделәр, допрос алдылар. Шүрләде Әхмәтша, үкенде Әхмәтша. Алай да нишләсең, булган эш инде булган, ни күрсәм дә күрермен дип, шактый ук тынычлана да башлаган иде. Ә бер көнне сак астында бу утырган бүлмәнең ишеген ачып җибәрделәр дә:

— Әйдә, егет, сыпырт моннан,— диделәр.

Сыпыртты Әхмәтша, үз аягы үзендә, әйтеп, куып торучы барында нигә дип ябылып ятсын әле ул.

Капка төбенә атылып чыкса, җигүле ат белән Солтангали абзасы көтеп тора иде. Исәнме юк, саумы юк, арбага ымлады да:

— Башың китәсе иде бит, малай актыгы, утыр, — диде. Тик бераз киткәч кенә өстәп куйды: — Бөтен авыл белән яклап калдык. Шулай ярыймы соң, җүләр баш?!

Юл буе сөйләшмәделәр. Әмма Солтангали абзасының әйтәсе сүзе тагын да калган икән әле. Авылга кайтып җитәрәк кенә, завод морҗасына таба чыбыркы сабы белән төртеп:

— Көн саен мунча керә икән хәзер директоры... Эшеннән алалар бугай,— диде...

Әхмәтша бабай, уйларыннан бүленеп, башын Гаяз картка таба борды да терсәге белән аның янтыгына төртеп алды.

— Син нәрсә... тора торып?

— Солтангали абзый искә төште әле. Син дә нәкъ шул. Койган да куйган.

Соң... Улы булгач. Шаулама, һидиятне тыңлыйк әле.

— ...Без көч куеп, тир түгеп тапкан байлыкны гына байлык итеп карарга өйрәнгәнбез. Бушлай килгәне, табигать биргәне исәпкә алынмый. Мәңге шулай булган, шулай булыр төсле тоела. Түгел икән ич. Әнә бит болынны нинди хәлгә китергәнбез?!

Авылларга су кертсәк, бу безнең хезмәт җимеше, зур казаныш дибез, мактанабыз. Ә чишмәләр? Аларны онытабыз. Чишмәләрне, елгакүлләрне һәм табигатьнең башка байлыкларын саклый белүне дә зур казаныш дип танырга өйрәник. Авыл Советы колхоз идарәсе каршында бер генә кузгатмады бу мәсьәләне. Әмма чишмәләрне ачарга җыену сизелми. Авыл Советының моңа көче җитми, монда хәзер бульдозерлар кирәк. Кешегә бер икмәк кенә димәгән. Заманыбыз хәзер ул түгел. Күңел байлыгы да, рухның көрлеге дә безгә бик кирәк. Без табигать балалары, безне табигать тә тәрбияли. Шул киң күңелле, юмарт, сабыр анабызны кайчагында оятсызларча талыйбыз, биргәнен дә алабыз, бирергә теләмәгәнен дә алабыз. Нинди матур, балыклы, аккошлы күлләр уры-

нында коп-коры чокырлар торып калды. Җил чыкса, күз ачкысыз ком бураны күтәрелә. Инде карап торган бер болыныбыз бар. Дүрт авылның тәрәзәсе шунда карый. Ул да хәзер кысасыннан төшкән алка ташы кебек кадерсезләнә, кыршыла бара. Кайтарыйк без аңа үзенең көмеш кысасын. Алкын елгасын. Ул безгә бише белән түләр... Мин колхоз идарәсенә болынны саклау турындагы карарын юкка чыгарырга тәкъдим итәм һәм авыл Советының башка депутатлары да бу фикерне яклар дип ышанам.

...Сөйләүчеләр күп булды. Депутатлар да, депутат булмаганнары да кыстатып тормадылар. Кайсы Билал, кайсы Һидият ягын каерды. Бәхәсләр куерды, кызу барды. Ниһаять, алдан ук кыжырап та, никтер азакка табарак кына Әхмәтша бабай да сүз алды. Кулына тотып, әйләндергәләп утырган яңа эшләпәсен Гаяз картка калдырды да трибунага атлады...

— Туганнар! Без монда чакырулы кунаклар. Картлар, ягъни мәсәлән. Сезне дә тыңлап карыйсыбыз килә, диделәр. Без үзара сөйләштек, килештек тә... Менә миңа куштылар сөйләргә. Кыйбатка төшә ди ул Билал. Төшә инде. Хәзер төшә ул. Һидият тә сөйләп күрсәтте бит. Без аңа кушылабыз. Икешәр тапкыр чапкан елларыбыз да күп булды элек. Богыл куяр урын тапмый интегә идек...

Залдан:

— Алай ук булмагандыр инде, Әхмәтша бабай!

— Кайсыгыз ул анда? Болында богыл куйганың бармы соң синең? Җайлы урын дип әйтүем ул минем... Һе... Хәзер инде юк, чалгы селтәр җире калмады, кыршылган тун шикелле. Сәбәбе ачык, әнә сөйләп күрсәттеләр. Һәм дөрес. Аннан килеп, елганы бусак та су җитмәс диләр. Моныса да дөрес, бу килештән җитмәячәк. Сугарулы итәргә исәп тотсак — бигрәк тә. Каян килеп җитсен ди ул. Аралыктагы чишмә нинди иде? Гөбе юанлыгы булып ата иде бит. Шул булып шул томаланды. Әмма алай ук хафаланмыйк. Әхтәм белән, Гаязтин белән караштырып, чамалап йөрдек әле. Берсендә әнә Хәертдин дә бар иде. Арбада тыркылдый-тыркылдый әчләр коелып бетте.

Залдан:

— Без көн саен тыркылдыйбыз әле, ул-бу юк!

Район белән ике арадан кайтып керми торган симез гәүдәле сельпо председателе иде бу. Хәер, залның икенче очыннан үзенә дә чәпәделәр:

— Сиңа ни булсын... Синең сиртмәң йомшак, сиздермәс!

Әхмәтша бабай башкаларга кушылып көлде дә тагын ялгап китте:

— Саркый әле ул чишмәләр, Мәликә чокырындагылары да, аралыктагысы да. Кипмәгәннәр икән, шөкер. Күзләрен генә ачасы бар. Эше күп күбен, нишлисең, туры килә инде. Тотасың расходны...

Әхмәтша бабай, әйтәсе сүзен оныткандай туктап, такыр башын сыйпаштыргалап бер залга, бер президиум өстәленә таба каранып торды да тагын дәвам итте:

— Син, Билаттин, хуҗалык җанлы, кайда зыян, кайда файда икәнен чамалый беләсең. Шулай булмасаң, без сине персидәтел итеп сайлый идекмени? Тик бу юлы саташасың. Сиңа хәзер кирәк, бүген кирәк. Исәпләгез әле тагын бер. Алгарак карап. Планнарны бергә кабул иттек, кул күтәрдегез, дисең. Дөрес, шулай булды. Соң, шундый хәл килеп чыккач... Күктән ингән план түгел ич ул. Тагын бер клуб саласы бар, пекарня, дисез. Алары да кирәк. Әмма елына күрә түзәргә була. Яшьләр үпкәләмәсеннәр, заманында без дә театр уйнап йөргән кешеләр. Пекарня юк дип иписез дә утырмыйбыз. Түзик тагын беразга. Шуларга дигән акчаны буага, болынга тотыйк. Теге чакта да селтәнүчеләр булды инде ул болынга. Саклап калдык. Саттар исә бөтенләй эштән чыкты. Бүген әнә сессиягә дә килә алмады, больниста ята.

Президиумнан:

— Фикерен язып калдырды ул, укырбыз...

— Калдырса бик шәп. Ә менә Хәсәнбай тугаен саклый алмадык. Плотина коргач, элекке хәленә кайтачак, дидең. Ай-һай... Әле кайчан корыла ул? Бу бишьеллыкның өч елы бар. Киләсендә тагын биш ел. Озакка китә бит. Ә без, картлар, ашыгабыз. Тулып калсын бездән ул елгалар, ул күлләр. Яшәрсен болыннар. Киләселәр безгә үпкә сакламасын.

Инде авыл Советы турында. Һидият зарланды да зарланды. Тыңламыйлар, үтәмиләр, ди. Үтәтергә кирәк. Хәзер инде колхоз элекке колхоз түгел. Ябык еллар, шөкер, үтте. Шулай булгач, ник йөрергә бозавына үпкәләгән сыер кебек. Хокук бирелгәнме, бирелгән. Куллан тулысынча!

Тагын бер сүз. Колхоз зур, идарәнең эше муеннан. Хуҗалык итү, һәркем белә, бик четерекле нәрсә. Очын-очка ялгыйсы бар. Кайчагында, мавыгып китеп, табигатьне оныталар. Нишләргә соң? Турыдан-туры үзләре җигелсеннәр моңа советлар. Ничек итеп дисезме? Колхозның кеременнән табигатьне саклау өчен кирәк кадәр акчаны авыл Советы бюджетына күчерергә кирәк.

Залдан:

— Әхмәтша бабай, андый закон юк бит!

— Булмаса булдырырга кирәк. Депутатлар ич сез. Кертегез шундый тәкъдим, карасыннар югарыда. Ә болай!.. Зират әйләндереп аласы булса да, колхоз идарәсенә чабалар. Акчасы булса, Совет кирәген үзе табар, үзе эшләтер иде. Колхоз да авыл Советы белән ныграк исәпләшә башлар. Идарә биш кат уйлар иде ул чагында, вак урманны кисәргәме, юкмы?.. Азмыни шундый хәлләр...

Әхмәтша бабай сүзен төгәлләгән кебек туктап калды. Залдагылар кул чабарга тотындылар. Тик картның сәхнәдән төшәр исәбе юк иде әле. Һәм менә ул, президиум өстәле янында кырыйдан гына урын алган Салихка таба борылып, нидер әйтте. Тегесе, җәһәт кенә торып, сәхнә артына кереп китте. Әхмәтша бабай тагын залга карап:

— Җәмәгать, инде күп сөйләдек. Мин дә шул, һич тә уйламаган җирдән, шактыйга суздым. Менә Салих чыксын да... Бетерәм,— диде.

Карт, трибуна янында торган килеш, артына борылып карады. Анда зур гына арыш капчыгын күтәреп Салих чыгып килә иде. Зал гөжләп куйды. Ул арада Әхмәтша бабай белән комбайнчы капчыктан калын-калын катыргыларга ябыштырып ясалган зур-зур рәсемнәр чыгара башладылар. Чыгара баралар, я трибуна, я президиум өстәле кырыена элә торалар... Сессия ачылыр алдыннан кемнеңдер кулы уйнаганы сизелә иде. Кайда кирәк — шунда кадагы кагылган.

Залдагылар аптырашта калдылар. Һидият исә сикереп ук торды. Ул чиктән тыш дулкынланган иде. Шау-шуны басарга тырышып, президиум өстәле аша Әхмәтша бабайга дәште:

— Әхмәтша бабай, ничек булды бу?!

Карт та аңа ишетелерлек итеп җавап кайтарды:

— Гаязтин белән министрга кердек...

Бу сөйләшүне алгы сафта утыручылар да ишетеп алды. Әмма берни дә аңламыйлар иде әле. Тик «министрга кердек»кә генә ишарәләп, берсе шаяртып куйды:

— Әйтәм аны, яңа эшләпә кигәнсең!

Әхмәтша бабай тавыш килгән якка күз йөртеп чыкты һәм кулъяулыгы белән итләч муенын сөрткәләп, көлеп утырган сельпо председателен күреп алды.

— Тагын син икәнсең! Ерма син авызыңны, ерма, менә боларга кара... Ачыбрак кара күзеңне...

Күзләр инде болай да рәсемнәргә төбәлгән иде. Ә анда — теләсәң нинди залны, теләсәң нинди почмакны бизәрлек табигать күренешләре. Менә-менә җил исеп куяр да, балан, шомырт куакларына, төнбоеклы күл буендагы җикән камышларына, елга кырыена сырышкан тал-тирәкләргә кинәт җан кереп, барысы да берьюлы тибрәнә, шаулаша башлар төсле...

— Менә, ичмасам, бизәделәр!

— Күргәзмә агитация...

— Көн тәртибе шундый ич...

— Ш-ә-әп!..

Әхмәтша бабай, залга колак салгалап, күкрәге белән трибунага капланган килеш, тавышсыз-тынсыз тора бирде. Һәм менә ул, ниһаять, кулын күтәрде дә тамак кырып куйды. Зал тынычлана төште. Каян алган карт бу рәсемнәрне, нигә дип китергән ул боларны? Һәркемнең шуны беләсе килә иде. Әхмәтша бабай да инде озак көттермәде:

— Мин өлкәннәр турысында әйтмим, алар беләләр. Ә яшьләр... Кайсыгыз таныды шушындагы берәр күренешне? Карап тордым, никтер сизелмәде. Күргәзмә агитация, дидегез. Булса соң? Тик әллә кайдан алып кайткан рәсемнәр түгел. Барысы да элекке Алкын елга буйлары, безнең әрәмәлекләр, безнең күлләр, безнең тугайлар. Хәзер инде алар юк. Нәрсә, әллә шушы рәсемнәрне генә калдырыйкмы үзебездән соңгыларга? Без инде бозасын боздык, корыта алган кадәресен корыттык, сез теләсәгез нишләгез, дикме?!. Без картларның сүзе менә шул. Калганын әнә депутатлар, колхоз идарәсе уйласын...

Әхмәтша бабайдан соң зал озак кына шаулап торса да, сүз алып тагын да сөйләргә теләүчеләр табылмады. Мәсьәләне тавышка куйдылар.

Алып баручы:

— Кем дә кем колхоз идарәсе болын турындагы карарны юкка чыгарсын дигән тәкъдимгә кушыла, кул күтәрегез!.. Берәү, икәү... Хәертдин бабай, Дилбәр! Иптәшләр! Депутатлар гына күтәрә кулны... ун... унбиш... егерме. Кемнәр каршы? Берәү, икәү, өчәү... Сигез кеше каршы. Шулай итеп, күпчелек тавыш белән, болынны сукаламаска, табигатьне саклауга җитди игътибар бирергә дигән тәкъдим кабул ителде.

*

* *

Председатель итеп сайланганнан бирле, бәлки әле беренче тапкырдыр, Билал хуҗалыкка бер ул гына, бер идарә генә хуҗа түгел, ә колхозны бар иткән авыл Советы да үз урынында — сакта икәнлеген сизде. Сессиядә утырганда да, аннан соң ялгыз калып уйлана башлагач та ул үзен беркадәр югалып калгандай хис итте. Ләкин кемгәдер үпкә дә, рәнҗү дә юк аның күңелендә. Бары тик каушау, сүзен сүз итә алмавына чак кына үрсәләнү. Бары шул гына.

Әле тагын бер нәрсәне сизде Билал. Яраталар икән ич үзен, ышаналар икән. Уйласа уйларлыгы бар.

Бүген ул шоферсыз гына юлга чыкты. Район үзәгенә барышы. Машинасын да кумый. Иң әкрен тизлектә. Башлап кая сугылыр, райкомгамы, райбашкармагамы? Бәлки сельхозтехникагадыр? Әйдә, уйласын, сайласын. Ул да бит табигать баласы.

ooooooooooooooo

## Рәдиф Гатауллин

### Нигез сагындырса

Гомер чишмәсеннән ерак китеп,
Якынайган саен диңгезгә,
Ешрак сагынам һаман әнкәм өен,
Ныграк табынам туган нигезгә.

Чит җирләрнең күреп йолдызларын —
Җилләр көчен тойган хәлемдә,
Туган җиремә мин урап кайтам, —
Тукаема,
Такташ,
Җәлилгә.

...Өмет белән сугылам якташларга —
Мостай ага, Наҗар Нәҗмигә.

Гадиерәк хәзер идеаллар да,
Матильдалар түгел, я Сандлар:
Истә күбрәк Сәмитова апа,
Мозаффария, Гыйффәт туташлар[1].

Эйфель башняларын күрдем инде,
Ләкин
Сөембикә җанга якынрак,
Парижларда сагынам Казанымны,
Тик каладан — авыл артыграк...

Зур хыялга тимим, дөнья гизсен,
Әүвәлгечә, юлым — диңгезгә.
Тик еш сарыл, җаным, арышларга,
Төштә әйдә һаман ныграк үксе
Үзең ташлап киткән нигездә....

---

[1] Газизә Сәмитова, Мозаффария, Гыйффәт туташ — шагыйрәләребез.

•

Сиңа багышланган шушы җырым
бәхетләргә озата барсын сине!
Туй атына таккан кыңгыраудай,
 сискәндереп шатландырсын сине,
 җаныңа үтеп кергән көе белән...
Котлап
язмышка кул биргән көнең белән,
 тарантасың артына ук басып,
ак йортыңа озата барсын сине!

Ә син
иске алма бу көнеңдә мине:
ахры,
җиңә алдым мин
үз-үземне,
өстен куеп синең бәхетеңне...
(Тик бәхетле булсаң иде, эх, булсаң иде!)

Җырым
бәхетләргә озата барсын сине!
Борыла күрмә үткәннәргә кире:
анда — яфрак койган урман, хыял иле.
Ә алдыңда тормыш үзе инде —
тигезләр я тигезсезләр җире!

Ләкин, җырым
бәхетләргә озата барсын сине!
Туй узгач та,
якын моңы белән
әле озак яңгырар кыңгыраудай,
хәтереңдә күпкә калсын иде
сиңа багышланган шушы җырым!

•

Болытлы көннең кояшы
югалып, ерак йөри.
Иртәдән бирле офыкта
борчулы йөрәк йөри.
Мәңгегә китмәгәндер ул,
 үз юлын белми булмас.
Болытлар үтәр, аязыр...
Кояшын табар бу яз!
Күгеннән, күздән югалып
Китсә дә вакытлыча,
борчылып, Кояш юлыннан
күңелләр күккә оча!
Болытлы күңелдән дә бит
Кояшы ерак йөри.
...Күр, күктә давыл агышы...
Болытлар белән тартышып
ул минем йөрәк йөри!

## Якташ шагыйрь турында

Дүртөйледән без дүртәүбез...
*Н. Нәҗми, «Шәйхзадә Бабич»*.

Дүртөйледә нигә тумаганмын?! —
Иркен урамында Әсәннең
Үсмәгәнмен нигә?!
Беләм ямен
туган якны сагынып яшәүнең! —
Бу якларның беләм матурлыгын,
ишетеп түгел, тоеп наз-җилен...
«Дүртөйледән — дүртәү»... Күреп беләм
Минештесен Нажар Нәҗминең!
Күреп беләм
Бәдрүш Мокамайның туган авылын, —
Зыя Мансурның...
(Якташ итеп белсен алар исемен
авылымның минем, Марсымның!)
...Нәни Куәш аккан җирдә Әсән,
шагыйрь авылы, исемең таныш бик, —
Сөйлә, каян килде аңа садә,
Тукайга тиң моң, көч — Бабичлык?!
Халык йөрәгеннән ургылганмы
зур гамь тулы җырлар чишмәсе?! —
...Сусаганда ешрак кайтасы бар,
туган якның суын эчәсе.
Гаҗәпмени сихри моңнар белән
кабатланса шагыйрь башкада?!
«Дүртөйледән — дүртәү» генә булмас —
Бабичыннан исәп башланса...
Матурлыгы шул ук Дүртөйленең,
урамы киң, иркен Әсәннең...
Беләм мин дә ямен —
туган якны,
якташымны сагынып яшәүнең!

## Роза–Турайда

Латвиянең күмеп урманнарын
салкын карлар яуган бу айда
каян килде сиңа тере чәчәк —
ал розалар, Роза-Турайда?[1]
Усаклары шаулый Сигулданың,
җилләр сызгыралар юлларда.
Ә гашыйклар йоклый,
язын алар
уяныр мы, Роза-Турайда?
Латыш Джульеттасы, Ромеосы...
Легендалар охшаш — дөньяда:
Таһир белән Зөһрә кушылган җир
кайда икән, Роза-Турайда?

[1] Роза-Турайда — Латвиядәге мәгълүм легендага бәйле урын.

Ә мәхәббәт үлми,
синдәгедәй
мәңге янар җаннар булганда...
Бу розалар алар гомерен бәлки
дәвам итә, Роза-Турайда?
Мине мәңге соклandырыр гөлләр
Иделемдә, болын-тугайда....
Гел эзләрмен гашыйкларың төсен...
Антым сиңа, Роза-Турайда!

## Һәйкәл янында

Таш атларын тыеп
тынып калган
Латыш укчылары.

...Туктал, Кеше, башың иеп уйлан
бер минутка бары.
Нәрсә сөйли сүзсез латыш батырлары?

«Җиңеп кайттык. Тик, югалтулар зур...
Авыр хәбәр. Ничек әйтик аны?
Иптәшләрнең күбесе кайталмады,
еракта — атлары...
Кайтты илгә канлы байраклары...
Ерак Идел, Уралларда ятып
калды
латыш укчылары, җайдаклары...
Таш атларда
ярып үтик әле бу тынлыкны!
Ул кургаштай авыр.
Сузыйк матәм көен сүзсез генә —
кыен ул җыр...
Ә аннары Тарих өчен аны
мәңгеләштерер чор».
Һәйкәл булып калган таш атларда
кайткан авыр минут.
...Туктал, Кеше: синең хәтерең өчен
яна мәңгелек ут.

Таш атларда — латыш укчылары.

●

Э. Г. га

Тукта әле, туктал тик беразга,
Әгерҗе поезды!..
Әллә нигә гомер синең кебек
гел ашыгып узды...
Ашкынганга чыккандыр рельсеннән
Кайчакта яшьлегем.
...Тойгыларның авыр йөген бүген
яшемә яшердем...

Туктал әле, поезд, гамьсез узып
син калдырган якта
шпалларга башын салып бәлки
үкенечем ята?!
Төшлегенә җитә гомер, ахры,
гүзәл мизгел узды.
Тоталмадым. Нигә туктамадың,
Әгерже поезды?

●

Үзбәк шагыйрәсе Этибор Ахуновага

Күк диңгезнең күкрәгендә дулкын уйный...
Ярда исә яшь бер ханым. Ул ни уйлый?!
— «Мәһабәт бу чиксезлектә, хәрәкәттә
юлыктыммы җанга охшаш бер халәткә?
Давыл, тынлык, көрәш, яшәү — кушылганмы?
Тын дөньяны шаулатыр җыр шушындамы?
Дулкыннарга сәбәп — Кояш, Ай, Җир эше,
тарту көче. Ни — тартышу сәбәпчесе?!
Нинди гәүһәр өлгерсен дип упкыннарда,
әрмый-талмый йөзү язган дулкыннарга?!
Үзенә чакыра яр диңгезне сере белән,
күңелнең дә яры юыла җыры белән.
Бетми һич моң... тормыш язган сүзләр кала,
ә дулкыннан ярда нинди эзләр кала?..
Вак-вак ташлар, мәрҗәннәр, буш кабырчыклар
моңмы — диңгез күкрәгеннән ярып чыккан?
Бәлки серле бер хат — дулкын язулары?
Суга язган антны саклый алырлармы?»
...Үзе сорау, үзе җавап — диңгез уйный...
Ә ярында уйчан ханым. Матур уйлый...

## Айдар Хәлим

Жырчы Илфак Смаковка багышлыйм.

### Кышкы фантазия

Январь, январь!..
Ерып чыккысыз көрт!
Турыга юл яру бик кыен.
Карлар коры.
Изеп басмасаң да,
Ифрат шәп шыгырдый ул быел.
Моржалардан төтен — ак багана,
Кымшанмый да, әнә, сак кына
Оеп калган,
Салкын йолдызларны
Җирдән җылытып торган шәм сыман
Һаваларда сихри өн шәйләнә,
Челтер-челтер карлар агышы —
Көрт астыннан каз бәбкәләредәй
Бип-бип итә уҗым арышы...
Әлегә суык, дуслар, яз ул — килер,
Араларны февраль бикләгән.
Карны ачып, сезне сөяр идем, —
Өшерсез дип уйлыйм, шикләнәм...

### Каз йолкыйлар кызлар

Башланды каз өмәләре! Оча каурый иләккә.
Таушалмаган мәрмәр сымак, казлар ята беләккә.

Өйдә — шау-гөр, өйдә — шат җыр, хәлләре бетәр көлеп,
Бу мизгелдә шушы бер йорт җирне яктырткан кебек...

Бит очлары — уймак чокыр, чокырлары алсудан,
Ясалма алсу түгел, ул — эчтә кояш балкудан.

Кулларның тормыш утында янасы-көясе бар,
Көясе бар — тупылдатып, бәбәйләр сөясе бар!

Казләр әзер. Әйдә, хәзер! Көянтәләргә асып,
Киләләр урамнан кызләр кыр казларыдай басып...

Елга өстен яшь боз өргән — тәрәз пыяласымы?!.
Бозлы суда, кул өшетми, казлар юаласыңмы?

Кинәттән кызлар дерт итте, — әллә күзгә күренә? —
Егетләр җыр яңгыратты Шәрифҗан күпереннән:

«Ал тәгәрмәч, арт тәгәрмәч, барысы бергә әйләнә,
Без кызларга бәйләнмибез, кызлар безгә бәйләнә...»

Кызлар калырмы җавапсыз, аһ, алар — тел бистәсе!
Егетләр сагаеп калды, — бар икән ишетәсе:

«Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Галимҗан,
Сөюеңне үзем беләм, тик әйт, күпме жалуньяң?»

Егетләр — ялт, егетләр — шалт, елмаешып килделәр,
«Эһ» дигәнче көянтәне иңнәренә элделәр.

Килештереп атлый алар, кызлар исә — эргәдә,
Күреп калыйк дигән сыман, тартыла ак пәрдәләр...

Як-ягыңа өчәр каз да, көянтә саен алты,
Күңелле су буйларыннан шулай парлашып кайту!..

Капка турысына җиткәч, кызлар: «Рәхим итегез!»
Егетләр юнәлткән була: «Юк, кермәбез... Китәрбез...»

Үзләре ишеккә карый, үзләре инде — тупсада,
Шул чак берсе морҗадагы төтенгә дә күз сала.

Һәм әйтә гармунын тартып: «Дөрләткәнсез учакны...
Егетләр, саныйкмы эчтән — бу йорт ничә почмаклы?»

Бипелдәшеп бәбкәләрдәй тышта карлар тәңкәли,
Өйдә — казлар, өйдә — кызлар, керми китсәң, үпкәли.

# ОЧЕРКЛАР

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**НОЯБРЬ, 1974 ЕЛ**

Бөек Октябрьның 57 еллыгын камазлылар лаеклы каршылыйлар. Аларның эшләре тагын да ритмлырак бара, көн саен миллион сумнан артык акча даими рәвештә үзләштерелә башланды. Хәзер төзүчеләр беренче чиратта торган проблемаларны хәл итәләр: кою, җыю, двигатель, пресс-рам, тимерчелек заводларының түбәләрен ябалар, аларга җылылык трассалары үткәрәләр. Бәйрәм алды вахтасы көннәрендә шәһәр салучылар һәм КамАЗ заводларын коручылар аеруча тырышып эшлиләр. Күптән түгел генә хезмәт ияләре депутатларының Чаллы шәһәр Советы XIV сессиясе шәһәрдә төзелеш башланганнан бирле эшләнгән эшләргә йомгак ясады. Өч елдан артык вакыт эчендә миллион ярым квадрат метр файдалы торак мәйданы күләмендә йортлар, 14 гомуми белем мәктәбе, 17 балалар бакчасы, 11 җәмәгать туклануы бинасы, 24 кибет, 3 больница һәм уннарча культура объектлары төзелгән...

**«Известия», Мәскәү.**

Хабаровск шәһәреннән Чаллыга — бөтен союз комсомол төзелешенә — «1Б-125» һәм «1Б-140» маркалы токарь-револьвер автоматлары җибәрелде. Станоклар төзү заводы КамАЗ заказларын срогыннан бер айга элегрәк үтәде.

Бу станокларның җитештерүчәнлеге элеккеләренә караганда 20—30 процентка артыграк. Алар тишү, фрезерлау һәм катлаулы кыру эшләре өчен өстәмә җайланмалар, чүпләрне алып китү өчен автомат транспортер белән тәэмин ителгән.

Болар КамАЗ өчен станок төзүчеләр башкарган беренче генә заказ түгел. Шулай ук КамАЗга универсаль фрезер станоклары да графиктан алдарак озатылган иде. Хәзер завод коллективы үтә төгәл автомат станоклар әзерләүгә кереште. Аларның беренче партиясе КамАЗга җибәреләчәк.

**«Комсомольская правда», Мәскәү.**

Мәскәүдә Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә, совет автомобиль төзелешенә 50 ел тулу юбилее уңае белән, Бөтенсоюз автотехника күргәзмәсе ачылды. «Халыклар дуслыгы» мәйданында уннарча автомобильләр, парадтагы кебек, ике рәткә тезелгән. Аларга карап, 1924 елның ноябрендә булып үткән икенче бер парад хәтергә төшә: ул вакытта Мәскәү авомобиль җәмгыятендә ясалган ун данә беренче йөк машинасы горур рәвештә Кызыл мәйданнан узды. Шуларның берсе — тарихи истәлеккә әверелгән «АМО-Ф 15» хәзер бу күргәзмәдә түр урында тора.

Күп тонналы «БелАЗ»лар, куәтле «МАЗ»лар һәм «КрАЗ»лар, уңайлы «Рафик»лар — хәзерге заман автомобиль промышленносте үрнәкләре.

Болардан тыш күргәзмәдә илебезнең иң зур предприятиеләрендә, шулар исәбеннән КамАЗда эшләнәчәк зур йөк күтәрешле машина үрнәкләре дә бар.

**«Социалистическая индустрия», Мәскәү.**

Бөек Октябрьның 57 еллыгы уңае белән СССР Элемтә министрлыгы күп буяулы маркалар бастырып чыгарды. Шул маркаларның берсенә куәтле «КамАЗ» дизель йөк машинасы сурәте төшерелгән.

**«Советская Татария», Казан.**

Бетончы Т. Васюкова КамАЗга комсомол путевкасы белән килә. Удар хезмәте өчен ул күп тапкырлар «Автозаводстрой» тресты һәм 4 нче төзелеш-монтаж идарәсенең Почет грамоталары һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

Газетада төзелеш ударнигы портреты һәм завод төзелеше панорамасы басылып чыккан.

**«Известия», Мәскәү.**

Әлегә кадәр илебездә иң зур автогараж Тольяттида иде. Хәзер Чаллыда икенчесе сафка басу алдында. Аның беренче чираты срогыннан ике ай элек эксплуатациягә тапшырылды.

Гараж-гигантта берьюлы 500 авыр йөк күтәрешле машинага һәм шул кадәр үк ярым прицеп-фургоннарга комплекслы хезмәт күрсәтеләчәк. Анда ремонтчылар ярдәмчесе автоматлар, электроника, кибернетика булырга тиеш. Катлаулы гараж комплексы белән идарә итүне автоматлаштырылган система башкарачак.

**«Социалистическая индустрия», Мәскәү.**

Троицк станок төзү заводында электроэррозион станоклар эшләп чыгарыла башлады. Бу станокларда аерата нык корычтан коелган материалларны, штампларны, кискечләрне һәм башка инструментларны бик җиңел эшкәртергә мөмкин.

Яңа продукциянең беренче партиясе КамАЗ инструментальчыларына һәм башка машина төзү предприятиеләренә, сәгать заводларына җибәрелде.

**ТАСС, Троицк шәһәре.**

Илебезнең зур төзелешләрендә, предприятиеләрендә, авыл хезмәт ияләре янында булып кайткан художниклар үз хезмәтләрен Мәскәүдә «Туган ил» исемле күргәзмәгә куйдылар. Алар арасында П. Малаянның (Ереван) «КамАЗда плита коючы Люба Гвардецева» дигән рәсеме дә бар.

**«Правда», Мәскәү.**

Чаллыда КамАЗны үз шефлыгына алган СССР Кинематографистлары союзын җылы сүз белән телгә алалар. Анда кинофестивальләр үткәрү матур традициягә әверелде. Күптән түгел Чаллыда Союз идарәсе секретаре А. Караганов җитәкчелегендә кино артистлары группасы булды. Артистлар, режиссерлар, сценаристлар төзелеш мәйданнарында, инде сафка баскан предприятие корпусларында эшчеләр белән бик еш очрашалар. КамАЗ темасы илебезнең күп кенә киностудияләре планнарына кертелде. «КамАЗ причаллары», «КамАЗ — минем язмышым», «Бригадирлар», «Рәис Ганиев» фильмнарында төзүчеләрнең героик хезмәте сурәтләнә.

Төзелеш язмышы белән СССР һәм РСФСР Язучылары союзы идарәләре дә даими кызыксынып тора. Алар Чаллыга әледән-әле үз делегацияләрен җибәрәләр. Роберт Рождественский, Феликс Чуев, Михаил Львовларны бригадаларда бик җылы каршыладылар, һәм алар төзелештәге иң яхшы кешеләр турында яңа әсәрләрен яздылар.

СССР Художниклары союзы да КамАЗны онытмый. Художник-акварелистлар Чаллыда ике мәртәбә булып, шәһәр музеена картиналар, скульптуралар, график әсәрләр коллекциясе бүләк иттеләр. Бөтенсоюз театр җәмгыяте белән Үзәк актерлар йорты да төзелештә һәм шәһәрдә иҗади очрашулар сериясе үткәрде.

КамАЗ төзелеше, андагы көндәлек хезмәт героикасы Татарстан язучылары, художниклары, композиторлары, артистлары иҗаты өчен мул чыганак. Төзүчеләр Геннадий Паушкинны, Мәхмүт Хөсәенне, Сибгат Хәкимне, Әхсән Баянны һ. б. язучыларны яхшы беләләр. Аларның төзүчеләргә багышланган әсәрләре КамАЗ кешеләренә яхшы таныш. Чаллыда үткәрелгән әдәби конкурска йомгаклау җыелышлары моның ачык мисалы. Укучылар конференцияләренә сигез меңгә якын кеше катнашты.

Хезмәт темасы, автомобиль гигантын һәм яңа шәһәр коручы замандашыбыз образын тулы канлы итеп сурәтләү — республиканың күп кенә сәнгать осталары иҗатында үзәк урынны алды.

Шулай да төзүчеләр җырчыны, язучыны, художникны, кинофильмны тудыручыны алкышлаганда рәхмәт белдереп кенә калмыйлар, шул ук вакытта алар зур промышленность үзәге булып килә торган Чаллыда иҗат союзларының тагын да киңрәк, тирәнрәк, төрлерәк эш алып баруларын да таләп итәләр. Иҗат союзларына, Культура министрлыгы белән берлектә, мәгаен, шәһәрнең социаль-культура үсеше, культура учреждениеләре планын эшләүдә катнашырга кирәктер.

**«Советская культура», Мәскәү.**

Моннан ике ел элек беренче бишьеллыклар геройлары Алексей Стаханов, Петр Кривонос, Мария Виноградова, Иван Гудов, Александр Бусыгин КамАЗ төзүчеләренә ачык хат белән мөрәҗәгать иткәннәр иде. «Сезнең эшләрегездә җәмгыятебезнең иң яхшы традицияләрен тою күңелле, — дигәннәр иде ветераннар. — Безнең буын — сезнең бабаларыгызның һәм әтиләрегезнең хезмәт казанышлары эстафетасы энергияле, яхшы белемле, иң алдынгы техника белән коралланган җитмешенче еллар төзүчеләренең ышанычлы кулларына күчте. Без сездә, кадерле дуслар, үзебезнең кайнап торган яшьлегебезне күрәбез, сезнең девизларыгызда героик беренче бишьеллыклар эшенең дәвамы яңгырый».

Чыннан да, Чаллыга килгән саен, буыннар җаваплылыгы тойгысын сизәсең. Ул панно мозаикаларыннан яңа шәһәргә карап торучы буденновка кигән быргычыларның

йөзләрендә күренә, «Даешь КамАЗ» дигән шигъри лозунгларда яңгырый. Ул тойгыны, ниһаять, революцион романтика, АМО, Горький автозаводы, автомобиль промышленностеның башка предприятиеләрен төзүчеләрендәге чиксез фидакарьлек эстафетасын дәвам иттерүче КамАЗ автогигантын коручылар үзләре тудыра.

...Еллар узар. Уннарча еллар үтәр. Кама буендагы автомобиль батыры капкасыннан ел саен йөз меңнәрчә куәтле «КамАЗ»лар чыгар, тугызынчы бишьеллыкта барлыкка килгән Яңа Чаллы шәһәрендә заман бәйләнеше хакына, буыннарның революцион һәм хезмәт бәйләнеше хакына әрмый-талмый эшләүчеләрнең йөз меңнәрчә балалары, балаларының балалары бәхетле тормыш итәрләр.

**«Социалистическая индустрия», Мәскәү.**

Бөек Октябрь алды ярышында «Каздорстрой» тресты коллективы зур уңышка иреште. Дәүләт комиссиясе Казан — Чаллы автомобиль магистраленең 43 километрдан артык булган беренче участогы сафка басу турындагы актка кул куйды. Шулай итеп, автомагистраль Алабугадан Мамадышка кадәр арада әзер. 9 метр киңлектәге асфальт лента автомобильләргә иң зур тизлектә йөрергә мөмкинлек бирә. Магистраль буена хәзерге заман юл билгеләре, күрсәткечләре куелган, пассажир павильоннары ясалган.

**«Советская Татария», Казан.**

Әлегә «КамАЗ» төзелә генә, ә инде Одесса автоҗыю заводында Кама автогиганты чыгарган машиналар өчен прицеплар эшләнә башлады.

Алар 14 һәм 20 тонна йөк сыйдырышлы. Терлекләр йөртү өчен махсус прицеплар микроклимат булдыру өчен җылыткыч һәм вентиляция җайланмалары белән җиһазландырылган.

**«Известия», Мәскәү.**

Чаллыда автомобиль индустриясе төзүчеләрнең йөз меңлек армиясе бүген үк инде үз хезмәтләренең нәтиҗәләре белән горурлана ала: Кама буенда мәһабәт төп һәм ярдәмчел производство корпуслары калкып чыкты. КамАЗ — түбә астында, КамАЗ пыялага, бетонга төренде. Аның йөзе 1,5 миллион квадрат метр торак мәйданлы күп катлы йортларда, хәзерге заман архитектура ансамбльләрендә күренә. Шәһәр өр-яңадан салына. Анда 1,3 миллиард сумлык төзү-монтаж эшләре башкарылды. Бер мәйданда шундый масштабтагы, шундый колачтагы эшләрнең моңа кадәр илебездә әле башкарылганы юк иде.

КамАЗ төзүчеләрнең узган юлы якты һәм мөһим вакыйгалар, казанышлар һәм уңышлар белән тулы. Әмма аларның файдаланып бетмәгән резервлары да бар әле. Новороссийскида сөйләгән речендә Л. И. Брежнев болай дигән иде: «Коммунистлар партиясенең яңа — XXV съездына без лаеклы нәтиҗәләр белән килербез дип уйлыйм. Барлык партия, профсоюз, комсомол оешмаларының, совет һәм хуҗалык органнарының, безнең барлык совет халкының эше хәзер шуңа юнәлдерелгән». Чаллыда үткәрелгән партия активы җыелышына катнашучылар үз максатларын нәкъ менә шундый итеп билгеләделәр, алар беренче «КамАЗ» автомобилен КПССның XXV съездына чыгарырга карар кабул итте.

**«Социалистическая индустрия», Мәскәү.**

Соңгы елларда Кама буенда, Чаллыда зур үзгәрешләр барлыкка килде. Бинһая зур мәйданда автогигантның күп катлы корпуслары үсеп чыкты. Күптән түгел генә әле кечкенә шәһәр булган Чаллы илебезнең зур индустриаль үзәгенә әверелде. Завод конвейерыннан авыр йөк күтәрешле автомобильләр чыгу көнен якынайту өчен КамАЗ төзүчеләре рухланып эшлиләр.

**«Сельская жизнь», Мәскәү.**

Соңгы елларда Советлар Союзында шәһәр төзелеше бик нык алга китте. Илебез картасында йөзләрчә яңа шәһәрләр, поселоклар барлыкка килде.

Яңа торак районнар төзү комплекс белән алып барыла. Йортлар белән бергә культура-көнкүреш объектлары да төзелә.

Автомобиль төзүчеләр шәһәре Чаллы көннән-көн үсә, матурлана. Кама автогиганты корыла башлаганнан бирле бире дә йөз меңнән артык кеше өй туйлары үткәрде.

**«Экономическая газета», Мәскәү.**

**Хөсәен Хәсәнов,**
тарих фәннәре докторы

# РЕВОЛЮЦИОНЕРНЫҢ СОҢГЫ ХАТЛАРЫ

1905—1907 еллардагы революция алдыннан бер төркем алдынгы татар яшьләре демократик ирек өчен көрәшүчеләр хәрәкәтенә кушылды. Шулардан җәмгыять тормышындагы политик үзгәрешләрне яхшы аңлаганнары үзләренең язмышларын эшчеләр сыйныфы белән бәйләде, социал-демократлар партиясе сафына керде. Бу юнәлештә беренче сукмакны салучылар рәтендә Зариф Садыйков та бар иде. Кызганычка каршы, без аның турында бик аз беләбез. Революция таңында ук халыкка хезмәт итү дәрте белән янган һәм үзенең бөтен тормышын шул изге эшкә багышлаган бу ялкынлы көрәшченең биографиясе бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Шуны искә алып, без, яңа табылган архив материаллары һәм истәлекләр нигезендә, аның кыскача тормыш юлын, революцион эшчәнлеген яктыртырга, туганнарында сакланып калган берничә хатын игълан итәргә булдык.

Зариф Шәриф улы Садыйков 1877 елда Казан өязе, Зур Күлбәш авылында крестьян семьясында туа. Ул биш яшькә җиткәндә, аның атасы кинәттән үлеп китә. Ике яшь баланы тәрбияләп үстерү авырлыгы ана өстенә төшә. Шушы авырлыкны бераз җиңеләйтү нияте белән ул үзенең язмышын икенче бәрәү белән бәйли: Казан шәһәрендә Яңа Бистәдә торучы Шәрәфетдин Мәсгутов дигән кешегә иргә чыга. Зариф Казан мәдрәсәләренең берсенә укырга керә. Зирәклеге һәм акыллылыгы белән башкалардан нык аерылып торучы Зариф тырышып укый, дөньяви фәннәрне үзләштерүгә күбрәк игътибар бирә. Мәдрәсәне тәмамлап чыкканда инде ул әйләнәтирәне, заманның рухын, юнәлешен сизенерлек дәрәҗәгә килә.

Унбиш-уналты яшьләрендә Зариф үз көнен үзе күрү турында уйлана башлый. Укуын дәвам иттерергә беркнинди мөмкинлеге булмаганлыктан, ул Шакир Гафуров дигән Казан баена яллы хезмәткә керә. Башта вак-төяк йомышка йөрүче малай, аннары приказчик булып эшли. Хезмәт процессында төрле кешеләр белән таныша, алардан төрле фикерләр, киңәшләр ишетә. Бигрәк тә ул азатлык турында, илдә демократик тәртипләр урнаштырырга кирәклек турында кайгыртучыларның сүзләренә колак сала. Шулар ярдәмендә җәмгыять тормышының кая таба барганын аймыллый, революцион яшьләр белән элемтәгә керә: Хөсәен Ямашев, Гафур Коләхметов белән дуслаша. Алар Зарифны әкренләп марксистик әдәбият белән таныштыралар, партия эшенә тарталар. Көннән-көн дөньяга карашы киңәя һәм үсә барган, социаль каршылыкларның кискенләшүен үз күзе белән күреп торган яшь егет, пролетариатка хезмәт итү изге бурыч икәнлегенә инанып, 1904 елда большевиклар партиясе сафына керә.

1905 елгы революциянең көчле дулкыннары бөтен илгә таралган көннәрдә Зариф Садыйков халык арасында кайный, эшчеләр митингларына, стачкаларга, демонстрацияләргә катнаша. Бер үк вакытта ул массалар арасында большевистик листовкалар тарату буенча да актив эшли. Хөсәен Ямашев белән берлектә Казан партия оешмасының прокламацияләрен русчадан татарчага тәрҗемә итә, җилем басмада баса, ышанычлы кешеләр аркылы аларны завод-фабрикаларга, авылларга җибәрә. Суфия Коләхметова үзенең бер истәлегендә абыйсы Гафур янына Хөсәен Ямашев белән Зариф Садыйков килүе һәм өчәүләшеп аларның Рыбнорядский (хәзерге Куйбышев) урамындагы конспиратив йортта төне буе большевистик прокламацияләр басулары турында яза.

1905 елның җәендә Казанда революцион хәрәкәт тагын да киңрәк җәелә һәм куәтлерәк төс ала. Локке фабрикасы, Шабанов заводы эшчеләре забастовка игълан итәләр. 7 июльдә алафузовчылар көрәшкә күтәрелә һәм атна буена эшкә чыкмый. Слесарьлар һәм күп кенә бүтән профессия кешеләре стачка хәрәкәтенә кушыла. Укучы яшьләр арасында чуалышлар башлана. Билгеле, болар барысы да большевиклар җитәкчелегендә эшләнә. Зариф Садыйков, партия оешмасының актив бер члены буларак, эшчеләрнең һәм бүтән демократик катлау кешеләренең революцион чыгышларын әзерләүгә якыннан торып катнаша.

Зариф Садыйковның революцион активлыгы полиция күзенә чагылмый кала алмый. Охранка агентлары аны бертуктаусыз күзәтеп торалар. Төрмәгә эләгү куркынычын сизеп, ул җәй ахырында Кырымга, Ялтага китә. З. Садыйков биредә дә революцион эшчәнлеген туктатмый. Җирле большевиклар белән бик тиз элемтәгә кереп, эшчеләр, һөнәрчеләр һәм укучы яшьләр арасында эшли башлый, аларны царизмга каршы көрәшкә өнди. Ләкин жандарм идарәсе агентлары аны биредә дә тыныч тотмыйлар. Патша хөкүмәтенә каршы агитация алып баруда гаепләп, З. Садыйковны 1906 елда хөкемгә тарталар һәм полициянең махсус күзәтүе астына алалар. Төрмәгә утырту алдыннан ул Ялтадан Астраханьга качып китә һәм анда Ибраһим Муратов дигән ялган фамилия белән яши башлый.

Астрахань чоры Зариф Садыйковның революцион эшчәнлегендә аерым урын алып тора. Барып җитү белән ул җирле большевиклар белән танышып өлгерә һәм зур энергия белән татар эшчеләре арасында революцион идеяләр таратырга керешә. Шушы юнәлештә З. Садыйков үз тирәсенә бер төркем актив та туплый. Салихов дигән укытучы аның иң якын ярдәмчесе була. Ул рус эшчеләре белән дә тыгыз элемтәдә тора. Партия членнары арасында ышаныч казангач, аны социал-демократик комитет секретаре итеп билгелиләр.

Бу вакыт Астраханьда «Борһан тәрәкъкый» дигән татарча газета чыгып килә. Әмма либераллар кулындагы бу орган «Мөселман иттифакы» партиясе сукмагыннан атлый, халык арасында милли-буржуаз идеяләр тарата. З. Садыйков аның политик юнәлешен үзгәртергә уйлый. Шушы максат белән ул «Борһан тәрәкъкый» газетасы редакциясенә эшләргә керә. Кыска гына вакыт эчендә З. Садыйков әлеге газетаны демократик идеяләрне чагылдыручы органга әверелдерә. Г. Ибраһимов үзенең «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле китабында З. Садыйков эшләгән 3—4 ай эчендә «Борһан тәрәкъкый»ның шактый ук «кызаруын», «Мөселман иттифакы»на каршы кискен көрәш алып баруын һәм социалистик идеяләрне яклавын күрсәтеп үтә. Үткен каләмле публицист буларак, ул бу газетада тирән революцион эчтәлекле һәм киң катлау массаларының теләкләрен чагылдырган көчле мәкаләләр бастыра.

1907 елда Астраханьда «Туп» исемле татарча журнал чыга башлый. Дөрес, ул бик кыска гомерле була. 3 нче номеры чыгу белән аны, хөкүмәткә каршы материаллар бастыруда гаепләп, яптыралар. З. Садыйков демократик юнәлештәге шушы органның хезмәткәре һәм идея җитәкчесе була.

Астрахань большевиклар оешмасының күренекле җитәкчеләреннән берсе булып киткән Ибраһим Муратов (Зариф Садыйков) полициянең даими күзәтүе астына алына. Патша хөкүмәтенә каршы көрәшүче куркынычлы җинаятьче санап, аны тагын эзәрлекләргә керешәләр, суд хөкеменә тарту өчен материаллар туплыйлар. Шушы кара теләк белән Таврия һәм Казан губерна жандарм идарәләре арасында язышулар башлана. Беренче чиратта, Ибраһим Муратовның чын фамилиясен, ата-аналары-

ның, аралашкан кешеләренең кем икәнен белергә тырышалар. Шушы эзләнүләр процессында жандармнар кулына Гафур Коләхметовның да адресы килеп эләгә. Зариф Садыйков белән дус һәм элемтәдә торуын белеп, алар Коләхметовларның барлык семья членнарын эзәрлекләргә тотыналар.

Тәҗрибәле конспиратор Зариф Садыйков Астрахань жандармнары корган тозакка да эләкми. Аларның туктаусыз күзәтүләрен сизеп, ул 1908 елда яшерен рәвештә Казанга кайта, аннан Уфага китә. Бу тотылмас революционерны жандармнар тиргә батып эзлиләр, ләкин эзенә баса алмыйлар. Тик социал-демократлар арасына үтеп кергән провокатор «Шах»ның чагуы аркасында гына ул полиция тырнагына эләгә. Берникадәр вакыт З. Садыйков Уфа төрмәсендә утыра, аннан Ялтада башланган тикшерү эше буенча аны этап белән Симферопольгә озаталар. Биредә З. Садыйков ике елга төрмәгә ябарга хөкем ителә. Яшеренеп яшәү елларында шактый нык какшаган сәламәтлеге төрмә шартларында тагын да начарлана. Салкын һәм юеш камерада ачлы-туклы яшәп, ул үпкә авыруы ала. Ләкин шулай да аны ирекккә чыгармыйлар. Бары тик 1911 елда срогы тулгач кына З. Садыйков азат ителә. Әмма бу вакыт инде ул физик зәгыйфьләнгән, бөтен сәламәтлеген югалткан була. Шунлыктан З. Садыйков, төрмәдән чыгу белән, больницага кереп ятарга мәҗбүр була. Ирекккә чыгуы турында тиз генә Казандагы туганнарына хәбәр итә. Җавап та килеп җитмәстән, әнисенә тагын бер хат яза. Ул хатның тулы эчтәлеге түбәндәгеләрдән тора:

«Мөхтәрәмә газиз әнкәем!

...Төрмәдән халас[1] булган көннең иртәгесен үз җәнабегезгә ачык мәктүп язмыш идем. Шаять алгансыздыр. Мин мәзкүр мәктүбемдә бу Симферопольдә кайвакытка кадәр калачагымны аерып яза алмамыш идем. Чөнки мин төрмәдән чыккач та урынга яттым. Соңра берничә көнләр үткәч, күкрәк авыруына оста булган докторларга күрендем. Алар һәммәсе дә минем күкрәгемне тыңлап бактыкдан соңра бер авыздан диделәр ки, иштә минем уң тараф үпкәм авырудыр. Берничә вакытларга монда, Симферопольдә, торып ял итәргә мәслихәт иттеләр, ягъни миңа тыныч аулак торакта яхшы ашап, саф һавада йөрмәк кирәк диделәр, юкса, синең хәлең уңайсыз һәм куркынычлы диделәр. Үзегезгә мәгълүмдер: минем хәзерендә докторлар кушканча торыр хәлем юк, чөнки минем айга 30 яисә 40 таңкә килеп торган урным юктыр. Һәм миңа шәмдики хәлдә урынга керергә дә ярамыйдыр, чөнки урынга кереп хезмәт итү түгел, урамга чыгып йөрергә дә хәлем юктыр. Хәлемнең ошбу рәвештә җайсыз икәнчелекне бер белеш докторыма барып сөйләдем. Ул миңа больницага кереп ятуны мәслихәт итте. Шәмдики хәлдә бүген 11 нче көнемдер бер больницада ятамын. Сәламәтлегем бер рәвештә чибәрләнеп киләдер, ягъни бераз аякка басып йөри башладым инде, юкса, моннан ике атна мөкатдәм бөтенләй хәлем начар иде. Бу больницада кай вакытка кадәр ятачагымны, ягъни кайчан чыгачагымны хәзергә аерып әйтә алмаем. Гәрчә тиз көннән больницадан чыксам да, хәзер үк поездга утырып Казанга китәрлек хәлем тиз булмас әле, чөнки, бердән, минем җылы киемнәрем юктыр, вә, икенчеләй, минем авыру хәлдә сезгә кайтып ятасым килми. Сезнең үз хәлегез үзегезгә җиткән. Аның өстенә мин дә авыру килеш сезгә кайтып керсәм, бөтенләй сезнең өчен уңайсыз булыр... Бәлки тиз көннән сәламәтләнермен, ягъни урынга кереп хезмәт итәрлек дәрәҗәдә сәламәтләнсәм, ул вакыт Казанга кайтып, җәнабегезнең фатихасын алырга тырышырмын. Минем хәзерендә бар эч пошкан нәрсә Шәйхетдиннең солдат эшедер. Мин монда Симферополь военное присутствиесенә прошение язмыш идем: мине карасагыз икән һәм эшкә ярап яисә ярамаганлыгымны Казанның военное присутствиесенә мәгълүм итүегезне үтенәмен дип, хәлбуки, бу көнгә кадәр җавап алганым юктыр. Бер таныш адвокатның мәслихәте буенча тиз көннән Казанның военное присутствиесенә ике докторның минем эшкә ярамаганлыгымны шәһадәт иткән имзалары белән прошение күндерәчәкмен... Бәлки, Шәйхетдинне вакытлыча калдырып торырлар, ягъни мин үзем кайтып күренгәнче. Кулымнан килсә иде, ягъни ике мең чакрымнан артык җирне поездга

---

[1] Халас — азат.

утырып кайтырлык һәм анда кайткач та бераз ял итәр өчен кулымда акча булса иде, мин үзем кайтып күренер идем дә, Шәйхетдинне бер авыз сүзсез котылдырыр идем. Ни эшләмәк кирәк соң? Минем хәзерге көндә Казанга кайтыр хәлем юктыр. Насыйп булса, ягъни бераз сәламәтләнсәм, кайтырмын. Шәйхетдиннең кайчан каралачагыны мәгълүм итеп һәм үзегезнең хәлегезне ачык мәгълүм итеп хат язуыгызны үтенәм. Шәйхетдингә һәм башка кардәш-кабиләләрнең һәр кайсына сәламемне юлладым. Хәзергә хуш, сәламәт улып торасызлар.

Угылыгыз Зариф».

Больницада бераз хәл алгач, З. Садыйков Казанга кайту турында кайгырта. Авырудан терелеп җитмәсә дә, туган җиргә булган мәхәббәт, кардәшләрне, дус-ишләрне күрү теләге аны урыныннан күтәрә. 1911 елның ахырында З. Садыйков көч-хәл белән Казанга кайтып җитә. Озын юл аны тәмам вата, эштән чыгара. Якын иптәшләре З. Садыйковны Иске клиникага урнаштыралар. Ул биредә беркадәр вакыт дәвалана, ләкин тазара алмый. Врачлар аңа Көньякка, Кырымга китәргә киңәш бирәләр. Әмма З. Садыйковның ерак җиргә дәваланырга барырлык бернинди материаль мөмкинлеге булмый. Менә шундый авыр моментта аңа Хөсәен Ямашев ярдәмгә килә. Үзе студент булуга карамастан, ул З. Садыйковка юлына һәм беркадәр вакыт дәваланырга җитәрлек акча табып бирә. 1912 елның февралендә З. Садыйков Мәскәү аша Симферопольгә юл тота. Партия эше буенча белгән иптәшләре һәм туган-тумачалары аны озатып калалар. Мәскәүгә барып җиту белән ул әнисенә түбәндәге открытканы җибәрә:

«Мәскәү. Сәгать кичке 6 һәм 22 февраль.

Җәнаб газизләрегезнең һәр кайсына сәләм юлладым... Сәләмәт Мәскәүгә килеп җиттем. Хәзерендә Курский вокзалында Симферопольгә китәчәк поездны көтеп утырамын. Кәефем бер килеш яхшы, юлда бик аз йөткердем. Ләкин ейдән чыкканнан бирле рәтләп бер нәрсә ашаганым юк. Тик шул килеш ятып барамын. Поездны сәгать 10 да килә диләр. Миңа китәргә яңадан 3 ярым сәгать бар. Хәзер кайнар аш ашамакчы булып тора.

Зариф».

Симферопольгә барып җиткәч, З. Садыйков анда ничек урнашуы, үзен ничек сизүе турында әнисенә түбәндәгеләрне хәбәр итә:

«Симферополь шәһәреннән, 1912 сәнә, 6 март.

Миһербанлу вә шәфкатлү әнкәем!

Әткәм илән һәр икегезгә... сәламемне күндердем. Мөхтәрәм кардәшем Шәйхетдингә җәмәгате һәм сөекле кызы белән барчасына хәерле вә бәхетле гомерләр теләп сәләмемне юлладым. Күземнең алмасы бәрабәрендә күргән сөекле сеңелем Әминә белән хөрмәтле Мәфтуха апакга хәерле сәламәтлекләрени теләп... сәләмемне күндердем. Хәдичә апакга мөхтәрәм ак сакаллы җизни белән һәр икесенә күптән-күп һәм чукдин-чук сәләмемне тапшырып, Хәдичә апакга хәерле сәламәтлекләр теләгәнлегемне сөйләрсезләр. Апак-абыстайларның һәр кайсына (И. Заһидә! белмисең минем хәлне)... сәләмемне тапшырасызлар. Хәзерге сәләмнәр-фәләннәр җитеп торсын инде. Киләек үз хәлебезгә.

Үземнең монда Симферопольгә килеп төшкәнгә бүген нәкъ 10 көн тулды. Сез минем монда килеп җиткәч тә язып җибәргән хатымны алган көнне үк җавап язган булсагыз иде, бу көн сездән хат булырга тиешле иде. Хәлбуки, әлегә кадәр хат-фәлән күренми... Үзем бер килеш... тагын йөрештергәли башладым. Беренче марттан башлап дүрт көн рәттән бер дә көнләрнең рәте-башы булмады. Салкын һәм вак яңгыр сибәләп кенә торды. Ошбу дүрт көн эчендә һичбер кая аяк атлап өйдән чыкмадым. Кичәге һәм бүген яңадан кояш чыгып көнләр матурланып торадыр. Бу соңгы көннәрне яңадан тыным бетә башлады. Су җыелган булырга тиеш. Ләкин өүвәлге кебек йөткерүем куәтле түгел. Йөткергәлим, әмма алай булса да Казандагы шикелле буылып утырулар хәзергә

күренми торадыр әле. Кичә янәдән докторга барып күренеп кайттым. Яңадан тыным бетә башлаганлыкны сөйләдем. Доктор башта бу тын бетүне һаваларның бозылып торуларыннан гынадыр дисә дә, соңра тишендереп тыңлап карагач, үпкәңне яңадан су баса башлаган, шул сәбәпле тының бетә диде. Ләкин доктор Казан клиникасындагы кебек су алдыруны мәслихәт күрмәде. Минем фикеремчә, алдырмавың файдалы дип, хәзергә алдырмаенча торырга киңәш бирде һәм дару бирде. Әгәр дә ошбу даруның тын бетүгә файдасы тимәсә, яңадан миңа килерсең, ул вакыт янәдән уйлашырбыз дип җибәрде. Бүген иртәдән башлап биргән даруны эчә башладым. Файдалымы яисә файдасызмы — хәзергә әйтеп булмый. Ахры ничек булыр... Бүген көндез көн бик җылы һәм кояшлы булгач, ишегалдында байтак кына утырып кердем. Ашка кадәр бакчага төшеп менмәкче идем, ләкин доктор хәзергә күп йөрмәскә, күбрәк урында ятарга кушты. Шул сәбәпле бакчага төшмәенчә ишегалдында гына утырып кояшка кызынырга мәҗбүрмен.

Мин әүвәлге хатымда, ихтимал, көз көне яткан больницага яңадан берәр атнага кереп ятармын, чөнки шулай итәргә белеш докторым киңәш итә дип язган идем. Хәзергә керәсе итмәдем инде. Бүлмә алып бу март аен ошбу Симферополь шәһәрендә үткәрергә уйладым. Чөнки диңгез буенда бу март аенда көннәр вакыты-вакыты белән бик кинәт кенә үзгәрүчән була икән. Хосусан, мин бармакчы булган Алушта дигән җирдә. Мин Казанда вакытта Алупка дигән җирдә тормакчы идем. Монда иптәшләрем һәм доктор анда барырга кушмадылар, чөнки барыбер мине аннан куарлар диделәр. Берәр айдан Ялтага падшa үзе киләчәк. Алушта да Ялтадан бик үк ерак түгел. Әмма алай булса да Алуштада хәвефсез торырга мөмкин булыр диләр. Хәзергә монда һавалар бик яхшы булып тора әле. Монда ушандак җылы һәм кояшлы һавалар булып торган хәлдә моннан китү мәгъкуль түгел диләр. Шул сәбәпле монда бер айга 12 сум белән бүлмә алып тора башладым. Баштарак бүлмә таба алмаенча гаҗиз булдык. Минем биткә генә карыйлар да, син бик каты авырыйсың икән, бу кадәр авыру кешегә бүлмәбезне бирә алмыйбыз дип чыгарып җибәрәләр. Хәзерге бүлмәм, бик кыйммәт булса да, бик якты, җылы һәм ике тәрәзәле бүлмәдер. Иртәдән кичкә кадәр кояш эчендә уйныйдыр. Көндезге ашны шул ук фатир хуҗаларым пешереп бирәләр. Аена 10 сум түлим. Көндезге аш ике тәлинкәдән гыйбарәт. Беренчесе аз гына ит белән шулпа. Аның артыннан икенче тәлинкәдә котлет яисә жаркое кебек нәрсә. Менә бүген җиденче көнем көненә бер стаканнан артык чәй эчкәнем юк. Иртә белән сәгать 9 яисә 10 да торам. Җуынып бетерүгә хуҗа хатыны бер стакан кайнар сөт белән ике йомырка пешереп өстәлгә китереп куядыр. Стакан кайнар сөткә бер кашык эч мае салам. Ул эрегәнче ике йомырканы ничек кирәк алай итеп ашап бетерәм дә тиз генә күзне йомып мәзкүр майлы сөтне эчеп җибәрәм. Укшыта башласа, тиз генә бер кашык кортлы май алып кабам. Иртәнге чәй тәмам. Кем дә булса берәр берәү хәл белә килсә, сөйләшеп утырасың. Килүче булмаса, кояшка каршы утырып китап укыйм. Сәгать ике җитә. Хуҗа хатыны, югарыда әйткәнчә, ике тәлинкәдән гыйбарәт ашны кертеп куя. Мин акрынлап кына ашыйм. Кай көнне бөтенләй чыертам, кай көнне кала. Ятып ял итәм. Көн матур булса, ишегалдына чыгып утырам. Сәгать 4 йә 5 чамаларында бер стакан чәй эчәм. Сәгать 8 дә янә ике йомырка һәм стакан ярым сөт эчкәч, бер ярты сәгатьләп йөрим дә йокларга ятам. Менә шулай итеп көн артыннан көн үтә бара. Килеп-китеп йөргән иптәшләремнең сүзе буенча, бу соңгы бер-ике көннәрдә бераз төс кереп киткән була диләр... Күңелем күтәренке. Үлчәнеп караганым юк. Артканмынмы яисә кимегәнменме — белмим. Болай үземне бераз хәл кергән кебек хис итәм... Ни язса, шул булыр инде. Хәзергә хуш, сау булыгыз. Үзегездәге хәлләрне мәгълүм итеп хат языгыз. Хатыгызны бу соңгы адрес белән языгыз. Моннан әүвәлге хатымдагы адрес буенча язмагыз, чөнки ул кеше мәзкүр аптекадан чыкты һәм башка урынга керде. Адрес хат эчендә булыр».

Каты авыруга дучар булган революционерның хәлен Кырым һавасы да җиңеләйтә алмый. Башта беркадәр рәтләнәм дип үзен юатса да, соңга таба ул сәла-

мәтлеге тагын начарлануыннан, өстәвенә дәвалану өчен акчасы бетүдән зарлана. Бу энисенә җибәргән түбәндәге хатта ачык чагыла.

«Симферополь. 1912 ел, 27 март.

Гыйззәтле әткәм белән мөшфика әнкәм җәнаб газизләрегезнең һәр икәвенә сәламемне күндердем. Мөхтәрәм туганым Шәйхетдингә җәмагате вә сөекле кызы Һаҗәр белән һәр кайсысына тәүфикъ вә сәгадәтле гомерләр теләп сәлам юлладым. Сөекле сеңелем Әминә белән мөхтәрәмә Мәфтуха апакга хәерле вә бәхетле гомерләр теләп сәләмемне күндерәм. Апак-абыстайга, Шакир җизнигә вә башка кардәш-кабиләләрнең һәр кайсысына сәләмем сөйләрсезләр. Хәдичә апакга мәктүп язганда һәр икәвенә миннән сәләм әйтеп язарсыз. Җибәргән хатыгызны алгач, сәләмәтлегегезне белеп бик шатландым. Хосусан, Шәйхетдиннең чакырып язуына... бик шатланып чын күңелемнән рәхмәтләр укырга мәҗбүр булдым. Авыру кешенең күңеле балалар күңеле белән бер: юк кына вә кечкенә генә күңелгә ятышлы сүз кем тарафыннан булса да булсын авыру кешенең хәлен җиңеләйтеп һәм бераз хәсрәтен киметеп җибәрәдер. Хөсәен Ямашевның үлем хәбәре мине шул кадәр ватып ташлады, хәтта ике йә өч көн авызыма аш ала алмадым. Мин аңар 12 мартта гына хат язып җибәргән идем. Ихтимал, ул бичара минем хатны алган көнне үк яки иртәгесен үлгән булырга тиеш. Менә син агай,



*Зариф Садыйков. 1907 ел. Матбугатта беренче тапкыр чыга.*

гомер дигән нәрсә! Кем уйлаган иде шундый таза егет шулай тиз генә һәлак булыр дип. Минем өчен дусларым арасында иң кыйммәтле, кадерле вә саф калебле бер дус иде һәм шуның өчен дә бу егетнең болай вакытсыз һәлак булуы минем өчен бик зур хәсрәттер. Хосусан, минем буйлә авыру булып торганым хәлдә, мине монда җибәрүче дә ул иде бит. Ул мартның 8 ендә телеграф белән миңа 23 рубле акча җибәргән иде һәм озакламыйча яңадан җибәрермен дип язган хатын да алган идем. Хәзергә шул ул җибәргән акчага торып торам әле... Бәлки, башка иптәшләрем бу хакта берәр нәрсә мәгълүм итеп хат язсалар кирәк иде дип өмет итеп торамын. Монда минем бер белеш татарым бар. Ул үзе җәй көне бакчалар алып, фруктларны базарга куядыр. Ә кыш көне фрукта кибете тотып көн күрәдер. Үз йортлы-җирле бер чибәр генә кеше ул. Мин монда килгәч тә ул минем белән күрешеп, ул үзенә, бакчасына, торырга чакырган иде, ягъни көннәр җылынып бакчада торырлык булгач та туп-туры тот та миңа кил, юкка борчылып анда булмәдә сасып ятма дип киткән иде. Бу көннәрдә яңадан шуны көтәм әле. Әгәр дә минем бераз аякка басып йөрерлек хәлем булса иде, шаять мәзкүр татар мине шунда үз янында бер эшкә кушар иде, хәлбуки, минем бер дә хәзергә шул торып йөрерлек хәлем юк. Аз гына җир йөрсәм, тыным бетеп хәлем китә, соңра йөткерә башлыймын. Бу соңгы көннәрдә тыным бетүе яңадан куәтләнеп торадыр. Су тәмам тулган булырга тиеш. Ашавымның да бик үк рәте юк. Хосусан, йоклый алмыймын. Күптән түгел генә докторга да күренеп карадым. Ул да: үпкәңне тәмам су каплаган; хәзер сиңа бер дә урамга чыгып йөрергә ярамый, һаман ятып кына торырга тиеш һәм уң кабыргаңа, киндерне чылатып, ягъни компресс куярга

тиеш; суны алдыру мәслихәт түгел дип дару язып калдырды һәм хәзерендә һичбер яры чыгып йөргәнем юк. Хәтта ишегалдына да чыгып утырганым юк, чөнки җил тиюдән куркам.

Болай, иптәшләремнең әйтүенә караганда, төскә бик үк начар түгелмен, ягъни бу соңгы көннәрдә артмасам да, бик үк күзгә күренерлек кимемим шикелле. Әлхасил башта килгәч тә бераз чибәрләнгән кебек күренсәм дә, бу соңгы көннәргә караганда әллә никадәр алга киткән җирем юктыр. Монда килгәнемә бүген айда ике көн булды инде. Казанга кире кайтуым турында хәзергә бер дә аерып бер нәрсә дә әйтер хәлем юк. Казандагы иптәшләремнең кайсысыннан булса да берсеннән бер-бер хәбәр алмыйча торып хәзергә бер сүз дә әйтә алмыйм. Әлбәттә, бу килеш ятар өчен акча кирәк. Әгәр дә алар миңа бу акчаны җибәрмәсәләр, мин хәзер яткан шикелле ята алмаем. Ул вакыт ничек итеп булса да ике якның берсен тотарга тиеш буладыр: яисә мондагы больницага кереп яту, яисә шундый авыру килеш Казанга кайтып һәм соңра авылга, Күлбәшкә, кайтып ятарга туры киләдер. Әйтәм бит, хәзергә бу хакта һичбер нәрсә аерып әйтә алмаем. Ничек тә булса бер-ике атналарны монда торырга туры киләдер. Апрель ахырларына бераз хәл алып мәзкүр әйткән татарның янына бакчага барырлык хәлем булмаса, ул вакыт кайтып китми дә хәлем булмас. Әгәр... шушы апрель аенда бераз җиңеләя төшсәм һәм шул татарга кушылсам, ул вакыт бераз вакытлар монда калыр идем дип уйлыйм. Һәр ни булса да... вакыты белән хәбәр итәрмен. Хәзергә хуш, сау булып торыгыз... Мөмкин кадәр еш язарга иҗтиһад итегез.

Касыймның сезгә килгәне бармы? Мин аңар ике мәртәбә открытый хат язган идем, бу көнгә кадәр җавап-фәлән алганым юк әле. Әнкәй, мин Касыймга мәзкүр казакиемне чистарткан өчен акчасын бирергә хәтеремнән чыккан. Бер сум 20 тиен иде. Килсә, шуны биреп җибәрсәнә.

Шәйхетдин туганкай! Мөмкин булса, озаклатмаенча гына март аенда чыккан «Йолдыз» газетасының барча номерларын җыйнап миңа монда җибәрсәнә. Син «Йолдыз» идарәсендәге Ибраһим Кулеевтән генә кереп сора. Миңа икәнлеген әйтерсең, бәлки ул сиңа акчасызга җыйнап бирер һәм ничек итеп җибәрергә кирәклеген өйрәтеп җибәрер. Һәм Гафурга барып ни сәбәпле хат язмаганын белешеп язсана.

Зариф».

Ләкин ничек кенә тырышмасын, күпме генә рухи һәм физик көчен сарыф итмәсен, ул каты авыруны җиңә алмый. Халык бәхете өчен көрәшүчеләр сафына яңадан басу өмете белән яшәгән бу ялкынлы революционерның йөрәге 1912 елның 27 апрелендә тибүдән туктый. Ул үлгәч, аның халыкка иткән олы хезмәтләренә югары бәя биреп, большевистик «Невская звезда» газетасы: «Зариф Садыйков йөзендә татар социал-демократиясе үзенең турылыклы улларыннан берсен югалтты», — дип язды. Азатлык өчен көрәш юлында вакытсыз һәлак булган бу күренекле революционерның якты образы коммунистик җәмгыять төзүче совет кешеләре өчен сокландыргыч үрнәк булып тора.

## Ибраһим Салахов

# СИРЕНЬНӘР ЧӘЧӘК АТКАНДА

**«Иманнәр тамыр җәйгәндә» романыннан өзек**



Кәрим, тыкрык чатына җиткәч, атын Яңа мәчет урамына бора гына башлаган иде, кинәт чаттан өч кораллы җайдак килеп чыгып аны урап алды:

— Тукта!

Кәрим, сул кулы белән җирән кашканың тезгенен тарта биреп, уң кулын галифе кесәсендәге наганга суузды һәм басынкы тавыш белән:

— Сез кемнәр? — дип сорады.

— Патруль.

— Пароль.

— Күп сөйләмә, парольне үзең әйт!

— Йолдыз.

— Улбай, монау үзебезнең комиссар Кәримҗан гой — дип, колга буйлы кавалерист куанып кычкырып җибәрде. — Кор, кор, әй, тукта! — хуҗа тезгенне тартып атны тынычландырырга тырышты. — Кор, кор, дим. Ал, җол булсын. Бол җиде төн уртасында кайдан килә җатырсыз, комиссарҗан?

— Ташҗан әкә, бу сезме? — Кәрим кесәсеннән кулын алды.

— Ничек, вокзал тынычмы? Чехлар кузгалмыйлармы?

— Без хәзер генә шул яктан уралдык. Пока ул-бу сизелми. Чехлар — вагоннарында.

— Иптәш комиссар! — әле һаман атын туктата алмый борылып йөргән яшүсмер егет Кәрим белән Ташҗан арасына килеп кереп сүзне бүлде. — Кайчан инде бу чехлар коралларын бирә башлыйлар? Ато ведь, көн дә иртән, көн дә иртән. Наверно хитрит итәләр, ышанмыйм мин ул сволочьларның сүзләренә.

— Менә нәрсә, иптәшләр,— диде дә Кәрим, аргамак аты белән юлны кисеп, туктаусыз тирә-якка каранып, күзәтеп торган мәһабәт гәүдәле зур кара сакаллы кешегә таба иелә төште һәм пышылдап кына

сөйли башлады, — яңа гына семеркада[1] шул мәсьәләне карадык. Бүген, төнге сәгать уникедә, коралны тапшыра башлау турындагы килешүнең срогы тулды. Без инде артык көтә алмыйбыз. Таң алдыннан вокзалны урап алачакбыз. Иптәш Тодояш, — Кәрим кара сакаллыга төбәп карады, — мадьяр эскадронына иптәш Зайкин китте. Сез аның җитәкчелегендә хәрәкәт итәрсез. Төшендегезме? — Кәрим Ташҗанга таба борылды.— Ташҗан әкә, сез хәзер тагын вокзал ягыны урап карап чыгыгыз. Иртә белән штабта күрешербез. Карагыз, — Кәрим соңгы сүзгә аеруча басым ясады, — карагыз, егетләр, сак булыгыз, засадага эләкмәгез. Хушыгыз! Кара әле, оныта язганмын,— Кәрим, кулын күтәреп, кузгала башлаган патрульне туктатты, — бүген штабта иптәш Алиев дежурить итә, ул-бу сизелсә, аңа гына хәбәр итегез...

Атлар берьюлы юыртып юлга чыкты һәм кара төнгә кереп югалды. Кызыл Яр каласы тирән тынлыкка чумды.

— Әйдә, кашка, без дә кузгалыйк! — Кәрим, тезгенне тартып, атын мәчет ягына борды.

*

* *

Кәрим штабка килеп кергәндә, анда инде ыгы-зыгы иде. Берәү керә, берәү чыга. Өзек-өзек сөйләшүләр, шау-шу. Тәмәке төтене һәм төче май исе. Почмактагы кечкенә өстәлдә куыгы шартлаган иске җиделе лампа «лып-лып» итеп утыра. Стенада — телефон. Дежурный телефоннан сөйләшә. Ишектән Кәрим керүгә, дежурный сөйләшүен өзеп трубканы элеп куйды да өстәл артыннан чыгып смирно басты һәм, уң кулын фуражкасына куеп, көр тавыш белән рапорт бирде:

— Иптәш комиссар, штаб буенча дежурный рота командиры Али Алиев!

— Вокзалдан ни хәбәр?

— Тынычлык. Без аларны даими күзәтеп торабыз. Солдатлар — вагоннарында. Мин әле яңа гына вокзал янындагы пост белән сөйләштем. Хәвеф сизелми.

Алиев үзе Кызыл Ярныкы түгел, читтән килгән кеше. Мөгаен, Мәскәү ягы мишәредер, теле каты. Элек ул каладагы җирле командалык штабында хезмәт иткән офицер. Хәрби эшне белә, ярата. Аңа тапшырылган һәр эш вакытында урынына җиткерелеп үтәлә. Әмма отрядтагы кызылгвардиячеләр аны яратып бетермиләр, кырын карыйлар. Мөгаен, аның аеруча күзгә ташланып торган пөхтәлеге, бигрәк тә патша армиясе поручигы булуы ошамыйдыр. Дөресен әйткәндә, Кәрим дә Али Алиевка артык җылы түгел. Ләкин нишләтәсең, хәрби белгечләргә мохтаҗлык зур. Шуның өчен, хәзер шәхси мөнәсәбәтләр белән хөкем йөр-

---

[1] 1918 елның 25 маенда Кызыл Яр Советы республика реввоенсоветыннан Кызыл Яр тимер юл станциясенә үтүче эшелоннардагы ак чехословак корпусы гаскәрләрен коралсызландырырга, әгәр буйсынмасалар, эшелоннарга паровоз бирмәскә дигән боерык ала. Шул көнне ике эшелон чехословак гаскәрләре, Омск шәһәрен үз кулларына алу нияте белән Кызыл Яр станциясенә тукталмыйча, турыдан-туры Омскида үтә. Аның артыннан ике эшелон — артиллерия һәм интендант гаскәрләре станциягә килеп туктый. Икенче көнне тагын бер эшелон чехлар килә. Кызыл Яр Советы эшелон командованиесенә коралларны тапшырырга таләп итә, югыйсә, паровоз бирелмәячәген белдерә. Чехлар, бу станциягә үз көчләрен туплап восстание күтәрү, шәһәрне үз кулларына алуны ниятләп, Совет белән сөйләшү-килешү башлаган була. Ул арада Кызыл Ярның түбән каласындагы казаклар, чехословаклар белән килешеп, ачыктан-ачык үз көчләрен тупларга тотыналар.

Совет каланы камалу хәлендә дип игълан итә һәм җиде кешедән Кызыл Ярны саклау хәрби комиссиясен оештыра. Бу комиссиягә түбәндәге иптәшләр сайлана: Дубинин Исидор Дмитриевич (председатель), Сутюшев Кәрим (урынбасар), члennар: Зайкин, Трацевский, Идрисов, Базарбаев, Батырбаев.

31 нче май көнендә шушы җиделекнең ашыгыч утырышы була. Хәзер сүз шул комиссиянең карары турында бара.

теп булмый. Менә ул, Кәримне хөрмәтләп, штаб начальнигы кабинетының ишеген ачты.

— Рәхим итәсез, сезне көтәләр иде, иптәш комиссар.

Бүлмә уртасында озын өстәл. Ярым караңгы. Тәмәке төтене, керосин исе. Өстәлдә — карта. Биш-алты кеше өстәлне урап шул карта өстенә иелгән. Ишек ачылуга, барысы да кузгалып, бусага ягына таба борылдылар.

— Ә, Сутюшев! — Өстәлнең аргы башында — уртада басып торган штаб начальнигы Исидор Дмитриевич Дубинин калын бас белән сүз башлады, — сине көтә идек. Нинди яңалыклар?..

— Чехлар әле вагоннарында. Кузгалмыйлар. Юлда Хәмитне очраттым. Мәүлеттән көлә. Андагы иптәшләр семофор алдындагы полотноны сүтә башлаганнар.

— Ә Хәмит үзе кайда?

— Центрга мөселман яшьләре дружинасына китте. Семерканың соңгы карарын аңа белдердем. Ул үз дружинасын әзерләячәк.

— Яхшы, уз!

Өстәл тирәсендәгеләр, бераз чигенеп, юл ачтылар, ияк кагып кына исәнләштеләр. Һәммәсендә дә авыр, борчулы караш. Кәрим дә сүзсез генә баш иде. Беренче тапкыр күргәндәй, һәрберсен җентекләп карап чыкты...

Барысы да күптәнге танышлар, бергә аралашкан консерва заводы эшчеләре. Ә хәзер? Хәзер алар — үз теләкләре белән Кызыл Гвардия сафына тупланган хөррият сакчылары. Алай гына да түгел, турылыклары, кыюлыклары белән иптәшләренең ышанычын казанган дружина командирлары бит алар.

Менә иң кырыйда колга буйлы ябык, озынча битен сары сакал баскан, гомер буе бөкрәеп тимер чүкүдән аркасына бөкре чыккан карт тимерче Галимҗан ага басып тора. Ул озын киндер күлмәк өстеннән иске камзул кигән. Башында җәлпәеп төшкән сырма эшләпә. Мылтыгын таяк төсле көпшәсеннән генә тотып таянып тора. Аның янында — шундый ук озын буйлы, сары чәчле, сипкелле битле яшь егет. Ләкин ул гәүдәгә тулы, иңнәре киң, күкрәге калкып тора. Егетнең өстендә — кыек якалы кара сатин күлмәк. Башында — күн фуражка, штаб начальнигына охшатып аз гына кыңгыр киелгән. Биле киң солдат каешы белән буылган. Сул як күкрәк өстендә — кара сатин күлмәктә — кызыл бант ут булып янып тора. Егет мылтыгын сул иңенә элеп, кулы белән каешыннан тартып, смирно баскан. Галимҗан абзый күз кырые белән генә аңа карап алды. Аның эчкә баткан яшьле күзләре бу минутларда яктырып китте. Ник яктырмасын? Бу егет карт тимерченең терәге, ышанычлы булган өлкән улы Гарифҗан бит. Ул да әтисе янында завод тимерчелегендә эшли. Дөрес, ул әле оста түгел, ярдәмче генә, мех өрдерә, чүкеч уйната. Ә берничә елдан, һичшиксез, Гарифҗан да атасы кебек үк атаклы тимерче булыр. Карт моны күңеле белән сизә һәм шуның өчен улына караган саен күңеле киңәя, буш егет түгел, атасына охшар! Ничек баскан әнә, эфиссәрдән ким түгел!..

Өстәлнең аргы кырыенда — касабчы Болтабай әкә. Тәбәнәк. Юан. Җәенке бит, солы күз. Алар тәмам йомылганнар. Юк! Кәрим яхшы белә бу күзләрне. Алар — мәргән күзләр. Күкчәтау иленең атаклы сунарчысы бит ул. Күктәге кош, җирдәге җәйран аның угыннан китә алмый. Болтабай исә хәзер карабинын култыгына кыстырып уйга калган — солы күзләр йомылган. Аның башында кырпулары кырылып беткән алты өлгеле казаки бүрек, өстендә — гомер буена өстеннән төшмәгән, майланып беткән иске чапан.

Дубинин янында — заводның май кайната торган казаннарын ямау-

чы бакырчы Әхмәтбәк Туганов. Газават алдыннан ант биргән сыман, бар уен, бар көчен көрәшкә туплаган — җан фида!

Дубининның сул ягында әле күптән түгел генә фронттан кайткан, әлек шушы Кызыл Яр консерв заводында слесарь булып эшләгән Николай Новиков белән Микола Таран. Алар икесе дә солдат киемендә — таушалган, уңган гимнастерка, козыреклары яньчелеп-чатнап беткән фуражка. Кулларында — герман окопларында аунап шомарып беткән штыклы трехлинейка.

Кәрим өстәл янына утыруга, Дубинин, колак артына кыстырган калын, кызыл карандашын кулына алып, картага иелде. Башкалар да өстәл янына тыгызландылар.

— Менә монда Меновой двор,— дип, штаб начальнигы карандашын кала картасы өстеннән йөртә һәм аңлатма бирә башлады. — Анда безнең кавалерия эскадроны тора. Командир — Бөркетбаев. Ә менә монда, татар зираты янындагы Ахун йортында, пехота ротасы һәм Хәмит Сүтюшев оештырган мөселман яшьләре дружинасы. Менә монда — Чиркәү мәйданында, Ганшин йортында, интернациональ отряд. Венгр, латыш доброволецлары. Тире заводында — Кызыл Гвардия отряды. Менә монда вокзал,— ул карандашның икенче очы белән күк божра урады,— козгыннар оясы! Удар шушы яктан булачак. Әзер булырга кирәк! Без — аларның каршысында.

— Бәс, шулай итеп... — диде Галимҗан абзый, мылтыгын бер кулыннан икенче кулына күчереп, тынычсызланып,— илаһи уптым алганда, без инде ничә штык булабыз шунда?

— Кызыл Ярның барлык почмакларына таралган бар отрядларны җыеп исәпләсәк, Галимҗан абзый, бер мең дә бер йөз илле кызыл сугышчы була.

— Ә чехлар өч эшелон... — дип башын чайкап куйды Микола Таран.

— Да... — диде Дубинин, картадан башын күтәреп, — аларда өйрәтелгән, инде сугышта булып үткән өч меңгә якын солдат һәм офицер...

— Аларда — артиллерия,— дип өстәде Николай Новиков, авыр сулап.

— Әйе, шулай, Николай Иванович,— диде Дубинин,— дошман безгә караганда сан ягыннан ике тапкыр артык. Өстәвенә, пулемет, артиллерия. Ләкин! — Ул бу сүзгә аеруча басым ясады. — Ләкин аларда бер нәрсә юк. Безнең нигез һәм терәк: — халык, юксыллар. Без аларның азатлыгы өчен көрәшәбез. Ә чехлар — килмешәк. Алар...

— Иптәш начальник! — Али Алиев ашыгып кереп смирно басты, шпорлары зыңлап китте. — Сезне телефонга чакыралар.

Дубинин ал як бүлмәгә чыгып телефон трубкасын алды:

— Тыңлыйм. Кем? Хәмит. Әйе, нәрсә?.. Хәзер үк кавэскадронны түбән калага! Үзеңнең дә дружинаңны алып шунда төш! Тиз! Мин моннан бер взвод җибәрермен. Ашыгыгыз!

Дубинин телефон трубкасын урынына элде дә, тып-тын калып, «Нәрсә булды?» дип аптырап торган штабтагыларга борылды, авыр итеп көрсенде.

— Түбән каладагы казаклар баш күтәргән.

Ул арада тышкы ишек ачылып китте. Аннан йөгереп, мышнап Ташҗан әкә килеп керде, ярым казакъча, ярым русча кычкырып әйтте:

— Уйбай, чехи! Вокзалдан чыгып монда килә җатыр. Идут сюда!

*
* *

Чехсловаклар, вокзалдан чыгу белән, таң алды каралыгыннан файдаланып, консерв заводын — штабны урап алырга омтылганнар иде. Әмма инде кичтән үк вокзал артындагы котлованнарда, канауларда

күзәтүдә яткан ике отряд аларны аз гына якын җибәрде дә ике яктан пулемет һәм мылтык уты астына алды. Аягүрә торып ата-ата килгән солдатлар кинәт ятарга мәҗбүр булдылар. Кара-каршы ятып ату башланды. Ул арада заводның цехларында дежурда торган эшчеләр — кызылгвардиячеләр, штабтагылар — чыгып, каралтыларга ышыклана-ышыклана, алдынгы линиягә — канауда атышып ятучыларга якынлашты.

— Иптәш комиссар! — әле генә, канауга килеп ятып мылтыгын цехларга төби башлаган Кәримгә янәшә чокырдан Гарифҗан шуышты. — Иптәш комиссар, әгәр мин үземнең егетләр белән әнә теге сарайлар арасыннан яшел ыштаннарның артына төшсәм ничек булыр? Арт сабакларын укытыр идем имансызларның, ә?

Бер-бер артлы берничә пуля канау кырыендагы түмгәкләргә бәрелеп сызгырып үтте — ком коелды.

— Ят тизрәк!

— Вот, контрлар, сөйләшергә дә бирмиләр, ә?

Кәрим прицелен бераз төшереп төбәп атып җибәрде. Канаудагылар бергәләп берничә залп бирделәр. Чехлар ягы тынды.

— Иптәш комиссар!

— Ярый, рөхсәт. Но, кара, егет, засада булмасын, сак булыгыз.

— Була ул, комиссар абый.

Ул арада, үз телләрендә нәрсәдер кычкырып, чехлар ата-ата якынлаша башладылар. Кәрим кирпеч өеме артына урнашкан «максимка» пулеметы расчетына команда бирде:

— Николай, әйдә башла!

Якында гына кемдер кычкырып җибәрде. Кәрим шул якка борылды.

— Болтабай әкә, сезме? Кай җирегезгә тиде?

— Уйбай комиссар. Монау җегет бәйләйде, зарары җок, сул кул.

Кәрим канау кырыеннан үрелеп төбәп ата башлады.

Ерак Көнчыгыш — Күкчәтау як офык алсуланды. Салкынча җил исте. Болытлар тарала башлады. Чехсловаклар, ачыктан-ачык күренмәсәләр дә, инде ерактан төсмерләнәләр. Алар, торып-ятып, торып-ятып ата-ата, һаман якынлашалар... «Их, тагын бер-ике «максим» булсачы...» — дип, Кәрим, эчтән рәнҗеп, заводның ташландык базларына якынлашып килгән бер соры күләгәне мушкага алды.

Күләгә ауды. Әллә юри, әллә яраланып... Шул арада Кәримнең сул ягына берәү шуышып килеп ятты да өстерәп килгән пулеметын канауга рәтләп куеп тыкылдата башлады.

— Ә, Галимҗан абзый,— Кәрим куанып кычкырып куйды.— Бир әйдә кирәкләрен...

Шундук чехлар ягыннан да бер-ике пулемет ут ачты. Николайның «максимка»сы тынып калды.

— Их, нәкъ кирәгендә... — Кәрим «максим» расчетына таба үрелде. — Ни булды?

— Николай...

— Кызганыч, Микула, син аны штабка санотрядка алып кит. Без монда үзебез, Гриша белән... Гриша, давай лентаны! — Кәрим пулеметын рәтләп, тагын төбәп гашеткага басты. — Мәгез, сволочьлар!..

Ләкин сул яктан бер төркем солдатлар инде канау өстенә чыгып киләләр. Урыйлар! Кәримнең өстенә салкын су сипкәндәй булды. Калтыранып китте. Нишләргә? Чигенергәме? Кая? Артта завод! Юк, юк! Кузгалмаска! Кәрим, пулеметны әле уңга, әле сулга борып, солдатларны ут сызыгыннан уздырмаска тырышты. Ләкин көчләр тигез түгел иде. Сул канат — завод як сынды, чигенә башладылар.

Шул чак сарайлар артыннан көчле «ура!» яңгырады.

— Иптәшләр! — Кәрим телдән телгә күчмәле команда бирде.— Алга!

Беренче булып ул үзе күтәрелде. Аның артыннан канауда яткан башка кызылгвардиячеләр тордылар.

Әле генә үзләренең көчләренә масаеп йөгереп килгән чехословаклар, артларыннан һөҗүм башлануны сизеп, тәртипләрен бозып җиргә яттылар, аннан вокзалга таба чигенә башладылар.

— Но, молодец, малай! — Галимҗан агай куанычыннан, сугышта икәнен дә онытып, аягүрә торып кулын болгый башлады, — шулай-шулай, малай, бир үзләренә. Мать якаларыннан!

— Галимҗан ага, ят тизрәк, — Кәрим аның чабуыннан тартып яткызды да атарга кушты, — әйдә, малайга булышырга кирәк бит...

— Бик дөрес!.. — ул, үзен-үзе орыша-орыша, пулеметын җайлады һәм чигенеп барган солдатларга ут төбәде.

Һөҗүм башланган җиргә — сарайлар янына — беренче булып Кәрим йөгереп килеп чыкты да, почмактан борылуга, таш булып катып калды: кирпеч өеме артында сузылып Гарифҗан ята, күкрәгеннән — кызыл бант өстеннән — кайнар кан саркый иде.

Ул арада арттан, пулеметын күтәреп, Галимҗан абзый йөгереп килеп чыкты.

— Әйдә, әйдә, комиссар, туктама! — диде ул. — Кыздырдыкмы үзләрен! Я алла! — Һәм картның күзләре җирдә яткан Гарифҗанга тукталды, кулындагы пулемет төшеп китте. Галимҗан, кулларын җәеп, иңрәп улы өстенә ауды.

— Гарифҗан! Гарифҗаным...

*

* *

...Шушала[1] ишегендәге йозак шалтырауга, Кәрим язып утырган кәгазен каршыдагы мичкә астына тыкты. Шәмне сүндерде. Револьверын кулына алды.

Ишек акрын гына ачылды.

— Әһе, әһе... Тым-караңгы, гой...

— Ата? Хәзер...

Кәрим, тире артыннан чыгып, ящик өстендәге шәмне кабызды. Шушала яктырып китте. Чал ишекне ябып алга узды.

— Карының ачып калган чыгар, балам, — Меңбай әкә комганның капкачын ачып, аннан кушкабырга, ыслаган казы һәм бер төргәк чыгарып мичкә өстенә куйды,— аз-маз йөрәк ялгап ал. Сораган кәгазьләреңнән дә кайберсен таптым, карагым.

— Рәхмәт, ал, ни хәбәр ата?

— И балам. Нисен сорыймсың? — Чал, гадәтенчә, сакалын учлап авызына капты,— башым әйләнде... Кара кайгы... Зиратта булдым.

— Кемнәрне җирләдегез, ата җан?

— Ой, нисен әйтәсең, үзең белгән сары нугайның улы Гарифҗанны... Үзебезнең мәргән Болта әкәне, җәнә Әхмәтбәкне... Черкис булса да мөселман, гой, байгыш.

— Ни дисез?! — Кәрим сискәнеп китте, Чалның авызына керердәй булып үрелде, — Әхмәтбәк Тугановмы? Булмас! Ялгыша торгансыздыр, әкә. Ул заводтан бергә чигенде, этәч каласына минем белән бергә килде бит... Әкә?

— И балам...— Чал ашыкмыйча, сабыр тавыш белән сүзен дәвам итте.— Дөньяны кортып торган яман күз, гой. Ул күрми каламы? Кичә төндә Әхмәт байгыш кулга төшкән. Барып ул хәзрәти Галидәй гайрәтле җан, гой. Ике казакны пычаклап качкан.

— Ал, шуннан, ата? Кайда киткән?

---

[1] Шушала — ит каклый торган бина, коптилка.

— Байгыш, башка барыр җире калмагач, үзебезнең мәчеткә кереп качкан. Таң иртән халык белән бергә иртәнге намазны укыган, муллага сәдака биргән... Ә намаздан таралганнан соң, унбер-унике атлы казак килеп мәчетне урап ала.

— Мөгаен, бирәү күрсәткән.

— Ой, балам, нисек әйтәсең? Ходай өендә дә сатлык җаннар утырганда дөнья төзәләме? — Чал авыр итеп көрсенде, җирдә аунап яткан бер әрҗәне алып каплап куеп утырды. — Я хода, мәдәт бир.

— Әйе, шуннан, ата?

— Әйтергә тел бармый, балам, — Меңбай әкәнең тавышы калтырады, изелеп-иңрәп китте. Ул чапан җиңе белән күзләрен сөртте. Мәчет ишеге алдында кылыч белән турап ташлаганнар мәлгуньнәр...

Шушала артында эт шыңшыды.

— Их! — Кәрим ачуга, кайгыга чыдый алмый арлы-бирле йөри башлады. — Сволочьлар, хайваннар, нинди асыл затларны харап иттеләр. Бу вәхшәтлеккә түзеп торырга мөмкинме? Юк! Юк!

— Ал, балам,— Меңбай әкә башын күтәрмичә генә Кәримне бүлде,— куй, кайгырма, шәһит җаннар, гой. Җаннары җәннәттә булыр, иншалла! — Чал башын күтәреп ике кулы белән битен сыйпады, ниндидер дога укыды. Кәрим дә, картның ихлас күңеллелеген хөрмәтләп, кулларын күтәрде.

— Амин!

Дога тәгәлләнде. Тагын дөнья хәле алга килеп басты. Кәрим бераз уйланып йөрде дә Меңбай әкә янына әрҗә өстенә килеп утырды.

— Ал, ата, энегез Ташҗанның хәле ничек?

— Безнең күршедә үпкәсе сырхау бер эель[1] бар иде. Ахун хәзрәтнең доктор кызы шул эельне караганнан соң безнең өйгә дә кергән... Ташҗанның кулын карап май җаккан, бәйләгән... Моннан соң ул башка өйгә күчкән. Ташҗанны әйтәм, ходай саклаган. Ул китүгә өенә өч казак килеп тентү ясаган... Уйбай, оныткanмын, гой,— Чал сүзен бүлеп иелде, кәвешен салды, олтырак астыннан бер кәгазь алып Кәримгә сузды,— хәтер дигәнең юк, гой. Онытып барам. Мә, ал, балам, бу әманәтне ахунның кызы сезгә тапшырырга кушты...

Меңбай әкә, әманәтен тапшыргач, тиз генә кәвешен киеп, комганын алып шушаладан чыгып китте. Кәрим шәмнең көеген бармаклары белән өзеп ташлап бераз яктыртты да иелеп хатны укый башлады.

*«...Һаман кулга алулар бара. Дубинин, Идрисов, Зайкин — барысы да төрмәдә. Имәнтаулык Абдрашитов дигән кеше сезгә барган икән, аны да тотып япканнар. Бүген төндә бер төркем венгр доброволецларын атачаклар икән дигән хәбәр бар. Аннан Али Алиевны аклар штабында күргәннәр. Сине эзлиләр, зинһар саклан.*

*1918 сәнә, 1 июнь. Дустың.*

*Кирәк сүзләрең булса, шушы почта белән юлла. Хуш, үбәм».*

— Алиев аклар штабында?! Кәрим хатны икенче тапкыр укып чыкты да аптырап үз-үзе белән сөйләшә-бәхәсләшә башлады. Булмас! Ул кадәргә үк барып җитмәс. Мөгаен, башка кеше белән саташтырганнардыр. Ә менә венгр дуслар? — ул шушала буенча арлы-бирле йөри башлады.— Их, безнең азатлык өчен мадьяр егетләре газиз башларын корбан итәләр. Ничек соң аларны коткарырга?..

Шәм бер якка кыйшаеп сүнә башлады. Кәрим аны, тәлинкәсе белән алып, бармакларын пешерә-пешерә тигезләде, фителен корымнан тазартты. Утырды, уйга калды: «Юк, болай бикләнеп ятып эш чыкмый. Төрмәдәге иптәшләрне коткару чарасына керешергә кирәк!»

---

[1] Эель — хатын.

Ишек ачылды. Кәрим сискәнеп урыныннан торды. Бу ни бу? Нәрсә? Әллә күзгә күренә генәме? Юк! Ишектән зур бер капчык кереп килә. Кәрим ни уйларга, ни әйтергә белмичә аптырап калды.

— Меңбай әкә?

— Улым, мин, гой. — Чал капчыкны шушалага этеп кертеп ишекне ябып, келәсен салып куйды. — Аллага шөкер...

— Ата, монавыгыз ни?

— Сабыр. Хәзер әйтәм, гой. Менә...

Кинәт абаланып Озын колак өрә башлады. Шушаладагы ике кеше тын да алмый катып калдылар. Ә эт һаман чинап-чинап өрә.

— Син инде, Кәримҗан, яшерен. Мин аллага тапшырып... — Чал сак кына атлап чыкты. Ишекне бикләде. Шәм сүнде. Ниндидер әрҗә авып төште. Нәрсәдер челпәрәмә килеп ватылды. Озын колак һаман абаланып өрде.

— Ал, кил, улым, монда кер,— Меңбай әкә шушалага унбер-унике яшьләрдәге бер баланы ияртеп керде. — Уф алла! Казак кереп калдымы дип курыккан идем... Монау сары нугайның кече улы икән. Сине сорый, Кәримҗан.

— Я, улым, кил, курыкма.

— Мин курыкмыйм, — бала бик тере генә атлап Кәрим янына килде. — Әти җибәрде.

— Бик әйбәт. — Кәрим баланың кыюлыгына сокланып карады. Озын, ябык. Соры чәч. Почык борын. Күзләре төбәлеп карый. Нәкъ Галимҗан абыйның копиясе. — Исемең ничек соң?

— Сабирҗан.

— Яхшы. Абыең кебек кыю икәнсең.

— Бүген... Бүген... — Сабирҗан кинәт үксеп елап җибәрде. — Абыйны... абыйны күмделәр бит...

— Беләм, беләм, җаным! — Кәрим якын килеп Сабирҗанны кочты, керпе чәчләреннән сыйпады.— Утыр менә бу әрҗә өстенә. Елама. Абыең кебек батыр булып үс!

— Мин болай гына... — Сабирҗан җиң очлары белән күзләрен сөртте. — Мин... еламыйм. Күзләрем генә яшьләнә бит...

— Ярый, ярый, тынычлан.

— Ал, Кәрим, син бала белән әңгәмәләшә бир, мин курага чыгып күз-колак болаем.

Чал сөйләнә-сөйләнә шушаладан чыгып китте. Кәрим әрҗәсен Сабирҗанга якынрак тартып утырды.

— Я, сөйлә, Сабирҗан, әтиең кайда? Сине нигә монда җибәрде? Үзе кайда соң?

— Әти, — Сабирҗан күлмәк итәге белән борынын сөртте, — зират каравылчысы Әхмәдулла абзыйлар өендә. Казак урыслар безгә бүген ике рәт килеп тентү ясады. Әтиең кайда? Кая качты, диләр.

— Ә үзегезгә тимәделәрме? Кыйнамадылармы?

— Әни мине, казак атлары күренә башлагач ук, күрше Апушлар курасына җибәрде. Мин шунда койма ярыгыннан гына карап тордым. Бер кара сакаллысы әнигә камчы белән сугып калды. Мин чак-чак кына йөгереп чыкмадым. Башына таш белән бәрәсем килгән иде.

— Инде син әтиең янына күп барып йөрмә. Артыңнан күзәтеп барулары мөмкин. Сакланырга кирәк.

— Ә без, абый, әүвәле Апуш белән ат-ат уйнап далага чыгабыз. Аннан соң гына зират урманына керәбез.

— Анда ярый. Алай да алдыңа-артыңа карап йөр, яме? Я, әйт, әтиең ни диде соң?

— Әти әйтте, ни дип... Әй, анда Әхмәдулла абзыйларга теге хәреф җыючы Җамал апа да килде бит. Ул да әйтте. Ни дип... Монда килеп кәгазьләр алып кайт дип.

— Ә юлда үзеңне казаклар тотса?

— Юк ла, абый, — Сабирҗан тереләнеп элеккеге кыюлыгына кайт-ты,— каян тотсыннар мине. Мин бит әллә кайдагы тыкрыклардан йө-рим. Кичә генәк әле этигә өйдән алтатар да алып барып бирдем. Сарай-да күмелгән иде. Гарифҗан абый яшергән булган...

Сабирҗан тагын йомшарып, еламсырап куйды. Кәрим юри аңа елар-га мөмкинлек бирмәскә тырышып сүзгә тартты.

— Молодец, андый юлларны белгәч. Бик әйбәт... Хәзер мин сиңа, — Кәрим урыныннан торды да, каршыдагы мичкәне кыйшайтып, астыннан бер төргәк кәгазьләр алды.— Менә болар Җамал апаң әйткән кәгазь-ләр. Син аны кайда яшерерсең икән, ә?

Сабирҗан зур тимер юлчылар фуражкасын башыннан салды да эчлеген әйләндерде.

— Менә монда, абый... Эчлеген юри сүтеп куйган идем...

Кәрим кәгазьләрне иплэп кенә фуражканың астары эченә җәйде, ан-нан френч кесәсенең капламасыннан җепле инә алып эчлекне бераз теккәләп тә чыкты. Калган җебен чалды. Фуражканы кагып-сугып Са-бирҗанның башына кидерде.

— Ярый, хуш. Әтиеңә әйт, иртәгә кич мин аны табармын. Кәгазьләр-не Җамал апаңа тапшырсын...

Сабирҗанны озаткач, Меңбай әкә тагын шушалага кайтты, теге зур капчыкның авызын чиште.

— Ата, бу нинди капчык? Нигә монда алып килдегез?

— Сабыр. Сабыр кыл, балам,— дип, сорауга җавап бирмичә, Чал капчыкны бушата башлады. Аннан яшел бәрхеттән алты өлге белән тегелгән казакъ бүреге, буй-буй яшел чапан, бөрмә ыштырлы кара бумази чалбар, читек, кәвеш чыкты.

— Боларыгыз ни, Меңбай әкә?

— Күршемездә бер сырхау әель бар дип әйткән идем, гой. Сол әель иртән җәйләүгә йөреп китмәк. Мин аның туышлары белән сөйләштем: алар риза. Инде сезгә сол әель менән җәйләүгә йөреп китү мәгъкуль. Инде менә осы киемнәрне табып алып килдем. Төсне үзгәртү кирәк.

— Ата! — Кәрим сикереп торып картны ике кулы белән кочты. — Сезгә бик зур рәхмәт. Әмма юлдашларым камауда, тоткында ятканда ялгыз башымны алып качу егетлеккә ятмас!

— Уйбай, монау ни дигәнең? — Чал еларга житешеп, ялварып Кәримнең күзләренә карады. — Бол жирдә Кызыл Яр туфрагында калу куркыныч. Әйткәнне эшлә, өлкәннәргә каршы торма.

— Юк, ата, — Кәрим башын чайкады, — булмый, ата.

Кинәт якында гына ике тапкыр мылтыктан аттылар. Шушала сел-кенеп китте кебек. Атлар чабып узды. Әтләр өрә башлады...

*
* *

Шәфәкъ сүнде. Биш күл ягыннан инде бер ягы кителә башлаган кызгылт ай күтәрелде. Көндезге тымызык эсседән соң җир аз гына суы-нып, иркенләп тын алды. Бәлҗегән үләннәр, яфраклар талгын җил бе-лән иркәләнеп җәелеп, күтәрелеп, яшәреп киттеләр. Ниһаять, Кызыл Яр өстенә июнь киче күксел канатын җәйде, ерак күктә йолдызлар же-мелдәде.

Гадәттә, мондый кичләрдә кала халкы өен-курасын ташлап бакчага агыла иде. Ник агылмаска? Ник ашыкмаска? Кызыл Яр каласының бакчасы — шәһәр паркы барлык Себер калалары арасында дан тоткан бакча. Мәһабәт карагайлар, яшел ефәк тәңкәле, ак тәнле назлы каен-

нар, кара-кучкыл вак яфраклы моңсу карагачлар, туктаусыз шыбырдап торган усаклар. Алар арасында ышыкланып, шау чәчәккә күмелеп утырган шомыртлар, сиреньнәр, тирә-якка хуш ис бөркеп, тәнгә шифа, җанга рәхәт бирәләр.

Бу агачлар XVII гасыр башларында бу якка килеп чыккан атаман Ермакны, аның тынгысыз отрядын күргәннәр һәм изге Павел белән Петр хөрмәтенә дип казакъ даласын үзләштерү өчен корылган хәрби крепостьны җил-давылдан ышыклап торганнар. Күпне күргән бу кала уртасында шаулап торган урман... Ул гынамы. Бөтен Себердәге бердәнбер җәйге цирк — гөмбәз бина шушы бакча уртасында утыра бит. Яз житте исә, монда дөньяның әллә кай почмакларыннан шаккатыргыч клоуннар, артистлар, акробатлар, жонглерлар, фокусниклар-күзбәйләүчеләр, көрәзчеләр, чегәннәр, тагын-тагын әллә кемнәр җыела. Бакча, цирк шау-гөр итә.

Ә менә бүген җылы, җил-давылсыз, тыныч кич булуга карамастан, бакча буш, цирк ябык. Аллеяларда, урындыкларда бер кеше, бер генә пар егет белән кыз күренми.

Бу бакча каланың нәкъ урта бер төшеннән башланып китә дә, сузыла торгач, мөселман зиратына барып тоташа. Зират зур. Кызыл Ярдагы барлык мөселманнар: татарлар, казакълар, үзбәкләр, кавказ халыклары, уйгурлар йөз елдан артык инде үзләренең мәетләрен шушында җирлиләр һәм һәрбер кабер өстенә язулы таш кую, чардуган-мазар кору белән беррәттән, берничә төп агач та утырталар. Менә шушы нәни агачлар урман булып күтәрелгән. Элегрәк бакча белән зират арасында такта койма да булган. Еллар узу белән, баганалар черегән, койма ауган. Һәм бакча белән зират тоташ бер кара урманга әверелгән.

Гадәттә, татар халкы кабер өстенә истәлек итеп язулы таш һәм чардуган куя. Ә менә үзбәкләр, казакълар (билгеле инде хәллеләре) кирпечтән, таштан тәрәзәсез-ишексез гөмбәз-өй салып, мәетне күммичә таш плитә өстенә куеп калдыралар. Кызыл Яр зиратында да берничә шундый мазар бар.

Кемдер менә шундый бер мазарның стенасын кеше мүкәләп керерлек итеп тишкән. Бу төнне әнә шул мазар эчендә, уртадагы таш плитәдә биш кеше утыра иде. Мазар эче караңгы. Утыручылар берсен-берсе күрмиләр. Сөйләшү бик сак, пышылдау белән генә бара.

— Башта әйткәнемчә, — диде уртада утырган эшләпәле кеше, кулындагы трость белән аяк астындагы җирне чокып, — бу операцияне иртәгә таң алдыннан башларга кирәк. Шуннан да соңга калырга ярамый. Алынган хәбәрләргә караганда, аларга берсекөнгә суд ясарга һәм атарга җыеналар.

— Ә бездә корал җитәрлекме соң? — диде эшләпәле янында утырган сакаллы кеше карлыккан тавыш белән.

— Корал барын бар, әмма азрак. Тимер юлчылар ике пулемет вәгъдә иттеләр. Хәмит төрмә сакчыларының берничәсен безнең якка аударган. Алар, какраз, берсекөнгә сакка чыгалар.

— Менә бусы ярый, — диде әлеге сакаллы кеше, урыныннан бераз кузгалып.

— Галимҗан абзый, — диде эшләпәле, сакаллы кешегә таба борылып, — син инде үзеңнең егетләреңне кичтән үк төрмә янындагы кабакка алып бар. Әгъләм, шау-шу күбрәк булсын өчен, гармунын да алсын. Уйнасын, җырласын, шик-шөбһә булмасын, эчкән булып, җырлап, сүгенеп утырсыннар. Операция вакыты житкәч, кабакчы (ул безнең кеше) кабакны ябам дип сезне куып чыгарыр. Сез гармун белән җырлап төрмә ягына барырсыз. Кузгалу вакытын иртәгә билгеләрбез. Мин түбән каладагы иптәшләргә хәбәр салдым. Ә бүген...

Кинәт мазарның эченә, ук кебек атылып, бер малай килеп керде. Утыручылар, сискәнеп, куркып, сикерешеп тордылар, коралларына тотындылар. Галимҗан ага, лачын кебек атылып, малайның өстенә ташланды, муеныннан тотты.

— Әтәй...— малай җан тавышы белән кычкырып җибәрде,— бу мин бит...

— Үтерә яздым бит үзеңне, хәерсез. Нишләп йөрисең монда?

— Ә-ә, эти,— малай мышнап, көчкә-көчкә тын алып, ашыгып сөйләп китте,— мине монда доктор апа җибәрде, зиратчы өенә бер офицер килде, Кәрим абыйны эзли, ди. Ни ди, тизрәк таралсыннар, ди... Сезне...

— Рәхмәт, Сабирҗан,— Кәрим малайның башыннан сыйпады,— молодец! Ә сез, иптәшләр, берәмләп зират эченәрәк китеп таралыгыз. Иртәгә шушы тирәдә күрешербез...

*
* *

...Үткән төн Кызыл Яр хәрби госпитале врачы Мәдинә Урманова өчен аеруча тынгысыз, хәвефле булды. Кичен бертуктаусыз яралы казакларны ташыдылар. Палаталар гына түгел, коридорлар да шул дәү сакаллы, яман күзле казаклар белән тулды. Ыңгырашу, акыру, сүгенү. Җитмәсә, өлкән врач Моисей Абрамович, казакларны күрү белән, коты очып инфаркт белән егылды. Бар авырлык Мәдинә өстенә ауды. Аларны кара, дәвала, операция ясa...

Ә төн уртасында? Иң хәвефлесе әнә шул төн уртасында булды бит. Ярый әле, алдан сизенде. Барысы да һәлак була иде.

...31 май төнендә Кәримнең сугышта яраланган дуслары Николай Новиков белән Микола Таранга Мәдинә өйләрендә перевязка ясаса да, гангрена башлану куркынычы тугач, яшертен генә госпитальгә алдырган иде. Менә кичкырын сеңелесе Марзия килеп казакларның госпитальдәге авыруларны тикшерергә җыенуларын әйтте. Ә Марзия аларның штабында машинистка булып эшли иде. Мәдинә ике Николайны процедурага дип чакыртты да подвалдагы моргка төшерде. Ишекне бикләп өскә күтәрелгәннәр генә иде, кылычларын, шпорларын шылдыршылдыр китереп, бер төркем казаклар килеп керде. Берничәсе ишек төбендә калды. Ә дәү сакаллы гыйфрит төсле өч казак Мәдинә кабинетына керде. Башлыклары — яшь бер офицер.

Мәдинә, бу чакырылмаган кунакларның килеп басуларыннан каушап, нәрсә эшләргә белмичә иңге-миңге булып торганда, теге офицер аның алдына килеп басты:

— Гафу итәсез!.. Әллә танымыйсыз да инде, Мәдинә туташ?! Гарнизон начальнигы полковник Волков әфәнде приказы буенча! Мөгаен, сез каршы түгелдерсез, әгәр без палатадагы авыруларны тикшереп чыксак?

— Мин монда туташ түгел, ә врач, Али Алиев әфәнде...— Мәдинә эченә тулган ачу, нәфрәтен яшерә алмыйча агарып китте. Иреннәре дерелдәде һәм шушы хәлен сиздермәскә тырышып, ишек төбендә куркудан катып калган шәфкать туташы Машага борылды.— Офицер әфәндегә халат бирегез!

Али Алиев госпитальнең барлык палаталарына кереп, һәр авыруның йөзенә җентекләп карап, тикшереп чыкты. Аннары процедура кабинеты янында торган Мәдинә янына шак-шок атлап килеп басты да, аның күзләренә сынау белән карап, коры, рәсми тонда сорады:

— Авырулар тагын кайда ята, врач әфәнде?

Мәдинә бер-ике адым читкә авышты, аптырап тирә-якка караган булды.

— Белмим... Сездә ничектер? Врач авыруларын подвалга яшерми.

— Алайса, — диде Али Алиев, шпорларын зыңлатып, һәм уң кулын фуражкасына күтәрде, — борчуыбыз өчен гафу үтенәм.

Ике Николайны Мәдинә бары тик дежурстводан чыгар алдыннан гына морггтан терапея палатасына күчертте һәм Машага тапшырды. Ә аннан, өенә дә кайтып тормыйча, түбән калага — Гыйльмулла абзыйга Кәримнең пакетын тапшырырга йөгерде.

Банк урамы чатына чыгуга, Мәдинә аптырап туктап калды. Урамның аргы башыннан бер төркем халык килә иде. Нидер кычкыралар, таяклар белән кизәнәләр. Төркем арттарак калды. Алга атлы казак чыкты. Ул нигәдер бертуктаусыз артына әйләнә. Кулындагы озын камчы белән кизәнеп суга. Кемгә?! Абау, бу ни бу?! Кемнедер муенына мунчак салып ат койрыгына бәйләгәннәр ич. Ат җилдерә башлады. Теге, мескен, ат артыннан иярә алмый тартыша, сөртенә. Арттан килүчеләр таяклары белән аның башына, аркасына сугалар, ямьсез тавыш белән акыралар:

— Мә сиңа.

— Мә, кызыл эт!

— Теләгеңә житештеңме, комсыз комиссар!

— Әйдә, әйдә, җилдер атны, кызыл комиссар йөгереп карасын!

Кемдер атка таяк белән сугып алды, ат элеккегегә караганда да тизрәк җилдереп китте. Койрыкка бәйләнгән кеше бераз йөгерде дә абынып егылды. Алда яңгырдан җыелып калган пычрак су. Казак юри атны шул пычрак эченә әйдәде. Койрыкта сөйрәлеп килгән кеше шул суга чумды. Адәм карагысыз булып пычранып чыкты. Шуны үткәч, атны туктаттылар. Теге мескенне типкәләп, муенындагы җебеннән тартып торгыздылар. Ул чайкалып көчкә-көчкә генә басып тора. Өстеннән пычрак су ага...

— Я алла... Бу... Бу — Кәрим ич...

Мәдинә, якындагы коймага сөялеп, хәлсез, өнсез калды.

Менә аркылы урамнан ат алдына озын буйлы, бик тулы гәүдәле, кара пальто, кара эшләпә кигән ап-ак сакаллы кеше килеп чыкты. Ул кулындагы тимер тростьны алга ташлап эре-эре атлый. Мәдинәнең йөзе яктырып китте, күзләре ачылды. Извозчиклар тотучы, атаклы купец Масляков бит бу. Әйе, әйе! Мәдинәләрдә берничә тапкыр кунакта да булды бит ул. Мәдинәнең әтисе, ахун хәзрәт, аны бик тәрәккый, киң күңелле дип мактаган иде. Мөгаен, хәзер ул Кәримне бу хурлыктан, җәфадан коткарыр өчен ашыгадыр. Әнә-әнә якынлаша. Атны туктатыр. Юк, нигәдер туктатмады. Масляков туры Кәримгә таба атлады... Якынлашты. Мөгаен, ул аңа нәрсәдер әйтергә телидер. Мәдинәнең күз аллары караңгыланып китте.

— Я алла!.. Нишлисез сез?

Масляков кулындагы авыр тимер таягын югары күтәрде дә бар көче белән Кәримнең башына сукты.

— Мә, җәһәннәмгә дөмек, мәлгунь!..

*

* *

...Кәримне җирләгәннең икенче көнендә Бибиҗамал апаларга госпитальдә шәфкать туташы булып эшләүче кыз — Маша килде.

Ул, ишектән кергәч, ишетелер-ишетелмәс кенә исәнләште дә түрдә бала тирбәтеп утырган Бибиҗамал апага бер кәгазь сузды:

...Менә... Сез... — иреннәре дерелдәде, сүзен әйтеп тә бетерә алмады, үксеп, елап сәке кырыена чүкте. Бишек селкенеп, чайкалып китте, кәгазь өстәл өстенә төште. Бибиҗамал апа да алъяпкычы белән битен каплап үкси башлады. Тавышка бишектәге бала уянып еларга тотынды. Өйдә өч җан өчесе дә үксеп, тыела алмыйча елыйлар. Шулай да Бибиҗамал апа үзен кулга алды, бишеккә иелде.

Ниһаять, бала йоклап китте. Ана бишектән күтәрелде, изүләрен каптырды:

— И аллам... Мәдинә туташның хәле ничегрәк соң... кызым? Ул кайда?

— Аны кичә генәк, җеназадан соң, психиатрия больницасына алып киттеләр бит... Апа җаным...— Маша, яулыгы белән күзләрен сөртә-сөртә, сәкедән торды. — Ярый, хушыгыз... Мин инде сменага соңга калам. Хушыгыз, апа җаным...

— Карале, кызым, — Бибиҗамал, кызны тотып калырга теләгәндәй кулларын сузды,— тукта әле! Бу язуны кем бирде соң?

— Үзе, апа... үзе биргән иде... Соңгы сәгатьләрендә язды...

Дерелдәп торган бармаклар өстәлдәге кәгазьгә үрелделәр...

> *«Туганым, Хәмит! Нәрсә генә эшләсәм дә, мин халык азатлыгы өчен эшләдем. Әгәр син, туганым Хәмит, исән калсаң, соңгы җиңүгә хәтле, эшчеләр эше өчен көрәш! Хуш!*
>
> *Синең Кәрим. 1918 сәнә, 5 июнь»* [1].

— Я раббем! — Бибиҗамал, хәлсезләнеп, үксеп сәкегә ауды, кәгазь идәнгә төшеп китте.

Кинәт җил кузгалды. Ябылыр-ябылмас торган бакча як тәрәзә ачылып китте. Әле күптән түгел генә чәчәк аткан сирень гөлләре иелеп бүлмәгә үрелде. Җил тагын сугылды. Бүлмәдә хуш ис, сирень исе аңкыды...

---

[1] Бу текст Төньяк Казагыстан өлкә комитеты каршындагы партия архивында сакланган рус телендәге документтан сүзгә-сүз тәрҗемә. Автор.

Рафаэль Мостафин

# АНЫ КОМСОМОЛ ҮСТЕРДЕ

СССР Язучылар союзына җибәрү өчен язган автобиографиясендә шагыйрь болай ди: «1919 елда, мәктәпне (сүз Оренбург шәһәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсе хакында бара — Р. М.) яңабаштан үзгәртеп кору өчен, реакцион мөгаллимнәргә һәм шәкертләргә каршы кискен көрәш бара иде. Мин әлеге хәрәкәтнең сул канатында торып көрәштем. Нәкъ менә шунда комсомолга да язылдым».

Ләкин Муса Җәлилнең тормыш юлына караган рәсми документлар буенча фикер йөрткәндә, ул комсомолга 1920 елның 17 февралендә Мостафа авылында керә. Ниһаять, Җәлил комсомолга 1923 елның көзендә, Казан рабфагында укыган чагында алына дип раслаучылар да бар. Шуларның кайсы дөрес? Кемгә ышанырга?

Шушы мәсьәләне ачыклау өчен, мин Мусаның абыйсы Ибраһим Җәлилов белән хат алыша башладым. Озакламый аның үзе янына — Фрунзе шәһәренә киттем. Ул Җәлилнең комсомолга чыннан да 1919 елның язында кергәнлеген раслады.

Бик авыр еллар була. Шәһәр янында ук дошман гаскәрләре. Урал арты урманнарында сары казак кырпулары күренгәли, шәһәр урамнарына снарядлар төшеп шартлый. Урамнарда учаклар яна. Алар янында, кулларыннан винтовкаларын төшермичә, кызыл патрульләр җылына. Коймаларда, афиша такталарында әйбер төрә торган кәгазьгә басылган прокламацияләр. Алар халыкны революция дошманнарына каршы көрәшкә күтәрелергә чакыралар:

«Эшче иптәшләр! Шәһәребезгә зур куркыныч яный. Котырынган буржуазия, халыкара капитал белән союзга кереп, революция казанышларын канга батырырга тели. Һәммәбез бер кешедәй булып, дошманга каршы күтәрелик! Кызыл Армия, эшче һәм крестьяннар армиясе сафларына язылыгыз!»

«Эшче яшьләр һәм эшче хатын-кызлар!

Советлар Россиясе, бөтендөнья пролетариаты белән берлектә, халыкара капиталга каршы көрәшкәндә, без, яшь эшчеләр, халыкара пролетариат революциясенең алдынгы вәкиле буларак, бу көрәшкә зур активлык белән катнашырга тиешбез. Пассивларга безнең арада урын юк. Бердәм, оешкан булсак кына иптәшләребезгә туганнарча ярдәм күрсәтә алырбыз.

Иптәшләр! III Интернационалның коммунистик яшьләр союзын төзегез!»

Унөч яшьлек шагыйрьнең беренче шигырьләре дә шушы прокламацияләр рухында языла. Автобиографиясендә үзе күрсәткәнчә: «...Бу шигырьләрнең төп эчтәлеге эшче-крестьян яшьләрен Кызыл Армия сафларына чакырудан, буржуйларны, генералларны, байгураларны фаш итүдән, атаман Дутов бандасына нәфрәт тәрбияләүдән гыйбарәт була».

1919 елның сентябрь-октябрь айларында Төркстан фронты каршында татар телендә чыгып килгән «Кызыл Йолдыз» газетасында М. Җәлилнең шундый сигез-тугыз шигыре басыла.

1919 елда Оренбургның элекке биржа бинасында шәһәр яшьләренең гомуми җыелышы уздырыла. Шәһәр советы председателе Александр Коростелев агымдагы хәл һәм яшьләр союзы алдында торган бурычлар турында доклад сөйли. Җыелыш бик шау-шулы уза. Арткы рәтләрдә утырган гимназистлар докладчыны әледән-әле бүлдерәләр, «Долой! Теләмибез!» дип кычкыралар. Эш тукмашуга хәтле барып җитә. Гимназистларны залдан куып чыгарганнан соң гына, А. Коростелев докладын тәмамлый ала. Ахырдан теләгән кешеләрне комсомолга язалар. Бу елларда комсомолга керүчеләрдән рекомендация дә соралмаган, һәр кешене аерым-аерым тикшереп тору да булмаган. Комсомолга керүчеләрдән шунда ук Кызыл Гвардия отрядлары төзеп, берникадәр өйрәткәннән соң, аларны фронтка җибәрә торган булганнар.

Ихтимал, эшче-крестьян яшьләре союзына Муса да шундый җыелышларның берсендә язылган. Ләкин, бик яшь һәм буйга да кечкенә булганлыктан, аны отрядка алмыйлар...

Фрунзедан кайтып берникадәр вакыт узгач, Оренбург журналисты Альтовтан хат алдым. Ул Оренбург партия архивыннан Мусаның кайчан комсомолга керүен ачыклый торган документ табуы хакында хәбәр иткән. Билгеле, беренче мөмкинлек булу белән, мин Оренбургка киттем.

Минем алда 1920 елның 13 февралендә язылган 1 нче номерлы беркетмә кәгазе. Сүз анда Мостафа авылында уздырылган ячейка җыелышы хакында бара. Җыелышта РКСМның Оренбург губерна комитеты вәкиле Хәкимов авылда коммунистик яшьләр союзын оештыру турында доклад ясаган. Ахырдан авыл яшьләре комсомолга язылган. Алар арасында Мусаның абыйсы Ибраһим Җәлилов та бар. Ләкин исемлектә Муса юк.

Бу хәл мине аптыраошта калдырды. Замандашларының истәлекләренә караганда, ул Мостафа авылының беренче комсомолы, комсомол ячейкасы оештыручыларның башлап йөрүчесе була бит.

Баксаң, мәсьәлә менә ничек торган икән.

Чама белән 1919 елның ноябрь аенда Муса туган авылы Мостафага кайта һәм шунда ук җәмәгать эшләренә күмелә. Оренбург өлкәсендә беренчеләрдән булып коммунистик балалар оешмасы төзи. Бу оешмага «Кызыл чәчәк» дигән исем бирелә.

Муса төрле кичәләр оештыра, спектакльләр куюда катнаша, лекция, докладлар укый. һәм, билгеле, Мостафа авылында комсомол ячейкасын төзү артыннан йөри башлый. Шул эш белән Шарлык волкомына китә. Ул үзен күптән комсомол дип саныса да, кулында комсомол билеты булмый. Шарлыкта аңа комсомолга яңадан керергә туры килер, дип аңлаталар һәм Мостафа авылында комсомол ячейкасы оештыруда ярдәм итәргә вәгъдә бирәләр. Берничә ай вакыт уза, ләкин волкомнан берәү дә килми. Муса тагын Шарлык волкомына мөрәҗәгать итә, вәкил җибәрүләрен сорап, Оренбург губкомына хат язып җибәрә. Тик җавап килгәнен көтеп тормыйча, РКСМның өяз комитеты урнашкан Каширинскига китеп бара. Мусаның китүе була, Мостафа авылына губком инструкторы Хәкимов килеп төшә. Хәкимов шул ук көнне авыл яшьләрен җыеп, беренче мәртәбә оешкан төстә җыелыш уздыра. Яшьләр Мусаның кайтып җитүен көтәргә телиләр. Ләкин Шарлыкта кичектергесез эшләре булганлыктан, Хәкимов монда озак тора алмый. Ул, Җәлилне комсомолга соңыннан, Мостафада комсомол оешмасы рәсмиләшкәч кабул итәрсез, ди. Шулай килешәләр дә. Соңыннан, бюрога Мусаны да кертүне күздә тотып, Зифа Ибәтуллина җитәкчелегендә бюро сайлана.

Мостафа авылында уздырылган бу җыелыш турында Ибраһим Җәлилов болай сөйли:

«Без төне буе утырдык. Җыелыш мәктәп бинасында барды. Төн уртасында мәктәп тәрәзәсендә утлар күреп, авылдашлар, мөгаен, гаҗәпләнгәннәрдер. Хәкимовның докладын хәзер без күнеккән докладлардан нык аерыла иде. Губком хезмәткәре безнең белән гади әңгәмә алып барды, большевиклар партиясе, Ленин комсомолы, аның ике съезды турында сөйләде. Шәһәр һәм авыл ячейкалары турында аңлатканнан

соң, булачак комсомолларның ни белән шөгыльләнергә тиешлекләрен төшендердә һәм илебезнең сәяси хәлен аңлатты. Без дә, үзебезнең чиратыбызда, тормышыбыз, эшләнгән эшләребез, бигрәк тә «Кызыл чәчәк» оешмасы турында сөйләдек. Хәкимов безне тырышлыгыбыз, җәмәгать эше дигәндә янып торуыбыз өчен мактады һәм Мостафа авылы ячейкасы бердәм, сугышчан ячейка булыр, дигән өмет белдерде. Балалар арасында эшләргә җаваплы кеше билгеләргә кирәк булгач, без бертавыштан эшне Мусага тапшырырга кирәк, дидек. Хәкимов безнең белән килеште һәм бу турыда беркетмәгә дә язып куярга тәкъдим итте. Ләкин, минем әйтеп узасым килә, Муса бу мәсьәлә белән генә шөгыльләнмәде. Чынлыкта, ячейканың төп эшен ул алып барды, чөнки мондый эшләрдә ул башкаларга караганда әзерлеклерәк иде».

Ике көннән соң Муса кайта. Билгеле, җыелышның аннан башка узуына бик көенә. Икенче көнне ул РКСМга член итеп алына. Мостафа авылы комсомол ячейкасының 1920 елның 16 февралендә уздырылган җыелыш беркетмәсендә болай диелә: «Җәлилов Мусаның РКСМ союзына кабул ителүен сорап язган гаризасын тыңладык. Аны РКСМга кабул итәргә дигән карар чыгарылды» [1]. Беркетмә 17 февральдә язылган.

Шул ук җыелышта тагын шундый мәсьәлә карала:

«1. Президиумга яңа бюро сайлау. 2. Драма түгәрәге оештыру. 3. Җыр ясаучылар түгәрәге төзү. 4. Пропаганда материаллары алып кайту өчен бер кешене Оренбургка җибәрү».

Шул ук архивтан мин Мостафа авылы ячейкасының 1924 елның 3 август беркетмәсен таптым. Беркетмәдә дүртенче пункт итеп менә нинди мәсьәлә каралган: «Тыңланды: Җәлилов Мусаның гаризасы. Гаризада күрсәтүенчә, ул Союзга 1920 елның 17 февралендә кергән, ләкин 21 елда документларын югалткан, әмма хәбәр итә алмаган. 23 елда Казанда яңадан Союзга кергән. Ул, документларын югалту сәбәпләрен һәм дәлилләрен күрсәтеп, үзенең 20 ел комсомолы икәнлеген һәм элекке стажын раслауларын сорый. Карар: Җәлиловның теләген искә алып, өлкә комитетыннан аның үтенечен канәгатьләндерүне сорарга».

Беркетмәнең почмагына икенче бер кул белән: «М. Җәлиловның комстажын 1920 елның 17 февраленнән дип санарга», дип язылган.

Шулай итеп, соңгы документ барлык шикләнүләрне юкка чыгарды. 1921 ачлык елында Мусаның 150 чакрым араны җәяүләп, ач-ялангач, тәрбиячесез балалар белән тулган Оренбург шәһәренә килүен искә төшерик. Ул биографиясендә: «Мин ачлыктан качып килүчеләр арасында болганып... ике ай чамасы ни туры килсә, шуны ашап, кайда туры килсә, шунда куныл... йөрдем»,— дип яза. Шулай булгач, аның комсомол билетын югалтуы һәм вакытында бу турыда хәбәр итә алмавы гаҗәп түгел.

Формаль рәвештә комсомол секретаре булып исәпләнмәсә дә, Муса авылда комсомол эшләренең җитәкчесе, оешманың җаны булып танила. Ул стена газетасы, кульъязма әдәби журнал чыгара, фикер алышулар, кичәләр оештыра, үзешчән сәнгать түгәрәге оештыра. Озак та үтми, Мусаны өяз комитеты члены, бераз соңрак губерна комсомол конференциясе делегаты итеп сайлыйлар. Үзенең шушы конференциягә баруы турында ул «Комсомол мәхәббәте» дигән шигырендә болай яза:

**Безнең сөешү болай кызык кына**
**Булды бугай:**
**Кызыл вагонда,**
**Икебез дә волком членнары,**
**Бер съездга барган чагында —**
**Син, өшегәч,**
**Килеп уртаклаштың**
**Минем җылы бәрән тунымны.**
**Менә шунда, каһәр,**
**Әллә ничек,**
**Бик үз булып миңа тоелдың.**

---

[1] Оренбург өлкәсенең партия архивы, 217 фонд, I тасвирлама, II саклау берәмлеге 2.

Оренбург партия архивындагы Муса Җәлил биографиясен ачыкларга ярдәм итәрлек кыйммәтле документлар болар белән генә чикләнми. «Муса Җәлил — педагог» дигән китап авторы Ф. Мостафин шул ук архивтан Мостафа авылы партячейкасының 1921 елның 11 февралендә уздырылган җыелышының 4 номерлы беркетмәсен тапты. Шуннан бер өзек китерәбез: «Муса Җәлилнең үзен РКП сафларына кабул итүне сорап язган гаризасы тикшерелде. Җыелыш Җәлиловны РКП сафларына кандидатлыкка кабул итәргә һәм райкомнан аңа вакытлы билет бирүләрен сорарга дигән карар чыгарды». Мусага бу вакытта әле унбиш тә тулмаган була. Шуны искә алып, райком бу карарны расламый. Әмма ни генә булмасын, Мусаның партия сафларына омтылуы һәм авыл партячейкасының аны партиягә лаеклы дип санавы үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Ә бит бу Оренбург далаларында ак банда калдыклары йөргән, «сәнәкчеләр» фетнәсе яңа гына бастырылган, коммунистлар наганнарын баш асларына куеп йоклаган иң тынычсыз көннәр була. Әйе, Мусаның сүзе бервакытта да эшеннән аерылмый.



**Яшим халкым өчен, көчләр табам мин,**
**Халык өчен һаман алга барам мин,**
**Минем гомерем тәгәлләнер шуның чөн,**
**Күмелсәм дә бу юлда, бер дә янмыйм!**
**Халык хакына хаклап җыр язам мин!**
**Бизеп, күңелемне алмыйм доньядан мин!**
**Берәр караңгы көн өчен үземне**
**Бөтен зур кайгы-хәсрәткә дә салмыйм!..**

1920 елның январь аенда язган бер шигырендә Муса Җәлил әнә шулай ди.

Кайбер кешегә архив киштәләрен актару күңелсез һәм кызыксыз эш булып күренергә мөмкин. Ләкин чынында һич алай түгел. Кайвакыт архивта бик кызыклы материаллар табыла. Менә Шарлык волосте комсомол ячейкасы утырышы беркетмәсеннән бер өземтә: «Т ы ң л а д ы к: керосин өләшү турында. К а р а р  к ы л д ы к: картлар аяз көннәр вәгъдә иткәнлектән һәм эңгер-меңгер вакытта күктә ай булу сәбәпле, бу атнада керосин өләшмәскә».

Менә тагын берсе: «Т ы ң л а д ы к: НЭП турында. К а р а р: Ленин НЭП яклы булганлыктан, НЭПка каршы чыкмаска. Ләкин капкорсакка тозны капкорсак бәһасеннән саттырмаска, тозны экспроприацияләргә һәм ярлы халыкка совет бәһасеннән сатып, акчасын капкорсакка бирергә».

Бу елларда комсомол ячейкасы бик күп мәсьәләләрне хәл итүдә катнаша. Кайбер очракларда исә алар авылларда Совет властеның вәкаләтле илчеләре булалар. Оренбург архивында эзләнә торгач, мин моңа кадәр билгеле булмаган документларга юлыктым. Бу 1924 елның җәендә Мостафа авылы комсомол ячейкасы уздырган җыелыш беркетмәләре иде. Алар арасында шагыйрьнең үз кулы белән язылган отчетлар да бар. Рабфак студенты Муса Җәлил җәйге каникул көннәрендә бик күп җәмәгать эшләре башкарган. Бу кәгазьләр буенча аның җәйге ял вакытындагы һәр көнен күз алдына китерергә мөмкин.

1924 елның 1 июлендә Муса авылга кайта. Шул ук көнне ул, 7 комсомолны җыеп, җыелыш уздыра. Аның чыгышы беркетмәгә тулысы белән теркәлгән: «Комсомол членнарының санын барлап, сафларны ныгытырга. РКСМ программасын һәм уставын өйрәнүне оештырып, гомуми җыелыш җыярга, шунда комсомол һәм аның алдында торган бурычларны яңадан аңлатырга. Шулай итеп, без сүздә генә түгел, эштә җәмгыятьнең алдынгы көрәшчеләре булырга тиешбез» [1].

Алга таба Муса дингә каршы пропаганда эшләрен көчәйтергә чакыра, спектакльләр куеп һәм үзешчән сәнгать концертлары оештырып, халыкның күңелен ачарга кирәк, ди. Яшьләр аның чыгышын яратып тыңлыйлар һәм җәй айлары өчен аны вакытлыча комсомол секретаре итеп сайлыйлар.

---

[1] Оренбург өлкәсенең партия архивы, 217 фонд, I тасвирлама, саклау берәмлеге 2, 4 бит.

Озакламый Мостафа авылы ячейкасының эше бермә-бер җанланып китә. Муса кырларда газета укуны оештыра, әңгәмәләр уздыра. «Ни өчен без ленинчылар дип аталабыз?» дигән темага комсомол җыелышы үткәрә. Партячейка белән берлектә авыл мулласына һәм дингә каршы сәяси суд оештыра. «Ни өчен без элек ярлы идек?» дигән темага һәм халыкара хәл турында лекцияләр укый. Халыкара эшчеләргә ярдәм оешмасының члены буларак, бер комсомол җыелышын чит ил эшчеләренә ярдәм итүгә багышлап, аларга ярдәм йөзеннән акча җыйный. Газета-журналларга язылуны оештыра.

Җәйге кыр эшләре чоры булуга карамастан, бер июль аенда гына да Мостафа авылы ячейкасы 5 комсомол җыелышы, 3 бюро утырышы, ике мәртәбә дин турында диспут уздыра, үзешчән сәнгать концертлары оештыра. Шушы вакыт эчендә комсомоллар һәм партиясезләр өчен 3 лекция, 5 доклад, 2 әңгәмә уздырыла. Комсомолга 5 яңа член алына, өлкә һәм республика газеталарына язу өчен хәбәрчеләр билгеләнә.

Муса авылда 23 августка кадәр була. Документлардан күренгәнчә, атна ярым авырып ята. Шуңа карамастан, август аенда ике гомуми җыелыш, бер бюро утырышы, комсомолның үз-үзен тотышы дигән темага һәм империалистик сугыш башлануга 10 ел тулуга багышланган ике кичә уздыра. Докладны, билгеле, Муса ясаган, пьесада төп рольне башкаручы, мандолина уйнаучы һәм шигырь укучы да ул булган. Комсомол оешмасы урындагы властьлар белән комсомолның бәйләнешен тикшерә, авыл Советына бер вәкил сайлый, самогон куучыларга каршы көрәш ача һәм башка шундый мөһим эшләр башкара. Соңыннан җәйге каникулга кайткан студентлар белән саубуллашу кичәсе уздырыла...

Бары 53 көн. Бу көннәрне ул барлык эшләрдән һәм мәшәкатьләрдән башка ял итеп кенә дә уздыра алыр иде. Әмма Муса әнә нихәтле эш эшләгән.

Оренбург партия архивыннан табылган яңа документлар Муса Җәлилнең зур җәмәгать эшлеклесе булуы хакында сөйлиләр. Соңыннан Муса үзе турында бик хаклы рәвештә: «Мине комсомол үстерде!» диде. Дөрестән дә, Ленин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгәнлек, күтәренке рух, кайнар теләк Мусаның иҗатында үзенчәлекле эз калдырды.

**Александр Шпирт**

# УЛ ЛЕГЕНДА БУЛЫП КАЙТТЫ

Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар җыр булып.

М. Җәлил.

1929 ел иде. Август аеның соңгы көннәре. Мин Мәскәүнең Варварка урамы буйлап барам. Кулымда—кыршылып беткән студент чемоданы.

Күптән түгел генә югары әдәби курслар ябылды. Ә мин шунда укыган идем. Шуннан мине Мәскәүнең 1 нче дәүләт университетына кабул иттеләр һәм университетның тулай торагында урын бирделәр. Тулай торак Варварка урамының 7 нче йортында иде. Хәзер бу урам Разин исемен йөртә. Ә тулай торак булган йортка Коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм башка учреждениеләр урнашкан. Ә каршысында—«Россия» гостиницасы.

Дүрт катлы йортның коңгырт төстәге зур ишеге алдына килеп туктыйм. Баскычтан югары күтәреләм. Караңгы коридор буйлап бик күп ишекләр янынннан үтеп, тулай то-

ракның комендантын табам. Комендант мине тулай торактагы бүлмәләрнең берсенә урнаштыра.

Бүлмәдә бер генә егет. Ул өстәл янына утырган. Ниндидер китап укый. Исәнләшәм дә кайсы койканың буш булуы турында сорыйм. Бүлмә эченә күз салам. Бүлмә зур түгел, квадрат формасында. Стена буйлап дүрт койка тезелеп киткән, араларында— тумбочка. Тумбочкалар өстенә китаплар, дәфтәрләр өелгән, кайберләрендә — стаканнар, чынаяк чокырлары. Бүлмә уртасында—зур өстәл, өстәл янында—берничә урындык.

Егет белән танышабыз. Ул Кубаньнан килгән, исем-фамилиясе—Миша Егоров, хикәяләр яза. Бу бүлмәдә әдәбият факультеты студентлары гына тора икән.

— Шагыйрьләр бармы соң монда?

— Бар,—ди Егоров.—Менә бу Долинин койкасы. Аның инде Мәскәүгә килгәнче үк кечкенә генә китабы чыккан булган. Ә монысы—Евсеевныкы. Ул да башлап язучы шагыйрь. Китаплары юк әле, шулай да журналларда басылгалый. Ә менә ишек янындагы койка—татар шагыйре Җәлилнеке, исеме Муса.

...Бу көннәрдән соң инде ярты гасырга якын вакыт үтте. Ул вакытта Совет иле күптән түгел генә үзенең беренче ун еллыгын үткәргән, тирә-як революция романтикасы белән тулы, сәнгатькә, әдәбиятка эшче һәм крестьян яшьләре килгән заман иде. Беренче курс студентлары, философия тәгъбирләрен аннан-моннан отып алып, бик кискен бәхәсләшәләр, бер-берсенә «идеалист», «Кант иярчене», «метафизик», «эмперик» һәм башка кушаматлар тагалар, «диалектик метод», «форма һәм эчтәлекнең бердәмлеге», «чагыштыру теориясе», «каршылыклар бердәмлеге» һ. б. тәгъбирләрне— гәрчә алар турында бик сай фикер йөртсәләр дә—еш кулланалар иде. Башлап язучы прозаиклар һәм шагыйрьләр шул вакыттагы РАПП, леф, конструктивистлар, перевал һ. б.лар кебек әдәби юнәлешләрне тәнкыйтьләп яки яклап тамаклары карлыкканчы бәхәсләшәләр, Маяковский, Есенин, Сельвинский, Асеев, Тихонов, Пастернак, Луговской һ. б. популяр шагыйрьләрнең исемнәрен һәр килештә кабатлыйлар.

Көннәрнең берендә безнең бүлмәдә шуңа охшаш бәхәс башланып китте...

Җәлил соң гына кайтты. Мөлаем, акыллы һәм бик тыйнак итеп елмайды. Аның тыйнаклыгында бер үк вакытта тәвәккәллек, максатка омтылыш, ныклык сизелеп тора иде.

Җәлил койкасына утырды, шактый вакыт дәшми генә безнең бәхәсне тыңлады. Аннан йокларга әзерләнә башлады. Бүлмәдәш егетләр беләләр: ул, университетта уку өстенә, татар телендәге балалар журналы «Октябрь баласы»ның редакторы да иде. Аруы бик табигый.

Без дә йокларга яттык. Ут сүнде...

*

* *

Иртә белән иң беренче Яша Полонский тора иде. Койкага торып баса да кычкырып Маяковский шигырьләрен сөйләргә керешә. Җәлил, башкалардан соң кайтуына карамастан, шундук сикереп тора да урыннарын җыештырып куя. Вакытның кадерен белә иде ул: бик тиз юына, бик тиз киенә.

Беренче карашка бик әһәмиятсез булып күренгән вак детальләр дә хәтергә сеңеп калган: Муса койканы бик матурлап җыя иде, ә башкаларыбыз—ашып-пошык, аннан-моннан гына.

Аннары, китап-дәфтәрләрне алып, беренче катка, ашханәгә йөгерәбез. Без анда иртәнге, кечке ашны гына ашый идек. Ә көндезге ашка университеттан ерак түгел Георгиевский тыкрыгындагы студентлар ашханәсенә йөрибез.

Әгәр вакыт сыйдырса, укырга без җәяүләп барабыз. Вакыт аз калса, трамвайга утырасың. Ул вакытта Кызыл мәйданда да трамвайлар йөри иде әле.

Ә кичләрен, дәресләрдән соң, бүлмәбездә кискен бәхәсләр, әңгәмәләр дәвам итә. Җәлил соңгарып кайтса да, әгәр шигырьләр, поэзия турында сүз барса, ялкынланып китеп бәхәскә кушыла иде. Аның бу вакытта арыган йөзе җанланып китә. Ә, гадәттә, ул үзен тыйнак тота, бәхәсләргә катнашырга яратмый иде.

— Муса,— дисең аңа,— нигә һаман дәшмисең?

— Ә мин бай булырга телим,—дип мәзәкли иде ул.—Сүзең көмеш булса да, дәшмәвең алтын, диләр бит.

Без аны шундый гадилеге, кешелеклелеге өчен ярата идек.

Безнең бүлмәдәге шагыйрьләр һәм әдәбият факультетында укучы күршеләр— Саша Отслендер, Паша Железнов, Вася Цвелев—үзләренең яңа язган шигырьләрен укыйлар. Аннан фикер алышу башланып китә.

Әлбәттә, без бу әңгәмәләрдә, бәхәсләрдә әдәбият темалары белән генә чикләнмибез, беренче курстан ук политэкономия, диамат, революция хәрәкәте тарихы дәресләре буенча лекцияләр тыңлагач, бик табигый, дөнья политикасы, капитализм илләрендәге кризис, чит илләрдәге сыйнфый көрәш, илебездә барган төзелеш эшләре, киләчәк турында да фикер йөртәбез. Безнең әсәрләр дә шулар белән бәйле иде.

Мондый әңгәмәләр вакытында Муса бер-ике сүз белән генә үз фикерен белдерә торган иде. Бу сүзләрне ул акрын тавыш белән, ашыкмыйча, уйлап кына әйтә. Әле хәзер дә аның тыныч, акрын тавышы колак төбемдә яңгыраган кебек. Шунысын һич онытасым юк: Җәлилнең кыска җөмләләрендә, кисәтмәләрендә партия эшчәнлегенә тирән ышаныч, какшамас идея юнәлеше сизелеп тора иде. Үзенең бер-ике сүзе белән дә безнең бәхәсләрнең юнәлешен бөтән якка юнәлткән очраклар еш булды.

Шунысын да әйтергә кирәк: безнең бүлмәдә яшәүче егетләр барысы да комсомоллар булып, арабызда бердәнбер коммунист Муса Җәлил иде.

*
* *

Студентларның вакыты аз була: лекцияләр, университет китапханәсендә утырулар, иҗтимагый эшләр, түгәрәкләргә, спорт залларына йөрү. Кич кенә бүлмәгә кайтабыз.

Беребез беренче катка кайнар суга йөгерә, чәй эчәргә утырабыз. Кемдә нәрсә бар—уртак итеп бүлешәбез. Мондый чәй мәҗлесенә, әгәр иртәрәк кайтса, Муса да катнаша.

Шунысы хәтердә: иртән Муса янына дусты килгәли иде. Аның белән бер яшьтәгеләр булыр. Буйлары да тигез иде. Кем икәнен белмим. Мөгаен, үзе кебек үк шагыйрь булгандыр. Бәлки, хәзер дә исәндер, Варварка урамындагы тулай торакта безнең бүлмәне хәтерли торгандыр...

Иртән иртүк еш кына Муса белән бергә, я җәяүләп, я трамвайга утырып, университетка бара идек. Төрле курсларда укысак та, мин аларга нинди дәресләр бирелүе, лекцияләрне кемнәр укуы турында сораша идем. Шулай да юлда йөргәндә күбрәк поэзия турында сөйләшү барды.

Ул вакытта милли әдәбият әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү киң колач алмаган иде әле. Мусаның Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Һади Такташ һ. б. күренекле татар шагыйрьләре турында сөйләгәннәре шуңа күрә минем өчен яңалык иде.

Тукай турында аеруча күп сөйли иде Муса. Аның шигырьләрен яттан белә, «Габдулла Тукай—минем остазым ул!»—дия иде.

Һади Такташны бик хөрмәт итә, аны шул заманда иң көчле шагыйрь итеп таный, новатор-шагыйрь дип атый иде.

«Шулай ук Багрицкий белән Маяковскийга да минем хөрмәтем бик зур!..» — дия иде.

Мөгаен, Муса Җәлил белән мондый әңгәмәләр миңа зур йогынты ясагандыр. Соңрак мин Тукай, Гафури һәм башка татар шагыйрьләренең күп кенә әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иттем...

...Муса белән бер бүлмәдә яшәсәк тә, көн саен күрешсәк тә, ул вакытта аның яшьлек биографиясен, ундүрт яшьлек малай вакытында ук гражданнар сугышына катнашуын, ялкынлы комсомолец булганын белми идек әле. Муса безгә авылда беренче комсомол ячейкасы оештыруы, кулына корал тотып, кулак восстаниеләрен бастыруга катнашуы, комсомолның Оренбург губкомында эшләве турында һичвакыт сөйләмәде. Болар турында мин сугыштан соң, китаплардан укып кына белдем. Мәскәүдә университетта укыганда да ул, Комсомол Үзәк Комитетының татар секциясе хезмәткәре булу өстенә, бик күп менә дигән әсәрләр язды. Сугышчы, язучы, коммунист Муса Җәлил эшкә бар күңелен бирә, янып эшли белә иде. Бу яну аның күңелен чыныктырды, аны зур сынаулар алдында каушап калмаска әзерләде. Җәлил укый, иҗат итә, эшли

иде, ә аның өчен палач ул вакытта ук балта кайраган икән инде. Әмма аның йөрәге бу геройлыкка шул заманда ук әзер булуы хак, минемчә.

Безнең бүлмәдәш, безнең иптәш Муса Җәлил шундый иде.

*

* *

Еллар бик тиз уза. Университет бусагасын соңгы кабат атлап чыкканга шактый вакыт узды. Без—дуслар-иптәшләр—төрле якка таралыштык.

Утызынчы елларның яртысына да җителде. Мәскәүдә калган сабакташлар белән сирәк-мирәк әдәби оешмаларда, газета-журнал редакцияләрендә, нәшриятларда очрашкалыйбыз. Бу елларда, мөгаен, Җәлилнең эше бик тыгыз булгандыр, чөнки аның белән бик сирәк очраша торган идек. Шул очрашуларның берсе бик яхшы хәтердә сакланган. 1936 елмы, 1937 нчеме—анысын тәгаен әйтә алмыйм. Мин аны Зур Черкас тыкрыгындагы нәшриятның өченче катында очраттым. Ул вакытта СССР халыклары поэзиясе редакциясендә Софья Моисеевна Хитарова эшли иде.

Ул елларда инде милли әдипләрнең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү планлы төстә алып барыла башлады. Нәшриятларда республикалар шагыйрьләренең поэтик антологияләрен, аерым шагыйрьләрнең җыентыкларын чыгару буенча махсус редакцияләр оештырылган иде.

Мин редакциягә кергәндә, Софья Моисеевна өстәле янында Муса утыра, аның белән «Татарстан шагыйрьләре» дигән җыентыкның язмышы турында сөйләшә иде. Бу китапны төзүчеләрнең берсе Җәлил үзе иде кебек...

Аннары без, тәрәзә янына барып, хәлләребезне сораштык, үткәннәрне искә төшердек.

— Хәтереңдәме, Муса,—дидем мин,—Син Тукай, Гафурилар турында сөйләгән идең. Хәзер мин аларның һәм башка татар шагыйрьләренең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итәм. Синең шигырьләрне таба алмадым, аларны да тәрҗемә итәргә исәп иде.

— Минем шигырьләрне бит Миних тәрҗемә итте.

...Александр Миних. Мин бу озын буйлы, ябык гәүдәле шагыйрьне белә идем. Миних тәрҗемә иткән шигырьләр җыентыгы Мусаның рус телендә басылып чыккан беренче китабы иде. Александр Миних Бөек Ватан сугышында һәлак булды.

Мин Мусага тагын Шәйхи Маннур, Нур Баян шигырьләрен тәрҗемә итүемне әйттем, тәрҗемә итү өчен аңардан да яңа әсәрләрен сорадым.

Муса елмайды да: «Тәрҗемә итәрсең әле»,—диде.

Аның ул сүзләре раска килде. Саубуллашканда бер шигырен Багрицкий тәрҗемә иткәнен әйтте.

Багрицкий һәм Җәлил!

Мин бу ике шагыйрьнең үзара бәйләнеше турында сөйләргә телим. Инде әйткәнемчә, Җәлил, университетта укыганда ук, Багрицкий поэзиясен яратуы турында еш сөйли иде. Егерменче еллар комсомолы, гражданнар сугышында үзе дә катнашкан Җәлилнең романтик шагыйрьне, гражданнар сугышы җырчысы, «Дума про Опанаса» авторы Багрицкийны яратмавы мөмкинме соң?

Багрицкий, гомумән, тәрҗемә белән бик аз шөгыльләнә иде. Шулай да ул яшь татар шагыйренең әсәрләре арасыннан үзенә ошаган бер лирик шигырьне сайлап рус теленә тәрҗемә иткән.

Ә соңыннан без 1942 елның февралендә Волхов фронтында һәлак булган яшь шагыйрь Всеволод Багрицкий урынында Икенче удар армиянең «Отвага» газетасында татар шагыйре, өлкән политрук Муса Җәлил эшли башлаганын белдек.

Яраткан шагыйренең улы урынында эшли башлаганда Мусаның нинди хисләр кичерүен күз алдына китерү кыен түгел...

*

* *

Утызынчы еллар ахыры. Илебездә төзелеш эшләре көннән-көн киңрәк колач ала. Ә дөнья тыныч түгел. Германиядә фашизм баш калкытты. 1939 елда ул Польшага һөҗүм итте, Икенче бөтендөнья сугышы башланып китте. Европа дәүләтләрендә урта

гасырлар кыргыйлыгы хакимлек итә башлады. Ә ике елдан инде Гитлер Германиясе хыянәтчел төстә безнең илебезгә каршы сугыш ачты.

Бик зур авырлыклар белән узган дүрт елдан соң, без, Беренче Белоруссия фронты гаскәрләре белән бергә, немец җиренә, Берлинга аяк бастык.

...Тирә-якта—тоташ янгын, коточкыч хәрабәләр. Тәрәзәләрдә исә ак җәймәләр, күлмәкләр, мендәр тышлары җилферди. Ә урамнарда безнең сугышчылар гына. Берлин кешеләре әлегә яшеренгән.

Без барысын да белми идек әле. Бу көннәрдә мин Шпандауда да, Берлин тирәсендәге башка шәһәрләрдә дә булдым. Якында гына Моабит төрмәсенең калын диварлары эчендә, Шпандау төрмәсенең таш казаматларында татар шагыйре Муса Җәлилнең фашизмга каршы көрәш алып барганы ул вакытта кем башына килсен?!. Әйе, ул вакытта без Германиянең үзәгендә, гестапо белән рәттән, Муса Җәлилнең хәрби әсирләрдән яшерен оешма оештыруын да, төрмәләрдә үлем көтеп ятуын да, иң авыр шартларда, төрмә каравылчыларыннан яшерә-яшерә, аерым кәгазь кисәкләренә өмет һәм киләчәккә, җиңүгә ышаныч белән сугарылган шигырьләр язуын да белми идек әле. Болар безгә сугыштан соң гына, аның палач балтасы астында язган җырлары туган илгә кайтып җиткәч кенә билгеле булды.

И минем кадерле дустым Муса! Коточкыч фашист төрмәләрендә нинди генә сынаулар үтмәдең дә нинди генә кыенлыклар кичермәдең син! Хәтта хәзер, күп еллар үткәч тә, синең башың өстендә палач балтасы ялтыравын күз алдыма китерсәм, тамагыма төер утыра, күз алларым караңгыланып китә.

Әмма син җиңдең, Муса! Тәрәзәләрдә, балконнарда ак җәймәләр җилфердәгәндә, фашист Германиясе синең алда да тез чүкте бит, Муса!..

*

* *

Илленче еллар башы иде. Илебез сугыш яраларын дәвалаган, зур төзелешләр алып барган заман.

Көннәрдән бер көнне «Литературная газета»ны ачып укырга керешсәм, күземә Муса Җәлил исеме чагылды. Дулкынлана-дулкынлана аның батырларча һәлак булуы турындагы хәбәрне, Илья Френкель тәрҗемәсендә чыккан шигырьләрен укып чыктым. Мусаның Моабит төрмәсендә язылган шигырьләре беренче мәртәбә басылуы иде бу.

Башта үз күземә үзем ышанмадым—шул Мусамы икән соң ул? Тыйнак, кыюсыз елмая торган студент, шагыйрьне—тәбәнәгрәк буйлы гына гади егетне—Моабит төрмәсендә җәфа чиккән куркусыз көрәшче, Гитлер җәлладлары белән көрәшкә чыккан каһарман образында күрү мине башта икеләндерде дә кебек. Юк, ул шул мин белгән, минем дус, минем бүлмәдәш Муса иде! Йөрәгем чәнчешеп китте...

Соңрак «Советский писатель» нәшриятының СССР халыклары поэзиясе редакциясе миннән Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә язган шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итәргә катнашуымны үтенде.

Аның шигырьләрен тәрҗемә итәргә бик рухланып, зур дулкынлану белән керештем. Үзе инде дөньяда булмаса да, каһарманлыгында, җырларында яшәүче шагыйрь белән кабат очрашу иде бу. Шигырьләренең һәр юлыннан аларның язу өстәле янында түгел, үлем камерасы диварлары эчендә, тоткынлыкта, ерткыч нацизм белән тигезсез көрәш дәвамында, баш өстендә палач балтасын күреп торган килеш язылган булулары сизелеп тора иде.

Шул вакыт мин Мусаның: «Минем шигырьләрне дә тәрҗемә итәрсең әле», дигән сүзләрен хәтерләдем. Һәм мин аның кан белән язылган изге җырларындагы ялкынлы хисләрне, фикерләрне саклау өчен җаным-тәнем белән тырыштым. Алардагы кайнар мәхәббәт, көчле нәфрәт, туган илгә, туган халкына чиксез бирелгәнлек, көрәш рухы мине тирәнтен дулкынландырды.

Әйе, Муса Җәлилнең башын кисәр алдыннан язган шигырьләрен дулкынланмыйча, тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Үлемгә баручы кешенең тормышка мәхәббәте нинди көчле! Аның шигырьләренә, пуля тишеп үткән партбилетка сеңгән кебек, шагыйрьнең кайнар каны сеңгән.

«Аның җырларында кырыс ихтыяр, кеше рухының җиңүе, какшамаслык гимны, күңелнең горур гүзәллеге ташып тора»,—дип язды Муса әсәрләре турында тәнкыйтьче Владимир Огнев [1]...

*
* *

Муса Җәлилнең исемен мәңгеләштерү хакында берничә сүз әйтергә телим.

Әлбәттә, Мусага иң зур һәйкәл—аның әсәрләре. Ул үз поэзиясенең шигъри юлларында бик озак яшәячәк. Аның җырлары гасырлар дәвамында яңадан-яңа укучыларның күңелен баетыр. Муса Җәлил образы Татарстан башкаласындагы һәйкәл бронзасында, аның исемен йөртүче Татар дәүләт опера һәм балет театрында, язучыларның аңа багышланган әсәрләрендә мәңге яшәр. Муса Җәлил исемендәге мәктәпләр, китапханәләр, колхозлар, урамнар, проспектлар, пионер отрядлары һәр вакыт аны искә төшереп торыр. Одесса портыннан чит илләргә йөзә торган зур тоннажлы судно «Муса Җәлил» исемен йөртә. Третьяков галлереясендә художник Харис Якуповның «Хөкем алдыннан» полотносын тамашачылар яратып карый. Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелде, ул Ленин премиясе белән бүләкләнде. Тууына 60 ел тулу уңае белән СССР Элемтә министрлыгы аның рәсеме төшерелгән почта маркасы, конвертлар һәм открыткалар чыгарды һ. б.лар һ. б.лар.

Муса Җәлил исемен чит илләрдә дә яхшы беләләр. Берлин заводларының берсендә иң яхшы бригадага Муса Җәлил исеме бирелгән.

...Мин еш кына элекке Варварка урамындагы (хәзер Разин исемендәге урам) 7 нче йорт яныннан узам. Монда, Мәскәү дәүләт университетының булмыш тулай торагы бинасында студент вакытында шагыйрь, олы җанлы патриот Муса Җәлил яшәгәне турында мемориаль такта куеласын да, әлбәттә, күрергә туры киләчәк әле дип уйлыйм.

Җәлил турында чын-чынлап сәнгатьчә эшләнгән нәфис фильм тудырырга да күптән вакыт инде. Аның гүзәл тормышы, батырлыгы бәя биреп бетергесез тәрбияви әһәмияткә ия булыр иде.

Киң укучылар массасы Җәлил турында торган саен күбрәк белергә тели. Укучыларның бу теләкләрен канәгатьләндерү—язучыларның гына түгел, Оренбургта, Татарстанда, Мәскәүдә шагыйрь белән бергә укыган, бергә эшләгән, фронтта бергә сугышкан, бергә фашист тоткынлыгында булган һәркемнең изге бурычы.

Соңгы минутына кадәр Ватанга, халкына, Коммунистлар партиясенә тугрылыклы булып калган, Туган иленә легенда булып әйләнеп кайткан каһарман шагыйрьнең исеме ил хәтерендә мәңге сакланыр!

# ЯҢА ДОКУМЕНТ РАСЛЫЙ

*Белоруссия Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты каршындагы партия тарихы институты, КПСС Үзәк Комитеты каршында марксизм-ленинизм институтының Белоруссия филиалы, БССР Фәннәр академиясенең тарих институты һәм «Беларусь» нәшрияты «Бөек Ватан сугышы елларында Белоруссиядә бөтен халык партизаннар хәрәкәте» (1942 елның июне-1944 елның июле) дигән өч томлык документлар һәм материаллар җыентыгы бастырып чыгарды. Бу җыентыкның беренче китабында Муса Җәлил җитәкләгән яшерен патриотик оешма эшчәнлеге нәтиҗәсендә партизаннар ягына чыккан «Идел-Урал» легионы батальоны турындагы документ та бар. Түбәндә без шул документны укучыларга тәкъдим итәбез.*

[1] Вл. Огнев. Поэзия һәм заман. «Советский писатель». 1961 ел. 292 бит.

Радом шәһәре тирәсендә һәм Едмино (?) [1] авылында «Идел-Урал» татар легионнары батальонында фашистлар безнең хәрби әсирләр белән 4 ай дәвамында өйрәнүләр оештыралар.

Формирование вакытында аларның партизаннарга каршы сугышка китәргә тиешлекләре билгеле була. 825 нче батальон врачы иптәш Жуков, фельдшер иптәш Таҗиев һәм штаб ротасының хуҗалык взводы командиры Рәхимов личный составның партизаннар ягына чыгуын әзерләү буенча төп җитәкчеләр булалар.

Формирование вакытында, инде ул бетеп килгәндә, барлык личный составка тулысынча немец формасы киендерелә, аннан соң немец анты бирергә мәҗбүр итәләр. Ант кабул иткәннән соң, аларны немец гражданнары итеп исәплиләр. Хәрби әзерлек буенча тактик һәм теоретик занятиеләрне немецлар күзәтүе астында турыдан-туры безнең комсостав уздыра.

Хәрби әсир булган командирдан тыш, һәр ротага, киңәшче сыйфатында, тагын немец та командалык итә. Рота командирының һәр кылган чарасы мәҗбүри тәртиптә киңәшче белән килешеп эшләнергә тиеш була. Ә взводларда хәрби әсир булган взвод командирыннан тыш шулай ук немец вәкилләре күзәтчелек итә. Алар инструкторлар дип йөртеләләр.

Батальон партизаннарга каршы җибәрелер алдыннан Едмино (?) авылына Берлиннан доклад ясар өчен профессор килә. Аның фамилиясе билгесез. Доклад чит телдә ясала. Докладчы легион әсирләрне большевикларны юк итәргә чакыра, Гитлерның «Татар дәүләте» булдыруы, «яңа гүзәл тормыш» тудырачагы турында сөйли.

1943 елның 14 февралендә эшелонга төяләләр һәм партизаннарга каршы көрәшү өчен Витебск шәһәренә җибәрелүләре билгеле була. Витебскига 18 февральдә төнлә килеп җитәләр, вагоннардан төшәләр дә Сураж юлы белән Белыновичи авылына юнәләләр, аннары Көнбатыш Двина елгасының сул ярындагы Гралево авылына борылалар. Көнбатыш Двина елгасы буендагы казаклар частен (номеры билгесез) алыштырып, 1943 елның 21 февралендә оборонага урнашалар. 1943 елның 21 февралендә Бирюлин җитәкчелегендәге партизаннар бригадасы белән элемтәгә керәләр һәм 1943 елның 22 февралендә 23 сәгатьтә партизаннар ягына күчәргә сөйләшәләр. 1943 елның 22 февралендә 22 сәгатьтә штаб ротасы командиры Хәсәен Мөхәммәтовка (1916 елда туган, ВКП(б) членлыгына кандидат, сугышка кадәр кадровый армиядә Көнбатыш Украинадагы Иске Самбар шәһәрендә 579 нчы АБ да кече лейтенант булып хезмәт иткән) безнең якка күчүне оештыручы җитәкчеләр Жуков, Таҗиев һәм Рәхимов иптәшләрнең фашистлар тарафыннан кулга алынуын әйтәләр. Бер минут та кичекмәстән, иптәш Мөхәммәтов партизаннар ягына күчүне җитәкләү инициативасын үз кулына ала. Шунда ук ул үз ротасының взвод командиры Галиев Гаригә немец штабын юк итәргә боерык бирә. Бу боерык үтәлә. Шул ук вакытта башка роталарга да хәбәр ителә. Бары тик 2 нче ротаның еракка урнашкан 2 взводына гына хәбәр җибәрергә мөмкин булмый.

60—70 кешедән торган немец командованиесен юк иткәннән соң, безнең якка күчү башлана. Ул 1943 елның 23 февралендә 14 сәгатькә кадәр бара.

Партизаннар ягына 45 миллиметрлы өч туп, 100 гә якын кул пулеметы, 1 станоклы пулемет, 550 гә якын винтовка, патроннар, атлар һ. б. лар белән 930 кеше күчте. Алар башлыча Захаров һәм Бирюлин бригадаларына бүленде.

*Белоруссия КП(б) Витебск өлкә комитеты җаваплы оештыручысы К. И. Шемялинсның БКП(б) Витебск өлкә комитеты секретаре И. Л. Стуловка «Идел-Урал» татар легионнарындагы 825 нче батальонның 1943 ел, 23 февральдә партизаннар ягына чыгуы турындагы хәбәре (КПБ Үзәк Комитеты каршындагы ПАНИП, 3500 ф., 4 тасвирлама, 16 эш, 221 бит).*

---

[1] Едлнно булырга тиеш. (Ред.)

## Леонид Попов,

якут шагыйре

# Муса Җәлил Якутиядә

Җәлил шигырьләре китабы якут телендә чыгуга багышлана

Үтерделәр сине зинданда,
Ә илеңә кайттың җыр булып.
Батырлыгың җирдә балкыды
Үлемсезлек белән бер булып.
Ә аннары юлың — ил буйлап:
Узып Урал, узып Себерне,
Күрдең килеп ерак якларда
Без «Сайсары» [1] дигән бер җирне.
Урын биреп тайга чатрында
Лена, Вилюй, Алдан ярында
Уранхайлар [2] сине сәламли,
Җырларыңның зурлый барын да.
Коймак каптың, җылы сөт эчтең,
Гәпләшкәндә телләр талмады.
Якын итте сине һәр якут,
Кан кардәш дип әйтми калмады.
Бүгенгегә сокланып карап,
Гасырларның уйлап үткәнен,
Бергә белдек уртак телебез
Үлемсез һәм бөек икәнен...
Безнең бәйрәм — ысыах [3] түрендә
Иң дәү кунак, шагыйрь, син идең.
Син элек тә яхшы биегәнсең,
Бүген исә шәбрәк биедең.
Менеп алдың кыю юргага
Һәм җил булып истең кыр буйлап.
«Сәлам!» дидең безнең кызларга,
Кымыз эчтең яңа җыр уйлап.
Күренеп тора: оста җайдаксың,
Ат холкын син яхшы беләсең!
Безнең сары [4], безнең билбауның
Килешкәнен сиңа күрәмсең?
Өстең-башың нәкъ-нәкъ безнеке,
Әйтерсең лә яшьтән шундый син.
Әйтә төсле якут гүзәле:
«Ничек моңа гашыйк булмыйсың!»
Син кадерле безнең һәр өйдә.
Күңелләрдә якут яктысын —
Яратуны безнең кабул ит,
Мәңге-мәңге моңа хаклы син.
Безнең җирдә урман-тау аша
Син атлыйсың, Муса — ир-егет.
Йөрәгеңдә — көрәш җырлары,
Бирешмәсләр алар бил бөгеп.

**Зәки Нури** тәрҗемәсе.

---

[1] Сайсары — хәзерге Якутск каласы урнашкан тугайлы һәм күлле киң урын.
[2] Уранхай — элекке якутларның үзатамасы.
[3] Ысыах — якутларның язны каршылауга багышланган милли бәйрәме.
[4] Сары — якут итеге.

# ОЗЫН ГОМЕР, БАЙ ТОРМЫШ

Әдәбият галиме һәм педагог Хәй (Габделхәй) ага Хисмәтуллинга 80 яшь тулды.

Озын гомер, бай тормыш юлы... Үткән юллар — озын да, тармаклы да. Хәй ага үзе әйткәнчә: «Менә мин, яшьләр «Хәй абзый» дип йөрткән кеше, дөньяның дулкынын да, тынычлыгын да күрдем, үзем дә шул дулкын эчендә тибрәндем, тынычлыгында ял иттем, тармаклы юлларыннан атладым...»

Хәй аганың эшчәнлеген, аның үткән юлларын тармакка аерып карарга мөмкин. Берсе аның — культура-агарту өлкәсендәге хезмәте. 20 нче елларда бу — наданлыкны бетерү өчен көрәш, авылларда клублар, уку йортлары оештыру, спектакльләр кую, 30 нчы еллар — яңалифкә күчү өчен көрәш, сугыш елларында — Татарстан дәүләт музеенда татар әдәбиятына караган экспозицияләр, күргәзмәләр оештыру...

Икенче тармак — педагогика һәм методика өлкәсендәге эшчәнлеге. Монысы — тагын да баерак, дәвамлырак, нәтиҗәлерәк. Татарстанда Хәй ага Хисмәтуллинны белмәгән, аны ишетмәгән кеше бик аздыр. Хәй ага укыту-тәрбия эшенә күп көч сарыф иткән, бу өлкәдә күп һәм файдалы хезмәтләр калдырган күренекле педагог-тәрбияче. Аның укучылары гаять күп. Берәүләр аңардан төрле чорларда мәдрәсә, мәктәп, рабфак, институтларда турыдан-туры дәрес алса, икенчеләр аның күп санлы дәреслекләрен укып-өйрәнеп тормыш юлына аяк басалар. Хәй ага автор буларак катнашкан «Синтаксис» дәреслегенең 23 тапкыр, «Морфология» дәреслегенең 22 тапкыр басылуын искә алу да күп нәрсә турында сөйли. Хәй ага озак еллар дәвамында әдәбият дәреслекләре язу, хрестоматияләр төзү, башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен программалар, методик кулланмалар төзүдә актив катнашып килә.

Хәй ага Хисмәтуллин эшчәнлегенең өченче тармагы турыдан-туры татар әдәбияты белән бәйләнешле. Мәдрәсәдә укыган елларында ук ул әдәбият белән кызыксына башлый. Хәтта шул чакларда «Вильгельм Телль» исемле пьесаны төрекчәдән тәрҗемә итеп, «Мәгариф» нәшриятына тапшыра. Әмма пьеса басылмый. Беренче басылган әдәби әсәре — «Чик саклаганда» хикәясе. Ул 1925 елны «Безнең юл» журналында «Хисмәт» имзасы белән дөнья күрә. Әйтергә кирәк, бу хикәя аның әдәби иҗат өлкәсендәге соңгы тәҗрибәсе, соңгы талпынуы була. Хикәяче булу теләге шуның белән сүнә, мәгәр аңарда әдәбиятны өйрәнү, тәнкыйтьче булу теләге уяна. Хәй аганы әдәбият дөньясында хаклы рәвештә таныткан өлкә — ул аның татар әдәбияты тарихын, язучыларның иҗатын өйрәнүдәге озак еллардан бирле дәвам итеп килә торган нәтиҗәле эшчәнлеге. Әдәбиятчы галимнең Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан кебек классикларның әсәрләрен текстологик яктан хәзерләп, укучыларга җиткерүгә гаять күп көч куйганын аеруча билгеләп үтәргә кирәктер. Тукай әсәрләрен хәзерләү өстендә генә дә ул 20 елдан артыграк (1933—1955) эшли. 1950—60 нчы елларда ул Каюм Насыйриның һәм Шиһап Мәрҗанинең сайланма әсәрләрен хәзерләүдә катнаша (К. Насыйри әсәрләре 1953 елны басылып чыга), Фатих Сәйфи-Казанлы һәм Гомәр Толымбай әсәрләрен туплап чыгара.

Хәй аганың әдәбият тарихын өйрәнүгә караган хезмәтләре дә шактый. Ул «Борынгы татар әдәбияты» (1963), «XX гасыр башы татар әдәбияты» (1954), «Татар совет әдәбияты тарихы» (1960) кебек коллектив хезмәтләрне язуда катнаша. Аеруча аның Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ф. Кәрими кебек әдипләрнең иҗатын өйрәнүгә шактый өлеш кертүен билгеләп үтәргә кирәк.

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты 1965 елны Хәй аганы зурлап лаеклы ялга озатты. Әмма Хәй ага пенсиягә чыккач та каләмен кулыннан төшермәде. Ул һаман да яза, иҗат итә. «Шиһап Мәрҗани» (1968), «Галиәсгар Камал» (1969) исемле китаплары пенсионер булгач дөнья күрделәр. Ул шулай ук «Фатих Кәрими» дигән хезмәт тә тәмамлады.

Быел, Фәннәр академиясенең 250 еллык юбилеен бәйрәм иткәндә, Тел, әдәбият һәм тарих институтында 25 ел буе фәнни эш алып барган Хәй ага Хисмәтуллинга академик Келдыш имзасы куелган Почет грамотасы тапшырылды. Бу бүләк аны тагын да канатландырып, рухландырып җибәрде. Ул шушы көннәрдә үзенең бай архивын — басылган әсәрләрен, басылмаган кульязмаларын институт архивына тапшырды. «Үткән юллар» исемле автобиографик язмаларын тәмамлады (түбәндә шушы истәлекләрнең берничә бүлеге урнаштырыла).

Хәй аганы олы тормыш бәйрәме белән котлыйбыз, ныклы сәламәтлек, яңа иҗат планнарының тормышка ашуын телибез!

**НИЛ ЮЗИЕВ,**
СССР Фәннәр академиясе
Казан филиалы тел, әдәбият һәм
тарих институтының әдәбият бүлеге
мөдире.

## Хәй Хисмәтуллин

# ҮТКӘН ЮЛЛАР

...Октябрь революциясен мин Казанда каршыладым. Беренче атышкан көн минем кебек өйрәнмәгән кешегә куркыныч булды. Икенче көнне Кабан күле буена чыгып, шәһәр өстеннән снарядлар очканын карап тордык.

Шәһәргә зур зыян килмәде. Кешеләр урамда йөрүдән дә бөтенләй үк туктамадылар. Тик университетның бер колоннасына снаряд төшеп, яртысын җимереп китте.

Октябрьда власть Советлар кулына күчсә дә, 1917—18 елда мәктәп-мәдрәсә эше элеккечә калды. Күрәсең, совет органнары әле мәгариф эшләрен үз кулларына тулысынча алып өлгермәделәр — башка эш һәм көрәш күп иде.

Совет идарә органнары Казанда мәгариф эшләрен яңабаштан кору эшенә 1918 елның җәендә керештеләр. Татар уку йортларын үзгәртеп кору өчен, шәһәр советы каршында Мөселман мәгариф шогъбәсе төзелде. Урта (ул чакта икенче баскыч) мәктәпләргә укытучылар хәзерләү өчен Казанда 6 айлык курслар ачылды. Мин дә шул курсларга укучы булып кердем. Анда төрле фәннәр укыту белән бергә, безне русча да җырларга өйрәтәләр иде. Укытучы безне тезеп куя да:

Во поле березенька стояла,
Во поле кудрявая стояла;
Люли, люли стояла,
Люли, люли стояла,

— дип җырлата һәм «стояла» сүзен әйткәндә тешләрне ике бармак сыярлык итеп ачарга куша, без авызга ике бармак тыгып җырлый идек.

Дөресен әйтим, бәлки минем наданлыктыр, үзем авызны алай зур ачып җырлауны әле дә яратмыйм, Тукай әйтмешли, иреннәрне кәгазь сыярлык итеп җырлау миңа күбрәк ошый.

Курста укыган чакта, мин ни сәбәптәндер авылга кайтып киттем. Шул чакта Казанга чехлар кергәннәр.

Казан чехлар кулында булса да, аларның властьлары төньякка таба 10 чакрым ераклыктагы Киндерле авылыннан уза алмады. Ул чакта Арчада берничә волостьны берләштергән район мәгариф бүлеге бар иде. Бу бүлекнең җитәкчесе өлкән буын большевик Анатолий Машкин, мәктәптән тыш мәгариф эшләренең җитекчесе партиясез педагог Николай Смолин иде. Болар һәр икесе гаҗәп культуралы гуманистлар булып хәтердә калган. Мин чехлар вакытында Казанга бармадым, бәлки шул мәгариф бүлеге җитәкчелегендә авылларда совет мәгарифе урнаштыру, совет мәктәпләре, китапханәләре оештыру эшләре белән шөгыльләндем. Нәкъ шул чакта мәктәпләрне челтәргә кертү дигән бер термин (школьная сеть) туды. Моны әле авыл кешесе белми. Бер көнне авылда кич сәгать 9 да йокларга ятарга әзерләнгәндә ике кеше менеп, мине җыенга чакырдылар. Бардым. Халык шау килә. Алар мәктәпне челтәргә кертүне зур челтәр хәзерләп, шуның белән мәктәпне каплап кую дип аңлаганнар һәм бу күренеш аларның акылларына сыймаган. Аңлаткач тиз төшенделәр. Шул чакта ике мәктәп — берсе ир балалар, берсе кыз балалар өчен — ачарга булдылар. Шул елның көзендә мин Яңа Кенәр авылында беренче тапкыр (бөтен волостька) китапханә ачтым. Бу китапханә «волость китапханәсе» дип атала иде. Әлеге Арчадагы мәгариф бүлеге мине китапханә эшчеләре хәзерләү курсларына җибәрде. Шулай итеп, мин мәктәптән тыш мәгариф эшчесе булып киттем.

1919 елда укый-яза белмәүне бетерү турында хөкүмәт декреты чыкты. Шул уңай белән ликбез пунктлары ачылды. Мин инде бу чакта мәктәп һәм мәктәптән тыш эшләр буенча волостьта мәгариф инструкторы идем. Ликбез мәктәпләре оештыруда актив катнаштым.

1919 елның көзендә мине мәктәптән тыш мәгариф эшчеләре хәзерләү курсларына Казанга җибәрделәр. Бу чакта Казанда тормыш авыр, ашау-эчү бик кысынкы булды. Икмәкне һәртөрле орлык: арыш, бодай, солы, арпа, тагын, белмим, нинди орлыклар кушып тарткан оннан пешерәләр, икмәк кибәкле, күкле-яшелле төстә була. Безгә столовойда ашарга 10 тиенгә талон бирәләр. Кашыкны, тозны да үзең белән алып барасың, чөнки аш тозсыз пешерелә. Икенчесенә солы ярмасыннан пешкән ботка. Солы ярмасын кибәктән әрчү өчен тегермәндә ике кат әйләндереп чыгарырга кирәк. Ә безнең ботканың ярмасы бер генә кат әйләндергән, шуңа күрә яртысы кибәк. һәркем ботканы авызына алып чәйни дә кибәген чыгарып өстәлгә өя, ашаучыларның алдында кечкенә генә солы кибәге өеме кала. Мәктәптән тыш мәгариф эшчеләре курсларында без шулай укыдык. Шул чакта мин беренче тапкыр кулга каләм алып, «Эш» газетасына «Мәктәптән тыш мәгариф эшләре» исемле мәкаләләр бирдем. Мәкаләләр «Укытучы» имзасы белән басылып чыктылар. Курслардан соң Халык мәгарифе институтына укырга кердем. Әмма тәртипле укып булмады. Сәбәбе — һаман шул тормыш кыенлыклары иде. Ул чакта институтларда лекцияләргә йөрү мәҗбүри түгел, укыган өчен акча да (стипендия) бирмиләр. Шулай да мин читтән торып укучы рәвешендә I нче курсны тәгәлләп, II нче курска күчтем, шуннан артык барып булмады. Тагын Яңа Кенәргә кайттым. Мәктәп һәм мәктәптән тыш мәгариф эшләре буенча волость инструкторы итеп билгеләндем.

Шул чакларда без Яңа Кенәрдә беренче сәхнә оештырдык. Ул болай булды: Яңа Кенәр волость идарәсе өчен салынган йортның яртысы олы писарьга квартирага бирелгән иде. Олы писарь күптән урыныннан төшерелгән булса да, ул һаман шунда тора иде. Без бер көнне аны квартирасыннан чыгардык та балта-пычкы белән кирәкмәгән бүлемнәрен кистек, сәхнә ясадык. Арча мәгариф бүлегеннән чаршаулык, төрле буяулар (грим өчен) алып кайттык, менә дигән сәхнә килеп чыкты. Шунда Шамил Усмановның «Канлы көннәрдә», «Беренче адым», Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесаларын куйдык. Халык театрга күп йөрде, артистлар — укытучылар, авыл егетләре исә катнашмыйлар иде.

Яңа Кенәр (Мәмсә) волосте ничектер өч волостьны (Яңа Кишет, Олы Мәңгәр һәм Мәмсә) берләштерә. Өч волость укытучылары айга бер тапкыр Яңа Кенәргә киләләр, Сәмигулла бай йортында җыелыш була иде. Ул чакта әле мөгаллим һәм мөгаллимәләр аерым утыралар. Алар арасы ширма белән бүленгән була иде. Без бер

көнне шул җыелыш алдыннан әлеге ширманы алып куйдык. Өй ике ишекле иде. Бер ишектән мөгаллимнәр, берсеннән мөгаллимәләр керәләр. Без ширманы алып куйган көнне мөгаллимә туташларыбыз үз ишекләреннән керәләр дә, ширма юклыгын күргәч аптырап: «Бәлеш!» — диләр дә урыннарына барып утыралар. Шуның белән мөгаллимәләрнең бездән йөз яшерү мәсьәләсе чишелде, ширма яңадан куелмады.

Кенәр — дүрт мәчетле зур авыл. Дүрт мәчеткә дүрт мәктәп. Нормаль булмаган бу хәлне бетерү өчен, без зур гына итеп салынган почта бинасын мәктәпкә алдык. Почтаны каядыр күчерттек. Сугыш, ачлык еллары нәтиҗәсендә ятим калып сорanып йөрүче балалар күп, шуларны тәэмин итү өчен бер байның йортын алып балалар йорты оештырдык. Балалар бакчасы да төзелде. Гомумән, Мәмсә волостенда өч урында балалар йортлары ачылды. Кантон мәгариф бүлеге кушуы буенча һәрбер балалар йортына 50 шәр бала, шуларны карау, ашату кебек эшләр өчен 5 әр кешелек штат бирелә иде. Бу балалар йортларында тәрбия эшләрен алып баручылар да — укытучылар. Гомумән, бу елларда укытучылар, эшләгән өчен акча-фәлән бетенләй диярлек түләнмәсә дә, зур дәрт һәм энтузиазм белән эшләделәр, һичбер авырлыктан курыкмадылар, читенсенмәделәр. Моның сәбәбе нәрсә? Сәбәбе — ирексезлектән, ябылып ятудан туйган яшьләргә революция биргән ирек иде. Бу хәл бер бездә генә түгел, барлык волостьларда шулай баргандыр, шуның белән авылларда советчылык идеясе таралуга, иске, йомык тормышның әкренләп бетә баруына юл сызылды.

Әгәр материаль тормыш кыенлыкларын исәпкә алмасаң, Кенәрдә тормыш күңелле иде.

Кенәрдә мәгариф эшчеләре коллективы зур, үзара дус яши идек, халык арасында да авторитет күтәренке, үзебез кирәк тапкан чараларны үткәрә ала идек. Без Кенәрдә танца түгәрәге оештырдык. Үзара җыелышып, арыш оныннан чумар пешереп булса да, бергәләп, күңелле итеп утырыша идек. Яшь чаклар!

...Арчада укытучыларның профсоюз җитәкчесе булып эшләгән чакта без укытучыларның политик хәзерлекләрен дә тикшереп йөрдек. Бу яктан эшләр шәп түгел иде. Мәсәлән, бер авыл укытучысыннан СССРда дәүләт идарәсе системасын сораган идек, җавап бирә алмый аптырап калды. Аннары сүзне кантонга күчердек, кантонда властьның кем, нинди учреждение кулында булуын сорадык. Ул уйлап торды да: «Ибраһим абзый Якупов кулында булырга кирәк», — дип җавап бирде. Моның хикмәте шунда иде: Ибраһим Якупов элекке учитель, бу чакта кино мөдире урынбасары. Ул элек-электән дисциплинага өйрәнгән кеше. Арчада дүшәмбе көн базар була, шунда базарга килгән укытучыларны: «Ник мәктәбегезне ташлап йөрисез?!» — дип куа иде. Шуннан безнең әлеге укытучыбыз да куркып калган һәм Арчада власть шул Ибраһим Якупов кулындадыр дип уйлаган. Тикшерү вакытында мондый кызыклар аз булмады, әмма алыштырырга мөмкин түгел, кадрлар юк. Аеруча кыенлык мәктәптән тыш мәгариф эшчеләре: китапханәчеләр, избачлар, клуб мөдирләре тирәсендә туа иде. Бу группа эшчеләрнең белем дәрәҗәләре аеруча түбән, шуңа күрә алар бик еш алыштырылалар, ә профсоюз бу мәсьәләгә катнашмый кала алмый.

Арчада эшләгәндә күп төрле конференцияләр, съездлар, җыелышлар үткәрелде. Шулар арасында иң зур хәзерлек белән үткәне кантондагы барлык укытучыларның съезды булды. Бу съезд партия Үзәк Комитеты карары нигезендә чакырылачак Беренче бөтенсоюз укытучылар съездына делегат сайлау өчен 1924 елның кышында җыелды.

1925 елның 1 апрелендә мине Казанга күчерделәр. Мин Казанда татар балалар шәһәрчегендә укыту-тәрбия бүлеге мөдире, Арча кыры районында мәгариф эшчеләре месткомы председателе, өлкә мәгариф эшчеләре союзы правлениесе члены, татар телен эшкә чыгару (РТЯ) курсларында укытучы булдым. 1926 елда Бөтенсоюз мәгариф эшчеләре съездында катнаштым. Съездда Луначарский, Украина мәгариф комиссары Рьяппо, Татарстан мәгариф комиссары Ш. Әхмәдиев иптәшләрнең докладлары булды. Без Шәһит Әхмәдиев белән бергә бер гостиницада яшәдек. Шәһит Әхмәдиев гаҗәп ягымлы, гади, югары культуралы кеше иде.

Казанга килеп урнашкач, миңа Казанның галимнәре, укымышлылары, театрлары белән якыннан танышырга, әдәбият дөньясына да якынлашырга киң юл ачылды. Казанга килеп урнашуның беренче елында ук РТЯ курсларының укыту бүлеге мөдире, гаять яхшы педагог һәм организатор Фазылҗан Хәмидуллин (хәзер пенсионер) һәм

башка укытучылар, ул чакта мәгариф эшчеләре өлкә союзының культура бүлеге мөдире, гаҗәп ягымлы һәм культуралы иптәш Удалов һ. б. белән якынлаштым. Казанда башланып та, өзелеп калган язу эшләре дә әкренләп кузгала башлады. «Безнең юл» журналында бер хикәя, соңрак «Мәгариф» журналында мәкаләләр чыга башлады. 1925—26 елларда инде татар язуын латин нигезендәге яңалифкә күчерү турында көчле бәхәс кузгалган иде. «Яңалиф» җәмгыяте төзелде, «Яңалиф» исемле журнал чыга башлады. Мин дә шул яңалифләшү хәрәкәтенә актив катнашып киттем.

Укыту эшләрен яңалифкә иң элек күчерүче безнең 18 нче номерлы мәктәп булды. Моның кайбер объектив җиңеллеге шул: аның укучыларының зур күпчелеге татар балалар шәһәрчегеннән булганга, ата-аналар арасында бу мәсьәлә буенча барган бәхәс балаларга тәэсир итми, алар барысы да безнең карауда иделәр.

18 нче мәктәп тәҗрибәсен популярлаштыру йөзеннән, Наркомпрос миңа авыл мәктәпләре өчен бер табак методик хат язарга кушты. Хат брошюра булып басылып, мәктәпләргә таратылды. 1928/29 уку елы өчен без, педагог Шакир Нигъмәтуллин белән бергә, яңалиф хәрефләре белән басылган тел дәреслекләре чыгардык. Гаяз Байкиевның «Обществоведение» буенча V класслар өчен төзегән дәреслеген дә мин яңалифкә күчереп бастырдым. 1932 елда профессор М. Фазлуллин белән бергә яңалифне олы яшьтәге кешеләргә өйрәтү өчен дәреслек-кулланма төзедек.

1929 елның көзендә мин 18 нче мәктәптән китеп, рабфакка күчтем. Шул көрдән 10 ел (рабфак ябылганчы) укыттым. Рабфакны мин әле дә бик сагынам. Андагы үзләре теләп укырга килгән эшче-крестьян яшьләре белән эшләү сагындыра. Хәзер инде олы яшьле кешеләр, хәтта пенсионерлар минем белән: «Мин сезнең шәкертегез!» — дип килеп күрешәләр, ә мин шатмын.

1929 елны Наркомпрос мине пединститутка белем күтәрү өчен җибәрде. Тел-әдәбият дөньясына ныклап кереп китүем нәкъ шул елдан башлана. Пединститутта мин әдәбият һәм тел галимнәре Габдрахман Сәгъди, Галимҗан Нигъмәти, Гали Рәхим, Җәмал Вәлиди, Галимҗан Шәрәф, Г. Толымбай, шулар аркылы Сәлах Атнагулов, Фатих Сәйфи, Гомәр Гали һ. б. белән таныштым.

Габдрахман Сәгъди әдәбият дөньясына күптән, 1908 еллардан ук килгән кеше. Аның белеме нигезендә Көнчыгыш (иран, гарәп, төрек) әдәбиятчылары концепциясе ята. Ләкин без укыган чакта ул аны рус һәм көнбатыш әдәбият белеме белән тулыландырган иде. Үзенең әдәби-тарихи-политик карашларында Галимҗан Ибраһимовка нык таяна иде.

Габдрахман Сәгъди үзен эре тота, ә Галимҗан Нигъмәти гади, садә кеше. Без соңрак, 1932—33 елларда аның белән бергәләп әдәбият тарихы да яза башлаган идек. Мин Закир Һади, Сәгыйт Рәмиев, Мәҗит Гафури турында язган идем. М. Гафури турында язганым Мәҗит аганың 1932 елда чыккан сайланма әсәрләре өчен сүз башында файдаланылды. З. Һади турында язганым югалды, С. Рәмиев турында язылганын институт архивына тапшырдым. Ник без моны төгәлли алмадык? — белмим.

Пединститутта фольклорны безгә Гали Рәхим укыта иде. Бераз чатанлап йөрүче, ләкин гаҗәп пөхтә киенә торган бу укытучы фольклор материалын җыюга зур әһәмият бирә, һәр лекциясендә укучыларга кәгазьләр өләшә һәм үзләре белгән җыр, бәет, мәкаль һ. б. язып килүне үтенә иде. Институтта укытканда илнең төрле почмагыннан килгән укучылардан ул күп кенә материал туплады.

Фәнни грамматиканы без Җәмал Вәлидидән укыдык. Җәмал Вәлиди — 1908 еллар тирәсендә матбугат дөньясына килгән кеше. Ул күп еллар «Вакыт» газетасы редакциясендә эшләде. 1917 елның октябрендә (Ф. Кәрими «Вакыт»тан киткәч) аның җаваплы редакторы булды, Оренбургта Халык мәгарифе институты ачылгач (1919 елдан соң), шунда укытты, аннан Казанга килде. Җәмал Вәлиди — Тукайның беренче биографы һәм аның әсәрләренең шактый тулы җыентыгын беренче чыгаручы (1914 елда), 1913—14 елда Г. Тукайны «халык шагыйре» дип бәяләүче өч кешенең берсе (калган икесе — Фатих Әмирхан белән Фатих Кәрими). Җ. Вәлиди — тел галиме генә түгел, аның әдәбиятка бәйләнешле хезмәтләре дә шактый.

Фонетика буенча лекцияләрне мәшһүр тюрколог профессор Богородицкий шәкерте Галимҗан Шәрәф укый иде. Шулай итеп, бу елларда пединституттагы тел-әдәбият кафедрасы тирәсенә татарның иң танылган кешеләре туплапдылар, без шулардан дәрес алдык.

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре кандидаты

# ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ СӘНГАТЬ һӘМ АНЫҢ СОЦИАЛЬ РОЛЕ ТУРЫНДА

Татар мәгърифәтчеләре сәнгать мәсьәләләренә багышлап язылган махсус хезмәтләр калдырмаганнар. Ул мәсьәләләргә алар дөньяны танып белүнең башка өлкәләренә караган әсәрләрендә кагылып үтәләр. Бу әсәрләрдә без мәгърифәтче галимнәрнең сәнгатькә, аның җәмгыять тормышында тоткан роленә, гүзәллекнең асыл табигатенә карата булган бик күп фикерләрен очратабыз.

Башка өлкәләрдәге кебек үк, сәнгать һәм эстетика мәсьәләләрендә дә татар мәгърифәтчеләренең карашлары ислам дине тәгълиматына, дини торгынлыкка каршы көрәштә формалаша һәм ныгый. Мөселман диненең сәнгатьне, эстетик фикер үсешен гасырлар буенча тоткарлап килүе һәркемгә мәгълүм. Руханилар театр һәм музыкага каршы даими көрәш алып баралар, скульптура һәм сынлы сәнгатьне катгый рәвештә тыеп, җыр-бию кебек нәрсәләрне зур гөнаһ дип күрсәтеп киләләр.

Нинди генә сәнгать әсәре булмасын, мөселман руханилары аларның һәркайсында бозыклык һәм әшәкелек күрәләр, сәнгать әсәрләрен таратуны әхлакый бозыклык чыганагы дип саныйлар, бу юнәлештәге теләсә нинди башлангычка каршы чыгалар. «Безнең тәрәккъыять заманында,— дип яза Петербург имамы Г. Баязитов,— нәфис аздыру вә тән мәхәббәтенә җирлекне киңәйтүгә омтылышны һәркайда очратасың. Сынлы сәнгать үз сюжетларына сылу кызларның баштанаяк шәрә гәүдәләрен, аларның хыял җитмәс аздыргыч позаларын сайлап ала; скульптура һәм башка сәнгатьләр дә шул ук эздән атлыйлар, тормышның үзендә дә, хыял вә теориядә дә шушы идея кешеләрнең күзләрен томдырган. Хәтта әдәбиятта да порнография хакимлек итә. Бу шартларда аларга мөрәҗәгать итеп, рух вә әхлак тәрбиясе чараларын без булмаган җирдән эзләмибезме икән» [1].

Мәгърифәтчеләр сәнгатькә мондый карашны кискен рәвештә кире кактылар. Сәнагыы нәфисәне дини фанатикларның һөҗүменнән, беренче булып, Шиһаб Мәрҗани яклап чыга. Ул, музыкада да, сәнгатьнең башка төрләрендә дә гаепкә алырлык берни юклыгын исбат итеп, болай дип яза:

«Кеше хуш, үлчәүгә салынган, мәгънәле, күңелләрне хәрәкәткә китерә торган көйне тыңлый. Сандугач һәм башка кошларның тавышын тыңлау тыелмаган. Тавышта (көйдә) асыл — хайваннарның тамакларыннан чыккан авазлар; уен кораллары башлап шуңа ияртелгәннәр. Беренче үрнәкләре... табигатьтә иҗат ителгән нәрсәләргә таянган һөнәрнең һичбер куркынычы юк. Бер тамак белән икенче тамак арасында, җансыз җисемнәр белән хайваннар арасында (бу мәсьәләдә) һичбер аерма юк. Кереше һәм дәвамы үзара яраша торган, үлчәүгә салынган хуш авазларны хәрам дип әйтү гаҗәп. Әгәр бер төрле дә мәгънәсе булмаган тавышларны тыңлау дөрес була икән, хикмәт

[1] А. Баязитов. Отношение ислама к науке и к иноверцам. Рус телендә. СПБ. 1887 ел. 74—75 битләр.

һәм дөрес мәгънә бирә торган тавышларны тыңлау ник дөрес булмасын? Шулай булгач, кеше кулы белән ясалган төрле инструментлардан чыккан, шулай ук тамактан килгән хуш авазларны тыңлау да дөрес булырга тиеш... Бүтән сизү әгъзалары аркылы алына торган ләззәтләр кебек, тыңлау ярдәмендә алына торган ләззәт тә үзенә махсус бер ләззәт була» [1].

Ш. Мәрҗани фикеренчә, сәнгать ләззәте кешеләрдә яшәү көчен арттыра. Эстетик ләззәткә омтылу — кешенең табигатенә хас сыйфат. Сәнгатьнең теләсә кайсы төрендәге чын әсәр кешеләрдә файдалы, уңай тойгылар уята. Язгы табигать һәм чәчәкләр, музыка һәм аның тавышлары белән ләззәтләнә белми торган кешене нормаль зат дип булмый, ди Ш. Мәрҗани. Андый кешенең табигате дәвалап булмаслык дәрәҗәдә бозылган була. К. Насыйри да шул ук фикерне куәтли: «Бер кемсәнең яз фасылында әнваг гөлләр ачылганда вә әнваг нәгъмәләр вә сазлар чыңлаганда күңеле хәрәкәткә килеп кузгалмаса, ул кешенең мәзаҗы бозыктыр, аңа гыйлаҗ юктыр; мондый кеше телебездә мүкле йөрәк диләр» [2]. Димәк, музыка ләззәте, табигать ямьенә соклану хисе кебек үк, нормаль кешенең нормаль ихтыяҗы булып чыга. Бәс шулай икән, эстетик ихтыяҗларны канәгатьләндергән чаралардан җыр, музыка, рәсем сәнгате һ. б. ларны тыю бернигә дә нигезләнмәгән.

Әдәби иҗат белән шөгыльләнү һәм сәнгать әсәрләреннән ләззәтләнүнең хак эш булуын исбатлау өчен Ш. Мәрҗани хәтта илаһи чыганакларны да ярдәмгә чакыра, борынгы заман авторитетларының фикерләренә таяна, мөселман цивилизациясе үзәкләреннән Багдад һәм Әндәлүс хәлифәтләрен мисалга китерә. Коръәндә булсын, хәдисләрдә булсын, җырны яки музыканы турыдан-туры тыйган сүзләрне таба алмыйбыз, ди ул. Ә мөселманнарның боларны гөнаһлы дип уйлавы — фанатик дин әһелләренең уйдырмасы нәтиҗәсендә килеп чыккан бер ялгышлык кына. Мөселман дөньясының әл-Фәраби һәм Әбугалисина кебек иң күренекле галимнәре музыканы, җырны һич тә яманламыйлар, ә, киресенчә, аларның кешеләр өчен кирәкле нәрсә икәнлегенә басым ясыйлар. Шәрыкта мөселман дәүләтләре чәчәк аткан чорда анда сәнгать тә торгынлык кичермәгән, музыка һәм матур әдәбият исә аеруча гөрләп үскәннәр. «Ислам килеп гарәпләр гаҗәм [3] солтаннарын җиңгәч, фарсы һәм румнар кулында булган җырчылар гарәпләр кулына керделәр... Бу һөнәр күтәрелүендә дәвам итте һәм Габбасилар хәлифәлеге чорында Ибраһим бине Мәһди, Ибраһим Мусыли, аның улы Исхак, аның улы Хаммат тарафыннан камилләштерелде. Алар нечкә мотивлар, яңа кораллар уйлап чыгардылар, боларны Багдад һәм Гыйракның башка шәһәрләренә тараттылар... Зирияб исемле җырчы-уенчы көнбатышка, Әндәлүскә китте. Андагы гарәп-мөселман падиша бу сәяхәтчене кырга чыгып каршы алды, җир-имение һәм бүтән байлыклар бирде... Бу Зирияб биш кыллы яңа уен коралы уйлап чыгарды» [4].

Ш. Мәрҗани мөселманнар арасында сәнгатьнең кайбер төрләрен инкарь итүгә китергән сәбәпләрне дә ача. Ислам туып килгән чорда, ди ул, гарәпләр потларга (таш сын) табына торган булганнар. Шушы мәҗүсилек гадәтен тамырыннан корыту өчен Мөхәммәт җан ияләренең рәсемнәрен ясау һәм таратуны тыйган. Ислам диненең беренче чорында урнаштырылган бу тәртипне диндар тәгълиматчылар соңыннан дини канун дәрәҗәсенә күтәргәннәр. Димәк ки, скульптура һәм сынлы сәнгать, дин әһелләре исбат итәргә тырышканча, һич тә алла кушуы буенча түгел, ә дөньяви максатлардан, үз заманының идеологик көрәш ихтыяҗларыннан чыгып тыелган. Шулай булгач, скульптура, сынлы сәнгать әсәрләрен һәм кеше сурәтен иҗат итүдә дә, аларны таратуда да хәзер бернинди гөнаһ юк. Мәккә шәһәренә сәяхәте вакытында Төркия мәгариф министры кабинетында күргән антик статуя хакында Ш. Мәрҗани сокланып сөйли. Ул үзе, замандашларының фикере белән исәпләшеп тормыйча, кат-кат фотоларга төшә, шуның белән башкаларга да үрнәк күрсәтә.

Мәгърифәтчеләр сәнгатьне динчеләр һөҗүменнән яклау белән генә чикләнмиләр, ә аның җәмгыять тормышында әһәмиятле урын тотуын да исбат итәләр. Алар күзаллавынча, сәнгать күңел ачу, кәеф-сафа кору чарасы гына түгел, ә кешеләрнең рухи дөньясына тәэсир итү коралы. Ул, үзенә хас чаралар белән, кешенең гакылына һәм

[1] Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, ф. 22, тасвирлама 1, саклау берәмлеге — 20, 80—81 битләр.
[2] К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса. Казан, 1884 ел, 443 бит.
[3] Гаҗәм гарәптән башка халыклар.
[4] Ш. Мәрҗани. Казан, 1968 ел, 26 бит. (Хәзерге заман музыка белгечләре исбат итүенчә, биш кыллы уен коралы (лютня) шәрыктә Зириябтан бик күп элегрәк тә кулланылган.— Авт.)

әхлагына уңай йогынты ясый, кешенең аң үсешен тизләтә, рухи дөньясын баета. Шуңа күрә дә, дип саный Ш. Мәрҗани, чын сәнгатьнең порнография белән, азгын хисләрне кабарту белән бернинди дә уртаклыгы юк. Музыканы да, җырны да тыелган уеннар, исерткеч эчемлекләр, кешене кимсетә торган башка нәрсәләр белән катнаштырырга ярамый, ди мәгърифәтче [1]. Шушы ук фикерне К. Насыйри да куәтли.

Мәгърифәтчеләр фикеренчә, әдәбият һәм сәнгатьнең мөһим бурычы — халыкның узаңын уяту, гуманизм, патриотизм, гражданлык хисләре тәрбияләү, мәгърифәтчелек, яңарыш һәм азатлык идеяләрен пропагандалау, урта гасырчылык, патриархальлек күренешләрен фаш итү. М. Акмулла, М. Акъегет-Задә, З. Бигиев, Г. Ильяси, Ф. Халиди кебек мәгърифәтче язучыларның әсәрләре нәкъ менә шундый идеяләр белән сугарылган. Мәгърифәтчелек әдәбиятының каһарманнары Хисаметдин менла, Гайса Зурколаков, Әбүзәр-бәк, Морат Сәлимов һәм башкалар мәгариф һәм прогрессны кайгыртучылар, үз халкын хәерчелек һәм торгынлыктан коткару теләге белән янып яшәүчеләр итеп сурәтләнәләр.

Эстетика проблемаларын тикшергәндә, мәгърифәтчеләр сәнгатьчә иҗатның җанлы тәҗрибәсенә таяналар. Әмма алар яшәгән чорда бу тәҗрибә татарларда шактый чикләнгән була. Динчеләрнең тыюы аркасында, милли театр, профессиональ музыка, рәсем сәнгате һәм скульптура бөтенләй булмый. Әмма, шул ук вакытта, халык авыз иҗаты, музыкаль фольклор, кәнкүреш һәм төзелеш сәнгате бай эчтәлекле булулары белән аерылып торганнар. Шигъри иҗатта исә мең ел буена тупланган тәҗрибә бар иде. Шулар өстәвенә, татар мәгърифәтчеләре руслар аша сынлы сәнгать белән дә таныша, ә кайберләре исә, Мәккәгә сәяхәт иткәндә, антик сәнгатьнең күп кенә үрнәкләре белән дә очрашалар. Эстетика мәсьәләләрен тикшергәндә, мәгърифәтчеләр менә шул тәҗрибәгә таяналар һәм әсәрләрендә сәнгатьнең, башлыча, поэзия, музыка, скульптура кебек жанрларына мөрәҗәгать итәләр. Скульптура хакында сүз алып барганда алар, әйтик, дин әһелләренең аңа карата кире мөнәсәбәтләрен тәнкыйтьләү, скульптура сыннарын иҗат итү һәм таратуның хак эш булуын дәлилләү белән чикләнсәләр, поэзия һәм музыка мәсьәләләренә исә шактый киңрәк тукталалар.

Поэзиягә Ш. Мәрҗани, мәсәлән, кеше табигате белән яраша, гармонияләшә торган сәнгать дип карый. Шигърият кешеләрнең психик хәлен, кичерешләрен, теләкомтылышларын тирәнтен ача, үзендә гомумкешелекнең танып белү һәм хәрәкәт итү тәҗрибәсен туплый, ди ул. Шуңа күрә дә поэзия кешеләрнең эшчәнлегенә, ул эшчәнлекнең характеры һәм юнәлешенә гаять зур тәэсир ясый. «Сөйләмнең әйтергә теләгән мәгънәгә уйгын килеп төгәл аңлатылуы, өлешләрнең киселү һәм бүленүдәге ярашуы, ягъни ритм һәм рифмаларның төзеклеге аркасында, — дип яза Ш. Мәрҗани, — шигырь кеше табигатенә хуш килә. Шуңа күрә гарәпләр максудларын шигырь белән аңлатырга яратканнар. Шигырь аларның сөйләмнәрендә иң кадерле урын алып торган. Шигырьне алар үзләренең тарихларын, хөкемнәрен, олылыкларын күрсәтүче мәхкәмә, арбитр, грамматик төзелешнең, стильнең матурлыгын билгеләүдә сынау ташы, үлчәгеч итеп тотканнар» [2].

Бу өзектән шигъриятнең иҗтимагый вазифасына Ш. Мәрҗанинның нинди әһәмият бирүе яхшы аңлашыла. Шуның өстенә, шигъриятнең урыны, роле, аның фикеренчә, кешенең рухи көчләрен арттыруда гына түгел. Бер үк вакытта, ул кешенең акылын, аның зирәклеген һәм тарихи тәҗрибәсен бер төенгә төйни, иҗтимагый тормышның барлык якларын чагылдырырга сәләтле булганга, чынбарлыкка куәтле тәэсир ясый.

«Көйләп укымак яки шигырь әйтмәк гүзәллärдән янә гүзәл нәрсәдер» [3] дип, К. Насыйри да поэзиянең тормыштагы урынын югары бәяли.

Татар мәгърифәтчеләре музыкага да зур әһәмият бирәләр. 1894 ел календаренда К. Насыйри җыр һәм музыканың, туклану, киенү, өйләнешеп яшәү кебек үк, кеше өчен зарури нәрсә икәнен күрсәтә. Икенче бер әсәрендә ул: «Гана (ягъни музыка) әрвахның азыгыдыр... Фәһемне саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, җәбенне баһадирландырыр, саранны юмартландырыр» [4], — дип яза. Музыканың тәэсир көче яу кырында бик ачык күренә. Ул хәлиткеч ми-

---

[1] Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, ф. 22, тасвирлама I, саклау берәмлеге 20, 81 бит.
[2] «Совет әдәбияты» журналы, 1964 ел, 4 сан, 128 бит.
[3] К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953, 46 бит.
[4] К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса. Казан, 1884, 442 бит.

нутта батырга куәт өстәсә, өркәк җанга рух ныклыгы бирә, кешене сугышчан батырлыкларга күтәрә. Музыка шулай ук тән һәм җан сырхавына да дәва була ала. Борынгы греклар ук инде каты авыру кешенең күңелен матур көй белән күтәрә торган булганнар һәм әйткәннәр: «Бераүгә хәсрәт вә көенеч ирешсә, сауте хәсәнәне истимаг кылсын, зирә нәфес көенсә, уты кабарыр, серур вә шатлык бирә торган хуш авазларны ишетсә, нәфеснең уты сүнәр»[1].

Ш. Мәрҗани да шул ук фикерне раслый. Көйләр, ди ул, җанны тынычлыкка өндиләр, сафлык һәм тугрылык дөньясына алып китәләр. Музыка кешене шатландыра, актив эшчәнлеккә чакыра, көләргә һәм биергә мәҗбүр итә. Кыскасы, музыка кешене төрле яхшы эшләргә рухландыра. Музыка тәэсирендә хәтта бишектәге бала да елавыннан туктый, чүлдә баручы дөя ачлыгын һәм сусавын оныта, адымын тизләтә.

Татар мәгърифәтчеләре музыка теориясе һәм тарихы буенча да мөһим фикерләр әйткәннәр. Шәрыктән килгән традиция йогынтысы астында, Ш. Мәрҗани да, К. Насыйри да музыканы математика фәннәре төренә кертәләр. Ш. Мәрҗани музыка гыйльмен «тавыш һәм мотивларны бер-берсе белән чагыштырып, аларны сан белән үлчи белү», дип билгели. Композицияне «ягымлы рәвештә тәртипләнгән югары һәм түбән тоннарның бер бөтен хасил итүе», дип атый[2]. Музыка тарихы турында сөйләгәндә, ул музыканың теоретик нигезләрен тикшерүгә Пифагор, Аристотель, әл-Фараби, Әбугалисина кебек галимнәрнең зур өлеш кертүләрен әйтә.

Табигать һәм җәмгыять күренешләрен аңлатуда стихияле материалистик позициядә торулары мәгърифәтчеләрнең сәнгать һәм чынбарлыкның үзара мөнәсәбәте мәсьәләсен ничек хәл итүләрендә дә чагыла. Алар фикеренчә, әдәбият-сәнгать әсәренең нигезендә табигый чынбарлык һәм иҗтимагый тормыш ята. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, гарәп поэзиясе гарәпләрнең яшәешен һәм тарихын чагылдыра, дип раслый. «Шигырь ул — гарәпләрнең диваны. Анда аларның гыйлемнәре, хәбәрләре, фәлсәфәләре тупланган, шигырь аларның олылык, юмартлыкларының, турылык һәм хаталарының шаһите»[3].

Сәнгатьнең асылын материалистик аңлаулары мәгърифәтчеләрнең гүзәллек проблемасын ничек чишүләрендә дә күренә. Алар биредә Н. Г. Чернышевский торган позициягә якын киләләр һәм гүзәллек чыганагын чынбарлыкның үзендә күрәләр. Шуның белән мәгърифәтчеләр суфичылык йогынтысы астында киң таралган карашлардан арынуга таба кыю адым ясыйлар. Суфичылыкның гүзәллек идеалы бары тик аллаһ тәгалә белән генә бәйләнгән булса, ә эстетик илһам чыганагын ул фәрештәләр, оҗмах кызларында гына күрсә, мәгърифәтчеләр исә кешеләр игътибарын матурлыкны җир өстендә, реаль тормыштан эзләүгә юнәлдерәләр. Эстетик ләззәт һәм илһам да бары тормышта гына табыла. «Хәкимнәр димешләрдер ки, агар суга карамак, яшел үләннәргә карамак, матур вә күркәм йөзгә карамак күзнең нурын вә гакылны арттырыр[4],— дип яза К. Насыйри. Аның фикеренчә, чын ләззәтне чынбарлык кына бирә ала, чынбарлыктагы матурлык — эстетик ихтыяҗларны канәгатьләндерә торган иң ышанычлы чыганак.

Җир йөзендәге иң гүзәл зат — ул кеше, дип исәплиләр мәгърифәтчеләр. Татар әдәбиятында мондый караш Г. Кандалый иҗатында ук ачык чагылыш таба. Ул суфичылык традициясен катгый кире кагып, гап-гади җир кызларын мактый. Гүзәллекнең объектив табигатен шагыйрь яхшы аңлый.

XIX гасырның икенче яртысында барлыкка килгән мәгърифәтчелек әдәбиятында бу тенденция яңа үсеш ала. Г. Кандалый шигырьләрендә әле беренче планда кешенең тышкы матурлыгы һәм күркәмлеге тора. Шагыйрь татар кызының акылын, эчке байлыгын, әхлакый сыйфатларын мактаса да, алары әле арткы пландарак тасвирлана. Соңгырак чорда иҗат иткән мәгърифәтче язучылар исә кешенең тышкы һәм эчке матурлыгын аерылгысыз бердәмлектә карыйлар. Гүзәл кеше — тышкы кыяфәте белән генә түгел, рухи дөньясы, акыл-зиһене, аң-белеме һәм әхлакый сыйфатлары белән матур. Болар — кешене бизи торган хәлиткеч сыйфатлар. Беренче татар романисты М. Акъегет-Задә гүзәллек идеясен нәкъ шулай аңлый. «Хисаметдин менла» романы-

---

[1] К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953, 393 бит.

[2] Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, ф. 22, тасвирлама 1, саклау берәмлеге 20, 76—77 битләр.

[3] Шунда ук, 51 бит.

[4] К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса. 446 бит.

ның героинясы Хәнифә баш геройның мәхәббәт хатына җавабында болай яза: «Куәтле вә мөхкәм гыйшык бер-беремезнең тыш вә зәһири күренешләребезне белмәклә хосулә кәлмәз. Сез зәһиремне яраттыгыз, бәлки, бән батиндә яманмын? Бәлки әхлаксызмын? Куәтле гыйшык икемезнең дә әхлак вә табигатемез беленгәч вөҗүдә кәлер» [1]. Хисаметдин менла исә Хәнифәгә, синең укымышлылыгың миңа мәгълүм, ә укымышлы һәм интеллигентлы кеше әхлаксыз була алмый, дип җавап бирә. Шулай итеп, әсәр авторы фикеренчә, гүзәллек идеясе, кешенең эчке һәм тышкы матурлыгын, эстетик һәм этик идеалларын бергә берләштерә. Кеше матурлыгын шушы рәвешчә аңлау бөтен татар мәгърифәтчелек әдәбиятына хас күренеш. М. Акъегет-Задә, З. Бигиев, Г. Ильяси, Ф. Халиди һ. б. ларның әсәрләрендәге геройлар үзләрендә һәм тышкы, һәм эчке рухи матурлык сыйфатларын туплаган шәхесләр булып гәүдәләнәләр.

Сәнгать әсәрләрендә эчтәлек һәм форманың үзара мөнәсәбәте мәсьәләсен дә мәгърифәтчеләр материалистик позициядән торып хәл итәләр. К. Насыйри фикеренчә, җыр, сәнгать әсәре буларак, менә нинди таләпләргә җавап бирергә тиеш: «Гананың лязим шартлары өчтер: әүвәл сазында гүзәл булсын, шигыре вә сүз татлы булсын, хуш холыклы вә фигыльле булсын вә янә мөганни белән тыңлаучы якын вә каракаршы булсын, шигырьләрнең әлфазы гариб вә гаҗәеп вә мәгънәләре ләтыйф булсын» [2]. Сәнгатьнең тулы канлы вә камил булуы өчен, димәк, форма нәфислегеннән тыш тирән мәгънәле, «хуш холыклы вә фигыльле» эчтәлек кирәк. Эчтәлек һәм форма, идеялелек һәм сәнгатьчәлек аерылгысыз бер бөтен тәшкил итәләр һәм менә шушы сыйфат сәнгать әсәрен максатка ярашлы итә дә.

Бу җәһәттән, Ш. Мәрҗани фикерләре дә кызыклы. Теләсә нинди китап, теләсә нинди хикәяне укыганда да, ди ул, өстән-өстән генә танышу файдасыз, әсәрнең мәгънә юнәлешенә, идея эчтәлегенә төшенү мөһим. Сәнгать әсәре өчен алар иң әһәмиятлесе. Шул ук вакытта әсәрнең идея эчтәлеген мәгълүм бер форма гына илтеп җиткерергә сәләтле була. Ш. Мәрҗани сәнгать әсәрендә форманы нәрсә тәшкил итүен һәм аның тәэсир итү көчен дә ачарга тырыша. Аның әйтүенчә, рәсем сәнгате һәм скульптура әсәрләренең «...рәсемнәре, сызыклары төгәл һәм үзара ярашучан булсалар, күркәм һәм матур күренәләр, андый нәрсәләрне күрүдән җан рәхәтләнә», музыкада «көйнең матурлыгы түбән һәм югары, йомшак һәм каты, тирбәнүчән һәм кысылучан һ. б. тоннар арасындагы ярашучанлык һәм уйгынлыклар, тавышларның яртысын, өчтән, дүрттән, биштән берен һ. б. тәртипле төзү, бер тавыштан икенчесенә күчүдә, тавышларны кайтарып алуда, тәртип һәм эзлеклелекне саклау аркасында була» [3]. Сәнгать әсәрен шушы сыйфатлар югарыга күтәрә, андый әсәр эстетик ләззәт алып килә, гакылны баета. Рәсем сәнгатендәге билгеле бер тәртипкә китерелмәгән сызык һәм төсләр, музыкадагы үзара ярашмаучы тоннар һәм авазлар бернинди дә мәгънә тудыра алмыйлар. Гакыл һәм хисләргә алар канат бирмиләр генә түгел, хәтта тискәре тойгылар да уяталар. Бәс шулай икән, сәнгать әсәрендә эчтәлек үзенә муафыйк һәм җанга ятышлы формага төренгән булырга тиеш.

Татар мәгърифәтчеләре үз эпохаларының эстетик фикер дәрәҗәсен алга үстерерлек идеяләрне дөньякүләм масштабта күтәреп чыкмыйлар. Алар яшәгән тарихи шартларда моның өчен объектив шартлар да булмый. Тарихи барышка алар керткән өлешне бу юнәлештән эзләү дөрес тә булмас иде. Реакцион мөселман дине хөкем сөргән бер чорда татар мәгърифәтчеләре сәнгатькә хокук яулап, динчеләрнең позицияләрен фаш итеп чыгалар, шуның белән кара көчләр тарафыннан сәнгать төрләре алдында куелган киртәләрне җимерүгә ярдәм итәләр. Татар эстетик фикере тарихында аларның урыны әнә шуның белән билгеләнә дә. Мәгърифәтчеләр татар иҗтимагый фикере тарихында беренче булып материалистик сәнгать теориясенә нигез салалар, сәнгатьнең иҗтимагый роле, сәнгать һәм чынбарлыкның үзара мөнәсәбәте, гүзәллек төшенчәсе һәм эстетик идеал проблемасы, эчтәлек һәм форма берлеге кебек реалистик сәнгатьнең мөһим принципларын алга сөрәләр. Татар мәгърифәтчеләре тарафыннан үстерелгән эстетик идеяләр мәгърифәтчелек реализмы әдәбияты дип исем алган прогрессив әдәбиятның нигез ташын салдылар. Иҗтимагый фикер үсешендә мәгърифәтчеләр башлап күтәргән идеяләр йогынтысында соңрак татар профессиональ театры, музыка һәм рәсем сәнгате туа.

---

[1] М. Акъегет-Задә. «Хисаметдин менла». Казан, 1886 ел. 25 бит.
[2] К. Насыйри. Фәвакиһелҗөләса, 443 бит.
[3] Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, ф. 22, тасвирлама 1, саклау берәмлеге 20, 78 бит.

**Вахит Хаков,**
филология фәннәре докторы

# ГАСЫРЛАР СУЛЫШЫ

*Әдәби тел һәм матур әдәбият стиленең тарихи үсеш мәсьәләләренә карата*

Телдә кешеләрнең табигате һәм холкы да, тормышы һәм көнкүреше дә ачык чагыла. Шунлыктан тел аралашу, аңлашу коралы гына түгел, ул кешеләрнең рухи эшчәнлеген чагылдыру чарасы да.

Тарихи юнәлештә тел стильләр белән тыгыз бәйләнештә үсә. Мондый бердәмлек матур әдәбият стиленә нисбәттә бигрәк тә ачык күренә. Чөнки художестволы сөйләм үзенең киң кулланышта булуы һәм сәнгатьчә яңгырашы ягыннан телдәге башка стильләрдән аерылып тора. Анда төрле сөйләм үзенчәлекләре, образлы сурәтләү алымнары бергә кушыла һәм язучының әдәби телне үстерүгә ярдәм итә торган үзенә хас стиль чараларына зур урын бирелә.

Матур әдәбият стиленең төп асылы — аның сәнгатьле сөйләмгә корылуында. Әдәби тел нормаларын эшкәртүдә, тел чараларыннан файдалануда матур әдәбият гаять әһәмиятле җирлек ролен үти. Художестволы сөйләмдә югары аһәңгә, сәнгатьчә яңгырашка ирешүгә ярдәм итә торган тел-сурәтләү алымнары нәфис чигешләр, матур бизәкләр — орнаментлар гына булып каралмыйча, әйтеләчәк фикерне фәлсәфи юнәлештә аңларга да мөмкинлек бирәләр. Аларның бер эчтәлеккә туры китерелеп кулланылуы нәкъ шуның белән аңлатыла да. Музыкада тормыш күренешләре, иҗтимагый вакыйгалар үзенчәлекле итеп, төрле тавыш чаралары белән бирелгән кебек, матур әдәбиятта тел-сурәтләү алымнары да әсәрнең идеясе, композициясе һәм образлар системасы белән органик мөнәсәбәттә киләләр һәм махсус кануннар җирлегендә төзеләләр.

Тарихи үсеш, эволюцион үзгәрешләр ике яклап бара. Бер яктан, телнең үсеше әдәбиятның жанрлар ягыннан тармаклануына йогынты ясаса, икенче яктан исә, художестволы әдәбият телдәге нормаларның ныгуына һәм аларның киң күләмдә халык арасында таралуына китерә.

Бөтен халык өчен уртак булып әверелгән тел нормалары нигезендә әдәби тел үсеп чыга. Ул, халык сөйләменең төп байлыгын, киң таралган үзенчәлекләрен үзендә туплап, сөйләм культурасының иң югары казанышы булып китә. Бай һәм камил әдәби телгә ия булу — халыклар тарихында яңа үсеш баскычына ирешү нәтиҗәсе.

Әдәби тел нинди юллар белән үскән соң?

Мәгълүм булганча, аның беренчел нормалары халык авыз иҗаты әсәрләрендә күренә башлый. Язу туганчы ук, татар халкының җанлы сөйләменә нигезләнеп, төрле жанрларны (бәет, легенда, риваять, җыр, әкият, мәзәк, табышмак, мәкаль, әйтемнәрне) эченә алган сөйләмә әдәбият — халык авыз иҗаты әсәрләре барлыкка килгән һәм шул җирлектә фольклор стиле формалашкан. Элек-электән халык арасында йөргән риваятьләр, Туйбикә кыйссасы, «Хан кызы Алтынчәч», «Янмый торган кыз», «Кырык кыз» легендалары, «Гыйса угылы Амәт» дастаны, Науруз бәете, Мөхәммәт

Әмин бәете, әкиятләр, төрле хикәятләр башта сөйләм телендә, аннары язуда теркәлгән хәлдә, буыннан-буынга күчеп, безнең заманга кадәр килеп җиткәннәр. Шунысы әһәмиятле, фольклор әсәрләрендә бер диалект һәм җирлек белән бәйләнешле үзенчәлекләр генә түгел, бәлки бөтен халык өчен уртак нормаларга китерелгән тел күренешләре ачык чагылыш тапкан. Тел-әдәбият галимнәре фольклор телен сөйләмә әдәби телнең башлангычы итеп карау ягында торалар.

Язма әдәбият барлыкка килү белән әдәби тел тотрыклы бер күренеш ала, һәрьяклап ныклы нормаларга салына. Сөйләмнең төзелеше дә катлаулана бара, фикерне төгәл һәм ачык итеп бирү өчен, тел чараларының иң уңышлы төрләрен кулланырга, иң матур үрнәкләрен саклап калырга мөмкинлек туа. Телнең билгеле бер максатка яраклаштырылган, төрле сөйләм үзенчәлекләрен эченә алган киң тармаклары үсеп чыга. Вакытлар үтү белән, телнең тагы да нормалашу һәм калыплашу чорында, алар аерым стильләр булып җитлегәләр.

Тарихта бер үзенчәлекле хәл күзәтелә: әдәби тел ролендә халыкның үз теле түгел, бәлки бөтенләй ят, башка чит телләр дә кулланылганнар. Мәсәлән, иранлыларда һәм кайбер төрки халыкларда шундый әдәби тел булып классик гарәп теле, японнарда һәм кореялыларда — классик кытай, герман халыкларында — латин, көньяк һәм көнчыгыш славяннарда — иске славян, Балтик буенда һәм Чехиядә — немец телләре саналган.

Татар теле тарихында бу мәсьәлә ничек тора? Борынгы язма истәлекләрне һәм татар әдәби теленең үсешен тикшерү түбәндәге нәтиҗәгә китерә: бездә язма әдәби тел төрле үзенчәлекләрне (борынгы төрки, угыз, чыгтай, гарәп, фарсы һ. б.) эченә алса да, ул халык өчен бөтенләй ят һәм чит тел булмаган, халык язма әсәрләрнең күбесен аңлаган. Татар халкы арасында матур әдәбият әсәрләрен җыелышып уку күптәннән матур гадәткә кереп киткән. Элек-электән оста укып бирүчеләр, тел осталары, чичәннәр, әкиятчеләр булган. Алар телнең киң байлыгыннан файдаланганнар, буыннан-буынга телне үстереп һәм баетып, аның рухын саклап килгәннәр.

Төрки халыкларда язу культурасы борынгы заманнарда ук туган. Матур әдәбият стиле дә үзенең тарихын бик ерактан башлап китә. Безнең эраның VI—VIII гасырларында ташка чокып, рун хәрефләре белән язылган төрки ядкарьләрдә үк инде поэзия һәм проза үрнәкләре чагыла [1]. Элекке төрки әсәрләрне язганда төрле әлифбалардан файдаланылган. Төрки истәлекләрнең күбесе гарәп хәрефләре белән язылган («Котадгу белек»нең аерым нөсхәләре, Мәхмүд Кашгарый сүзлеге — XI гасыр, Әхмәт Югнакиның «Һибәтел-хәкаикъ» әсәре — X—XII гасырлар, Замахшариның «Мөкаддимәт әл-әдәб»е — XI—XII гасырлар, Әхмәт Ясәви хикмәтләре — XII гасыр, Сөләйман Бакыргани хикмәтләре — XII гасыр, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы — XIII гасыр, Рабгузи «Кыйсса»сы, Котбинең «Хөсрәү вә Ширин», «Харәзминең «Мәхәббәт-намә», Сәйф Сараиның «Гөлстан» әсәрләре — XIV гасыр һ. б.).

Уйгыр әлифбасында язылган әсәрләр: дини һәм юридик документлар (X—XIII гасырлар), «Алтын йарук» (X гасыр), «Котадгу белек»нең уйгыр нөсхәсе (XI гасыр), «Мәхәббәт-намә»нең уйгыр нөсхәсе (XIV гасыр), Ярлыклар (XIII—XIV гасырлар) һ. б.

Латин язуында («Коман мәҗмугасы» — XIII—XIV гасыр), әрмән язуында (юриспруденциягә караган, рәсми-канцелярия стилен чагылдырган кыпчак документлары — XIV гасыр), рус язуындагы (төрле чыгышлар, дипломатия документлары, сүзлекләр — XVII—XVIII гасырлар) төрки-татар язма истәлекләре дә очрый.

Хәзерге төрки телләр төрле үсеш баскычы үткәннәр. Телләрнең эволюциясен тикшергәндә хосусый белән гомуми арасындагы диалектик берлек искә алынырга тиеш.

Татар теленең тарихи үсеше төрки телләрнең гомуми үсешеннән аерып каралмый. Төрки халыкларның кайберләрендә язма әдәби тел борын-борыннан үсеп килгән һәм ул телләрдә зур күләмле әдәби, фәнни-тарихи әсәрләр иҗат ителгән. Мәсәлән, әзербәйҗан, үзбәк, татар телләре бик электән иске язма телгә ия булган телләр рәтендә каралалар. Алар, элекке традицияләрне саклаган хәлдә, Октябрь революциясенә кадәр үк әдәби тел булып үсеп җитәләр, совет чорында тагы да киң үсеш алалар һәм камилләшәләр. «СССР халыклары әдәби телләренең үсеш закончалыкла-

[1] Кара: И. В. Стеблева. Поэзия тюрков VI—VIII веков. Мәскәү, «Наука» нәшрияты, 1965.

ры» дигән китапта бу хакта түбәндәгечә әйтелә: «Совет чорында иске язулы телләр үзләренең эчке ресурсларын төрле дәрәҗәдә файдаланалар. Мәсәлән, рус теленең сүзлек составы үзенең эчке ресурсларын максималь эшкә җигү юлы белән үсә. Украин, белорус, үзбәк, әзербәйҗан, әрмән, грузин, латыш, литва, молдаван, таҗик, татар, эстон һәм башка кайбер телләрнең лексик-семантик системасы нигездә аларның эчке мөмкинлекләре җирлегендә үсә» [1].

**Әдәби телләрнең үсешендә төп ике чорны аерырга һәм аларны буташтырмаска кирәк.** Аларның берсе — теге яки бу халыкта язма әдәби телнең барлыкка килү һәм башлангыч үсеш чоры. Икенчесе — әдәби телнең тулысы белән халык сөйләме теленә нигезләнгән, икенче төрле әйткәндә, халык теленең әдәби тел функциясендә йөри башлаган чоры. Аларның һәрберсе халыклар тарихында төп иҗтимагый шартлар туганда гына өлгереп җитә. Мисалга элекке язма әдәби традицияләргә ия булган төрки телләрне алыйк.

Әзербәйҗан телендә беренче чор XIII гасырга һәм аннан элегрәк булган дәвергә карый [2]. Ә икенчесе — милли әзербәйҗан әдәби теленең нормалары формалашу чоры — XIX гасырның утызынчы елларыннан башлап, XX гасырның егерменче елына кадәр сузыла [3].

Урта Азиядә төрки әдәбият һәм мәдәният шулай ук күптәннән үсә башлый. XV—XVI гасырларда иске үзбәк теле формалашып җитә [4]. Үзбәк милләте туу белән (ул процесс XX гасырдан башлана, Октябрь революциясеннән соң тәгәлләнә), иске үзбәк теле үзгәрә, андагы архаик нормалар кулланылыштан төшәләр, җанлы сөйләмгә нигезләнгән милли үзбәк теле барлыкка килә [5]. Димәк, үзбәк теле тарихында беренче чор XV—XVI гасырга карасa, икенче чор XX гасырдан башлана.

Ниһаять, Идел буенда үскән һәм нормалашкан татар язма әдәби теленә кагылышлы кайбер мәсьәләләргә тукталыйк. Татар теленең барлыкка килүе өчен төп шартлар күптәннән туган. Аның башлангыч формалашу, язуда теркәлә башлау чоры ерак тарихка барып тоташа. Иң читен һәм катлаулы мәсьәләләрнең берсе — әдәби телнең тарихи нигезен дөрес ачу, ягъни анда кайсы кабилә телләренең ятуын анык билгеләү. Тикшерүләр татар теленең борынгы болгар һәм кыпчак телләренә якынлыгын күрсәтәләр. Татар телен борынгы төрки тел белән бәйли торган күп кенә үзенчәлекләр бар. Борынгы төрки тел, үз нәүбәтендә, кыпчак, угыз, карлук телләре өчен дә элгәрерәк булганлыктан, татар теле фонетик, лексик һәм грамматик яктан угыз һәм карлук телләре белән дә билгеле дәрәҗәдә кардәшлек мөнәсәбәтендә тора.

Идел-Кама буенда төзелгән борынгы Болгар дәүләтендә үк, төрки кабилә телләренең бер-берсе белән тыгыз аралашуы нәтиҗәсендә, XII—XIII гасырларда татар язма әдәби теленең нормалары барлыкка килә һәм аерым стильләре (матур әдәбият стиле, фәнни стиль, эпиграфика стиле, дини трактатлар, үгет-нәсихәт әсәрләренең теле һ. б.) формалаша башлый. Димәк, татар әдәби теленең үсешендәге беренче чор Болгар дәүләте һәм андагы мәдәният белән бәйләнгән. Ә икенче чор XIX гасыр һәм XX гасырның башы белән билгеләнә.

Болгар дәүләте экономика һәм культура ягыннан югары үсеш баскычына ирешкән зур феодаль дәүләт була. Ул дәвердә үк әдәби телдә стильләргә бүленү башланганлыгын һәм төрле жанрлар туганлыгын күзалларга мөмкин. Элекке чордагы төрки язма истәлекләрдә телнең эчке мөмкинлекләреннән киң файдаланыла, күчерелмә мәгънәдәге сүзләргә, төрле сурәтләү алымнарына, фразеологик әйтелмәләргә зур урын бирелә. Мисалга XIII гасыр язма истәлеге — «Кыйссаи Йосыф» поэмасын алырга мөмкин. Тел чаралары борынгы төрки тел традицияләре нигезендә сөйләү теле үзенчәлекләре белән тыгыз үрелеп баралар. Геройларның портретын сурәтләгәндә дә бу ачык күренә. Шагыйрь Йосыфның портретын түбәндәгечә бирә:

---

[1] Закономерности развития литературных языков в советскую эпоху (внутриструктурное развитие старописьменных языков). Мәскәү, «Наука» нәшрияты, 1973, 17 бит.

[2] М. Ш. Ширалиев, М. Ш. Рагимов. Азербайджанский язык. «Закономерности развития литературных языков...» дигән китапта, Мәскәү, 1973, 222 бит.

[3] А. М. Демирчизадә. Әзербәйҗан әдәби теленең инкишаф юллары. Баку, 1958, 38—41 бит; Әзербәйҗан теленең өслүбияте. Баку, 1962, 18 бит. (Икесе дә әзербәйҗан телендә.)

[4] А. Н. Кононов. Грамматика современного узбекского литературного языка. М.—Л., 1960, 9 бит.

[5] Н. А. Баскаков. Введение в изучение тюркских языков. М., 1962, 265 бит.

**Һилалә биңзәр синең кашларың вар,**
**Энҗүйә биңзәр синең дешләрең вар,**
**Гамзә кылсаң, йолдыз тик күзләрең вар, —**
**Керпекләрең җанымнан кәчәр имди**[1].

Күренешләрне бер-берсе белән чагыштыру, охшату сәнгатьле сөйләмнең эмоциональлеген һәм аһәңен күтәрүгә ярдәм итә. Телнең төрле мөмкинлекләреннән файдалану тезем рәвешендә бирелгән сыйфатларда да ачык күренә. Мондый алым әдәби телдә стиль чараларының гасырлар буена үсеп килүен күрсәтә. Бер өзеккә мөрәҗәгать итик:

**Мөнадилар олы өнен чагырдылар,**
**Бу угланны кем сатып алыр дирләр,**
**Ун дөрле һөнәре вардыр дирләр, —**
**Һөнәрләрен берен-берен әйтер имди.**
**Әүвәл улдыр: кадде яхшы зариф үзле,**
**Икенче — бәңзе якты, йөзе нурлы,**
**Өченче — фәсих делле, сәхих сүзле,**
**Йитмеш ики телне тәмам белер имди**[2].

Халыкның зирәк тәҗрибәсе җирлегендә туган образлы сурәтләүләр, чагыштырулар, фразеологик әйтелмәләрнең төрле формалары XIII гасыр язма истәлекләрендә күп очрый. Мәсәлән: **тулун ай тик нурлы йөз, гәүһәр кеби яшь, бал-шикәрдин татлы сүз, һилалә биңзәр каш, кан аглау** (елау), **миһер уты кайнау, бәгырь яну, ата хакы, туның сую, ут ягу, кул тигерү, ант эчү, пошиман булу** һ. б.

Күреп үткәнебезчә, сәнгатьле сөйләм борынгы чорда ук аерылып чыккан һәм мөстәкыйль үсеш алган. Төрки әдәбиятта поэзиянең өстенлек алуы безнең борынгы бабаларыбыз һәм Көнчыгыш әдәбиятына хас күренеш булып тора. Гадәттә, ул әсәрләр мавыктыргыч сюжетка корылган булалар, элекке төрки язма тел традицияләрен дәвам иттерәләр.

Болгар дәүләтендә төп урынны алып торган болгарлар белән Казан татарлары арасындагы тарихи бәйләнешкә — культура, тел-әдәбият бағланышларына күптәннән игътибар ителгән. Бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри да, мәшһүр тарихчы Шиһап Мәрҗани да, халык шагыйре Г. Тукай да бу мәсьәләне читләтеп үтмәгәннәр. Совет чорында исә мәдәни һәм әдәби мирасны фәнни яктан тикшерү тагы да киң җәелде.

Тарих фәнендә исбат ителүенчә, Идел һәм Урал буенда төркиләшү процессының башлануында хәлиткеч урынны Азов буеннан килгән болгарлар гына түгел, ә аңа кадәр ук III—IV гасырларда һуннар һөҗүме һәм VI—VII гасырларда Бөек Төрки каганат вакытында Көньяк Урал һәм Көнбатыш Себер далаларыннан килгән төрки кабиләләр тотканнар[3].

Татарларның этногенезына һәм теленә кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә, төрле халыкларның (болгарларның һәм кыпчакларның) тоткан урыны дөрес ачылырга, тарихка бәйләнешле күп төрле факторлар искә алынырга тиеш. Шунлыктан соңгы елларда бу мәсьәләгә һаман да ачыклыклар кертелә бара. Бер төркем галимнәр раславынча, татар теле төрле тарихи-иҗтимагый сәбәпләр аркасында үзендә кыпчак теле үзенчәлекләрен күбрәк берләштерә. Эш шунда ки, Болгар дәүләте җимерелеп, XIII гасырда Алтын Урда дәүләте төзелгәннән соң, кыпчак теле шул хакимиятнең дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә. Нәтиҗәдә, болгар теленең элекке кулланылышы тарая, Идел буенда, борынгы Болгар дәүләте чорындагы язма әдәби телнең үзенчәлекләрен берләштергән хәлдә, кыпчак сөйләменә нигезләнгән яңа язма тел үсеп чыга. Без моны **хәзерге татар әдәби теленең тарихи җирлеге** дип карыйбыз. Бу язма телнең традициясе Алтын Урда дәүләте оешкан вакыттан гына башланмый, бәлки элегрәк дәверләрдән — Болгар дәүләте һәм Төрки каганат чорыннан ук килә.

---

[1] Һилал — ай, гамзә кылсаң — назласаң.
[2] Мөнадилар — базар хәбәрчеләре; өнен чагырдылар — тавыш бирделәр; кадде — буе; зариф үзле — зирәк табигатьле; фәсих — төзек; сәхих — дөрес.
[3] А. Х. Халиков. История формирования тюркоязычных народов Поволжья и Приуралья. «Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья» дигән китапта. Казан, 1971, 36 бит.

1968 елда Токиода үткәрелгән VIII Халыкара конгресста Ш. Ф. Мөхәммәдьяров татар халкының килеп чыгу тарихына багышланган докладында да болгар теле белән кыпчак теле арасындагы көрәш, нәтиҗәдә, кыпчак теленең җиңеп чыгуы турында сүз алып бара һәм хәзерге татарларның чыгышлары ягыннан өлешчә болгар, ә телләре ягыннан кыпчак булулары турында күрсәтеп үтә [1].

XIV гасырда Идел буенда киң күләмдә гомуми төрки культура үсеп китә, әдәби һәм фәнни-тарихи әсәрләр иҗат ителә. Ул чорда язылган әсәрләрнең шактый өлеше хәзерге замангача килеп җиткән. Алар безнең илдә генә түгел, Көнбатыш Европа һәм Көнчыгыш илләрендә дә табыла торалар. Шунлыктан XIII—XIV гасыр төрки язма истәлекләрен чит ил тюркологлары да зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

Мәсәлән, шагыйрь Котбиның ун мең шигъри юлны эченә алган «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы 1342 елда язылган. Күчермәсе Франциянең милли китапханәсендә саклана. Беренче башлап Польша Фәннәр академиясендә А. Зайончковский тарафыннан бастырып чыгарыла. Биредә XIV гасырдагы язма әдәби телнең гүзәл үрнәкләрен күрергә була. Шагыйрь бу әсәрендә шул чордагы әдәби телнең киң мөмкинлекләреннән иркен файдалана, табигать күренешләрен матур алымнар белән сәнгатьчә яңгырашта сурәтләп бирә, тормыш-көнкүрешнең аерым детальләрен гади итеп тасвирлый. Әсәрдә кулланыган тел-стиль чаралары хәзерге татар телендә дә дәвам итәләр. Түбәндәге шигырь юлларына мөрәҗәгать итик:

**Күңел кис таҗ тәхетдин, бул фаригъ,**
**Чыраең кыйлма кайгы берлә сарыйг,**
**Әгәр булсаң бу тәхет — таҗга мохтаҗ,**
**Сәңа йир — тәхет ирер, югары күк — таҗ [2].**

Биредә чагыштыруның үзенә бер төре — ике генә компоненттан торган чагыштыру бар: **җир — тәхет, күк — таҗ.** Мондый чагыштырулар гасырлар буе үсеп, киң кулланылышка кереп киткәннәр. Г. Тукайдан бер өзек:

**Бик күңелсез бер начар ж у р н а л — г о м е р**
**Анда, әйбәт, б а ш м ә к а л ә м а л ирер.**

Шагыйрь, сөйләмнең кыскалыгын тәэмин итү өчен, журналны гомер, баш мәкаләне мал белән чагыштыра.

С. Рәмиев бу чара аша портретның классик үрнәкләрен бирә:

**Кашлары — ай аның яңа туган,**
**Йөзе — айның тулган көннәре;**
**Керпекләре — нурлар кич чәчелгән,**
**Ике күзе — шул кичнең күлләре.**

һ. Такташта да шундый ук традицияләр дәвам итә:

**«Барабыз»га утырып, теләгән җиргә**
**Кошлар кебек очып барабыз,**
**К о я ш — безгә и п т ә ш,**
**Ә җ и р инде — б е з н е ң а н а б ы з.**

М. Җәлил дә бу төрдәге чагыштыруларны киң куллана. Түбәндәге өзектә кар белән кәгазь, кояш белән шагыйрь чагыштырыла:

**Кар —**
**әйтерсең, ап-ак кәгазь,**
**Теләсәң шигырь,**
**Теләсәң җыр яз.**
**Нур каләмен кулына тотып,**
**Чыгып баскан шагыйрь — кояш.**

---

[1] Ш. Ф. Мөхәммәдьяров. Основные этапы происхождения и этнической истории татарской народности. Мәскәү, 1968, 10 бит.
[2] Алынган өзекләр хәзерге орфографиягә яраклаштырып биреләләр. Сүзлек: бул фаригъ — бушан.

Менә 1353 елда Харәзми тарафыннан язылган «Мәхәббәт-намә» әсәре. Аның уйгыр һәм гарәп хәрефләре белән бирелгән күчермәләре Британия музеенда һәм Төркия китапханәләрендә сакланып калган. Бу әсәр үзенә бер алым белән — хатлар стилендә иҗат ителгән. Төрки әдәбиятта элек-электән аерым стильләрнең тыгыз үрелеп баруын күзәтергә мөмкин. Биредә эпистоляр стиль белән матур әдәбият стиле кушылып килә. Бер өзек:

**Әйа! Арслан йөрәкле хан ыругы,**
**Кечек яшьдин олугларның олугы,**
**Исәр таң җиледәг йилкенде атың,**
**Кояш йаилык җиһанны тотты затың.**
**Әгәр мең ел терелсә Хатим-и тай**
**Синең атың ишеткәч йирләр үпкәй.**
**Улус тотдың камуг гаклың көчендин,**
**Чиригтә кан тамар камчың эчендин.**

Ул чордагы әсәрләр халыкның тормыш тәҗрибәсе җирлегендә туган күп төрле гыйбрәтле сүзләргә, мәкаль-әйтемнәргә һәм халык афоризмнарына да бай. Моның үрнәкләре Сәйф Сараи тарафыннан 1390 елда язылган «Китабе Гөлстан бит-төрки» әсәрендә дә ачык чагыла. Мәсәлән: «Никадәр кем бәкләр ашы татлы булса, и кунак, ярлы-юксылга коры итмәке андан яхшырак», «Күрексез киленгә күрекле тун кидереб йарашмас», «Йитсә татлы суга сусамыш ир, курыкмас алнында булса аждаһа», «Озын буйлы ахмакдан кыска буйлы гакыл йахшырак дорыр», «Йимеше күб агачка таш атарлар», «Мал гомер рәхәте өчен дорыр, дәхи гомер мал җәмг итмәк өчен дәгел», «Эчереб илгә кашык берлә шурба, чүмеч сабы белән күзен чыкарма» һ. б.

Әсәрдә хәзерге халык сөйләмендә кулланылган фразеологик әйтелмәләр дә күп очрый. Кайбер мисаллар: **күңел теләге, җәһәннәм уты, ачы тел, юксыллык йөге, фәкыйрьләр аһы, саба йиле, йыллар кичү, йөз суын түгү, әл (кул) озайту, җәрахәт өстенә тоз куймак, гафләт уйкусы, йөз кайтармак, төн ката йөрү, йөз тоту** һ. б.

Төрки халыкларда матур әдәбиятның поэзия һәм проза стиле күптәннән үсеш алган. XIV гасырда бер күренеш күзгә ташлана: проза сөйләме, шигъри әсәрләрнең бер өлеше буларак, киң урын ала. Бу яктан «Гөлстан» әсәре бик үзенчәлекле. Анда хикәятләрдән торган проза сөйләме һәм поэзия бер-берсе белән керешеп килә. Үрнәк өчен бер мисал:

«Хикәят. Локман Хәкимгә сордылар:

— Әдәбне кемнән үгрәндең? Әйтте: — Әдәбсезләрдән. Бактым аларның әфгаленә — кайсы хәрәкәт, кем, миңа хуш килмәде, аннан ихтираз кылдым.

**Әгәр уйнап бер яхшы бер хәреф әйтсә,**
**Алыр андан белек әһле насыйхәт;**
**Килер ахмак колагына уйынчак**
**Укыр булсаң йөз илле баб хикмәт».**

XIV гасырда тулысы белән проза стилендә язылган оригиналь әсәрләр дә очрый. Хикәятләрдән һәм новеллалардан торган зур күләмле әсәрләрнең берсе — Мәхмүд бине Гали Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәре.

XIV гасырдан безнең чорга бик күп истәлекләр килеп җиткән. Алар арасында тагы Хисам Катибның «Җөм-җөмә солтан», Саядиның «Дастаны Бабахан» әсәрләре, «Коман мәҗмугасы», галимнәрдән Әбу Хәййанның «Китаб-ел-идрак...», Җамалетдинның «Китабе болгат-эл моштак» исемендәге сүзлекләре, фәнни хезмәтләре һ. б. зур әһәмияткә ия булып торалар.

Татар әдәби теленең һәм матур әдәбият стиленең үсешен күз алдына китерүдә XIII—XIV гасыр язма истәлекләре зур чыганак булып хезмәт итәләр. Аларда татар теленең тарихи үсеше һәм киң тел байлыгы чагыла. Бу чордагы язма истәлекләрне җентекле рәвештә Әмир Нәҗип өйрәнә. Ул аларны төрки халыкларның күпчелеге (нугай, төркмән, казакъ, үзбәк, башкорт һ. б.) өчен уртак мирас итеп карый [1].

[1] Ә. Нәҗип. Татар әдәбиятының һәм татар әдәби теленең кайбер онытылган язма истәлекләре турында. «Совет әдәбияты», 1957, № 12; Кыпчакско-огузский литературный язык мамлюкского Египта XIV века. Докторлык диссертациясе, М., 1965; Уртак хәзинә. «Казан утлары», 1971, № 2.

Алтын Урда дәүләте таркалганнан соң, ул территориядә яңа дәүләтләр, ханлыклар барлыкка килә. Шуның берсе — Казан ханлыгы. Татар халкының бер дәүләткә оешуы Казан ханлыгы төзелү белән тыгыз бәйләнгән. Бу чорда тел һәм культура ягыннан элекке традицияләр дәвам итә. XV—XVI гасырларда әдәби тел нормалары тагы да киң кулланылышка керә, матур әдәбият стиле үсә, ул төрле сурәтләү алымнары белән баий. Моны шул дәвер шагыйре Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» (1539 ел), «Нуры содур» (1542 ел) поэмалары мисалында ачык күрергә мөмкин. «Нуры содур» әсәреннән гаделлек турында әйтелгән бер өзеккә мөрәҗәгать итик:

**Гадел берлә ил камуг булыр әман,**
**Калмаз илдә фетнә вә золым һаман.**
**Бер сәгать гадел кыйлмак яхшырак,**
**Кем гыйбадәт алтмыш елдан озаграк.**
**Гадел берлә ил гыймарәт булыр уш,**
**Барча эшләр табар аның берлә хуш.**
**Гадел булыр барча эш башы, белең,**
**Гадел берлә даимән бәс эш кыйлың.**

Шагыйрь халык сөйләм теле үзенчәлекләреннән, тел байлыгыннан уңышлы файдалана, халык авыз иҗаты әсәрләренә таянып, художестволы сурәтләү чараларын, тасвирлау алымнарын оста куллана. Сәнгатьле сөйләм чарасы буларак, фразеологик әйтелмәләр сөйләмнең эмоциональ яктан югары яңгырашына, фикерне ачык һәм төгәл белдерүгә ярдәм итәләр: **багстан былбылы, кан эчү, ил күзе, гакылым кошы, җир үбү, колак салу, таңга калу, күз йомып ачканчы** һ. б.

Мәкальләр һәм әйтемнәр бик борыннан матур әдәбият әсәрләрендә зур урын алалар: «Борынгыдан ирер мәсәл — колак сал: ямандин сән буеныңи сатып ал», «Бер нәсихәт итәем мән, колак сал: иясен сыйласаң, этенә сөяк сал», «Гакыйль булсаң, иргә касд итмә, зинһар: «Каюг казып, үзе төшкәй» — мәсәл бар» («Төхфәи мәрдан»).

Моннан тыш Өмме Камал, Мөхәммәд Әмин, Гариф бәк шигырьләрендә, канцелярия документларында, ярлыкларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә ул дәвердәге тел нормалары киң чагылыш таба. Әдәби телнең күчерелмә мәгънәдәге сүзләргә һәм төрле сурәтләү чараларына бай булуы әсәрләрнең поэтик яңгырашына һәм сәнгатьлеккә ирешүдә зур роль уйный.

Аз сүз белән тирән мәгънә аңлатуга элек-электән зур игътибар ителгән. Телнең тәэсир итү көче дә нәкъ шуннан чыгып билгеләнә. Бу яктан татар теленең бик бай традицияләре бар. Моннан берничә ел элек кенә, VII—XIII гасыр төрки ядкарьләрендәге 20 меңгә якын сүзне һәм сүз тезмәләрен эченә алган сүзлек чыкты[1]. Анда борынгы төрки телнең киң байлыгы чагыла. Татар телендә дә шул борынгы төрки сүзлек катламы сакланып килә. Сүзләрнең күпчелеге элекке төп мәгънә төсмерләрен саклаганнар. Аерым тарихи-географик шартларда, төрле халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә һәр телнең үзенә хас үзенчәлекләре аерылып чыккан. Сүзләрнең кайберләре төрле үзгәрешләр дә кичергәннәр. Бер төркем сүзләр вакытлар үтү белән мәгънә ягыннан тарайган. Бу күренеш турыдан-туры телнең камилләшүе һәм мәгънәнең төгәллеге белән бәйләнгән. Мисалга **тары** сүзен алыйк. Безнең борынгы бабаларыбыз чәчү мәйданын, иген чәчә торган җирне, шулай ук җыеп алынган уңышны **тарыг** дип йөрткәннәр, ә җир эше белән шөгыльләнүче кешене, крестьянны, тарыгчы дип атаганнар. **Тарыг** сүзенең аерым чәчү культурасын белдергән тар мәгънәсе дә күптәннән кулланыла башлаган. В. В. Радлов үзенең сүзлегендә кайбер төрки телләрдә **тарыг** сүзенең **сөрү, чәчү җире** мәгънәсендә йөргәнлеген күрсәтә. Татар халык сөйләү телендә кушма сүз составында гына элекке мәгънә төсмере саклангаи. Мәсәлән: «Көз җитеп, **иген-тару** ындырга кердеме — ул инде миңа кыз димләргә тотына» (Г. Ибраһимов). **Тара** (чәч тара) сүзендә дә **тары** сүзенең борынгы мәгънәсе (эшкәртү, сөрү) белән бәйләнеш дәвам итә.

**Тун** сүзенең дә мәгънәсе тарайган. Ул өс киеменең тиредән ясалган бер төрен генә белдерә. Анда шулай ук борынгы төшенчә сакланган (борынгы заманнарда тире

---

[1] Древнетюркский словарь. «Наука» нәшрияты. Ленинград. 1969.

киемнәр генә булган). Ләкин элекке чорда һәм урта гасырларда бу сүз өчен гомумилек хас. Барлык өс киеме шул исем астында йөргән. Кайбер язма истәлекләрдә тун сүзенең мәгънәсе конкретлаша баруы да күренә. Казан ханлыгы чоры һәм аннан соңгы дәвер язмаларында, С. Хәлфин сүзлегендә, XIX гасыр һәм XX гасыр башындагы әсәрләрдә **тун** сүзенең конкрет мәгънәсе өстенлек ала. **«Тунсызларга** нурлы көннәр килде», «Килер ак тунлы кыш та» (Г. Тукай) һ. б. Ниһаять, элекке киң мәгънә бөтенләй югала, ул бары тик топонимик исемнәрдә (Каратун авылы) һәм аерым сөйләшләрдә генә сакланып кала.

Кайбер төшенчәләр киңрәк мәгънәле сүзләр белән белдереләләр. Ләкин бу чагыштырмача сирәк очрый. Мәсәлән, борынгы телдә **ил** сүзе кабилә союзы, халык яки бер этник төркем мәгънәсендә йөргән. XVI йөз татар әдәби телендә дә шул төшенчә саклана: **«Ил бәгенең** анда багы бар иде» (Төхфәи мәрдан»). Сөйләү телендә **корт иле, ил теле** кебек тәгъбирләрдә дә шундый ук төсмер чагыла. Сөйләмгә эмоциональ-экспрессив яңгыраш бирүдә матур әдәбият стилендә моны ачык күреп була. Г. Ибраһимовтан берничә мисал: «Җәй көне тамак **ил өстендә** туя», «Атаңны **илгә чиратка салдылар», «Илдә кемнәр юк**, дисең» («Көтүчеләр»), «Фаҗига **ил телендә** шул рәвешле тәфсыйль кылына» («Яшь йөрәкләр»). Элекке мәгънәне саклаган хәлдә **ил** сүзенең иҗтимагый функциясе киңәя, ул бер дәүләткә кергән барлык идарә органнарын, күп халыкларны, конкрет территориаль бүленешне белдерә торган гомумиләштерүче сүз булып китә. Шуңа карамастан, **ил** сүзенең билгеле бер өлкә, яши торган урын төшенчәсендә кулланылган очраклары да бар.

Әдәби тел һәм матур әдәбият стиленең тарихи үсешендә искергән, кулланылыштан төшеп бара торган сүзләрне дә очратырга мөмкин. Кайбер төрки-татар сүзләре, элек-электән язма истәлекләрдә урын алсалар да, соңгы чорларга таба сирәк кулланыла башлыйлар яки телдән бөтенләй төшеп калалар. Мәсәлән: турун (онык), йи (аша), бичин (маймыл), болак (елга, чишмә), әл (кул), ут (үлән), үкүш (күп), тархан (титул, чин), чиру, сү, ләшкәр (гаскәр), көбә (панцырь), чиркин (начар), төмән (бик күп), буга (үгез), йаг (дошман), йазы (дала), Чулман (Кама), кот (бәхет), туг (байрак), чыгай (ярлы), талуй (диңгез), асыг (файда), барк (бина, йорт), будун (халык), күни (кәнизәк) һ. б. XIX гасырның икенче яртысында, XX гасыр башында язылган әсәрләрдә әле аларның кайберләрен очратырга була. Мисаллар: «...тавык итләрен агу итеп **йидерә»** (З. Һади), «Янә сөймәс бер аен да, чытып **чиркин** чыраен да», «...ки **әлдән** үл сәне салмас», «Өмид илән каләм алды бу **әлем»** (Г. Кандалый). Кайбер искергән сүзләр хәзерге телдә аерым лексик берәмлекләр составында табыла алалар. Мәсәлән, **җимеш** сүзенең тамыры (җи), фонетик яктан үзгәреп, йи сүзеннән торганлыгын сиземләү читен түгел. Ут (үлән) сүзе кайбер очракларда элекке төшенчәсен саклый (утау, утлавык, чәнчү уты һ. б.). Милли әдәби тел нормалашу чорында **болак** сүзе борынгы мәгънәсендә дә йөри (елга, чишмә) һәм елганың исемен дә белдерә. Мәсәлән, **«Болагы** саф, чәйгә һәркем су салганда» (Акмулла), «Сал шаулый, сулар гөрли **болакларда»**, «Таулар, **болаклар** барысы да басылды» (Дәрдмәнд), «Шул сәбәптер ки: **«Болак** гөлдән вә рәйханнан ерак» (Г. Тукай).

Элек-электән кулланылган сүзләрнең бер төркеме авыл, елга, шәһәр, кеше исемнәрендә генә сакланып калган: **Чирү** (гаскәр), **Каратун, Дөбъяз** (төп дала), **Олыяз** (олы, зур дала), **Торнаяз** (торна даласы), **Сылуяз** (матур дала), **Котыш** (бәхетле), **Алабуга** (Ала үгез), **Төмән** (бик күп) һ. б. Борынгы чор әдәбиятында киң урын алган **атаг** (дан), **кот** (бәхет), **билгү** (акыллы, зирәк), **маг** (хөрмәт) сүзләре кушымчалар ялганып хәзер дә элекке мәгънә төсмерен чагылдыралар: **атаклы, котлы, билгеле, мактаулы.**

Татар теле кушма сүзләрнең күп кулланылуы белән дә аерылып тора. Кушма сүзләрнең төрле төрләре очрый. Икенче кисәге мәгънә белдерми торган кушма сүзләрдә (савыт-саба, мал-туар, бала-чага, кыз-кыркын һ. б.) җыймалык төшенчәсе аңлатыла. Борынгы телдә **саба, туар, чага, кыркын** сүзләре барысы да мөстәкыйль мәгънәгә ия булганнар. Җентекләп караганда, бу төрдәге кушма сүзләрдә бер үк төшенчәнең кабатлануы күренә.

Сөйләмне матурлый торган, аңа җегәрлек өсти торган фразеологик әйтелмәләр туры мәгънәдә кулланылган гади сүз тезмәләреннән килеп чыкканнар. Мәсәлән: ут ягу (күңел борчу мәгънәсендә), кул тидерү (сугу, кыйнау), чүбек чәйнәү (бушка сөйләү),

тауга менү (дәрәҗәгә күтәрелү), колакка салу (яхшылап ишетү), канат сыну (ятим калу, якын дустыңнан аерылу), җәясен тартып карау (уй-фикерен белү), җилләр исү (югалу, чыгып китү мәгънәсендә) һ. б. Кайбер тәгъбирләр аша халыкның тормыш-көнкүрешен, һөнәрен аңларга мөмкин. Мәсәлән, заманында туку станоклары белән бәйләнешле **киләп сару** сүз тезмәсе вакытлар үтү белән күчерелмә мәгънәдә бөтенләй яңа (бушка вакыт әрәм итү, тик утыру) төшенчәне белдерә башлаган. Бер төркем тотрыклы әйтелмәләр халыкның гореф-гадәтләре, этнографиясе белән тыгыз мөнәсәбәттә туган. Алар ерактан, мәҗүсилек чорыннан ук киләләр. Мәсәлән, **ата хакы — тәңре хакы** дигән тәгъбирдә ыруглык заманнарында ук кулланылган мәгънә төсмере сакланган. **Җир-су** төшенчәсендә төрки халыкларның туган-яшәгән җире күздә тотыла. Андый атамалар культ дәрәҗәсендә йөргән, аларда халыкның оешканлыгы да, көче дә һәм гадәтләре дә ачык гәүдәләнгән.

Телдәге әйтелмәләр төрле мәгънәви үзгәрешләр дә кичерәләр. Үрнәк өчен XIII гасыр язма истәлекләрендә очрый торган **бәгырь яну** тәгъбирен алыйк. Бу — хәзер **йөрәк яну** әйтелмәсенә туры килә. **Бәгырь** сүзе авазлар үзгәреше нәтиҗәсендә **бавыр** сүзеннән ясалган. Элек **бавыр** сүзе **йөрәк** мәгънәсендә тойгылы сөйләм тудыручы, үзенә хас мәгънәле бер сүз булып йөргән. Халыкта **минем бавырым, бавырга керү, чит бавыр, бавыр бәйләү, бавырыма басу, бавырыма таш булып яту** кебек борынгы тел күренешләре хәзер дә сакланганнар.

Сөйләмдә билгесез күплекне яки абстракт күплек төшенчәсен белдергәндә аерым саннарның кулланылуы да — борынгы тел күренеше. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» поэмасындагы «**Кырык** ирдән куәте артык имди», «Йитмеш ике телне белер» кебек җөмләләрдә бирелгән саннарның татар халык мәкальләрендә, фразеологик әйтелмәләрдә киң таралган булуы шуны күрсәтә[1]. Чагыштырыгыз: «Кыңгыр эш **кырык** елдан соң да беленә», «**кырык** тартмачы», «**кырык** корама», «**кырыкмаса кырык** кат», «**кырык** чөе кырылсын», «**Кырыкка** ярылу», «кызлы өйгә **кырык** ат бәйләнер», «**кырык** эше кырылып ята», «**кырыкка** бирәү тулмаган», «**җиде** кат үлчә, бер кат кис», «Егет кешегә **җитмеш** төрле һөнәр дә аз», «**җиде** кат тирене тунау», «**җиде** күккә менү», «**җиде** атасына җитү», «**җиде** төн уртасы», «**җиде** ят», «**җиде** ятып бер төшкә кермәү» һ. б. Шул хәзинә матур әдәбият әсәрләрендә киң файдаланыла. М. Җәлилнең «Ике йөзле кешегә» дигән шигырендә ул чаралар антитеза алымы белән килеп поэтик сөйләмнең яңгырашын күтәрүгә булышалар:

> **Киемем минем к ы р ы к ямаулы да,**
> **Күңелем саф, аның каравы.**
> **Син купшы, тик тузган йөрәгеңнең**
> **Җ и т м е ш  җ и д е  төрле ямавы.**

Әдәби телдә һәм матур әдәбият стилендә элекке чорларда ук халык телендәге чаралардан, андагы байлыктан киң файдаланылган. Бу традиция XVI—XVIII гасырларда да дәвам итә. XVII гасыр татар әдәбиятында М. Колый, XVIII гасырда Габдерәхим Утыз Имәни поэзиясе әһәмиятле урынны били. Хисаметдин бине Шәрәфетдиннең XVI—XVIII гасырларда язылган «Тәварихы Болгария», Кадыйр Гали бәк тарафыннан фарсы теленнән тәрҗемә ителгән «Җәмигъ-эт тәварих» әсәрләре фәнни-тарихи проза стиленең үсешен күзалларга ярдәм итәләр. Прозаик сөйләм драматургия стиленең дә үсүенә зур йогынты ясаган. Поэзиягә караганда проза әсәрләренең теле тарихи юнәлештә үзенең җанлы сөйләмгә якынлыгы белән аерылып тора.

XVII—XVIII гасырларда һәм XIX гасырның беренче яртысында (һибәтулла Салихов, Әбелмәних Каргалы, Шәмсетдин Зәки иҗатында һ. б. әсәрләрдә) элекке язма тел традицияләре шактый дәрәҗәдә саклана, шул ук вакытта, сөйләү теле чараларын куллану да активлаша.

Бу чорлардагы төрле стиль үзенчәлекләрен чагылдырган дәреслекләр-хрестоматияләрдә, кулланмаларда, сүзлекләрдә (С. Хәлфин, И. Хәлфин, М. Иванов, С. Кукляшев, М. Мәхмүдов, Г. Ваһапов һ. б. ларның хезмәтләрендә) әдәби телдәге үзгә-

---

[1] Өлкән әдип һәм фольклорчы Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» (3 томда), «Татар халык табышмаклары» дигән хезмәтләрендә телнең үсешен ачыклый торган гаять бай һәм күп материал тупланган.

решләрне күзәтергә була. Шулай итеп, халыкның җанлы сөйләме нигезендә татар теле үсешендә яңа этап башлана, милли әдәби тел туу өчен җирлек хәзерләнә.

XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасыр башында татар халкы милләт булып оеша. Әдәби әсәрләр саф татар телендә — халыкның сөйләү телендә языла башлыйлар. XIX гасыр — татар әдәби теле тарихында менә шушы үсеш тенденцияләрен гомумиләштерүче һәм синтезлаучы яңа чор була[1].

Поэзиядә мондый юнәлешне киң рәвештә үстереп җибәрүчеләрнең берсе Г. Кандалый иде. Халык иҗатының поэтик образларын, тасвирлау алымнарын оста куллану нәтиҗәсендә халыкчанлык юнәлеше аның әсәрләрендә төп сыйфатка әверелә.

Саф татар теле үзенчәлекләре белән беррәттән, ул чорда әле башка телләрдән кергән алынмалар да шактый очрый. Мисалга Гали Чокрый, Акмулла, Муса Акъегет, Заһир Бигиев әсәрләрен алырга мөмкин. XIX гасырның икенче яртысында татар милли әдәби теленең нормалары ныгу һәм тотрыклылану процессы проза стиле формалашу белән турыдан-туры бәйле (Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» повесте, Заһир Бигиев романнары һ. б.). Бу чор прозасына халык теле нигезендә чынбарлыкны һәм иҗтимагый күренешләрне сәнгатьчә итеп нечкәләп сурәтләү хас. Шәхесне һәм табигать күренешләрен лирик-романтик, эмоциональ-поэтик тасвирлаганда телдән оста файдалану, XX гасырга чыккач, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов әсәрләрендә үзенең иң югары чагылышын таба. Проза теленең эмоциональ-эстетик функциясе киңәя. Анда элекке төрки һәм Көнчыгыш поэзиясе традицияләре буенча килә торган образлы тасвирлау алымнары халык сөйләм теле үзенчәлекләре белән кушылып бара. Димәк, милли әдәби телнең үсеше сурәтләү чараларының да төрле тармакта күпләп кулланылуына, телнең эчке мөмкинлекләреннән киңрәк файдалануга этәрә. Әнә шундый үсеш — янәрыш әдәби телнең нормалашу процессы белән янәшә бара.

Әдәби жанрлар һәм стильләр барлыкка килү җәмгыятьтәге күп төрле иҗтимагый тарихи сәбәпләр белән бәйле. Мәсәлән, татар драматургиясенең теле-стиле формалашу милли әдәби тел туу мәсьәләләре белән тыгыз үсештә карала. Беренче татар драмалары XIX гасырның икенче яртысында языла башлый. Әдәбиятның башка төрләренә караганда драматургиянең үзенә хас яклары бар. Диалог һәм монологлардан торып, персонаж сөйләменә нигезләнгәнгә күрә, драматургия стиле төрле социаль катлау вәкилләренә хас тел үзенчәлекләрен чагылдыра. Бу стиль формалашу өчен әдәби тел нормаларының җанлы сөйләм теленә нигезләнгән булуы шарт. XX гасыр башында революцион-демократик хәрәкәтнең киң колач белән үсүе әдәби телнең сөйләм теленә якынаю юнәлешен көчәйтеп җибәрә. Шул рәвешчә, әдәбиятның аерым төрләре һәм жанрлары үсеше әдәби тел стильләренең үсешенә дә этәргеч ясый.

Драматургиягә хас үзенчәлекләрне, туры сөйләмнең кулланылышын матур әдәбиятта күптәннән күзәтергә мөмкин. XIII—XIV гасыр язма истәлекләре «Кыйссаи Йосыф», «Нәһҗел-фәрадис», «Хөсрәү вә Ширин», «Гөлстан», «Бабахан дастан»ында, аннан соң XV—XVI, XVII—XVIII гасырларда иҗат ителгән язма истәлекләрдә, сәяхәтнамәләрдә диалогларга һәм персонаж сөйләменә киң урын бирелә. Болар барысы да, әдәбиятның аерым төре буларак, драматургиянең аерылып чыгуын тәэмин иткән. Шул рәвешчә, реаль чынбарлык, тормыш күренешләре диалогларда һәм персонаж сөйләмендә тулы чагылыш таба башлаган.

Матур әдәбият стиленең үсеше башка функциональ стильләр белән тыгыз бәйләнештә бара. Аеруча матур әдәбият әсәрләрендә публицистик элементларның, публицистик әсәрләрдә исә матур әдәбият алымнарының бергә кушылып килүләрен, керешеп китүләрен дә еш күзәтергә була. Татар әдәби телендә иҗтимагый-публицистик стильнең беренче яралгылары күптәннән башлана. Ул элекке тарихи-публицистик очеркларда, сәяхәтнамәләрдә, вакыйганамәләрдә, ораторлык сәнгатен эченә алган өндәмәләр, мөрәҗәгатьләр, нотыклар, указлар, манифестларда һ. б. чагыла. Ә XX гасыр башында вакытлы матбугат тугач, публицистика бик нык үсеп китә һәм ул иҗтимагый вакыйгаларга бәйле рәвештә әйдәп баручы жанрга әверелә. Матур әдәбият

[1] Бу хакта авторның «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» (Казан, 1972) дигән китабында тулырак мәгълүмат бирелә.

үзе дә күп материалны публицистикадан ала. Матур әдәбият әсәрләренең күпчелеге иҗтимагый-политик эчтәлеккә ия булалар һәм көчле публицистик рухта язылалар. Язучы һәм публицист бер-берсе белән аерылгысыз мөнәсәбәттә тора. Публицистик әсәрләрнең кайбер жанрлары (очерк, фельетон, памфлет һ. б.) матур әдәбият әсәрләренә бик якын. Шуңа күрә публицистик стильдә сәнгатьчә тасвирлау алымнары, эмоциональ һәм экспрессив чаралар шактый зур урын били. Матур әдәбиятка һәм фәнни әсәрләргә охшаш кайбер үзенчәлекләрне берләштергән хәлдә, публицистиканың үзенә генә хас булган жанр һәм стиль аерымлыклары барлыкка килә.

Шул рәвешчә, стильләр арасында тыгыз бәйләнеш яши һәм аларда әдәби телнең үсешендә күзәтелә торган төрле үзгәрешләр чагыла. Әдәби телдә элек-электән килгән китап теленә хас традицион үзенчәлекләр дә киң кулланыла. Алар, сөйләү теле белән кушылып, әдәби телнең состав өлеше булып китәләр.

Соңгы елларда тел гыйлемен, тел тарихын өйрәнүгә һәм язма истәлекләрне тикшерүгә зур игътибар бирелә башлады [1]. Билгеле бер эзгә төшелде, күп нәрсәләргә ачыклык керде. Әле алда да хәл ителәсе шактый күп проблемалар бар. Әмма шунысы ачык: хәзер татар теленең һәм тел гыйлеменең үсеше һич тә XX гасырның 20—30 нчы яки 40 нчы елларындагыча түгел инде. Без тел белемен тоткарлап килгән «яңа тәгълимат»тан да, вульгар социологизм шаукымыннан да арындык. Ниһаять, тел кануннарына объектив бәя бирә башладык. Бу юнәлеш киләчәктә дә тел һәм әдәбият гыйлемен үстерүдә якты маяк булып торырга тиеш.

xxxxxxxxxxxxxxxx

---

[1] Хәзерге чорда әдәби телне лингвистик-социологик юнәлештә тикшерә һәм программа нигезендә югары уку йортларында укытыла торган яңа фән — **татар әдәби теле тарихы** фәне туды. Ул әдәби тел нормаларының төрле дәверләрдә тарихи үсеш кануннарын, стильләр тарихын һәм аның барлыкка килү юлларын өйрәнә.

Марсель Зарипов

# КИҢРӘК КОЛАЧ БЕЛӘН

Мәкаләне саннардан башлап китәсе килә. Безнең республикада татар телендә язучы 130 Союз члены бар. Узган ел аларның, яңадан бастырган әсәрләрен дә кертеп исәпләгәндә, 90 лап китабы чыккан. Болары — Татарстан китап нәшрияты чыгарган китаплар гына. Шулар янына Мәскәүдә һәм илебезнең башка нәшриятларында басылган китапларны өстик. Һәммәсен бергә җыйсак, шактый зур бер сан килеп чыгар.

Инде рус телендә язучы иптәшләрнең китапларын санап карасак, 15 Союз членына 9 китап туры килә. Күргәнегезчә, иҗади союзыбызның руслар өлеше татар язучыларына караганда сүлпәнрәк эшли икән. Дөрес, монда мәсьәләнең тагын бер ягын исәпкә алырга кирәк. Татарстанда яшәүче рус язучылары әдәби тәрҗемә өлкәсендә аеруча актив эш алып баралар. Соңгы елларда алар татар язучыларының бик күп әсәрләрен тәрҗемә иттеләр. Мәсәлән, узган ел Ян Винецкий Габдрахман Минскийның «Яшенле яңгыр» повестен тәрҗемә итеп чыгарды. Бу өлкәдә Тихон Журавлев та бик күп эшли. Ул Рафаил Төхфәтуллинның «Агымсу» повестен тәрҗемә итте. Ел ахырында гына аның тәрҗемәсендә тагын бер әсәр — Шамил Рәкыйповның партизан Иван Кабушкинга багышланган «Кайда син, Жан?» дигән документаль повесте дөньяга чыкты. Рус язучылары татарча язылган шигырьләрне рус теленә тәрҗемә итү буенча да күп эшлиләр. Бу өлкәдә Рөстәм Кутуй белән Николай Беляевның активлыгын билгеләп үтәргә кирәк. Н. Беляев тәрҗемә әсәрләрен үз шигырьләренә караганда да күбрәк бастыра бугай. Мин бу мәкаләдә ул тәрҗемәләрнең сыйфатын тикшерергә, аерым юлларның, образларның сәнгатьчә үзенчәлекләрен өйрәнеп, аларга гомуми бәя бирергә җыенмыйм. Әмма бер нәрсә бәхәссез, Рөстәм Кутуй, Марк Зарецкий, Лидия Григорьева, Мария Аввакумова кебек шагыйрьләребезнең тәрҗемәләре Мәскәү тәрҗемәчеләренекеннән бер дә калышмый.

Рус телендә язылган китаплар аз чыккан дидек. Димәк, чыккан кадәресенә киңрәк тукталырга мөмкинлек бар. Барыннан да элек, Рафаэль Мостафинның активлыгын билгеләп үтәсе килә. Узган ел аның Муса Җәлилгә багышланган китабы берьюлы ике нәшриятта чыкты. «По следам поэта-героя» дигән ул китап башта йөз мең тираж белән Татарстан китап нәшриятында, аннары «По следам оборванной песни» дигән исем һәм 220 мең данә тираж белән «Дружба народов» журналына кушымта итеп чыгарылды. Ике ел эчендә 400 мең данә китап чыгару (шул ук китап бернечә ел элек 50 000 данә тираж белән «Детская литература» нәшриятында басылган иде) — авторның зур уңышы, бу, язучы буларак, аның үсүен күрсәтә торган факт.

Р. Мостафинның әлеге китабы турында да, Муса Җәлилнең иҗатын һәм героик көрәш юлын өйрәнүгә багышланган мәкаләләре турында да үзебездә булсын, үзәк матбугат битләрендә булсын бик күп мактау сүзләре әйтелде. Мин аларны кабатлап тормыйм. Аларның барысы да диярлек урынлы иде, дөрес иде. Игътибарыгызны язучының җитди тәнкыйть сүзеннән читтәрәк калган икенче әсәренә — «Полтора эк-

ватора» дип аталган кульязмаларына юнәлтәсе килә.

Авторның бу әсәре «Муса Җәлил» теплоходында сәяхәт итү нәтиҗәсендә язылa. Башта ул Татарстан китап нәшриятында басыла, аннары «Дружба народов» журналына кушымта итеп чыгарылган китапка урнаштырыла. Дөресен әйтергә кирәк, «Полтора экватора» әсәре Муса Җәлилнең үзе турындагы китаптан йомшак чыккан. Билгеле, монда объектив сәбәпләрне дә искә алмый ярамый. Муса Җәлил шәхесе, аның шагыйрь һәм солдат буларак кылган батырлыгы болай да укучыда кызыксыну уята, аны дулкынландыра. Әмма «Полтора экватора» әсәренең кимчелекләре турында сүз барганда, авторның бары тик үзеннән генә торган сәбәпләр хакында да әйтмичә калып булмый. Әйтик, кульязмаларда диңгез тормышын белгән һәр кешенең колагын ярып керерлек ялгыш атамалар очрый. Ләкин эш анда гына да түгел. Иң үкенечлесе шул, автор үзен һәм судно командасын бер бөтен итеп бәйли алмаган. Әйдәгез, болай фараз кылыйк: авторны Муса Җәлил исемен йөрткән теплоходка түгел, ә бөтенләй башка корабльгә утырттык, ди. Нинди аерма килеп чыгар иде икән? Мөгаен, автор корабль кем исемен йөртә, шул кешенең тормышына караган мисаллар, фактлар китерер, башка шигырьләр укыр иде. Корабль исемнәрен алыштырып куюдан әллә ни үзгәрмәс иде. Ә бит Муса Җәлилнең үзе турында язылган документаль китап белән танышканда бөтенләй башка хәл. Укучы, шагыйрь, көрәшче һәм гражданин буларак, аның батырлыгына соклана, укучы күңелендә шушы батырлык тарихын өйрәнүгә 10 ел гомерен багышлаган авторга карата хөрмәт уяна. Ә инде авторның, очраклы рәвештә килеп эләккән пассажир сыман, «Муса Җәлил» теплоходына утырып дөнья буйлап сәяхәт итүе турында укыганда, күңелдә аңа карата әллә ни зур хөрмәт туа алмый. Бу очракта, киресенчә, «Муса Җәлил» теплоходына утырып сәяхәт итү авторга дөнья күрү һәм үзен күрсәтү өчен бер сәбәп кенә булган дип карыйсың. Рафаэль Мостафинның кульязмаларында төпле фикер йөртү җитми. Ул тизрәк нәтиҗә ясарга, укучыга үзенең әзер фикерен көчләп тагарга ашыга. Ә аның ул әзер фикерләре белән һәр очракта да килешеп бетәсе килми. Мәсәлән, Сингапур шәһәре турында автор болай дип яза. «Бу күңелне үзенә тартып тора торган, экзотикалы шәһәр. Монда барлык дәүләтләрнең корабльләре килеп туктый. Шәһәргә нигез салучы кеше дә бар. Ул — инглиз лорды...» һәм автор шул лордның һәйкәленә карап тора да, аның турында җитәрлек мәгълүмат биреп, аңлатып тормастан: «Аның йөзе бик кырыс», дигән нәтиҗә ясарга ашыга. Укучы шәһәрнең ничек салынуын, шәһәр салганда нинди каршылыклар килеп чыгуын — берсен дә белми кала.

«Бу йөздә мин кан диңгезен, кол ителгән кабиләләрне, экономик, политик һәм социаль гаделсезлекләр өемен күрәм», — дип әйтеп, автор ялгышмый, әлбәттә. Барысы да дөрес. Әмма андый шәхесләр турында язганда, мәсьәләгә берьяклы гына карарга ярамый. Бер генә түгел, ә дистәләгән фактларны янәшә куеп, чагыштырып карарга, шуннан соң гына нәтиҗә ясарга кирәк. Мисалга океаннарның бөек адмиралы Христофор Колумбны алыйк. Ул да, үзе артыннан яңа җир яуларга ябырылган башка пиратлар кебек үк, бер юлбасар була. Адмирал испан королевасына җибәргән хатында үзе ачкан Һиндстан җиреннән ел саен 4 мең кол алып кайтырга мөмкин дип яза. Бу эштән никадәр табыш алачакларына кадәр исәпләп күрсәтә. «Колларның байтагы юлда үлеп тә калсын, ди, әмма барысы да үлмәячәкләр бит», — ди шөһрәт ятучы диңгез пираты... Күрәсез, Христофор Колумб та фәрештә булмаган икән. Әмма ни генә булмасын, Американы башка берәү түгел, ә нәкъ менә Колумб ачкан. Шуның өчен аның исеме гасырлар үтсә дә онытылмаячак. Аның диңгезче һәм флот башлыгы буларак осталыгын, кыюлыгын һәм батырлыгын һәр вакыт мактап сөйләячәкләр. Мөгаен, Сингапурга нигез салган кеше дә характеры белән башкалардан аерылып торгандыр. Шулай булмаса, ул кыргый агачлар гына үскән тропик урманнар уртасында килачәктә җир йөзендә бердәнбер дәүләтшәһәр үсеп чыгасын алдан күрә алмас иде. Мондый шәхес турында тулырак һәм объективрак мәгълүмат биргәндә дә начар булмас иде диясе килә.

Күрсәтелгән кимчелекләренә дә карамастан, Р. Мостафинның «Полтора экватора»сы бөтенләй өметсез әсәр түгел. Киресенчә, ул кызыклы һәм кирәкле зур эшнең башы гына булып торырга тиеш. Аның Җәлил турындагы документаль китабы ничек язылганын искә төшерик. Язучы шушы олы уңышка ничек иреште соң? Иң элек ул Муса Җәлил турында аерым публицистик мәкаләләр бастырып чыгарды. Аннары, шагыйрьнең дусты Гази Кашшаф белән бергә, «Эзләнү дәвам итә» дигән китап язды. Бо-

ларның берсе дә Р. Мостафинны олы әдәбият югарылыгына күтәргән әсәрләр түгел иде әле. Андый югарылыкка күтәрелү өчен язучыга еллар буена тырышырга, эзләнергә, тикшеренергә, иҗат газаплары кичерергә туры килде. Шуңа күрә аның «Муса Җәлил» теплоходында сәяхәт итү тәэсирендә язылган очерклар китабын да олы һәм җитди тикшеренүләрнең, киләчәктә туачак зур хезмәтнең башы гына дип карарга кирәк. Андый зур хезмәт язу өчен исә авторга бөтенләй мөмкинлекләр бар. Республикабызда гына да Муса Җәлил исеме белән бәйләнгән күпме кызыклы фактлар очрый. КамАЗда ул, мәсәлән, Вазыйх Мәүликов бригадасы члены булып, автогигант төзи. Районнарда шагыйрь исемен йөрткән колхозлар күп... Менә шул коллектив кешеләренең ничек яшәүләре турында сөйләү кызыклы булмас идемени? Теләк булган тәкъдирдә, автор шушы матур башлангычны дәвам итә ала...

Узган ел Михаил Скороходов үзенең яңа, җитди әсәрен тәмамлады. Казанда аның «Текә таулар» дигән китабы басылып чыкты. М. Скороходов — безнең якташыбыз: сугыш елларында ул Чистайда яши. Аннары Архангельскига күчеп китә һәм берничә ел элек туган якларга яңадан әйләнеп кайта. Татарстанда яшәгән берничә ел вакыт эчендә ул төньяк поморларының борынгы юллары буйлап сәяхәт итүгә багышланган кызыклы китап һәм күп кенә шигырьләр язды. Узган ел шулар янына «Текә таулар» романы өстәлде.

Роман язу Татарстанда яшәүче рус язучылары өчен сирәк очрый торган хәл. Алар язган романнарның иң соңгысы моннан ун еллап элек чыккан иде. Мин Ян Винецкийның нефтьчеләр тормышына багышланган «Тот, кто верит» дигән романын күздә тотам.

Язучының һәр китабы аның иҗат биографиясендә әһәмиятле бер этап булып тора. Сүз дә юк, «Текә таулар» романы да — язучы тормышында үзенә күрә бер биеклек. Әсәрдә хезмәт юллары Бөек Ватан сугышы елларында башланган урта буын вәкилләренең язмышы, аларның әйләнә-тирәдәге кешеләргә мөнәсәбәте турында сүз бара. Анда бик матур язылган аерым эпизодлар очрый. Әмма, тулаем алганда, роман зур әдәбият алдына куела торган таләпләргә җавап бирерлек булып чыкмаган. Авторга әдәби сиземләү, чама тойгысы җитеп бетми. Ул еш кына геройларының яшьләрен, характерларын онытып җибәрә. Геройларыннан яшьләренә хас булмаган эшләр эшләтә, алардан үзе әйтергә теләгән сүзләрне көчләп әйттерә. Мәсәлән, В. И. Ленин хезмәтләре хакында алар тәҗрибәле пропагандистларга караганда да акыллырак фикер йөртәләр. Сугыш турында, икенче фронт турында сүз барганда, геройлар авызыннан полководецларныкына караганда да төплерәк сүзләр чыга. Героебыз әле кечә генә бер кызны яраткан, үпкән була. Кызның станок белән тупас мөгамәлә итүен күргә үк ул мәхәббәтеннән баш тартырга әзер. Әсәрдә шундый бер эпизод бар: Игорь белән Андрей өлгергәнлек аттестатына инша язалар. Икесе дә автор тарафыннан намуслыдан да намуслырак кешеләр дип тәкъдим ителә. Инде шуларның кылган гамәлләренә игътибар итик: «...Андрей күз кырые белән генә Игорьнең сочинениесен тикшереп чыкты... Ике артык өтерен тапты. Комиссия членнарында шик тудырмыйча гына шул өтерләрне бетерү өчен ярты сәгать вакыт узды...»

Менә шушы тормышларын ялганнан башлаган һәм бернинди вөҗдан газабы кичермәгән геройларыбыз трибун шагыйрь В. Маяковскийның югары поэзиясе турында фикер йөртәләр, М. Горький геройларыннан үрнәк алырга, В. И. Ленинча яшәргә ант итәләр.

Романның икенче өлешендә геройларның берсе дөреслек өчен көрәшүче, үзенең гражданлык һәм партиялелек принципларыннан беркайчан да тайпылмый торган кеше итеп күрсәтелә. Ә бит укучы әле аның бик оста алдалый белә торган кеше икәнен хәтерли. Бер тапкыр алдашкан кеше икенче тапкыр да алдашмас дип кем әйтә ала? Шуңа күрә, әсәрнең геройлары дөреслек һәм намуслылык өчен көрәшүче кешеләр икәненә ышануы кыенрак.

Бер караганда, «Текә таулар» романында барысы да дөрес кебек. Явызлык җиңелә, яхшылык тантана итә. Баш герой үзенә каршы кешеләрдән өстен булып чыга, аны икенче эшкә — дәрәҗәлерәк урынга чакыралар. Әмма автор уйлап чыгарган бу хәлләрнең берсенә дә ышанасы килми.

Бездә язучы күтәрергә ярамый торган темалар юк. Һәр нәрсәне күтәрергә, һәр тема буенча яңа әсәр иҗат итәргә мөмкин. Әмма бер шарт белән: язучы үз әсәрендә тормыш чынбарлыгыннан читкә тайпылмаска, чорны дөрес чагылдырырга, барысы турында да марксистик-ленинчыл позициядән чыгып фикер йөртергә тиеш. Юрий Белостоцкий иҗатын тикшерергә керешкән-

че, тагын бер тапкыр шул сүзләрне искә төшерәсе килде.

Соңгы елларда ул иҗат активлыгын бик нык кечәйтте. Аның «Текә вираж» дигән беренче повесте моннан күп еллар элек чыккан иде. Шуннан соң ул бик сирәк басылып килде. Хәзер аның ел саен яңа китабы чыгып тора. Минемчә, моның бер сәбәбе вакыт белән бәйләнгән. Элек Ю. Белостоцкий өлкә газетасында эшли иде. Ә журналист профессиясе кешене бөтенләе белән үзенә йота. Хәзер ул Татарстан язучылар союзында әдәби консультант булып эшли. Иҗади атмосферада яшәү һәм буш вакытның күбрәк булуы язучының иҗат активлыгына уңай йогынты ясады. Соңгы елларда аның «Кыска шырпы» дигән хикәяләр җыентыгы дөнья күрде. Озак та үтми, Татарстанда оештырылган очучылар эскадрильясына багышланган «Күк серләр саклый» дигән повесте зур тираж белән басылды. Узган ел Юрий Белостоцкий тагын бер яңа әсәр — «Күк тә, гомер дә — бер генә» дигән повесть тәмамлады. Бу повестенда, алдагы әсәрләре белән чагыштырганда, язучының иҗади үсеше сизелеп тора. Автор характерларны психологик яктан дөрес ача, материалларны, детальләрне сайлаганда бик таләпчән эш итә. Аның сугыш турында кешедән ишетеп кенә түгел, ә үзе белеп язганы күренеп тора.

Әгәр безнең үз гербыбыз, үз эмблемабыз булса, мөгаен, әдәбиятчыны да, дөреслек алласы Фемида шикелле, кулына микрометр тоттырып ясарлар, әмма күзләрен ачык калдырырлар иде. Чөнки язучы күрә белергә һәм күргәннәренә бик төгәл бәя бирә белергә тиеш. Менә бу яктан карaганда, Ю. Белостоцкийга төгәллек җитми. Ул әсәренең башында ук бер хата җибәрә дә ахырдан бөтенләй ялгыш нәтиҗә ясый.

Авторның яңа әсәре дә хәрби очучылар тормышына багышланган. Бомбардировщиклар экипажы командиры Шуваловка фронт сызыгын үтеп чыгып, дошман объектларын фотога төшерергә һәм шул фотолар белән базага кайтырга дигән бурыч йөкләнә. Тик кузгалып китәргә генә торганда, көтелмәгән хәл килеп чыга. Бомбардировщикны дошман самолетларыннан сакларга тиешле истребительләрнең өч минутка соңга калулары беленә. Акылы булса, Шувалов яхшылап уйлап карарга һәм берсүзсез истребительләрне көтәргә тиеш иде. Ә ул уйлап та, көтеп тә тормый, «Әй, ни булса шул булыр» дип, ялгызы һавага күтәрелә. Билгеле, «Мессершмидт»лар самолетын утка тоталар. Ул үзе парашют белән җиргә сикерә, ә бортрадист һәм штурман һәлак булалар. Нәрсә бу? Батырлыкмы, әллә малайлыкмы? Малайлык, әлбәттә. Хәтта алай гына да түгел, бу хәлне хыянәт дип тә бәяләргә мөмкин. Чөнки командирның малайлыгы аркасында экипаж һәлак була, машина яна.

Сугышта вак-төяк нәрсә булмый, анда һәр нәрсә әһәмиятле! Мәсәлән, кырык өченче елның җәендә безнең гаскәрләрнең Курск дугасында җиңүгә ирешүнең бер сәбәбе, бер караганда, кечкенә генә нәрсәгә бәйләнгән кебек. Совет командованиесе, разведка материалларыннан файдаланып, немецларның кайсы юнәлештә, кайчан һөҗүм итәчәкләрен алдан белеп тора һәм дошман белән көрәшкә өстәмә гаскәрләр туплый. Сугышта батырлык эшләү, панфиловчылар кебек, приказны төгәл үти белүдә чагыла.

Әйдәгез, Л. Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романын искә төшерик. Анда шундый бер эпизод бар: бервакыт Александр патша рус армиясе белән командалык итүче Кутузов янына килеп чыга һәм аның ни өчен һөҗүмне башламавы белән кызыксына.

— Полкларның барысы да килеп җитмәгән әле, — дип җавап бирә Кутузов.

— Сез бит Царицын кырында түгел. Анда гына бөтен гаскәрләр җыелып бетмичә парадны башламый торалар, — ди патша.

— Нәкъ менә Царицын кырында түгел, ә сугышта булганга күрә һөҗүмне башламыйм да, — дип җавап бирә Кутузов.

Ю. Белостоцкий әсәрендә исә башкачарак килеп чыга. Хәрби частька әйләнеп кайткач, Шуваловны судка бирәләр. Ревтрибунал аны хәрби заданиене үтәүдән читкә тайпылуда, машинаны һәм иптәшләрен һәлак итүдә гаепли. Очучы штрафной батальонга җибәрелә. Шуваловка җәза дөрес бирелгәнме, әллә юкмы? Әйе, трибунал дөрес хөкем иткән. Чөнки Шувалов гаепле — автор үзе шундый нәтиҗә ясый. Аның гаебен киметә торган бер генә нәрсә булырга мөмкин. Ул да булса — суд тәмамланганнан соң штурманның исән калганлыгы беленә: ул ике атнадан соң исән-сау әйләнеп кайта һәм үзе белән дошман объектлары төшерелгән кассетаны да алып кайта. Шулай да Шуваловны тулысынча аклап булмый. Ә автор исә аны акларга тырышып карый. Ул, үзенә-үзе каршы килеп булса да, Шуваловны яклап калырга, ә ревтрибунал һәм штрафной батальоннар сугыш вакытында бөтенләй кирәксез нәрсәләр булган дип дәлилләргә тырыша.

Без, язучылар, үзебез иҗат иткән геройларны балаларыбыз кебек күрәбез. Безнең уңай һәм тискәре геройларыбыз була. Балалар арасында да аеруча ярата торганнары һәм бик яратып бетермәгәннәре очрый. Шуңа карамастан, ата-ана баланың һәркайсына бертөсле карарга тиеш. Кызганычка каршы, Ю. Белостоцкий кайбер геройларын артык нык ярата — аларның бөтен кимчелекләрен гафу итәргә әзер тора, ә кайбер геройларына үги балага караган кебек карый. Автор прокурорны да, суд тикшерүчесен дә, каравыл хезмәтендәге солдатларны да акылсыз диярлек кешеләр итеп күрсәтә. «Смерш» капитаны артык бәйләнчек итеп бирелә, ревтрибунал полковнигы, аныңча, очучыга бәйләнергә генә тора. Шуваловны штрафной батальонга озата баручы солдаттан көләр өчен, ул аны арты белән кадакка утырта. Шуваловны заданиегә җибәргән штаб начальнигы исә иң кабахәт кешеләрнең берсе итеп сурәтләнгән.

Шулай итеп, башка геройларына караганда Шуваловны артык нык яратуы аркасында, автор бөтенләй ялгыш нәтиҗә ясый. Укучыга ул чынбарлыкка туры килми торган фикер тага. Билгеле, мондый әсәрнең ышандыру көче дә зур була алмый.

Рус язучылары иҗат иткән иң уңышлы әсәрләр рәтеннән Рөстәм Кутуйның «Кышкы алмалар» җыентыгын билгеләп үтәсе килә. Бу китапта тормыш турында тирән фәлсәфи фикер, геройларга карата җылы мөнәсәбәт, тормыш тантанасына, дөреслекнең явызлыктан өстен булуына ышаныч сизелеп тора. Гәрчә авторның интонациясендә бик үк төгәл булмаган акцентлар чагылса да, Р. Кутуйның бу китабына кергән хикәяләре күп милләтле совет әдәбиятының иң яхшы әсәрләре югарылыгында эшләнгән.

Тагын шунысына да тукталыйк: язучы бит повестьлар, романнар, хикәяләр һәм шигырьләр белән генә яшәми. Ул җәмәгать эшләрендә катнашырга, аңарда гражданлык хисләре югары булырга тиеш. Ә менә рус секциясендә член булып торган иптәшләрне инде бу яктан һич тә мактап булмый. Күптән түгел «Советский писатель» нәшриятында рус шагыйре Александр Яшинның «Миләш белән сыйлыйм» дигән хикәяләр җыентыгы басылып чыкты. Анда шундый юллар бар: «Минем тормышым хәзер дә әле тулысы белән туган авылым тормышына бәйләнгән — якташларыма авыр булса, миңа да авыр, аларның эшләре яхшы барса, миңа да яшәргә һәм эшләргә җиңел...»

Бездәге рус язучыларының иҗатын тикшергәч, аларны «туган авыллары» бик аз кызыксындыра икән, дигән фикергә киләсең. Роман, повесть, олы поэма тиз генә язылмый. Кайчакта моның өчен берничә еллар уза. Һәм шул вакыт эчендә язучыга бирәр ашыгыч тема очрамый калмый. Шул турыда матбугатта бүген үк, хәзер үк фикереңне әйтергә кирәк була. Кызганычка каршы, Татарстанда яшәүче рус язучылары вакытлы матбугатта бик сирәк катнашалар. Гражданлык публицистикасы алар өчен чит нәрсә булып кала бирә. Узган ел Мария Елизарова «Казан утлары» журналында А. Пушкинның Казанга килүе турында кызыклы гына мәкалә урнаштырды, Геннадий Паушкин КамАЗ төзүчеләре турында еш яза, бервакыт Нонна Орешина «Правда» газетасында очучылар турында кызыклы гына репортаж язып чыкты, аның берничә очеркы башка үзәк матбугатта да басылды. Һәм менә шуннан башка тагын телгә алырлык берни дә юк бугай. Рус язучылары әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә бик пассивлар. Күрәсең, алар каләмдәш иптәшләренең иҗатлары, яңа чыккан китаплар, тормыш, әдәбият, сәнгать мәсьәләләре турында вакытлы матбугат битләрендә чыгыш ясауны кирәксенмиләр.

Хәер, гражданлык пассивлыгы өчен рус секциясе членнарына гына түгел, ә Татарстанның бүтән күпчелек язучыларына да үпкә белдерергә мөмкин. Кайчандыр Достоевский: «Без барыбыз да Гогольнең «Шинель»ннән үсеп чыккан кешеләр»,— дигән. Татарстан язучыларының да күбесе газетадан, вакытлы матбугаттан үсеп чыккан кешеләр. Әйдәгез, газета-журнал битләрен ачып карыйк. Хөрмәтле һәм танылган язучыларыбыздан кемнәр генә шушы жанрда иҗат итә икән? Алар — бик аз, кайбер язучы гадәти генә биш-алты хикәя, повесть яки роман язды исә, әйләнә-тирәсендәге тормышка үзенең әдәби снобизмы югарылыгыннан карый башлый. Фикеремне дәлилләр өчен тормыштан конкрет бер мисал китерәсем килә. КамАЗда беренче субайлар гына кагыла башлаганда, Татарстан язучылары тугызынчы бишьеллыкның шушы зур төзелеше турында коллектив җыентык чыгарырга карар иткәннәр иде. КамАЗ турында кемнәр генә, кайда гына язмадылар. Хәтта Америкада да китап чыкты. Чаллыда инде ремонт-инструменталь заводында җыелган машиналар да йөри башлады. Тиздән төп конвейер да хәрәкәткә киләчәк. Ә Татарстан язучыларының вәгъдә ителгән җыентыгы һаман юк. Эш болайга

киткәч, хәзер инде әйтүе дә кыен: гигант автозавод алданрак төзелеп бетәрме, әллә әдәбиятчыларыбызның юка гына җыентыклары алдан чыгармы икән?

Без гаҗәеп матур чорда яшибез. Язучы кеше совет халкының көндәлек эшендә, тормышында катнашып, үзенең төпле фикере, дәртле сүзе белән экономик, социаль һәм әхлакый проблемаларны чишүгә өлеш кертергә, бишьеллык геройларына дан җырларга тиеш. Ләкин мәсьәлә анда гына да түгел. Язучының тормышка тирән үтеп керүе аның иҗаты өчен бик кирәк. Чөнки тормышны тирәнрәк белү аның үзен дә баета, ул бернинди белешмәләрдән дә таба алмаслык бай материал туплый. Дөрестән дә, республикабыз язучылары ауга чыгу, балык тоту, табигать турында язганда, менә дигән итеп, М. Шолохов кебек оста итеп яза алалар, ә инде геройны бүгенге көннең конкрет эш обстановкасында күрсәтергә кирәк булса, зур инженер, колхоз председателе, өлкә күләмендәге җитәкче психологиясен ачарга туры килсә, монда инде бик примитив, беркатлы фикер йөртү килеп чыга.

Бу яктан караганда, тагын Рөстәм Кутуйны мактап телгә аласы килә. Ул конкрет чынбарлыктан читкә тайпылмый, җыентыгының исемен дә җанлы кешедән — гомер буена кышкы алмалар үстерү белән шөгыльләнгән Галина Ивановна Розанова турындагы очерктан алган. Мин бу очеркның ничек язылуын, матбугатта нинди каршылыкка очравын беләм. Башта аны автор «Советская Россия» газетасына тәкъдим иткән иде. Анда басмадылар. Ә «Сельская молодежь» журналы шул әсәре өчен авторга 300 сум бүләк бирде.

Тугызынчы бишьеллыкның соңгы елы тәмамланып килә. Унынчы бишьеллыкта совет халкы алдына бүгенге көнгә караганда да зуррак бурычлар килеп басар. Совет халкының шушы олы иҗади хезмәтендә әдипләр дә турыдан-туры катнашырга тиеш. Әдәбиятның бөтен жанрларында — күп томлы эпопеялар да, романнар да, поэмалар да, үткен телле, ялкынлы публицистик очерклар да язарга кирәк. Әйдәгез, үзебезне сынап карыйк, төрле жанрларда иҗат итик. Үзебезне дә, көчебезне дә, сәләтебезне дә кызганмыйча эшлик.

## Таһир Нурмөхәммәтов

# ҮЗ ГАЛӘМЕ, ҮЗ КИҢЛЕКЛӘРЕ

Тәрҗемә әдәбиятның, чыннан да, үз галәме, үз киңлекләре бар. Узган ел ул, Балтик ярларыннан алып, үзбәк, казакъ җирләре аша, ерак Себер тайгаларына хәтле булган киңлекне һәм өч-дүрт гасырлык вакытны иңләп алды. Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган тәрҗемә китаплары арасында, бүгенге көн язучылары белән бергә, бөтендөнья классикасы үрнәкләрен дә байтак очратырга була.

Большевиклар партиясен В. И. Ленин төзеде. Партия аның мәхәббәте иде. Авыр көрәш елларында большевикларны төрмә белән каторга михнәтләре дә, дар агачлары да куркыта алмады. Дөньяда большевиклар партиясен җиңәрлек, аны революцион идеалларыннан ваз кичтерерлек көч юк иде. Елизавета Драбкинаның «Октябрь балладасы» исемле повесте революцияне хәзерләгән партиябезгә, юлбашчыбыз В. И. Ленин белән аның сугышчан көрәштәшләренә багышланган. Бу китапны Гыймади Камалиев тәрҗемә иткән.

Революцион көрәш идеяләре ерак провинцияләргә, шул исәптән, үзбәк халкына да барып ирешә. Ак патшаның ерткыч политикасына, империализм сугышына, ачлыкка, сусызлыкка түзә алмаган үзбәк халкы 1916 елда баш күтәрә. Тарихта Җиззах восстаниесе дип йөртелгән бу баш күтәрү Көнчыгыш халыкларының революцион аңын уятуда зур роль уйный. Тик аның ахыры

гына аянычлы булып бетә — восстание рәхимсез рәвештә бастырыла. Нәзир Сәфәревнең «Каргышлы һәм өметле көн» исемле романы әнә шул канлы вакыйгаларны сурәтли. Романны үзбәкчәдән Ясыйр Шәмсетдинов тәрҗемә иткән.

Бездә үз өлкәсе, үз темасы булган тәрҗемәчеләр бармак белән генә санарлык. Мәсьәләгә бу яктан караганда, Г. Камалиев та, Я. Шәмсетдинов та гаҗәп дәрәҗәдә даимилек, эзлеклелек күрсәтәләр. Г. Камалиев, мәсәлән, Октябрь революциясенә, революционер-көрәшчеләргә багышланган дүрт-биш китап тәрҗемә итте. Я. Шәмсетдинов исә үзбәк әдәбиятыннан гына да әллә ничә повесть һәм роман тәрҗемә итеп чыгарды. Фирдәвес Болгарскаяның да үз темасына — мәктәп тормышына багышланган китапларга тугры калуын әйтергә кирәк. Узган ел ул Владимир Кузнецовның «Очар кош» исемле романын чыгарды. Әсәр укучы яшьләребезнең хыял дөньясы, яшьлек хисләре белән тулы. Шуның белән бергә, әлеге тәрҗемәчеләрнең һәркайсы өчен характерлы булган бер кимчелек турында да әйтеп китәсе килә. Г. Камалиев та, Ф. Болгарская белән Я. Шәмсетдинов та вакыт-вакыт әдәби тәрҗемәнең нечкәлекләрен онытып җибәрәләр, үз тәрҗемәләренең сыйфатына, тел ягына тиешле игътибар биреп җиткермиләр. Дөрес, арада үзенең колоритлы, халык әйтемнәренә бай тәрҗемәсе белән Я. Шәмсетдинов аерылыбрак тора. Ул үзбәк халкының этнографиясен, гореф-гадәтләрен, гомумән, урта Азия халыкларының тел үзенчәлекләрен яхшы белә. Ләкин аңа да халык мәкальләрен, образлы тәгъбирләрне кулланганда саграк булырга кирәк. Юкса, кайчак аның тәрҗемәләре артык купшы була, кара миләш кебек, авызны бөрештерерлек дәрәҗәдә төче килеп чыга.

Узган елның тәрҗемә өлкәсендәге уңышы итеп мин Л. Толстойның К. Миңлебаев тәрҗемәсендә чыккан «Казаклар» повестен, Жюль Верның Ф. Гайнанова тәрҗемә иткән «Капитан Грант балалары»н (II кисәк), Г. Сабитовның «Богау чыңнары»н (Н. Иксанов әсәре) һәм Л. Хәмидуллин тәрҗемәләрен санар идем.

Кыям Миңлебаев Л. Толстой әсәрләрен беренче мәртәбә генә тәрҗемә итми. Бөек рус язучысының иҗатын якыннан белүе, гомумән, елдан-ел үсә барган осталыгы, зур тәҗрибәсе аңа «Казаклар» повестен да нәкъ үз дәрәҗәсендә тәрҗемә итәргә мөмкинлек биргән. Әмма кеше хатадан хали түгел, диләр. Кайбер кимчелекләр К. Миңлебаев тәрҗемәсендә дә очрый. Мәсәлән, китапның IV бүлегендәге менә бу җөмләне мин берничек тә аңлап җитә алмадым: «...Аның болганчык суы (сүз Терек елгасы турында бара — Т. Н.) киңәйгәннән-киңәя, сабырланганнан-сабырлана... текә сул ярны акрынлап ашый-кимерә, йөзәр еллык иманнәрнең тамырларын каезлый (?), черүгә тиз бирешә торган чинар һәм яшь агачларны **җыю төшерә** (?)».

Миңа калса, вакыт-вакыт К. Миңлебаевның җөмләләре интонациясе ягыннан бертөслегә әйләнә: «Капкадан әйләнеп **торганчы**, башкалар кебек, чытырман аша **гына** чыгарга булды. Киемендәге чәнечкеләреннән арынырга **өлгергәләгәнче**, әте алга йөгереп тә китте, ике фазанны җирдән дә күтәрде» (91 бит). Аның тәрҗемәләрендә менә шундый кимчелекләр, янә дә персонажлар телендә генә булырга тиешле шивә сүзләрне автор телендә куллану очраклары шактый. Җимешсез агачны селкетмиләр, ди халык. Әгәр К. Миңлебаевның алмалы агачын килеп-килеп селкеткәлиләр икән, моңа бер дә үпкәлисе юк. Аңа да, масаерга яраткан бүтән каләмдәшләребезгә дә тәнкыйтьнең шифасы тими калмас.

Үткән ел күренекле казакъ язучысы Әнвәр Әлимҗановның ике повесте, татар теленә тәрҗемә ителеп, аерым китап булып чыкты. Тәрҗемәчесе — Лирон Хәмидуллин. Ә. Әлимҗанов әсәрләрен рус телендә яза һәм, әйтергә кирәк, рус теле байлыгының барлык нечкәлекләрен белеп яза. Аның бу повестьларын тәрҗемә итүнең үз авырлыклары бар. Беренчедән, ни генә әйтмә, алар казакъ тормышыннан алып язылган, һәм ул тормышны, бөтен милли үзенчәлекләрен саклап, татар язучысына да җиткезә белергә кирәк. Аннан Ә. Әлимҗанов әсәрләре безне еш кына казакъ һәм Һинд илләренең борынгы тарихына алып кереп китә. Ә ул чорларны өйрәнмичә, белмичә торып, аның әсәрләрен уңышлы тәрҗемә итү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Бәхеткә каршы, Л. Хәмидуллин казакъ әдәбиятын әйбәт белә. Шул аңа бик күп кыенлыкларны уңышлы төстә җиңеп чыгарга булышкан.

Билгеле булганча, «Отрар хатирәсе»нең оригиналы бер-берсенә бәйләнгән кыска-кыска дүрт повестьтан тора. Мәскәү нәшриятларында булсын, тугандаш республикаларда булсын, аларны бер-берсеннән аермыйча бастырып киләләр. Безнең нәшриятта ул «кыскартылып», бары ике повесть кы-

на булып чыккан. Шуның нәтиҗәсендә тәрҗемәче аларны никадәр генә тулыландырырга, очын-очка ялгарга тырышмасын, повестьларның эчтәлеге аңлашылып җитми. Кәгазьгә экономия ясыйбыз дип кенә, мондый эшкә бармаска кирәк иде, билгеле.

Җай чыкканда, шунысын да әйтеп калырга кирәк, тугандаш казакъ халкы алдында без әле шактый бурычлы. Алар 30 нчы елларда ук Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы»н, 50 нче елларда Гомәр Бәшировның «Намус»ын, 60—70 елларда Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр»ен, Ш. Усманов әсәрләрен, татар язучыларының күп кенә хикәя һәм шигырь китапларын казакъ телендә чыгардылар. Г. Тукай җыентыклары аларда даими тестә басылып тора, 1975 елда казакъ дусларыбыз аның тагын бер җыентыгын бастырдылар. Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романы Бари Мәҗитов тарафыннан казакъчага тәрҗемә ителеп бер мәртәбә басылып чыккан иде инде. Киләсе елда бу романның икенче басмасы дөнья күрәчәк...

Совет халыклары арасындагы интернациональ дуслыкны тагын да ныгыта баруда әдәбиятның роле зур. Безгә тугандаш халыкларның, шул исәптән, казакъ әдәбиятының үрнәкләрен дә күбрәк чыгару һәм бу эшне ныклы план нигезендә алып бару турында уйларга кирәк.

*

* *

Шулай бервакыт татар китабының тарихын өйрәнүче, танылган галимебез Әбрар Кәримуллиннан: «Достоевский әсәрләре татар телендә чыкканы бармы икән?» — дип сорагач, ул икеләнебрәк: «Нәрсәседер басылган булырга тиеш»,— дип җавап биргән иде. Ләкин берничә көннән килеп, Ф. Достоевский турында татар матбугатында бер генә мәгълүмат та табылмады, аның бер генә әсәре дә татарча чыкмаган дип әйтте.

Димәк, Татарстан китап нәшрияты, язылуына йөз елдан артык гомер үткәннән соң «Җинаять һәм җәза» романын чыгарып, Федор Достоевскийны татар укучысына беренче мәртәбә ача. Шуңа күрә, бу тәрҗемә әдәбиятыбыз өчен генә түгел, ә бөтен культура үсешебез өчен дә бер вакыйга булып саналырга тиеш.

Романның эчтәлеген сөйләп тору кирәкме икән?.. Хәтерлисездер, Родион Раскольников төшендә сабый чак эзләре буенча әтисе белән җитәкләшеп йөри, туганнарының каберенә зыярат кылырга бара. Юлда алар бик кыргый бер тамашага очрыйлар. Йөгәнеп беткән арык ат җигелгән олауга төрле бозык халык төялгән: исерекләр, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр. Атны чыбыркылыйлар, сыртын каезлыйлар, ләкин йөге кирәгеннән артык авыр, ул кузгалып китә алмый тора. Ачуларыннан шашынган кешеләр—реакция көчләре, карагруһчылар — аның башына, күзенә сугарга кушалар... Ниһаять, аны, башына лом белән бәреп, кыйнап үтерәләр. Ат — Рәсәй иле — харап була. Нәни Раскольников дөнья ярып кычкыра, үлгән атның канлы башын кочагына алып, күзләреннән, иреннәреннән үбә. Билгеле, моңа карап кына ул терелми. Нәрсәдер эшләргә, кыю адым ясарга кирәк. Ярлы студент Раскольников ачлыкка, мохтаҗлыкка каршы протест белдерә, меңләгән кешеләрне упкыннан тартып алырга тели. Ул, шушы максатка акча юнәтү өчен, башкаларның гомерен үрмәкүч кебек имеп туенучы растовщик карчыкны үтерә... Нәкъ менә шушы урында авторның кисәтүле фикере алга чыга. Кеше җаны — чебен җаны түгел, аңа каршы кул күтәрү — кан кою белән бәйле. Әгәр син кеше җанын кыясың икән, Себер каторгасы белән дә котыла алмыйсың, сине иң куркыныч җәза — вөҗдан газабы, намус газабы көтә...

Л. Толстой әйткән бугай: язучы конфликтларны шундый итеп корсын, ул укучыны, якасыннан элэктереп алып, әсәренең ахырына хәтле җибәрми торсын. Ф. Достоевский исә элэктереп алу гына түгел, үзеңне дер селкетә, һушыңны алырлык дәрәҗәгә җиткезгән чаклары була. Бу, иң элек, язучының искиткеч осталыгыннан, аннары тәрҗемәче Рәис Даутовның әсәрне укучыларга тиешле биеклектә җиткерә белүеннән киләдер, дип уйлыйм.

Әсәрне кем генә укыса да, Р. Даутовның тел байлыгына сокланмый калмас.

«— Соң бераз гына утыр инде, **моржаңа ут капмагандыр** бит!» (141 бит).

«— Сиңа тагы **атаң башы** кирәкмени? — дип кычкырды янә Разумихин югары каттан» (142 бит).

Тәрҗемәдә персонажларның **теле дә** гаҗәп оста бирелә.

«— Нигә соң качып йөрдең?

— Курыктым, — ди бу.

— Ә ни өчен асылынмакчы булдың?
— Кайгыдан, — ди.
— Нинди кайгыдан?
— Өтермәгә ябарлар дип кайгырдым» (175 бит).

«— Журналмы? Журнал ул, энекәем, шундый **картинкә**, буяулы **картинкә**; мондагы тегүче халкы андый **нәстәне** һәр шимбә саен пушты белән алдыра» (216 бит).

Романдагы диалогларны укыганда, әсәрнең заманы, ул заманның кешеләре күз алдына килеп баса.

Р. Даутов фәнгә, философиягә, дингә караган урыннарны, гыйлем иясләренең фикер сөрешен, әйтик, юстициягә караган катлаулы уй-фикерне, укучыга соклангыч дәрәҗәдә эзлекле итеп, ачык итеп җиткерә. Тикшерүче Порфирийның, кеше психологиясен истә тотып, бик астыртын, мәкерле-нечкә итеп сорау алулары — болар һәммәсе дә татарчага оста күчерелгән.

Тәрҗемәченең көче әдәби тел байлыгын никадәр шәп белүенә бәйле. Бу яктан караганда, Р. Даутовка тел-теш тидерерлек түгел. Әдәби телне шәп белүе өстенә, аның үз гыйбарәләре, үзенчәлекле үз образлары булуын да әйтергә кирәк. Әсәрне бертөрлелектән, укучыны ялыгудан саклап калу өчен, ул татар әдәби теленең бөтен мөмкинлекләрен файдаланырга тырыша, хәтта тел кагыйдәләренә нигезләнеп, үзе дә сүзләр ясарга тотына: «Эңгер-меңгер **төшәр** чак» (70 бит); «һәм менә күп еллар яшерен янган шул хыял **гамәли** якка борылды» (380 бит); «Аның нигезендә **китаби** хыяллар ята» (565 бит); «**Еламсык** хатын-кыз табышы» һ. б.

Шул ук вакытта, Р. Даутовның тәрҗемәләре кимчелекләрдән дә азат түгел икәнлеген икърар итәргә тиеш булабыз. Мәгънәне дөрес бирү — тәрҗемәдә төп принцип. Мәгълүм булганча, Ф. Достоевскийның бу әсәрендә Катерина Ивановна бераз арттырып, мактанып сөйләргә ярата. «Взяла да выдумала, и не то чтоб из легкомыслия». Р. Даутов «легкомыслие» сүзен «аумакайлык» дип тәрҗемә иткән. 371 биттә: «...Минем белән уртак тел табасына ышанычы, **дәгъвасы** зур булуын әйтте», диелә. Монда «дәгъвасы» урынына «өмет» сүзе сорала. «Әйтергә кирәк, мондый көндәлек фактларны Соня бөтен ваклыкларына хәтле **тәфтишләп** яза иде» (678 бит). Әлбәттә, «тәфсилләп» язу сорала.

Мондый хаталар Р. Даутов тәрҗемәсендә күп түгел. Алар, вак ташлар поездны туктата алмаган кебек, әсәрнең агышын туктата алмыйлар.

Әсәрнең тигез агышына зыян китерерлек хаталар бүтән характердарак. Рус теленең үзенчәлекләренә нигезләнеп төзелгән образларны сүзгә-сүз тәрҗемә итәргә ярамаганлыгын Р. Даутов белми түгел. Ф. Достоевский кешенең ябык, озын гәүдәсен шырпы белән чагыштырырга ярата. Мәсәлән, «высокая и тоненькая, как спичка», ди. Кешенең кулын да шулай чагыштыра. Ләкин моны: «**шырпыдай** нечкә озын кулы...» дип тәрҗемә итәргә ярамый иде («җептәй нечкә озын кул» кирәктер бәлки). «Коридор караңгы иде; алар **лампа яктысы** астындарак тукталганнар иде» (388 бит). Мин бу җөмләгә бик тиз игътибар иттем. Коридордагы караңгылык турында сөйләгәндә, ничек индә язучы лампа яктысын телгә алды икән, дип гаҗәпләндем. Русчасын ачып карасам, анда: «В коридоре было темно, они стояли **возле лампы**» диелгән.

Мин кайчандыр, М. Галәүнең Рәис Раутов тәрҗемә иткән «Мөһаҗирләр»ен бик яратып укыган иде. Исегездәме икән, авыл халкы бунт күтәргәч, кемдер приставның кылычын йолкып алып атып бәрә. Тәрҗемәче шунда: «кылыч **чыңгырап** идәнгә төште», ди. Корычтан чүкелгән кылычның нәкъ үз сүзе, үз авазы табылган. Ләкин шул ук «Мөһаҗирләр»дә менә икенче бер нәрсә сәерсендерде. Геройларның берсе (Сафа бугай) төрмәгә эләгә, аның кәефе дә начар, камерадагы күренеш тә матур түгел. Шул вакыт тәрҗемәче түшәмдәге бик зәгыйфь электр лампасыннан нурлар сирпеттерә. Юк, лампадан нур сирпемәскә тиеш **иде**. «Сирпү» сүзенең үз урыны, үз «мохите» бар. Менә шундый ярашмауны аның әлеге тәрҗемәсендә дә кургәлибез. Ул хатын-кызларны **якага-яка килеп** талаштыра (26 бит), «**Шәһәр уч төбендәгедәй җәйрәп ята**», ди (70 бит).

Разумихин оригиналда бик игелекле, йомшак күңелле кеше итеп бирелә. Менә ул, дустының хәерче киеменә игътибар итеп, болай дип дәшә: «Да ты, брат, нашего брата перещеголял — прибавил он, **глядя** на лохмотья Раскольникова». Монда авторның «глядя» дип әйтүендә бернинди кискенлек, дорфалык юк. Әмма

тәрҗемәче Разумихинны сәләмә киемгә **күзләре белән кадаттыра** (140 бит). Тәрҗемәдә персонажлар гомумән бер-берсенә кадалып кына торалар. «Порфирий... Николайга кыргый күзләре белән **төбәлеп каткан** Раскольниковка борылып карады...» (437 бит); «Икесе дә бер-беренә **төбәлешеп каттылар»** (443 бит); «Соня... Петр Петровичның йөзенә текәлде һәм, аңа **тәмам берегеп каткандай**, күз карашын бүтән аңардан читкә алмады» (462 бит) һ. б.

Тәрҗемәдә фигыльләрнең гаҗәп «оригиналь» төрләрен очратырга мөмкин. Сүз төреләрне алыштыру турында барганда, тәрҗемәче болай ди: «Без аның белән **алышындык...»** (527 бит). «Порфирий, ничектер, Раскольниковның күз карашыннан качкан сыман, **бөкрәя төшә биреп** чыгып китте» (577 бит).

Р. Даутов киләчәк заман фигыльләрнең күп кенә вариантларын ясый: «Кыскасы, бурычыңны **түләячәгеңә** тегеләрне тәмам ышандырып, бу эшне... йолкып ташларга боердым...» (157 бит). Бик фәкыйрь, асрау кыз Настасья мәктәп грамматикасын гына түгел, вуз грамматикасын да өйрәнгән дип белерсең. Ул артык грамоталы итеп сөйләшә: «— Чәй **эчәчәксеңме**, әллә юкмы?— дип сорады Настасья» (193 бит).

Р. Даутов иркенләп, җөмләләрне җәеп-җәеп тәрҗемә итәргә ярата. Ләкин аның бу гадәте кайвакыт бөтенләй кирәкмәгән, эчпошыргыч тәфсилләүләр китереп чыгара: «**Ул тәмам** *теше-тешкә тимәс бер хәлдә* **бөтен гәүдәсе белән** *дер-дер* **калтырый** башлады» (112 бит).

«Җинаять һәм җәза» әсәренең тәрҗемәсенә карата күп кенә тәнкыйть сүзләре әйтергә туры килде. Әмма Р. Даутов — нигездә әйбәт тәрҗемәче. Аның бу хезмәтен укучыларга зур бүләк дип санарга була. Югарыда искә алынган кимчелекләр исә барыбызга да, һәммә тәрҗемәчеләргә дә хас алар. Без соңгы вакытта артык тынычланып киттек, ахрысы. Татарстан язучыларының соңгы съездында өлкән бер тәнкыйтьче әйткәнчә, үз эшебезгә анализ ясамый башладык. Юк, гамьсезлекне бетерергә иде, аның ахыры бервакытта да хәерле булмас.

*

*    *

Әдәби тәрҗемәдә аеруча зур игътибар бирүне сорый торган бер өлкә бар. Ул — поэзия тәрҗемәсе.

Поэзияне шагыйрьләр борын-борыннан гөл бакчасына тиңләп килгәннәр. Алар белән килешик, поэзияне гөл бакчасы дип атыйк ди. Ул чагында тәрҗемә ителгән шигырьне нинди гөлгә тиңләргә соң? Бу очракта гасырдан-гасырга татар өйләренең тәрәзә төпләрен бизәп килгән яран гөлен мисалга китерүем өчен шагыйрьләр гафу итсеннәр. Кайчандыр бик ерак Африка якларыннан алып кайтып утыртылган бу гөл чынлап та халкыбызның җырларына кергән, яраткан гөленә әйләнеп киткән. Тәрҗемә шигырьләр дә, әнә шулай бүтән әдәбият туфрагында җирлек табып, милли әдәбиятның яраткан гөленә әйләнеп китәргә тиеш дип уйлыйм. Әйтик, безнең шигырь тәрҗемәчеләре поэзия бакчабызда Габдулла Тукай, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким һәм башка шагыйрьләребез әсәрләре белән янәшә торырлык гөлләр үстерергә бурычлы.

Теләсә кемне тәрҗемә итеп булмый. Г. Тукай, мәсәлән, йөрәгенә якын булган М. Кольцов, А. Пушкин һәм М. Лермонтов шигырьләрен тәрҗемә иткән, алардан илһам алган. Немец шагыйре Гейнены XIX гасырда ук рус теленә тәрҗемә итә башлыйлар. Ләкин ул тәрҗемәләр сәнгатьчәлек күзлегеннән караганда бик түбән була. Гейне бары А. Блок белән очрашканнан соң гына рус укучылары аны үз шагыйрьләредәй кабул итәләр. Бездә исә хәзер кайбер шагыйрьләр кулына кем эләксә шуны тәрҗемә итү юлына басып киләләр. Без соңгы 7—8 ел эчендә шигъри тәрҗемә өлкәсендәге поэзия бакчасын ташландык хәлгә китерә язганбыз. Ул бакчаны киртәләп алмый торып, аңа чын бакчачы хуҗалар табылмый торып, анда гөлләр үстерү хыял гына булыр иде. Шагыйрьләр белән тәрҗемәчеләрнең ел ахырында уздырылган җыелышында шигъри тәрҗемәләрнең сыйфаты хакында бик кискен сүзләр әйтелгән иде.

Мәсьәлә бик принципиаль булу сәбәпле, мин шул җыелышта чыгыш ясаган өлкән шагыйрьләребезнең төп фикерләрен, сөземтә генә хәлендә булса да, кабат искә төшереп китүне кирәк саныйм:

— Сан ягыннан куу дөрес түгел. Кемне тәрҗемә итү, нинди әсәрне тәрҗемә итү турында уйларга кирәк. Тәрҗемә өлкәсендә үзебезнең ирешкән дәрәҗәбезне — Г. Тукайлар, Һ. Такташлар дәрәҗәсен төшермик.

— Соңгы елларда татар шигырьләрен француз, инглиз һ. б. чит телләргә тәрҗемә итеп чыгарганнар. Алар барысы да рус теле аша эшләнгән. Без беребез дә моны белмәдек. Баксаң, күбрәк очраклы әсәрләр, очраклы кешеләр тәрҗемә ителгән. Ә бит алар аша татар әдәбиятына, татар поэзиясенә бәя бирелә, фикер туа.

— Тәрҗемәнең төп принцибын истә тотарга кирәк: тәрҗемә халыкның рухын бирергә тиеш. Тәрҗемә итә торган халыкны яхшы белергә, өйрәнергә кирәк. Бүтән халык поэзиясе үрнәкләрен урта кул сыйфатта үз халкыңа тәкъдим итү булмасын, ә, киресенчә, яхшының да яхшысын күрсәтергә иде. Тик шул чакта гына тәрҗемә эше халыклар дуслыгын ныгытуга ярдәм итәчәк.

— Тәрҗемә эше — иң зур тәҗрибәле шагыйрьләр башкарасы эш ул.

*

* *

Рус һәм бөтенсоюз укучысын татар язучыларының иң яхшы әсәрләре белән дә таныштырып бару — бик авыр һәм җитди мәсьәлә. Үткән ел Татарстан китап нәшрияты Г. Минский, Г. Әпсәләмов, Р. Төхфәтуллин, М. Мәһдиев, Ш. Рәкыйпов, М. Хәсәновларның проза әсәрләрен, Х. Туфан, Р. Фәйзуллин, М. Шабаевның шигырь һәм поэмаларын рус телендә бастырып чыгарды. Татар язучыларының әсәрләре илебезнең үзәк, тугандаш республика һәм өлкә нәшриятларында да еш басыла. Әгәр 1973 елда үзәк нәшриятларда татар язучыларының 11 китабы чыккан булса, 1974 елда ул сан ике дистәгә җитте. Алар арасында Г. Тукай шигырьләре, М. Әмирнең «Балыкчы ялганнары» («Рыбацкие байки»), Г. Бәширов төзегән «Күңелле мәзәкләр» («Веселая россыпь»), А. Расихның «Дустым Мансур» романы («Мой друг Мансур»), Ә. Исхак, Ш. Мөдәррис, Ш. Галиев, З. Нури, Р. Фәйзуллинның шигъри әсәрләре, М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар»ы («Большая земля под крылом»), Р. Мостафинның «Өзелгән җыр» исемле китабы («По следам оборванной песни») һәм башка китаплар бар.

Бу җаваплы фронтта С. Липкин, Л. Ленч, Анатолий Чехов, Е. Леваковская, Р. Моран, Вл. Чивилихин, К. Горбунов, В. Гончаров, В. Ганиев, В. Кузнецов һәм безгә күптән мәгълүм Р. Фәизова, Х. Хәсәенова, Т. Журавлев, М. Рафиков, Р. Кутуй, М. Зарипов, Я. Мостафин, Н. Беляев кебек тәрҗемәчеләр эшли.

Югарыда искә алынган тәҗрибәле тәрҗемәчеләргә ияреп, алардан калышмаска тырышып эшләүче яшь каләмнәребез дә бар безнең. Узган ел аларның берничәсе Россия Федерациясенең Язучылар союзы идарәсе оештырган семинарында катнашты. З. Халитова, Р. Такташ, Н. Мальшакова белән А. Бадюгина хезмәтләре, Мәскәүнең күренекле әдәбиятчылары тарафыннан рецензияләнеп, яхшы бәя алды.

Тәрҗемәнең үз кыенлыклары, үз авырлыклары бар. Мәсәлән, Р. Даутовның тәрҗемәсен тикшергәндә, мин бер нәрсәгә игътибар иттем. Ул әсәрнең тәрҗемә иткән өлешенә, бит кырыена көн саен числосын куеп барган. Бер көнгә бары бер җөмлә тәрҗемә иткән очраклары да күп. Ләкин безнең хезмәт никадәр генә кыен булмасын, безгә киртәләрне үтмичә, үрләргә үрләмичә булмый. Кыен чакларда безгә һәр вакыт өлкән буын тәрҗемәчеләрнең иҗаты, аларның тәҗрибәсе, киңәше ярдәм итә. Әхмәт Фәйзи, Ибраһим Гази, Кашфи Басыйровлар, Хәсән Туфан, Шәйхи Маннурлар, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Афзал Шамов, Сәрвәр Әдһәмовалар — безнең хәлебезгә керүчеләр, безгә канат бирүчеләр. Аларның: «Бу яшьләр без очырган кошлар бит. Оясында ни күрсә, очканда шуны күрер»,— дип горурланып әйтергә хаклары бар.

# ӘДӘБИ ОСТАЛЫК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Фатих Хәснинең «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?» исемле яңа китабы[1] төрле елларда, төрле вакыйга уңае белән язылган тәнкыйть мәкаләләреннән төзелгән. Аларның һәркайсында диярлек нинди дә булса актуаль мәсьәлә күтәрелә. Бу фикерне дәлилләү өчен, конкрет мисалларга мөрәҗәгать итик. Җыентык «Күп милләтле — күп бизәкле» дигән мәкалә белән ачыла. Исеменнән үк күренүенчә, язучы биредә безнең игътибарны һәр әдәбиятның милли үзенчәлекләрен өйрәнү мәсьәләсенә юнәлтә. Ул бик хаклы, илебездәге төрле милләт әдәбиятларының сәнгатьчә үзенчәлекләрен өйрәнми торып, совет әдәбиятының эстетик байлыгын тулы рәвештә күз алдына китереп булмаячак. Дөрес, безнең әдәбият белемендә бу юнәлештә кайбер җитди адымнар ясала башлады инде. Н. Исәнбәт һәм Й. Нигъмәтуллина хезмәтләрендә әдәбиятның милли үзенчәлекләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Г. Халит, И. Нуруллин, Н. Юзиев китапларында да әлеге мәсьәләнең төрле аспектлары тикшерелә. Ләкин әлегә кадәр татар әдәбиятының төрле чорларына, аерым жанрларына, талантлы язучылар иҗатына хас үзенчәлекләрне җентекләп яктырткан махсус хезмәтләр язылганы юк. Димәк, бу — Ф. Хәсни мәкаләсендә күтәрелгән мәсьәлә бүген дә актуальлеген югалтмаган дигән сүз.

Китаптагы икенче мәкаләдә автор бу мәсьәләнең эченәрәк керә һәм әдәби хәрәкәткә, таррак алганда, әдәби әсәргә эстетик анализ ясауның нихәтле мөһим эш булуы хакында сүз алып бара. Моны ул Габдулла Тукай иҗаты мисалында аңлата. Бу очракта да аның белән килешми булмый. Чыннан да, бездә халык шагыйре Г. Тукай иҗатының төрле якларын яктырткан «әтрафлы әдәби-гыйльми хезмәтләр бар». Ләкин аның шигъри осталыгы әлегә кадәр рәтләп өйрәнелмәгән «...Тукайның, шагыйрь буларак, гүзәллек табигатен ачмыйча торып, бу сыйфатның образлардагы чагылышын эзлекле рәвештә күрсәтмичә торып, Тукайны тулысынча ачтым дип кем генә әйтә алыр икән!» (24 бит).

Җыентыкның алдагы битләрендә урнаштырылган шушы ике мәкалә аның гомуми проблематикасын ачыкларга да булыша. «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?» җыентыгының нигезен әдәбият һәм әдәби осталык мәсьәләләре турындагы мәкаләләр тәшкил итә. Китапта турыдан-туры әдәби осталык мәсьәләләренә кагылмаган мәкаләләр дә бар. «Тукай турында уйлану», «Баскычлы юл юк», «Моннан шагыйрь узды» һәм башка кайбер мәкаләләр әнә шундыйлар.

Әмма мондый типтагы мәкаләләрдә дә әдәби осталык мәсьәләләре күләгәдә калмый. Югарыда телгә алынган «Моннан шагыйрь узды» исемле очеркта, мәсәлән, автор башта һ. Такташ иҗатына гомуми бәя бирә, аның иҗатының үсеш этапларын, эволюциясен билгеләү юнәлешендә җитди фикерләр әйтә. Шул ук вакыт очеркның байтак өлеше һ. Такташның шигъри осталыгын ачуга багышланган.

Язучының әдәби осталыгы — гаять катлаулы һәм безнең әдәбият белемендә рәтләп өйрәнелмәгән мәсьәлә. Әле һаман Г. Ибраһимов, һ. Такташ, М. Җәлил кебек әдипләрнең әдәби осталыгына багышланган махсус хезмәтләр чыкканы юк. Бу өлкәдә әдәбият белгечләрен гаять кызыклы һәм мавыктыргыч ачышлар көтә. Ф. Хәсни мәкаләләрендә бу нәрсә кат-кат искәртелә. «Ник мин болай озын?» дигән мәкаләдә

[1] Ф. Хәсни. Ни әйтергә? Ничек әйтергә? Казан, 1974.

әдәби әсәрнең темасы һәм шул теманы ачу өчен алынган тормыш материалы хакында сүз бара. Автор фикеренчә, бездә бу ике төшенчә еш кына буталып йөри икән. Кайбер язучылар теге яки бу темага әсәр башлыйлар да, табак артыннан куып, аны бик озынга сузалар. Хәтта әсәрнең үзәгендә торган тема инде ачылган булса да... Чөнки «тормыш материалы очсыз-кырыйсыз, аны берсен икенчесенә, икенчесен өченчесенә ялгарга һәм очсыз-кырыйсыз дәвам итәргә мөмкин» (66 бит). Тема белән тормыш материалының үзара мөнәсәбәте мәсьәләсенә «Йөгердем, җитәлмәдем...» исемле мәкаләсендә ул кабат әйләнеп кайта. Гадәт буенча, биредә дә конкрет мисалларга мөрәҗәгать итә.

Әдәби осталык, барыннан да элек, тормыш хакыйкатен дөрес чагылдыра белүгә бәйләнгән. Әгәр әсәрдәге вакыйгалар, аларның барышы укучы күңелен ышандырмый, аңарда шик уята икән, мондый әсәрне оста язылган дип булмый. Ф. Хөсни үзе тикшерә торган һәр әсәрне нәкъ әнә шул яктан килеп бәяли. Бу җитди мәсьәләгә ул махсус мәкаләләр дә багышлый. «Чак-чак кына»...— шундыйларның берсе. Биредә ул Әнисә Ибраһимованың «Томан тарала» повестена һәм Әхсән Баянның «Челтәр аша» поэмасына тукталa. Тулаем алганда, һичшиксез, оста язылган бу әсәрләрнең кайбер эпизодларында автор тормыш чынлыгына хилафлык күрә. Үз идеяләрен гәүдәләндерү юнәлешендә әлеге язучылар тормыш чынлыгыннан «чак-чак кына» аерыла башлыйлар. Нәтиҗәдә кайбер күренешләр укучыда шик уята. Шуның белән бергә, әсәрнең эстетик дәрәҗәсе дә түбәнәя, аның тормышчанлыгына зыян килә. Янсә менә «Тормыштагыча булсын!» дигән ачык хатны алыйк. Анда сүз Р. Төхфәтуллинның «Яңа магазинда» исемле хикәясе хакында бара. Конкрет анализ нәтиҗәсендә олы язучы Р. Төхфәтуллинга һәм башка язучыларга гыйбрәт булырдай мондый сүзләр әйтә: «...Әдәби әсәрдә тормыш чынлыгына карата сизгер һәм гадел булыйк, әсәрнең укучы алдындагы уңышы, барыннан да элек, шуның белән тәэмин ителә» (204 бит).

Сәнгатьчә төгәллек — әдәби әсәрнең төп сыйфаты. Шунсыз чын сәнгать әсәре туа алмый. Ф. Хөсни проза турындагы фикер алышулар уңае белән язылган «Без китмәскә килдек!» мәкаләсенең бер бүлеген шул төшенчәне ачыклауга багышлый.

«Кеше күңеленең «серле бүлмәләренә!» дигән язмасында ул сәнгать әсәрендә образны тулы канлы итеп ачу мәсьәләсенә тукталa. Ф. Хөсни фикеренчә, тулы канлы образ иҗат итү өчен, язучы кеше күңеленең иң нечкә кыллары тибрәнүен тыңлый, аның эчке тормышын бөтен катлаулылыгы, каршылыклары белән гәүдәләндерә белергә тиеш.

Соңгы елларда әдәби тел хакында җитди сөйләшүләр, фикер алышулар булып узды. Ф. Хөснинең дә берничә мәкаләсе шул мәсьәләгә багышланган. «Әдәби телебез турында» дигәнендә автор мәсьәләне гомумирәк планда күтәрә, тәрҗемәләрнең сыйфаты, әдәби әсәр телендә аерым сүзләрнең кулланылышы хакында яза. Әйтик, ул, «гүзәл» эпитетына махсус тукталып, болай ди: «Мондый купшы сүзләрне бигрәк тә шагыйрьләр күп кулланалар. Гүзәл җыр, гүзәл моң, гүзәл йолдыз, гүзәл кыз, гүзәл бакча, гүзәл койма... Ә ныклабрак эзләгәндә боларның һәрберсенең үзенә хас туры килә торган эпитетларын, әлбәттә, табарга булыр иде» (99 бит). Сүз дә юк, бик урынлы кисәтү.

Ф. Хөсни китабында әдәби осталыкның бик күп яклары турында сүз бара. Аларның барысына да тукталып тормастан, китаптагы соңгы мәкаләгә мөрәҗәгать итеп карыйк. Ул «Кайда сез, олы язмышлар?» дип атала. Мәкалә 1969 елда язылган. Аннан соң безнең прозада җитди генә үзгәрешләр булып алды. Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур», М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар», Ш. Бикчуринның «Каты токым» кебек романнары басылып чыкты. Бүгенге көндә прозабыз җитди сыйфат үзгәрешләре кичерә. Акрынлап, олы язмышлы геройлар да күренә башлады кебек. Әмма, моңа карап, Ф. Хөсни мәкаләсенең актуальлеге кимегән дип булмый. Олы язмышлы геройлар һәр вакыт әдәбиятта төп урынны алып килде. Бу киләчәктә дә шулай булачак. Чөнки әдәбиятның иҗтимагый-эстетик дәрәҗәсен, ахыр чиктә, зур әдәби осталык белән сурәтләнгән олы язмышлы геройлар билгели...

Тәнкыйть мәкаләләрен кабул итүнең билгеле бер закончалыгы бар кебек. Андый материалларның тәнкыйть өлеше, ягъни язучыны, шагыйрьне, берәр китапны тәнкыйтьләүгә багышланган битләре, җиңелрәк укыла. Принципиаль тәнкыйть белән сугарылган мәкаләне, гадәттә, «полемик рухта» язылган диләр. Минемчә, бу закончалыкны Ф. Хөсни бик яхшы аңлый. Һәрхәлдә, ул язучыларны, шагыйрьләрне һәм тәнкыйтьчеләрнең үзләрен дә күбрәк тәнкыйть итәргә ярата. Ихтимал, шуңа күрәдер, аның мә-

каләләре җиңел укыла. «Кайда сез, олы язмышлар?» да шундый ук. Ул баштан ахырга кадәр кискен тәнкыйть рухы белән сугарылган. Моңа гаҗәпләнеп тә булмый. Алтмышынчы еллар прозасы, чыннан да, кискен тәнкыйтькә мохтаҗ иде. Аннан соң, проза өлкәсендә зур тәҗрибә туплаган олы язучының яшьләргә әйтәсе фикерләре дә еллар буе тупланып килгән булган, күрәсең...

Ф. Хәсни мәкаләләренең иң зур күпчелеге конкрет бер әдәби күренеш белән бәйләнгән. Ул төрле дискуссияләрдә актив катнаша. Әдәби хәрәкәтнең җитди күренешләре һәм үзенчәлекле әсәрләр аның игътибарыннан читтә калмый. Үз фикерләрен дәлилләү өчен, ул еш кына классикларга мөрәҗәгать итә, аларның тәҗрибәсенә таяна. Язучының Г. Тукай, Г. Ибраһимов, һ. Такташларга мөнәсәбәте, алардан үрнәк алырга чакыруы турында бер тапкыр әйтелгән иде инде.

Моннан тыш, Ф. Хәсни рус әдәбияты классикларына таяна, аларның әсәрләреннән өзекләр китерә, кайбер теоретик фикерләрен ала. Бигрәк тә ул А. С. Пушкин, А. С. Грибоедов, Н. В. Гоголь әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Тик аерым очракларда өлеге әдипләрнең фикерләрен беркатлырак аңлата кебек. «Кайда сез, олы язмышлар?» исемле мәкаләсендә ул Л. Н. Толстойның «Анна Каренина» романын телгә ала. Безнең кайбер әсәрләрдәге «рәхмәт фәрештәләрен» тәнкыйть иткәннән соң, автор Л. Толстой героинясы турында болай ди: «Анна Каренинаны, мәсәлән, аның бәхетсезлегендә баш очында «рәхмәт фәрештәсе» каравыллап йөрми, ул бәхетсез икән — логик ахырына кадәр, ягъни поезд астына ташланганчыга кадәр бәхетсез. Бу, элеккерәк термин белән әйткәндә, рок. Бу — трагик язмыш» (255 бит). Бу очракта Ф. Хәсни белән килешүе кыен. Аңа китсә, А а Каренинаны да «рәхмәт фәрештәсе» каравыллап йөри бит. Сүз Вронский турында бара. Инде килеп, Анна Каренина фаҗигасе тик «рок», «язмыш» төшенчәләре белән генә аңлатыла икән, бу роман рус классик әдәбиятының бөек әсәрләреннән саналып йөртелмәс иде. Анна Каренина язмышы — шәхси трагедия генә түгел. Ул, барыннан да элек, ил һәм халык язмышы, Россия тарихындагы иң катлаулы чорларның берсе (1861—1905 еллар), шул чорга хас иҗтимагый-политик каршылыклар, бер сүз белән әйткәндә, шул чорның үз каршылыклары белән бәйләнгән. В. И. Ленинның Л. Н. Толстой иҗатына багышланган мәкаләләре нәкъ әнә шул хакта сөйли.

Ф. Хәсни мәкаләләре җиңел укыла, дидек. Җитди тәнкыйть белән сугарылганга гына түгел, әлбәттә. Хикмәт шунда, Ф. Хәсни мәкаләләрендә авторның позициясе ярылып ята, ул һәрбер әсәргә, һәр әдәби күренешкә ачыктан-ачык үз мөнәсәбәтен белдереп бара. Язучылар теле «шома», төзек, ул һәр вакыт югары эстетик таләпләрне истә тотып яза.

Билгеле булганча, авторның проза әсәрләре халыкчан юморга бай. Бу сыйфат аның мәкаләләрендә дә чагыла. «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?» китабында ул комик күренеш тудыруның төрле ысулларына мөрәҗәгать итә. Әйтик, «Ләззәт тә бирәме?» мәкаләсендә шактый кызыклы алым кулланылган. Анда сүз кайчандыр Чаллыда булып узган укучылар конференциясе турында бара. Автор баштан ук мәкаләгә юмористик яңгыраш бирә. Конференциядә ике «тере язучы» да катнашты, ди. Бу тон алга таба да дәвам итә. Конференциядә катнашучыларга алдан ук темалар бүленеп бирелгән икән. Язучы фикеренчә, конференциянең барышы җиләк-җимеш сәүдәсе рәтендә карбыз сайлауга охшап кала. Шуның белән бәйле рәвештә мәкаләгә «уңай карбыз» һәм «тискәре карбыз» төшенчәләре килеп керә. Алар мәкаләнең буеннан-буена сузылып баралар. Шулай итеп, билгеле бер әдәби күренешне тормыш-көнкүреш хәлләре белән чагыштыру мәкаләгә юмористик яңгыраш бирә. Мондый алым Ф. Хәснинең кайбер башка мәкаләләрендә дә очрый.

Язучы юмористик алымнарны үзенә карата да куллана. «Без китмәскә килдек!» мәкаләсендә автор, «сәнгатьчә төгәллек» төшенчәсенең кайбер җитди аспектларын күрсәтеп үткәннән соң, болай дип өсти: «Менә шушы саналып үтелгәннәр һәм баш җитмәү аркасында саналмый калган бүтән бик күп компонентлар — бөтенесе бергә сәнгатьчә төгәллек дигән төшенчәне тәшкил итәләр дә инде» (46—47 битләр).

Тик кайвакыт ул көлкеле сүзләр белән артыграк мавыгып китә кебек. «Уйна, уйна, моңлы сазым!» исемле мәкаләсендә ул бер шигъри өзек китерә дә укучыга мондый сүзләр белән мөрәҗәгать итә: «Колак салдыгызмы, нәрсә бу? Традицион шигырьме яки кайбер «яшь әтәчләр» кычкыра торган «ирекле шигырь» дигәннәреме?» (193 бит). Әгәр мондый сүзләрне өлеге «яшь әтәчләрнең» берәресе әйтсә, бер хәл иде... Икенче бер мәкаләсендә язучы үзе

ихтирам иткән яшь шагыйрьне «кызыл материя күреп котырган цирк үгезе» белән чагыштыра...

Ләкин, ни генә булмасын, Ф. Хөснинең «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?» китабы төрле буын әдипләрен һәр вакыт борчып торган мәсьәләләрне күтәрә. Ул бүгенге әдәби хәрәкәтнең җитди бер үзенчәлеген — әдәби тәнкыйтькә һәм эстетик проблемаларга игътибар артуын чагылдырган әһәмиятле китапларның берсе.

**ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# КӨЛКЕ КУА КИЛӘ

„Чаян» журналына 50 тулу уңае белән шушы журналда соңгы елларда басылган кайбер әдәби әсәрләр һәм рәсемнәр аерым китап итеп чыгарылды. Ул «Көлке куа килә» дип атала. Җыентыкка 57 авторның 98 исемдәге сатира-юмор әсәре, шулай ук халык мәзәкләре һәм карикатуралар урнаштырылган.

Яңа фатирга күчеп, йокыга яткач кына, кайдандыр моңлы җыр яңгырый башлый. Баксаң, ул күрше фатирдан сибелә икән. Җырга сул як күрше дә, өске һәм аскы катта яшәүчеләр дә кушыла. Тора-бара үзешчән хорга җитәкче дә табыла. Һәркайсы үз квартирында торып, бөтен шартын китереп, төне буе җыр өйрәнәләр. Туфан Миңнуллинның «Ансамбль» исемле юмористик хикәясенең кыскача эчтәлеге әнә шундый.

З. Гомәрованың «Өч бажа һәм бер тәкә», Р. Фәизовның «Йомыкый», В. Шәриповның «Гарнитур» хикәяләре, Н. Мадьяров, Ш. Галиев, Г. Рәхим, Ә. Исхакларның китапка кергән шигырьләре дә яратып укырлык, рәхәтләнеп көләрлек булып чыккан.

Бу китапны бик озак мактарга була. Әмма без күзгә ташланган кайбер җитешсез якларын да күрсәтик әле.

Китапта аннотация бирелгән. Ләкин ул алты юлдан гына тора. Югыйсә, кыска гына итеп булса да, журналның үзе турында, кайчан һәм нинди шартларда чыга башлавы турында язарга бик мөмкин иде бит.

Җыентыкның нинди принципта чыгып төзелүен дә аңлап булмый. Шигырьләр хикәяләр белән аралашып килә. Китапта барлыгы 57 автор катнаша дип әйткән идек. Менә шуларның әсәрләре 79 урында бирелгән, ягъни бер үк авторны берничә урында очратабыз. Мәсәлән Г. Афзал, Ә. Исхак, Т. Миңнуллин, М. Мәһдиев, А. Яхин фамилияләре өч җирдә очрый, ә Ш. Галиев шигырьләре хәтта дүрт урында (8, 52, 96, 195 битләрдә) бирелгән. Сигез автор икешәр тапкыр кабатлана. Болай таркату нәрсәгә кирәк булды икән?

Карикатуралар да бер тәртип белән урнаштырылмаган. Әйтик, сабан туена багышланганнарны бер тирәгә җыярга булыр иде, ә алар ике җирдә. Эчүчелеккә каршы ясалган рәсемнәр белән дә шул ук хәл, алар алты урында бирелгән. Авторларның исем-фамилияләрен бутаулар очрый. Эчтәлектә Илдар Юзәй, Рәшид Фазлыев, ә китапның эчендә Илдар Юзеев һәм Рәшит Фазлыева дип бирелгән.

Гадәттә, мондый җыентыкларны кем дә булса төзи, һәм аның фамилиясе беренче биттә языла. Ә бу китапны кем төзегәнлеге дә билгесез.

Санап үтелгән кимчелекләр җыентыкның ашыгыч рәвештә төзелгәнлеген һәм игътибарның җитеп бетмәве турында сөйлиләр.

Китап моңарчы күрелмәгән 25 мең тираж белән чыккан иде. Хәзер аны кибетләрдән табуы кыен. Димәк, укучылар аны яратып кабул иткән.

Элек «Чаян» китапханәчеге чыга иде. Шуның кебек, бер-ике елда журналда басылган әйберләрне туплап чыгару бик мәслихәт булыр иде. Әйтик, бер елны татарчасын, икенче елны русчасын. Бу — үзешчән коллективларга да зур ярдәмлек булыр иде. Сәхнәдән сөйләү өчен күпме кызыклы, көлкеле әйберләр бар анда.

Сатирик байлыкны даими рәвештә туплап чыгаруны юлга салырга кирәк. Моның өчен «Чаян» журналының чираттагы юбилеен көтеп тору һич кирәк түгел.

**Р. ГАЛӘВИН.**

Равил Фәхретдинов

# КАЗАН АРТЫ

АРХЕОЛОГ ЯЗМАЛАРЫННАН

Мендем атның биленә,
Чыктым Казан иленә;
Казан иле — гөлстан,
Аерылмаем син дустан.

Борынгы татар халык җыры.

Казан арты... Ничәмә-ничә тапкыр ишетелгән яки китапларда укылган булуга карамастан, кабат колакка эленүгә яки күзгә чалынуга бу төгъбир ниндидер аңлатып бирә алмаслык самими, җылы хис уята, күңелләрне әллә нишләтеп җибәрә. Ул безнең күңелләргә «Әлифба» һәм «Туган тел» китаплары күтәреп сабакка йөргән бала чактан ук Тукай абыйның «нәкъ Казан артында»гы Кырлае, аның тылсымлы «Шүрәле»се, «Кәҗә белән сарык»ы, «Су анасы» белән гомергә онытылмаслык булып кереп калган. Сибгат Хәким сүзләре белән әйткәндә:

**Әкиятләрең белән ачылды телем,**
**Казан арты, әй, Казан арты.**

Шушы җирдә Казан татарларының матди һәм рухи культурасы тәмам формалашкан, шушы җирнең теле халкыбызның хәзерге әдәби теленә нигез булган.

Казан арты төшенчәсе фәндә ике төрлерәк мәгънәдә йөри. Беренчедән, ул — Урта Иделнең зур бер географик районы, Татарстанның Камадан төньяктагы, Идел белән Вятка арасындагы территориясе; географик әдәбиятта еш кына Көнбатыш Кама алды дигән төшенчә белән тәңгәл кулланыла. Хәер, бу бер коры географик бүленеш кенә түгел: борынгы тарихы, халкының теле һәм традицион этнографиясе ягыннан ул җирләр, аерым төбәк үзенчәлекләре булуга да карамастан, бер бөтен дөнья итеп карала. Әмма шул зур гына территориянең үзеге бар — географик түгел, ә тарихи-этнографик үзәге. Менә монысы инде әлеге шул, Тукайлар җырлаган, чын мәгънәсендәге Казан арты. Географик яктан ул кечерәк, аңа Казан һәм Ашыт сулары, шунда урнашкан хәзерге Арча һәм Биектау районнары керә. Аны «Ак як» дип тә атап йөртәләр. Бу — элекке Казан ханлыгының үзәге, Казан татарлары этнографиясе һәм сәнгатенең классик формалары таралган урын. Без түбәндә, нигездә, менә шушы як турында сүз алып барырбыз.

...Казан суы буенда җәй буе уздырылган разведкабызның бүген соңгы көне. Август ахыры булуга карамастан, көндезләрен бик кызу. Кичә 30 градус дигәннәр иде, бүген тагын да эссерәк тоела. Кичен елганың башланган җиренә килеп җитеп, эшне тәмам иттек һәм Казанка исемле кечкенә генә татар авылы янында лагерь корып җибәрдек. Без инде палатканы ял итү өчен җайлы, тыныч һәм матур урынга

корырга өйрәнеп беттек, бу юлы да авылдан бераз гына читтәрәк, агым буйлап югары таба, үзәнлектә урнаштык. Гаҗәеп матур урын. Аста моңсу таллар үсеп утыра, яр өстендә, төбәләрен күккә тидергәндәй итеп, мәһабәт чыршы-наратлар тезелгән. Үзәнлек буйлап аз гына югары таба кue урман башлана, шуннан елга агып чыга. Тулган ай яктысында болар һәммәсе серле дә, шомлы да, шул ук вакытта әйтеп бетерә алмаслык матур да булып күренәләр. Айлы төн туры килдеме, кичен ашап-эчеп, һәммә кеше йокыга яткач, мин шул ай яктысында көндәлек язарга утырам. Берәү дә комачауламый, уйларың белән икәүдән-икәү генә каласың. Ләкин бу бер дә хыялыйланып утыру түгел, ә экспедициядә күргәннәреңә бер төрле нәтиҗә ясау була.

Менә бүген дә учакны яңартып җибәрдем дә палатка янындагы агач төбенә килеп утырдым. Тирә-як тып-тын, хәтта авылда этләр дә өрми, бая ерактан ишетелгән ялгыз трактор тавышы да тынып калды. Шушы сихри тынлыкны бераз гына бозгандай итеп, вак ташлар арасыннан чишмәдәй саф сулы елга челтерәп агып ята. Хәер, аны елга дип әйтүе дә әллә ничегрәк, бу аның башы гына. Мәгәр ул менә шулай биредән башлана да, ага-ага, юлында очраган инешләрне үзенә кушып, чын елгага әйләнә һәм берничә дистә чакрымнар үтеп, Иделгә барып коя. Ничәмә гасырлар шулай агып торган, шул гомер эчендә нинди генә шатлыклы да, аяныч та вакыйгаларны күрмәгән ул. Дәрдмәндчә әйтсәк:

**Агышың, и агымсу, туп-тулы зар,**
**Синең ни хәсрәтең, ни моңнарың бар!**

Ә күргәннәре шактый күп аның, ул шаһит булган хәлләр бөтен бер Казан артының, Яңа Болгар-Казан җиренең тарихы белән аерылгысыз бәйләнгән.

IX—X йөзләрдә үк болгарлар Каманың уң як ярына һәм аның кечерәк кушылдыкларына үтеп керәләр, әмма калын-калын урманнар белән капланган Ашыт һәм Казан суы буйларына алар әле килеп җитмиләр. XII йөздә Болгар дәүләте экономик һәм политик яктан зур үсеш ала, аның җирләре төрле яктан нык киңәя башлый. Болгарның чикләре көнчыгышта һәм көньяк-көнчыгышта Агыйдел һәм Җаек елгаларына кадәр барып җитә; әкренләп төньяк җирләргә күчеп утыру башлана. Мәсәлән, көнбатышта Зөя суының түбән агымында да шәһәр-авыллар барлыкка килә, ә биредә, Казан суы буенда, беренче болгар авыллары күренә башлый. Шул авылларның урыннарын без хәзерге Боҗа, Чүриле, Урта Сәрдә, Өмбе һәм Сосновка авыллары янында таптык. Аларда җыйналган керамика үзәк Болгар җирләрендә XII—XIII йөзләрдә җитештерелгән керамик әйберләрдән бернәрсәсе белән дә аерылмый — төсләре дә, формалары һәм бизәкләре дә бер үк. Болар — бик кыйммәтле материаллар. Алар Татарстан археологиясендә һәм, гомумән, аның борынгы тарихында яңа бер мөһим сәхифә ачалар. Моңарчы булган әдәбиятта болгарлар Казан артына, аерым алганда, Казан суы буена, бары тик Алтын Урда чорында гына күчә башлаганнар дип язылып киленде. Ә менә соңгы мәгълүматлар ул карашның дөрес түгеллеген, болгарларның Казан суы буенда монголларга кадәрге чорда ук яши башлавы турында сөйли.

XIII йөзнең 30—40 нчы елларыннан, Болгар дәүләте монголлар тарафыннан яулап алынгач, төньяктагы тыныч урыннарга күчү тагын да көчәеп китә. Каманың уң як ярында һәм аның кушылдыкларында XIII йөзнең икенче, XIV йөзнең беренче яртысына караган истәлекләр шактый. Бу, беренче чиратта, әле XII йөздә төзелеп, соңга таба тагын да зуррак үсешкә ирешкән Кашан шәһәре һәм аның тирә-ягындагы авыллар. Н. Ф. Калинин фикеренчә, анда аерым Болгар әмирлеге (князьлеге) булган. Шундый ук икенче әмирлек бераз гына көнчыгыштарак, Омарка-Кирмән бассейнында оешкан. Биредә болгарларның атаклы шәһәрләреннән саналган Кирмәнчек һәм аның тирәсендә башка кечкенә шәһәрләрнең калдыклары бар. Шунда ук бөтен болгар җирендәге эпиграфик истәлекләрнең иң зур җыелмаларыннан исәпләнүче, «Ханнар зираты» исеме белән мәгълүм каберлек урнашкан.

Алтын Урда чорының шушы беренче йөз еллыгында Казан суы буйлары болгарлар тарафыннан тагын да ныграк үзләштерелә. XII йөз ахырларында барлыкка килгән авыл үсә, Казан (Иске Казан) шәһәренә әверелә; аңа каршы, елганың икенче ягында, шәһәрнең кальгасе төзелә. Елганың түбән агымында да, Кабан күле буен-

да, бер феодаль биләмә оеша, анда кечерәк бер шәһәрлек һәм ике кабер ташы мәгълүм: аларның берсе 1297 елда куелган. Ниһаять, бу чорда болгарлар Ашыт елсына кадәр үтеп керәләр: анда XIV йөзнең беренче яртысына караган кабер ташлары сакланган ике зур гына зират һәм кайбер башка табылдыклар бар.

Шулай да Казан арты болгарлар тарафыннан киң колач белән Алтын Урда чорының икенче яртысында гына үзләштерелә. 1350 еллар азагында Сарай шәһәрендә зур чуалышлар башлангач, алардан да бигрәк, Новгород юлбасарларының һәм кайбер рус князьләренең һөҗүмнәре нәтиҗәсендә Болгарның Кама арьягындагы үзәк җирләренә зур зыян килә, аның халкы шул өзлексез яу-талаулардан тәмам җәфа чигә. Менә шул чордан алып болгарларның тынычрак җирләргә күпләп күчеше башлана. Кама аръягында бу чорга караган бер генә эпиграфик истәлек тә юк. Бу күчеш турында шулай ук ул җирләрдә күмеп калдырылган бай хәзинәләр сөйли. Акчалардан һәм зиннәтле ювелир әйберләрдән торган мондый хәзинәләрне күмеп, туган-үскән җирләрен ташлап киткән болгарлар бәлки кайчан да булса кире әйләнеп кайтырга ниятләнгәннәрдер. Ләкин язмыш башкача килеп чыккан, алар яңа, төньяк җирләрдә мәңгегә урнашып калганнар.

Болгар җиренең яңа политик, экономик һәм культура үзәге Казанга (Иске Казанга) күчерелә, әйткәнебезчә, ул Яңа Болгар дип исемләнә башлый. Шушы ук чорда булса кирәк, Казан суы буенда Арча шәһәрлеге төзелә; һәрхәлдә, рус елъязмаларында ул 1497 елдан искә алына башлый (хәер, Мазурин елъязмасында бер тапкыр 1296 елда дип искәртелеп үтелә).

Дөрес, бу дәвернең эпиграфик истәлекләре Казан артында бернича генә. Бүгенгә көнгә сакланып калган ташлардан Мишә буендагы Нырсы авылы янында 1357, 1399 һәм 1433 елгы, Казан суының Ямәширмә авылында 1384 елгы ташлар гына мәгълүм. Хәер, бу күренеш болгар культурасының әлеге чорда торгынлык кичерүе белән аңлатыла, ә ул торгынлык югарыда әйтеп үтелгән политик һәм экономик кыенлыклар белән бәйле. Хәлбуки, шуңа да карамастан, аз гына сандагы эпиграфик истәлекләрнең дә Кама аръягында түгел, ә төньяк җирләрдә сакланып калуы халыкның нәкъ менә шул җирләрдә яшәве турында сөйли дә инде.

Болгарларның Казан артына күчеше, археологик истәлекләрдән башка, язма чыганаклар һәм фольклор материаллары белән дә раслана. «Дәфтәре Чыңгыз-намә» елъязмасы, башка кульязмалар, Хисаметдиннең «Тәварихы Болгария»се, күп сандагы риваять-легендаләр Аксак Тимернең Болгар җирен һәм шәһре Болгарны тар-мар китерүе, соңгы Болгар ханы Габдулланың һәлак булуы, аның исән калган улларының Казан суына килеп шәһәр төзүләре турында ачык сөйлиләр. «Тәварихы Болгария»дә Казан суы буенда күп кенә бәк һәм шәехләрнең каберләре булганлыгы әйтелә, җөмләдән: Байтирәк углы Иштирәк, Габдулла углы Гадел, Мөхәррәм углы Зөлмөхәммәт, Хаҗи Армали, аның кызы Гайшә бикә, улы Таҗетдин. Бу каберләрнең кайберләре бүгенге көндә дә билгеле; мәсәлән, Иске Казаннан ерак түгел, Татар Әйшәсе авылына каршы тау башында Гайшә бикәнең кабере мәгълүм (шунда гына без болгарларның Алтын Урда чорына караган авыл урынын да таптык). Әлеге Әйшә авылының шул Гайшә бикә исеменә мөнәсәбәтле булуы шөбһәсездер. Иске Казан янындагы «Мулла Хаҗи» кабере Гайшәнең атасы Хаҗи Армалиныкы булуы бик мөмкин. Әйтергә кирәк, бу ике кабер, бигрәк тә соңгысы, Казан артында бер изге урын итеп санала. Аңа хәтта Казаннан, алай гына да түгел, шактый еракларда да гыйбадәт кыларга йөргәннәр.

XIV йөзнең ахырында Казан суының тамагында Яңа Казан зур үсеш ала һәм ул 40—45 елдан соң төзелгән Казан ханлыгының башкаласына әверелә. Бөтен Казан арты яңа тормыш белән яши башлый. Болгарларның монгол яуларыннан соң юкка чыгарылган дәүләт мөстәкыйльлеге яңадан торгызыла, экономика аякка баса, игенчелек, һөнәрчелек, сәүдә итү рәткә салына. Элекке калын урманнар киселеп һәм яндырылып, чәчүлек җирләр киңәйтелә. Татарның бер мәкале бар бит әле: бодай чәчсәң, сазга чәч, арыш чәчсәң, көлгә чәч. Саз сүзе биредә туры мәгънәсендә түгел, ә Кама аръягының кара туфраклы иңкүлек җирләре мәгънәсендә алынгандыр (Ибне Фазлан да бит болгарларның бодайны нәкъ шундый, аның сүзләре белән әйтсәк, черек җирдә чәчүләре турында язган иде). Ә менә «көлгә чәч» дигәне урманнарны яндырып арыш чәчү турында сөйли булса кирәк. Яңа үзләштерелгән көлле җирләр уңышны мул бир-

гәннәр. Шуңа күрә Казан ханлыгы чорын тасвирлаучы язмаларда Казан артының уңдырышлы җирләре, гомумән аның бай һәм матур табигате хакында күп сөйләнелә. «Казан тарихчысы»на мөрәҗәгать итик: «Ул җир бик иркен һәм мул, анда терлек асрыйлар, умарта тоталар, күп төрле ашлык һәм яшелчә үстерәләр, ул шулай ук киеккә, балыкка һәм башка бик күп кәсепле урыннарга бай; башка андый урынны бөтен бер Рус җирендә табып булмый, белмим, шундый матур, нык һәм бай урын башка җирдә булыр микән...» дип языла анда.

1552 елда, Казанны алыр алдыннан, Казан арты, Арча яклары А. Курбский язмаларында болай тасвирлана:

«Ул якларның һәр җирендә гаҗәеп уңдырышлы һәм һәртөрле уңышларга бай кырлар күп. Әмир һәм байгураларның йортлары гаҗәеп матур һәм сокландыргыч; авыллар анда бик куе утырган. Ул җирләрдә чәчелгән ашлыкның күплеге күктәге йолдызларга тиң, шулай ук анда терлекнең саны хисапсыз күп һәм кыргый җәнлекләрдән алына торган табышның күләме зур: сусар, тиен һәм тире яки ит өчен аулана торган башка киек. Янәдән ул җирләрдә кешләрне күп аулыйлар, бал җыялар». Менә шуңа күрә дә шул чор дворян идеологларының иң күренеклеләреннән Иван Пересветов әлеге бай урыннарны, алар атаганча, «җәннәт җире»н, тизрәк басып алырга өндәгән.

Язмаларны кузгатканбыз икән, аларда телгә алынган Арча шәһәре хакында да берничә сүз әйтеп китәргә кирәк. Тагын да шул «Казан тарихчысы»на мөрәҗәгать итик:

«Ул кальга Арча дип атала, нык итеп шәһәрчә корылган, һәм башнялары, һәм бойницалары бар, һәм анда кеше бик күп, шәһәрне яхшы саклыйлар, аның әле беркайчан да алынганы юк; ул Казаннан 60 чакрым ераклыкта, бик нык һәм үтә алмаслык чытырманлы-сазлыклы җирдә урнашкан: аңа бары тик бер юл белән генә килеп яки чигенеп була. Воевода князь Симеон күрде: моны алай җиңел генә алып булмый, халкы бик күп, гаскәре генә дә 15 мең; шуннан соң ул пушкалар һәм пищальләр китертеп аттыра башлады».

Арча сүзенең кайдан алынганлыгы күпләрне кызыксындыра. Тарихи әдәбиятта ул моңарчы «ар» (удмурт) сүзеннән алынган дип язылып килде; хәтта рус чыганакларында еш очрый торган «Арская земля» сүзе дә нәкъ шул «арлар җире»н аңлата дип каралды. Алай гына да түгел, борынгы Арчаны удмуртлар шәһәре булган дип аңлаттылар.

Без моның белән һич кенә дә килешә алмыйбыз. Чөнки Казан ханлыгының үзәк җирендә удмурт шәһәре бөтен бер татар князьлегенең башкаласы була алмый. Арча тирәсендә хәзерге вакытта бер генә удмурт авылы да юк һәм алар элек тә булмаган. Без Казан суы бассейнын, шул исәптән Арча якларын да җентекләп өйрәнеп чыктык, тик бер генә удмурт археологик истәлеге дә тапмадык. Дөрес, ул җирләр элек угро-фин җирләре булган, ләкин XV—XVI йөзләрдә түгел, ә шактый элгәрәк, анда болгарлар килгәнче үк. Ул вакытта да әле ул удмуртларга түгел, ә марийларга нисбәтле булган, чөнки Казан һәм Ашыт суы буйларында «чирмеш зираты» дип аталган борынгы, ташландык зиратлар шактый күп. Ә Болгар, аннан да битәр Казан ханлыгы чорларында инде Арча яклары, әлбәттә, татар җирләре булган. Арчаны алу күренешен сурәтләгән рус елъязмаларында һәм А. Курбский истәлекләрендә ул мөселман, ягъни татар шәһәре булып телгә алына, аның халкы удмуртлар да, марилар да түгел, ә мөселманнар дип атала. Менә шуңа күрә дә, рус чыганакларында очраган «Арская земля», «Арские люди» төшенчәләрен тарихчыларның «арлар җире», «ар кешеләре» дип атавы белән килешеп булмый. Бу сүзләр, һич шик юктыр, «Арча җире», «Арча кешеләре» дигәнне аңлаталар.

Әмма нәрсә соң ул «Арча»? Арча төрки халыклар телендә «артыш»ны аңлата. Академик В. Радлов сүзлегендә аның биш мәгънәсе китерелгән; иң беренче чиратта һәм татар телендә дә ул нарат һәм артыш агачларының исеме итеп бирелгән. Калган мәгънәләре: чык, ягъни үлән чыгы; кәләш бүләге. Мәгълүм ки, Урта Азиянең төрки халыклары телендә артыш агачы әле дә арча дип атала. Бу агач безнең якта да элегрәк арча дип аталгандыр, шулай булмаса, аны В. Радлов татар телендә дә күрсәтмәс иде. Менә шуңа күрә, халык арасында һәм әдәбиятта киң таралган «Арча кыры» сүзен «артыш кыры» мәгънәсендә аңларга кирәктер. Игътибар

итик: болгарларның кайбер шәһәрләре агач яки үлән исемнәре белән аталганнар. Җөмләдән: Җукәтау, Тубылгытау (тубылгы — кечкенә генә куак сыман үлән). Тау башына урнашкан Арча шәһәренең дә артышлы тауга мөнәсәбәттә аталуы бик тә аңлашыла. Шунысы да кызыклы: Арча исемле авыл Тау ягында да бар. Анда шулай ук удмуртларның бервакытта да яшәгәннәре юк.

Арча беренче тапкыр рус елъязмаларында 1497 ел белән искә алынса да, аның элегрәк, Алтын Урда чорының икенче яртысында, ягъни XIV йөзнең ахырларында һәм XV йөзнең башларында барлыкка килүе мөмкин дип әйтәсе килә. Арча шәһәрлегендә табылган җучи акчасы да шуңа ишарә ясый сымак. Шәһәрлек хәзерге Арчаның үзәгендә, «Мещаннар чиркәве» урнашкан җирдә булып, биек яр буе һәм зур гына чокыр арасындагы өчпочмак рәвешендәге мәйданны биләп тора. Казан юлы белән килеп, елга аша күперне чыккач та, борылып тауга менеп китәр алдыннан каршыда шул шәһәрлек күзгә ташлана. Ә шул ук юл белән Арчага менеп җитеп, үзәк урамга килеп кергәндә, уң яктагы тирән чокыр аша аның борынгы урлары күренеп калалар.

1552 елда Казан артында, Арча белән бергә, башка күп кенә шәһәр-авыллар алына. Шуннан соңгы биш ел эчендә Казан ханлыгы җирләре Россиянең үзәк җирләреннән күчеп килүчеләр бәрабәренә интенсив рәвештә колонизацияләнә башлый. 1565—1567 елларда төзелгән писцовый кенәгәләрдән күренгәнчә, рус помещиклары татарларның 206 авылын үз кулларына төшерәләр. Шунысы кызык: Казан артында һәм Тау ягында бүгенге көндә нәкъ шул чамада татарча исемле рус һәм өлешчә рус-татар авыллары бар. Һәрхәлдә, мин 203 авыл санадым. Дөрес, бу сан төгәл үк була алмый, чөнки кайбер рус авыллары исемнәренең татарчадан алынганлыгын чамалау кыен. Шулай ук Кама аръягында, Алабуга ягында, Мари һәм Чувашстан республикаларында да андый авыллар шактый.

Исемнәре элекке татар авылларыннан алынган рус авыллары бигрәк тә Казанга якын районнарда, мәсәлән, Биектау, Питрәч, Лаеш, Зеленодольск, Югары Ослан, шулай ук Арча, Апас районнарында күп: Арск (Арча), Алат, Айша (Әйшә), Бирюли (Бөреле), Бишбатман, Булатово (Булат), Бурнашево (Борнаш), Девлезери (Дәүләтьяр), Дюртили (Дүрт Өйле), Казыли (Казиле), Камаево (Камай), Киндери (Киндерле), Клетни (Келәтле), Куюки (Көек), Кулаево (Колай), Кульсеитово (Колсәет), Маматкозино (Мәмәтхуҗа), Толмачи (Толмач), Урмат, Чепчуги (Чыпчык), Чулпаново (Чулпан), Чурилино (Чүриле), Шигалеево (Шигали, ягъни Шаһ Галидән), Ширданы (Шырдан), Юнусово (Юныс), Ямбухтино (Ямбакты) һәм башка бик күп авыллар. Андый авылларның исемнәре я бөтенләй үзгәртелмичә, я өлешчә үзгәртелеп, рус теленең үз законнарына буйсындырылып алынганнар. Кайбер атамалар шактый үзгәртелгән. Әйтик, Казан суы буенда Абзябар һәм Кишметьево исемле кечерәк рус авыллары бар, татарлар аларны хәзер Абҗабар һәм Кишмәт дип йөртәләр. Картлардан сораша торгач, аларның элек Габделҗаббар һәм Ишмөхәммәт исемле кешеләргә мөнәсәбәттә аталганнарын белдек (Кишмәт авылының нәкъ уртасында Казан ханлыгы чорының кабер ташы да сакланган). Бу урында шуны да искәртеп үтик: кайбер авылларның исемнәре тарихи шәхесләргә, мәсәлән, хан, сәет, князьләргә нисбәтле (Шигали, Колсәет, Камай, Борнаш).

Казан ханлыгы авыллары хакында сүз кузгатканбыз икән, шундый авылларның Е. И. Чернышев төзегән картасы хакында да берничә сүз әйтеп китми булмый. Карта 1565—1568, өлешчә 1603 елларда язылган писцовый кенәгәләргә карап төзелгән. Картада 700 авыл бар, шуларның 478 е Казан артында (Казан арты киң мәгънәдә алына), 196 сы Иделнең уң ягында, 15 е Кама аръягында, 11 е Алабуга ягында. Кенәгәләрне төзүчеләр, Казан ханлыгы бетеп 13—15 ел узгач, андагы һәр авылны искә алганнар, ул авылларның халкы турында да мәгълүмат биргәннәр. Болар бик мөһим мәгълүматлар, чөнки кайбер чуваш тарихчылары (Мәсәлән, П. В. Денисов, В. Д. Дмитриев, В. Ф. Каховский) өлеге авылларның күбесе, шул исәптән Казан артындагылар да, чувашныкы булган дип язып киләләр. Эш шунда, ул авылларда «чуваш» кешеләре телгә алына. Денисов боларның хәзерге чувашларга нисбәтле булуын раслау өчен бер документ китерә: Төрек-Тәмте (хәзерге Саба районында) авылының Көчкәй Моратхуҗа исемле «чуваш» абызына бирелгән ясак грамотасы аның улы йомышлы татар Дусмөхәммәткә күчкән. Димәк, дип нәтиҗә ясый П. В. Денисов, чуваш татарлаш-

кан һәм бу мисал, аның фикеренчә, Казан артында чувашларның мөселманлашуын, татарлашуын бик ачык чагылдыра. Мондый беркатлы аңлатуга Е. И. Чернышев кискен каршы чыга һәм Казан ханлыгының үзәк җирләрендә чувашларның татарлардан күп булуы мөмкин түгеллеген әйтә. Кенәгәләрне җентекләп тикшергәннән соң, Е. И. Чернышев шундый нәтиҗәгә килә: аларда телгә алынган «чуваш» кешеләре — йомышлы татарлардан үзгә булган ясаклы татарлар, ди ул, кайбер документлар «чуваш»ларны турыдан-туры ясаклы татарлар дип атыйлар; гомумән, йомышлы татарлар бик күп мәртәбәләр искә алынса да, ясаклылар гадәттә «чуваш» сүзе белән атап йөртеләләр. Әмма ни өчен соң алар «чуваш» дип язылганнар? Е. И. Чернышев фикеренчә, йомышлы татарлар ясаклы татарларны «җуаш» (юаш) дип атаганнар, кенәгәләрне төзүчеләр дә, алардан ишеткән буенча, «җуаш»ны бераз үзгәртеп, аларга билгеле булган халык исеме буенча — «чуваш» формасында язганнар (мәгълүм ки, чуваш татар телендә чуаш дип әйтелә). Җуаш-чуаш параллельлеге ничектер, әмма ясаклы татарларның чыннан да «чуаш» исеме белән аталып йөртелүе бик тә мөһим әйбер. Чыннан да, П. В. Денисовның «атасы чуаш, баласы татар булган» дигәненә ышанырлык түгел. Атасының ясаклы, ә улының йомышлы татар булганына ышанырга мөмкин. Ә бер халыкның икенчегә әверелүе — ул әле бер буында түгел, ә дистәләрчә буыннарда сирәк очрый торган нәрсә.

Казан ханлыгы үзәк җирләренең этник картасын күз алдына китерү өчен түбәндәге цифрларны алыйк: Казан артында (киң күләмдә алганда) бүгенге көндә 1167 торак пункты бар (авыллар, поселоклар, район үзәкләре). Шуларның 622 сендә татарлар, 396 сында руслар, 78 ендә катнаш рус-татар яки татар-руслар, 49 ында удмуртлар (болары төньяк һәм көнчыгыш районнарда), 9 ында марилар яшиләр, берничәсе удмурт-татар яки удмурт-рус авыллары. Шулар арасында бары тик бер генә Шигали исемле чуваш авылы, шул тирәдә яңадан бер кечкенә генә чуваш поселогы, ике катнаш рус-чуваш авылы бар. Димәк, татар һәм чуваш авылларының чагыштырмасы 622 : 1 яки, соңыннан бүленеп чыккан бер кечкенә поселокны санасак, 622 : 2 була. Мондый пропорция үзе үк борынгы тарихи күренешне ачык чагылдыра.

В. Д. Дмитриев һәм В. Ф. Каховский Казан артында чувашлар элегрәк кенә түгел, хәтта соңгарак, XVIII йөз ахырларында да татарлардан күп булган дип яздылар. Бу — чынлап торып тарихи дөреслекне бозып күрсәтү. XVIII йөз ахырында Казан артының халкы турында бернинди мәгълүмат булмаганда да бу рәвешчә фикер йөртү акылга ятышмый торган нәрсә булыр иде. Әмма андый мәгълүмат бар — чын мәгънәсендә документаль материал, ифрат кыйммәтле тарихи чыганак ул. Без «Казан наместниклыгы турында ведомость» дип аталган, 1781—1782 елларда Казан губернасында үткәрелгән ревизия нәтиҗәсендә төзелгән статистик мәгълүматлар җыентыгын күздә тотабыз. Аны Д. А. Корсаков Юстиция министрлыгының Мәскәү архивыннан таба һәм 1908 елда бастырып чыгара. Ведомостьта губернадагы 13 өязнең һәр авылы, авылның милли составы һәм андагы ревизия җанының (йорт хуҗасы) исәбе күрсәтелгән. Авылларны игътибар белән җентекләп санаганнан соң шундый нәтиҗә килеп чыга: XVIII йөз ахырында Казан артының барлык 4 өязендә (Казан, Арча, Лаеш, Мамадыш өязләре; Казан арты киң мәгънәдә алына) 822 авыл булган. Шулардан 511 татар, 266 рус, 30 удмурт һәм 15 мари авылы (татар авылларының 136 сы йомышлы, 278 е ясаклы татарларныкы, 26 сы катнаш авыл, 72 керәшен авылы; Казан артының төньяк-көнчыгышындагы, элекке Вятка губернасы, Малмыж өязенә караган шактый гына татар авыллары, табигый, ведомостьта юк) саналган. Һәм шунда бер генә чуваш авылы да күрсәтелмәгән. Булган булса, һичшиксез, күрсәтелгән булыр иде. Мәсәлән, Казан губернасының башка җирләрендә (хәзерге Чувашстанда, өлешчә Тау ягы һәм Кама аръягында) яшәгән чувашлар ведомостьта чыннан да чувашлар дип аталганнар.

Казан артында, Казан суы буенда йөргәндә, ул җирнең археологиясе һәм борынгы тарихы белән бергәттән, аның традицион этнографиясе, архитектурасы, сынлы гамәли сәнгате дә мине бик кызыксындырды. Археолог-тарихчы, әлбәттә, бу өлкәдән дә хәбәрдар, мәгълүматлы булырга тиеш. Экспедициядә йөргәндә юлың, һичшиксез, авыл аша үтә һәм шунда, вакытың тар булса да, картлардан авыл тарихын сорашасың, кулъязма һәм иске китаплар җыясың, әбиләрнең сандык төбендә яткан каюлы читекләренә, энҗеле калфакларына, кызыл башлы сөлгеләренә дә күз сала-

сың, урамнарын әйләнеп, өй-мәчетләрне, капка-коймаларны рәсемгә төшерәсең, зиратларына кагылып, кабер ташларын кәгазьгә күчереп чыгасың. Казан артының этнографиясе, аның архитектура-сәнгате һәм аларның классик формалары фәндә шактый киң яктыртылса да, очрашкан саен сокланмый калу мөмкин түгел. Ни өчен халыкның борынгы архитектурасы һәм сәнгате нәкъ менә шушы Казан артында яхшы сакланган соң? Шушындыйрак сорауларны кешеләрдән еш ишетергә туры килә. Моңа җавапны Казан татарлары материаль культурасын тикшеренүгә багышланган фәнни хезмәтләрдә (мәсәлән, күренекле этнограф Н. И. Воробьев, эпиграфист Һ. В. Юсупов, архитектор һәм сәнгать белгече Ф. Х. Вәлиев хезмәтләрендә) табарга була. Бу җәһәттән Ф. Х. Вәлиевнең «Казан татарлары орнаменты» исемле рус телендә чыккан мәгълүм китабы шактый кызыклы. Китапта XIII—XIV йөз болгар таш архитектурасы белән XV—XVIII йөз татар эпиграфик истәлекләре арасында органик бәйләнеш булуы исбат ителә. Шунысы характерлы, бу истәлекләрнең стиль үзенчәлекләре, бизәкләү алымнары, бигрәк тә «киль» формасындагы эшләнеше, Казан ханлыгы җимерелеп, монументаль архитектура өчен җирлек беткәннән соң, агач архитектурада киң кулланыш тапкан. Мондый бизәкләү алымнарын Казан артындагы, өлеге шул «Ак як»тагы күп санлы өй кыекларында күрергә була. Халык арасында соңгарак «балкон» исеме белән таралган мондый парчалы кыекларның борынгылыгы, аларның Болгар-Казан таш архитектурасы һәм эпиграфикасы белән тыгыз бәйләнеше Ф. Х. Вәлиевнең озак еллар алып барган гыйльми тикшеренүләре белән бик яхшы расланалар. Югарыдагы сорауга җавап менә шунда табыладыр төсле.

Казан татарлары, шул исәптән Казан арты матди сәнгатенең тагын бер бик бай төре — алтын-көмештән, кыйммәтле ташлардан һәм төсле пыяладан эшләнгән ювелир, ягъни зиннәтле бизәнү әйберләре (чулпылар, хәситәләр, яка чылбырлары, алкалар, беләзекләр, медальоннар һ. б.), алардагы бизәкләүнең бай алымнары, өйтик, кою, нәкыш, бөртекләү, каралту, кырлау, басма. Гәрәбә, энҗе, якут, ахак, фирәзә һәм башка асылташлар куеп, яссы нәкыш, бигрәк тә төерчекле нәкыш техникасында эшләнгән бизәнү әйберләре бөтендөнья ювелир сәнгатенең иң гүзәл үрнәкләреннән саналырга хаклы. Шунысы да бик әһәмиятле: XX йөзнең беренче чирегенә кадәр дәвам иткән халык ювелир сәнгате Казан татарларында вак кустарчылыкка әверелмәгән. Шуңа күрә дә бу сәнгать үзенең формалар байлыгы һәм колоритлылыгы белән аерылып тора. Бу хәл шулай ук Болгар һәм Казан ханлыгы чорыннан килә торган традицияләрнең тотрыклылыгы хакында сөйли.

Казан арты миңа, тарихчы буларак, менә шул югарыда сөйләнгән яклары белән аеруча якын, газиз. Әмма аның миңа, әдәбиятыбызны яратучы гади бер укучыга, икенче якынлыгы да бар. Ул да булса, Казан артының культура-әдәбиятыбызны югары күтәргән күп кенә әдип һәм галимнәрне үстерүе. Шулар арасында яктылардан да иң якты йолдыз, кадерлеләрнең дә иң кадерлесе — Тукай. Шәехзадә Бабич сүзләре белән әйтсәк:

> **Дөньяда бик аз буладыр чын шагыйрь Габдулладай;**
> **Ул — караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай...**
> **Алса, укыса халык шигырен аның — истә кала,**
> **Һәм аның шигыре халыкның күңеленә зур хис сала...**

Тукай шигырен ятлап йөри башлаганнан бирле, аның туган-үскән җирләрен күрү теләге көчле иде. Элегрәк, бала чакта, Кырлай урманнарында, соңрак авылында да булдым, ә менә Кушлавыч, Өчиле авылларын быел беренче тапкыр экспедиция вакытында күрдем. Өчиледә булып, аның бабасының йорт урынын тамаша кылдым, үзенә күрә кызыксынып, шул йорт нигезенә салынган йортта торучылардан шагыйрь турында сораштым. Мәгълүм ки, Тукай Өчиледә ике тапкыр була. Әүвәл сабый чакта, Кушлавычтан Соснага барып кайткач, тәмам ятим калып, үги әбисенең «алты күгәрчене эчендә бер чәүкә булып», кагылып-сугылып яши. Икенче тапкыр 1912 елның кышында, авыруы шактый көчәйгәч, әнисе белән бертуган Кәбир абыйсының өенә кайтып тора.

Кушлавычта булуым белән мин үземне аеруча бәхетле саныйм. Минемчә, кушлавычлыларның Тукайга ихтирамы, Өчиле, хәтта Кырлай кешеләренекенә караганда да

көчле. Алар Тукайны шул авылда туган үз уллары итеп зурлыйлар, аның исеме белән, үз авылдашлары булуы белән чиксез горурланалар.

Кушлавыч елганың ике як биек ярында, тау башында урнашкан. Шагыйрь үзе болай ди бит әле:

**Тау башына салынгандыр безнең авыл,**
**Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.**

Бу чишмә чыннан да авыл янындарак, елга үзәнендә, яр астыннан бәреп чыга. Авыл халкы аны «Тукай чишмәсе» дип атый. Менә бу шагыйрьне мәңгеләштерүнең чын халыкча бер төредер инде! Чишмәне кадерләп тоталар, аны әйбәтләп бура белән әйләндереп алганнар, туктап су эчүчеләргә дип савытын да куярга онытмаганнар. Тирә-юньне әйләнеп кайтканда, юлдашым Рафыйк белән икәүләп, шунда тукталып рәхәтләнеп суын эчтек, ял итеп утырдык.

Тукай шушы авылда туган булса да, ачы язмыш аны сабый чактан моннан китәргә, төрле җирдә, төрле кешеләр кулында каңгырып йөрергә мәҗбүр иткән. 1907 елда, инде шагыйрь булгач, солдатка каралыр өчен Уральскидан Кушлавычка кайта ул. Туган җирен сагынып, күптән күрәсе килеп кайта шагыйрь.

**Аерылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин,**
**И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин, —**

дип яза ул шул вакыт. Туган җиренең рәхәтлеген тоя, тәмен татый алмый киткән бала, зур үсеп кире кайткач, шул изге җирен күреп сөенә.

...Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» исемле яңа әсәрендә «И Казан арты» дигән бүлек бар. Шунда әсәрнең герое язучы Камилнең туган авылына чираттагы кайтуында күргәннәре, кичергән кичерешләре сөйләнә. Камил үзен поездга озата килгән энекәшенә еракта күренеп торган шәһәрчек уртасындагы күперне күрсәтеп, болай ди:

«— Янә дә килеп, әнә шул күпернең теге ягына, тауның иң биек урынына Тукай фигурасын куйдырыр идем. Яшь егет кыяфәтендә, Казанга барырга чыккан итеп».

Бу матур теләккә без дә кушылабыз һәм якын киләчәктә шундый бер һәйкәл булыр дип ышанып калабыз. Чыннан да, тау башында, юл чатында кулына кәрзинен тотып Тукай басып торса? Ә һәйкәл куелган постаментка әлеге канатлы сүзләр дә язылган булса:

**Аерылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин**
**И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин...**

# «БЕЗ—ҖИҢӘРГӘ ӨЙРӘНГӘН ХАЛЫК...»

Шушы елның ноябрь аенда фронтовик шагыйрь Мифтах Вәдүтнең тууына 60 ел тула.

Вәдүт Кашшаф улы Мифтахов Татарстанның Сарман районы Яхшы Каран авылында туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Лубьян урманчылык техникумына керә. Аннан соң Казан педагогия институтында укый.

1934 елда республика газета-журналларында М. Вәдүтнең беренче шигырьләре басыла. Һәм тиз арада ул үзен сәләтле шагыйрь итеп таныта. 1939 елда аның беренче җыентыгы басылып чыга. «Җырла, җир!» дип исемләнгән ул китапта иң зур урынны колхоз кешеләренә, аларның фидакарь хезмәтенә багышланган шигырьләр алып тора. Аның шул шигырьләренә гомуми бәя биреп, 1939 елда Муса Җәлил болай дип яза: «Аның әсәрләре барыннан да бигрәк колхоз тематикасына язылганнар. Алар гади, халыкның җанлы телендә язылган булулары белән кызыклы».

Вәдүт Мифтахов Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә. Анда үзен кыю солдат итеп таныта, полк комсоргы булуга кадәр күтәрелә. Алгы сызыкта да шигырьләр язуын дәвам иттерә. Аның «Без — җиңәргә өйрәнгән халык», «Үлем фашистларга!» кебек көчле шигырьләре нәкъ шул чорда языла.

Ләкин сәләтле яшь шагыйрьнең гомере вакытсыз өзелә. Мифтах Вәдүт 1942 елның мартында батырларча һәлак була һәм Тула өлкәсенең Арсеньев районы Рыдань авылында хөрмәт белән күмелә.

1956 елда Татарстан китап нәшрияты «Җыр һаман яңгырый» исемле җыентык басып чыгарды. Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган яшь татар шагыйрьләре иҗатына багышланган бу җыентыкка Мифтах Вәдүтнең дә күп кенә шигырьләре кертелгән.

## Зәки Нури

# «ЧӘНЕЧКЕЛЕ КИТАП»ТАН

## Килде дә... китте

ФЕЛЬЕТОН

— Башлык эштәме?
— Эштә.
— Кабул итәме?
— Итә.
Чиратка язылучылар
Инде сиксәнгә җитә!..
— Кемнәр?
— Барсы да хатын-кыз,
Яслегә урын даулап.
— Башлыкка әйт, хәзер киләм,
Булмасе булсын аулак!..

Килде. Зур чират агышын
Һәм кабулны туктатып,
Заказын биргән аулакка
Керде китте тып та тып.
Халык көтте. Янәсе, ул
Зур бер эш көйләп китте.
Ә ул... нәниләр турында
Анекдот сөйләп китте.

## Тиз туу һәм күз буу турында

«Кулсыз кеше келәт баскан
Кереп ябык ишектән!
Сукыр шуны күреп торган,
Чукрак шуны ишеткән.
Телсез каравыл кычкыргач,
Аксаклар куа киткән...»

Ялганчылар, сезнең гайбәт
Шулай тиз туа икән!
Ялагайлар, сезнең мактау
Шулай күз буа икән!

## Белергә өйрәтү

— Әтием, бу кем сурәте?
— Үзең кара, белмим.
— Ә монысы нинди манара?
— Үзең кара, белмим.
— Ә бу кай илдә, нинди тау?
— Үзең кара, белмим.
— Әти, сиңа бик күп сорау
Яудырмыйммы бер мин?
— Ә бусына бик кыскача
Җавап бирә алам:
Сора! Сора! Шулай гына
Белеп була, балам!

## Ике рәссам сөйләшә

— Буявың ничек җитә дә
Ничек талмый кулларың:
Сурәт иттең илнең күпме
Кызларын һәм улларын?

Көнләшеп әйтмим, куанам!
Димәк, бар — шөкер! — фикер!..
Меңләп сереңнең, ичмаса,
Дәлилгә берсен китер?!

— Агымның барча яманын
Яхшыга борыр өчен
Уйлыйм мин башта аларның
Кәефне кырыр төсен.

Аннары сызам сурәттә
Шушының нәкъ киресен...
Ялганны шулай җиңәм дә,
Шулай табам дөресен!

Эшләнми бу эш аларны
Каралар-таплар өчен.
Язма, дус, бары кемнеңдер
Хәтерен саклар өчен.

1975

# Зыя Мансур

## Дуслар хөкеме

Әле генә кулдан төшкән эшне
Дуслар хөкеменә куям да,
Жулап китә йөрәк һәм җан поса
Әйләнеп бер куркак куянга...
Бер-бер артлы килеп карый кеше
Башкарылган эшнең үзенә.
Күрәм һәм җан керә башлый бер чак,
Шатлык күргәч алар йөзендә.
Шыла курку яннан шыпырт кына,
Шатлык ала җанны кочакка.
Һәм әйләнә бер тау бөркетенә
Әлеге «куян» әнә шул чакта!..

## Кем гаепле?

Бер ишегалдында
Сугәләр ишәкне:
«Җан кебек эшләрне
Менә бит нишләтте!..
Пычратты бар юлны,
Оста тик ишәргә.
Һич акыл билгесе
Күренми эшләрдә,
Нишләргә, җәмәгать,
Нишләргә?..»
Ә ишәк бер мәхлук,
Еламый, көлми ул.
Никадәр суксаң да,
Шул мәхлук инде ул.
Тел белмим, ышанмыйм,
Эш кушкач аңарга,
Кирәктер, мөгаен,
Үзеңә карарга,
Ахмаклык гаебен
Ник аңа ягарга?..

## Ташмаңгай

Әйттеләр аңа:
— Эшең начар бит.
Кыймылдамасаң,
Юшкын басар, — дип.

— Юк, — ди Ташмаңгай, —
Төзәтәчәкмен.

Эшне нигездән
Үзгәртәчәкмен.

Рәхмәт, иптәшләр,
Хак сүзегезгә!
Тәнкыйть һавадай
Кирәк ул безгә!..

Тагын җыелыш,
Тагын һәм тагын...
Күрсәтә һәркем
Кимчелек ягын.

Әйтәләр һаман:
— Эшең начар бит,
Кыймылдамасаң,
Юшкын басар, — дип.

Ә ул утыра
Бик җитди төстә.
Пошынмый ләкин,
Ыжламый һич тә.

## Тычкан һәм аңа баш игән «Җанлы тау» мәсәле

Авыр иде бик
Тычканның хәле.
Калган иде тик
Чыкмаган җаны.
Фил янына ул
Сыенды килеп.
Ябышты җимгә,
Ач талпан кебек.

«Әйдә, — диде фил, —
Ашасын, җәлме?
Бигрәк начар бит
Мескеннең хәле».
Симерде шунда,
Үрчеде тычкан.
Һәм, беләсезме,
Нишли ул, дошман?

Бөтен нәселен
Ала да җыеп,
Яши явыз җан
Кара яу булып.
Ни чара күрсен,
Ниләр кылсын фил?
Йотарга кала
Аңарга тик җил.

Симерә тычкан,
Елмая, көлә.
Таяна ныклап
Бөерләренә:
— Авыз ачасы
Булма һич кенә,
Керермен ату
Борын эчеңә!

Сизеп алган шул
Авырткан җирне.
Бар дип тә белми
Фил тикле филне.
Бармак зурлыгы
Гына бер җанвар...
Ә бит «җанлы тау»
Баш игән аңар...

Әйе шул, көчле,
Куәтле алар
Салпы колаклар
Янында хамнар...

## Фәнияр

# ЭПИГРАММАЛАР

**Гөлшат Зәйнашевага**

Сандугачлар сайраса да
Җырларын язып алам.
Бәрәңге бакчасыннан да
Мин җырлар казып алам.

**Мөдәррис Әгъләмовка**

Эшлә диләр, эшлә диләр,
Мине эшкә димлиләр.
Эшләп чалбар туздырамы
Минем кебек генийлар.

## Галимҗан Латыйп

●

Сез иске дә без яңа дип,
«Аһ» орулар кирәкмәс.
«Искелекне» аңламаган,
Яңалыкка эләкмәс.

●

Бер гаме юк аның синдә, миндә,
Асты өскә килсен дөньяның.
Кайгырта ул кара тиргә батып,
Чыпчык борыны кадәр үз җанын.

●

Карап торсаң, болай тышкы яктан
Тыйнак кеше булып күренә.
Үзе һаман шыпырт-шыпырт кына
Күтәрә алмас данга үрелә.

## Идрис Туктар

### Җөмләләр

Ашыкма гүргә, ашык үргә: ашыккан үргә — халык белән бергә.

Ул бик күпне белмәвен бик күп белүе сәбәпле бик күп белергә тырыша иде.

Әйбәт әйбәтне арттыра, гайбәт гайбәтне арттыра.

Гөлчәчәкләр — гөл чәчәкләр, энәләре сизелсә; коткаралмый һичбер чәчәк, мәхәббәттән бизелсә.

Алдау белән урлау култыклашып йөриләр.

Кешеләр гел генә янәшә яшәсәләр дә, бер-берсен гел генә таба алмыйлар.

Тәрбиялелегеңә карап абруең үсә.

Оптимистның оптимистлыгы күпмегә төшүен оптимист үзе генә белә.

Кеше хатынына карасаң, бер картаясың, үз акчаңа карасаң, ике картаясың; боларның берсенә дә карамасаң, өч яшәрәсең.

Алдамаган алданмаган, алдаган алданган.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## «ДЕТСКАЯ ЛИТЕРАТУРА» ЖУРНАЛЫНДА

Мәскәүдә басыла торган «Детская литература» журналы үзенең август санында татар балалар әдәбияты һәм сәнгате мәсьәләләренә зур бүлекчә багышлап чыгарды.

Редакция тарафыннан бирелгән кереш сүздә социалистик Татарстанның балалар әдәбияты һәм сәнгатен журнал битләрендә киң күләмдә яктыртуның очраклы түгеллеге әйтелә. Татарстан язучылар оешмасы РСФСРда — Мәскәү һәм Ленинградтан кала — иң зур оешма. Аның тугандаш башкорт совет әдәбияты, Урта һәм Югары Иделдәге башка халыклар әдәбиятлары белән күп уртак сыйфатлары бар. Татар әдипләре бүгенге шәһәр һәм авыл балаларын, аларның рухи тормышларындагы җитди үзгәрешләрне сурәтләүгә торган саен кыюрак мөрәҗәгать итәләр.

Татарстанның бүгенге чынбарлыгы һәм балалар әдәбияты, әдипләр, сәнгать эшлеклеләренең яңа буынны тәрбияләүдәге җаваплылыгы турындагы бу сөйләшү КПСС-ның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев мәкаләсе белән ачылган. Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, «Кечкенә кешедә олы дөнья» дип исемләнгән чыгышында татар балалар әдәбияты үткән озын юл, аның казанышлары һәм аерым сыйфат үзенчәлекләре, бүгенге бурычлары хакында сөйли. Татарстан язучылар союзының балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе Ләбибә Ихсанованың «Характерлар формалашканда» дигән мәкаләсендә соңгы елларда балалар язучылары иҗат иткән әсәрләр бәяләнә, уңышлы һәм кимчелекле яклар күрсәтелә. Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин үзенең мәкаләсен «Җәлил — балалар шагыйре» дигән темага багышлаган.

Журнал битләрендә шулай ук Равил Фәйзуллин белән Гәрәй Рәхимнең балалар өчен иҗат ителгән поэзия әсәрләре турындагы мәкаләсе, күренекле тәрҗемәче Семен Липкинның «Шүрәле» һәм Тукай шигърияте хакында, шагыйрь Сибгат Хәкимнең «Тукай-Кырлай» дигән язмалары урнаштырылган. Г. Тукай исемендәге республика премиясенең соңгы еллардагы лауреатларыннан берсе, әдәбият галиме Нил Юзиев «Тылсымлы көзге» дигән мәкаләдә Шәүкәт Галиевнең балалар өчен язылган шигырь китапларын анализлый, язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Мәһдиев Нәкый Исәнбәтнең балалар әдәбияты һәм фольклоры өлкәсендәге эшчәнлеген бәян итә. Журнал битләрендәге сөйләшүдә тагын «Балалар һәм музыка» исемле мәкалә белән Татарстан композиторлар союзы идарәсе председателе Нәҗип Җиһанов, республикабыздагы балалар өчен эшләүче художникларга багышланган язма авторы Эрот Зарипов, Казан курчак театры хакындагы мәкаләсе белән драматург Роберт Батуллин катнашалар. Журнал бүлекчәсендә моннан башка, күренекле татар совет балалар язучылары Гариф Гобәй, Шәүкәт Галиев, Нәкый Исәнбәт, София Борисовна Радзиевская, Госман Бакиров, Ләбибә Ихсанова, Җәвад Тәрҗеманов, Хәкимҗан Халиков һ. б. — барлыгы утыздан артык әдипнең — фоторәсемнәре, алар хакындагы белешмәләр урнаштырылган. Журналның эчлегендә һәм аерым битләрдә балалар өчен нәшрият чыгарган китап тышлыкларының төсле рәсемнәре дә басылган.

## ӘДИПЛӘРЕБЕЗНЕҢ ӘСӘРЛӘРЕ — ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ТЕЛЕНДӘ

Калининградта рус телендә фронтовик шагыйрьләр һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан Калининград шагыйрьләренең әсәрләре тупланган «Хәтер. Утларда чыныккан сүз» дигән җыентык дөньяга чыкты. Бу китапта солдат-шагыйрь Фатих Кәрим шигырьләренә зур урын бирелгән. А. Ахматова, Я. Смеляков, П. Шубин, Р. Моран, В. Потапова тәрҗемәләрендә шагыйребезнең ике дистәләп шигъри әсәре урнаштырылган.

*
* *

«Совет композиторы» нәшриятында «Музыка дөньясында Пушкин» исемле белешмә басылып чыкты. Бөек шагыйрьнең шигырь һәм сюжетларына музыкаль әсәрләр язган композиторлар арасында Татарстан композиторлары Юрий Виноградов, Нәҗип Җиһанов, Мансур Мозаффаров, Фәрит Яруллин, Җәүдәт Фәйзи, Мәрьям Рахманкуловаларның да исемнәре бар.

*
* *

Язучы Салих Батталның «Сигезенчесе кем?» повесте «Байкал» журналының 1975 ел икенче санында басылган.

## КамАЗ ТУРЫНДА ДОКУМЕНТАЛЬ ФИЛЬМ

Чаллы шәһәрендә «КамАЗ-74 ел» исемле яңа документаль фильм күрсәтелде. Ленинград документаль фильмнар студиясе тарафыннан чыгарылган бу фильмны әзерләүдә Казан шәһәренең документаль кино осталары да катнашты. Быел язын Кишиневта үткән VIII Бөтенсоюз кинофестива-

лендә ул фильм беренче премиягә лаек булган иде. «КамАЗ-74»нең геройлары арасында «Спецстрой» идарәсе бригадиры, Ленин комсомолы премиясе лауреаты Рәис Ганиев, «Металлургстрой» идарәсе бригадиры, Социалистик Хезмәт Герое Алексей Новолодскийлар бар.

## ӘДИПЛӘР — УКУЧЫЛАРЫ АЛДЫНДА

Мордва АССРның партия өлкә комитеты чакыруы буенча Татарстаннан бер төркем язучылар һәм яшь сәнгать көчләре бу республиканың Рузаевка һәм Лэмбер районнарында булып кайттылар. Культура йортларында һәм авыл клубларында үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәләрдә алар бүгенге татар әдәбияты, язучы һәм шагыйрьләребезнең яңа әсәрләре хакында сөйләделәр, үз иҗат үрнәкләре белән таныштырдылар, әдип һәм композиторларның яңа әсәрләрен башкардылар. Татар әдәбияты һәм сәнгате вәкилләре татар совет әдәбияты классигы Шәрәф Камалның туган ягында, мордва халкының сөекле художнигы Эрьзя музеенда булып, халкыбызның бу бөек шәхесләргә карата булган уртак хөрмәт хисләрен белдерделәр.

Очрашуларда прозаик һәм шагыйрьләребездән Хәсән Сарьян, Зөлфәт, Фаил Шәфигуллин, үзешчән композитор Зиннур Гыйбадуллин, яшь җырчылар Рафаэль Сәхәбиев, Розалия Гарипова, Татарстан язучылар союзының әдәбиятны пропагандалау бюросы мөдире Эльс Гаделев катнаштылар.

*

* *

Прозаиклар Вакыйф Нуруллин, Кояш Тимбикова, шагыйрь Рөстәм Мингалимов август аенда Зеленодольск районында булдылар, колхоз һәм совхозларда игенчеләр, терлекчеләр, авыл механизаторлары белән очрашуларда әдәбиятыбызның бүгенге уңышлары, үзләренең иҗатлары хакында сөйләделәр, әсәрләреннән өзекләр укыдылар.

*

* *

Шагыйрьләребездән Зөлфәт, Фаил Шәфигуллин Мари АССРның Бәрәңге районы хезмәт ияләре белән очрашулар үткәрделәр, әсәрләрен укыдылар, республикабызның әдәби тормышы хакында сөйләделәр.

*

* *

Чүпрәле районы игенчеләре алдында Нәби Дәүли, Роберт Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов чыгышлар ясадылар, үз иҗатлары һәм әдәбият яңалыклары белән таныштырдылар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

Татарстан язучылар союзының август аенда үткәрелгән ачык партия җыелышында шагыйрьләр Зөлфәт һәм М. Әгъләмовның иҗат отчетлары тыңланды. Әдипләребездән Ш. Маннур һәм М. Шабаев аларның соңгы еллардагы иҗади эшчәнлегенә анализ ясап, уңай һәм кимчелекле якларны күрсәттеләр. Фикер алышуларда катнашучылар яшь шагыйрьләрнең иҗат колачларын тагын да киңәйтү, үстерү теләгеннән чыгып күп кенә фикерләре белән уртаклаштылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет театр сәнгатен үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Марсель Хәким улы Сәлимҗановка РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Татарстан китап нәшриятында күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның ике томлык «Сайланма әсәрләр»енең II томы басылып чыкты. Бу томга галим тарафыннан җыелып эшкәртелгән халык иҗаты җәүһәрләре — мәкаль һәм табышмаклар, җыр-бәетләр, әкиятләр тупланган.

*

* *

Нәшрият татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең сигез томлыгын чыгара. Әсәрләрнең инде III томы китап сәүдәсе челтәренә керде. Монда язучының «Казакъ кызы» романы, «Яңа кешеләр» драмасы һәм «Кызыл чәчәкләр» повесте кертелгән.

*

* *

Лирик һәм юмористик әсәрләре, балалар өчен язылган китаплары белән танылган шагыйрь Шәүкәт Галиевнең яңа җыентыгы да укучыда кызыксыну уятмый калмас. «Тамчылар тамар чаклар» дип исемләнгән бу китап шагыйрьнең лирика өлкәсендәге иҗатын шактый тулы чагылдыра. Анда төрле елларда иҗат ителгән шигырь һәм җырлар, поэма, балладалар тупланган.

*

* *

Г. Афзалның «Кышкы озын кичләрдә» исемле яңа китабы дөньяга чыкты. Бу — күренекле шагыйребезнең беренче хикәяләр җыентыгы. Анда әдипнең соңгы елларда язылган гыйбрәтле, үткен хикәяләре, кечкенә-кечкенә шаян юморескалар тупланган.

*

* *

«Һәркемнең гомере бер генә», Хисам Камаловның Татарстан китап нәшриятында чыккан бу повестенда дәһшәтле фронт вакыйгалары тасвирлана. Илне фашист илбасарларыннан азат итү өчен барган аяусыз көрәш фонында автор гади совет солдатының рухи куәтен, фидакарьлек сыйфатларын калку күрсәтә.

## *Безнең рәхмәтебез*

Киләсе ел өчен газета-журналларга язылу башланган көннәрдә «Казан утлары» журналы редакциясе республикабызның барлык элемтә бүлекчәләренә һәм хат ташучыларына бу эшне уңышлы башкаруда аларның редакциягә якыннан торып булышуларын сорап язылган хат белән мөрәҗәгать иткән иде. Редакциянең шушы соравына җавап итеп, соңгы ике ай эчендә безгә бик күп хатлар килде.

Менә шул хатларның берсе. Аны Минзәлә районының Җәмәк авылы хат ташучысы Хава Кашапова яза:

— Мин йөз хуҗалыкка хезмәт күрсәтәм. Быел «Казан утлары» журналын 47 хуҗалык алдырган иде. Ел дәвамында аны укучылар саны тагын да артты. 1976 елда журналны 69 хуҗалык алдырачак.

Шул ук районның Шикәрлекаен авылы хат ташучысы Рәмзия Вәлиева да киләсе ел өчен журналга быелгыдан күбрәк яздыруы турында хәбәр итә.

Актаныш районының Такталачык элемтә бүлегеннән Хөрмә Галимованың хаты да куанычлы.

— Мин подписка үткәргән участок зур түгел, — ди ул, — нибары 40 йорттан тора. Шулай да анда «Казан утлары» журналын бик күпләр алдыралар һәм яратып укыйлар. Киләсе ел өчен журналга һәр ике йортның берсе язылды. Бу — журналны һәр йөз кешенең 35—40 ы даими укып барачак дигән сүз.

Алдагы елда журналыбызның укучылар арасында быелгыга караганда күбрәк таратылачагын хәбәр иткән хатлар республикабызның башка районнары хат ташучыларыннан да алынды. Редакция аларның һәркайсына рәхмәт белдерә, эшләрендә, шәхси тормышларында уңышлар тели һәм журнал белән киләчәктә дә тыгыз элемтәдә булырлар дип ышана.

**ЖУРНАЛ РЕДАКЦИЯСЕ.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210